# казан утлары

4

АПРЕЛЬ·1977

# Казан утлары

АЙЛЫК ӘДӘБИ ҺӘМ ИҖТИМАГЫЙ-ПОЛИТИК ЖУРНАЛ
ТАТАРСТАН ЯЗУЧЫЛАР СОЮЗЫ ОРГАНЫ
1922 елның май аеннан башлап чыга

4
АПРЕЛЬ
1977

## Бу санда

Р. ТӨХФӘТУЛЛИН. Китә казлар... Повесть . . . 3
Р. ӘХМӘТҖАНОВ. Уяну. Шигырьләр . . . . . 33
Ф. ШӘФИГУЛЛИН. Ник кайтмый! Шигырьләр . . 40
Г. АХУНОВ. Идел кызы. Роман . . . . . . . . 42
М. ӘГЪЛӘМОВ. Бердәнбер кыз турында... Шигырьләр . . . . . . . . . . . . . . . 99
Ш. МАННАПОВ. Гимнастерка. Шигырьләр . . . 105
В. Иваненко. Арча. Хикәя . . . . . . . . . 107

ОКТЯБРЬНЫҢ 60 ЕЛЛЫГЫНА

Д. ДӘҮЛӘТШИНА. Үзгәрешләр үргә илтә . . . 112
И. ЗАРИПОВ. Туган кыр батыры . . . . . . . 124

ГАБДУЛЛА ТУКАЙ ИСТӘЛЕГЕНӘ

М. ХӘСӘНОВ. Тукай хакында сүз . . . . . . . 134
Илебез әдипләре Тукай турында . . . . . . . 141
И. БРАГИНСКИЙ. Габдулла Тукай һәм Урта Азия әдәбиятлары . . . . . . . . . . . . . 147

ГАЗИ КАШШАФНЫҢ ТУУЫНА 70 ЕЛ

Н. ЮЗИЕВ. Фидакарьлек . . . . . . . . . . . 149
Г. КАШШАФ. Журналистлык кайда бетә! . . . 154

ИСТӘЛЕКЛӘР

Г. КАЙБИЦКАЯ. Дустым Сара турында . . . . . 159

ӘДӘБИЯТ БЕЛЕМЕ

Ф. МУСИН. Бердәмлек һәм күптөрлелек . . . . 161

КПССның
ТАТАРСТАН
ӨЛКӘ
КОМИТЕТЫНЫҢ
ГАЗЕТА ҺӘМ
ЖУРНАЛЛАР
НӘШРИЯТЫ
КАЗАН

КИТАП КҮЗӘТҮ

**З. РӘМИЕВ.** Үзәк проблемалар . . . . . . . 171
**Р. МОСТАФИН.** Йөз дә беренче могҗиза . . . 173

ЕЛМАЕП ТА, КӨЛЕП ТӘ...

«Капкын» журналы бездә кунакта . . . . . . 176

Әдәбият һәм сәнгать яңалыклары . . . . . . 190

Редакциянең адресы. Казан, 420066, ул. Декабристов, 2.

Телефоннар: Баш редактор — 3-07-60, җаваплы секретарь — 3-07-09, проза бүлеге — 3-07-69, поэзия бүлеге — 3-07-69, тәнкыйть бүлеге — 3-07-63, сәнгать бүлеге — 3-07-63, очерклар бүлеге — 3-07-61, хатлар бүлеге — 3-07-61, корректорлар — 3-07-65, техник редактор — 3-07-65, машинисткалар — 3-07-60.

Баш редактор: **Зәки Нури**

Редколлегия: **Әхсән Баянов, Хәй Вахит, Шәүкәт Галиев, Аяз Гыйләҗев, Ләбибә Ихсанова** (җаваплы секретарь), **Шәйхи Маннур, Рәфыйк Нәфиков, Атилла Расих, Гали Халит, Сибгат Хәким, Нил Юзиев, Мирсәй Әмир**

Техник редакторы *Р. Нәбиуллина*
Корректорлары *Р. Сөләйманова, К. Корбангалиева*

Производствога бирелде 3/I-1977 ел. Басарга кул куелды 10/III-1977 ел. ПФ 09005. Кәгазь форматы 70×108¹/₁₆. Учетн.-изд. табак 14,2. Басма табак 12(16,8). Тираж 84644 экз. Заказ Б-1. Бәясе 50 тиен.

КПССның Татарстан өлкә комитеты нәшрияты типографиясе.
Казан, Декабристлар урамы, 2.

© «Казан утлары», 1977 ел.

Рафаил Төхфәтуллин

# КИТӘ КАЗЛАР...

ПОВЕСТЬ



Халисә өенә тау асты буйлатып, аулак сукмактан гына кайтырга булды. Көндезен, ул җәйләүдә чакта, фермада Мәскәүдән килгән корреспондент булып киткән, Халисә турында аеруча төпченеп сорашкан. Гадәттәгечә, план да йөкләмә турында гына түгел, өлкән терлекченең бөтен үткәне-булганы, тазалыгы-саулыгы, ире кем дә бала-чагалары ничекләр?.. Барысы турында да кызыксынган корреспондент. «Үзебезчә, саф татарчалап, шундый да оста сөйләшә Мәскәү егете; ул чибәрлекләре, ягымлылыклары тагы! — диделәр кызлар.— Берәр туган-тумачаң түгелдер ич, Халисәттәй, нигә алай аерып алып сорашты икән?»

Юк, андый, үзе каләм иясе, үзе башкалада яшәүче туганнарын хәтерләми Халисә. Эше шул булгач, сорашыр да, кирәк тапса, газетына да язып чыгарыр. Ни гаҗәбе бар моның?

Гаҗәбе юк югын, ә менә күңелнең әллә генә кайсы кыллары рәхәт авыртулы тибрәнеп алды. Кара инде... янәсе, аны газетага язарга ниятлиләр. Мәскәү кадәр Мәскәүнең үзеннән килгән егет, кашык очына элеп йотардай сылуларны бер читтәрәк калдырып, аның турында күбрәк сорашкан... Вәт, карт тиле!

Һәм менә Халисә кичке моңсу күләгә иңеп килүче тын сукмактан ялгызы гына атлый. Күптәннән буйлаганы юк иде аның бу тау асты буйларын. Баксаң, тал-тирәк куаклары ничек куерып, ничек шәбәреп үсеп киткәннәр биредә. Әйтәм җирле, язын бытбылдыклар бигрәк олыдан кубып сайраштылар быел — аларга тагын иркенлекләр кайткан икән шул. Тау битләрен эре-эре җир җиләге яфраклары каплаган. Күп сабаклар инде икенче кабатын чәчәк атып утыралар. Болары җиләк өлгертмәс өлгертүен, әмма язгы чәчәкләр җиләкне бик мул биргәнгә охшый — хуш исләре хәзер дә борынга килеп бәрелгәндәй булды. Бала чакларны, кыз чакларны искә төшереп, берәр уч, берәр бөртек кенә булса да җиләк капкалап үтәргә, нигә инде элегрәк әйләнмәскә иде бу тирәләрне? Юк шул, гел ашыгасың да кабаланасың. Эштән кайтканда, тузан йотып, тизрәк туры юлдан чабасың, юл уңае машина очраса, шул булыр-булмас бер чакрым өчен дыңгырдык кузовка менеп кунаклыйсың.

Халисә гел җил-җил генә атларга гадәтләнгән аякларын тыя төште.

Җай гына бер атлап уз әле син, Халисә, бу тирәләрне. Әнә бит, кайчандыр инде корып бетә язган тал-тирәкләр яңадан гөрләп калыкканнар. Ата-бабалары куаклыгына бытбылдыклары да кайтып житкән. Кайчандыр уем-уем гына калган җир җиләкләре яңадан бөтен тау битен биләгәннәр. Хуҗа булганнар да, бернигә карамый, чәчәк атуларын беләләр...

Әнә тал-тирәкләрнең мәһабәт бабасы — колачын киң җәйгән бөдрә тал да исән икән әле. Шулай горур җәелсә дә, колач җитмәс бил-кәүсәсен түбән үк игән ул хәзер. Челтәр инеш аның чал сакал-чәчләрен иркәләп кенә юып үтә.

Халисә, шул бөдрә тал кәүсәсенең тирән сыр-җыерчыкларын сыйпап узды да, адымнарын акрынайта-акрынайта тукталып калды.

Туктал, Халисә, бер тукталып ал син бу турыда. Ул карт тал белән уртак серләрегез күп иде сезнең, сагынып искә алыр хатирәләрегез дә җитәрлек. Һәм... нәкъ әнә шул хатирәләр алып килде дә түгелме инде сине бирегә? Баягынак, корреспондент егет турында сүз чыккач, ул күңел кылларың тикмәгә генә тибрәнде дисеңме?..

... Шаһбаз да шулай авыл кешеләре, колхоз хәлләре турында гел газетага язып чыгарыр иде. Хәер, монысы соңрак... Яңа килгән укытучы беренче көннәрдә шактый сәер һәм бераз серлерәк тә булып телгә менде. Өс-баш бик затлы-пөхтәдән иде моның, һәрвакыт матур галстук тагып, ялтыр ботинка киеп йөрер, яше-картына баш иеп, «Хәерле иртә» яисә «Хәерле көн» дип исәнләшеп үтәр. Ә мәктәптә укучыларга әйткән: «Мине Шаһбаз Кәримович дип йөртегез», дигән, үзе дә башка укытучыларга шулай «ович» лап кына дәшә икән. Болар бер дә аларча, Мөндешчә түгел, ул вакытта әле андый сүзләр гадәткә кермәгән, шунлыктан шактый мәзәк яңгырый иде.

Боларына шулай сәерсенеп-гаҗәпсенеп йөргәндә, яңа укытучы турында тагы бер бик берәгәйле хәбәр таралды. Герой икән ич ул Шаһбаз Кәримович дигәннәре! Фин сугышында батырларча сугышып, орден алып кайткан икән ич.

Орденлы кешене дә Мөндешләрнең моңарчы бары рәсемдә генә күргәннәре булганлыктан, бу хәбәргә бик ышанып бетмәүчеләр дә булды. Нигә соң, алайса, күкрәк киереп, орденын тагып йөрми ул? Газеталарда рәсеме дә чыкмады шикелле.

Тиздән ышандылар. Кызыл Армия көнендә Шаһбаз клубка баштанаяк хәрби киемнән килгән, ә күкрәгендә Кызыл Йолдыз ордены балкый иде.

Ордены белән генә әсир итмәде ул кичне Шаһбаз Мөндешне. Докладтан соң үзешчәннәр концерты булды. Шаһбаз Кәримович Такташ шигырьләрен чыгып сөйләде. «Без сыныйбыз көчебезне», «Өйрәнегез!», «Мокамай». Халык идәннәрне дөбердәтә-дөбердәтә кул чапты, тагын сөйләвен сорадылар. Шаһбаз яңадан сәхнәгә чыгып басты да, аяк астына текәлгән килеш, беразга сүзсез басып торды. Аннары башын күтәреп, оялчан гына елмайды. «Рөхсәт итсәгез, иптәшләр, мин үзем язган берәр шигырьне дә укып күрсәтер идем», диде. «Сип, әйдә сип!» — диделәр залдан — яңа укытучының сәерлекләренә инде күнегә башлаганнар иде.

Шаһбазның үзе чыгарган шигырьләре дә Мөндешләр күңеленә бик хуш килде. Тагын түшәмне күтәрердәй гөрләтеп кул чаптылар. Шундый юллар хәтергә нык сеңеп калган:

Хисләремне җырга салып,
Каеннарга килеп таянам.
Җырдай илем, халкым өчен
Гомеремне дә аямам.

Шул төнне микән, әллә бераз соңракмы, Шаһбаз Халисәнең төшенә керде. Имеш, укытучы шундый да ягымлы-якты елмаеп, «Хәерле иртә, Халисә!» дип аңа сәлам бирә, башын игәндә дулкын-дулкын чәчләре чигәләренә ишелеп төшә. Аннары алар янәшә атлап китәләр. Ни өчендер такыр сукмактан түгел, чуер ташлар өстеннән, челтерәп аккан инеш буйлап, тубык тиңентен су ерып атлыйлар...

Шуннан соң Халисә, Шаһбаз аңа үзенең «Хәерле иртә»сен өнендә дә әйтсен өчен, гел аның юлына юлыгуны чамалап йөри торган булды. Ләкин бик сирәк очрашалар, Шаһбаз Кәримович мәктәпкә барышлый-кайтышлый, Халисә фермада эштә кала, ә тегендә-монда чыкканын кайдан чамалап бетерәсең?. Нигә инде берәр ел элегрәк, Халисә дә мәктәптә укыганда килмәде икән соң ул сөйкемле-сихерле укытучы? Дәрес буе ягымлы йөзенә карап, тылсымлы сүзләрен тыңлап утырулары үзе бер бәхеттер!..

Көтмәгәндә мондый бәхет Халисәгә дә елмайды. Шаһбазны фермага агитатор итеп билгеләделәр дә һәр шимбә көнне, кичке савым бетәр-бетмәстә, укытучы, кояштай балкып, алар янына килеп җитә иде. Башта, шук-шаян сүзләр кыстыргалап, барысының да хәл-әхвәлләрен сораштырып йөри, аннары ферма өенә җыелалар. Монда инде укытучының йөзе җитдиләнә, болай да бер-беренә бик якын куе кара кашлары бергә кушыла. Кара тәреле фашист танкларының Европада тагын бер илгә басып керүләре турында ярсып сөйли ул. Илебездәге хәлләр турында сөйли башлагач кына, кырыс күләгәле кашларга якты нур төшә.

Ничек шулай башланганын Халисә сизми дә калды. Алар фермадан еш кына бергә кайталар иде. Нилэр сөйләшәләр иде соң әле? Хәер, Халисәнең сүзләре «әйе, әһе» дән артмый, юл буе Шаһбаз нидер сөйли иде. Нидер дип... Күбесенчә, шигырьләр сөйли иде бит ул. Үзе чыгарган шигырьләр булды микән ул, әллә башка шагыйрьләрнекеме? Бу турыда Халисәнең сораганы булмады.

Ә менә газеталарда Шаһбаз язган мәкаләләрне Халисә яхшы хәтерли. Авылдагы үзең күргән хәлләр, фермада бергә эшләгән иптәшләрең турында газетадан укулары бигрәк күңелле икән ул. Шундый да килештереп, күңелле итеп яза иде шул Шаһбаз. Халисә аларны кат-кат укый, җыр шикелле күңеленә ятлап бетерә иде.

Ә бервакыт Халисәгә дә әйтте Шаһбаз: «Синең турыда да язам әле мин, чыннан да җыр шикелле яңгырардай итеп язам». — диде.

Юк, фермадан бергә кайтышлый түгел, менә шушында, тау астында әйтте.

Шушы юан тал шаһит бу сүзләргә.

Нәкъ бүгенгедәй, кичке эңгер төшеп килгән чаклар иде, Халисә көтүдән кайтмый калган сарык бәтиләрен эзли төшкән иде. Тал турысына җиткәч, тукталып калды. Халисәнең бала чак дусты иде бу тал, сабый чакларда шушы талның әнә теге юан ботагына, куе яфраклар арасына менеп утырыр иде дә, дөньяларын онытып, хыял дулкыннарында тирбәнер иде. Бу юлы да шул ботакка менеп утырасы килде Халисәнең, «олы тиле» дип, үз-үзеннән көлеп кенә куйды да, талның кытыршы кәүсәсенә килеп сөялде. Ә хыяллар, хыяллар... Буй үсергә белән генә һич бетәселәре юк икән аларның, яңадан-яңалары туа тора икән. «Шаһбаз» дип пышылдады кызның иреннәре, хыяллары да шул серле-сөйкемле егет тирәсендә бөтерелә иде, һәм... Могҗиза юк диген инде син бу дөньяда. Шунда, күктән иңгәндәй, алтынсу шәфәкъ нурларына уралып, Шаһбаз үзе каршына ук килеп чыкмасынмы! Гаҗәп, Халисә элеккечә укытучы сөйләгәннәргә «әйе, әһе» дип кенә бармады бу юлы, егетнең шаян сүзләренә шуклык, җитди сүзләренә төптәнрәк уйлап,җавабын кайтара барды.

Әнә шул кичне әйтте инде Шаһбаз: «Җыр булып яңгырардай итеп язам әле мин синең турыда. Хәзергә сүзләрен генә табып бетерә алмыйм», — диде. Ә үзенең болай да һәр әйткән сүзе Халисә өчен иң матур җыр булып яңгыраганын белде микән?

Карт тал белән тын сукмак кына да ишетеп калмадылар бит әле ул җырны. Күпмедер атлагач, икесе берьюлы артларына борылып карасалар, качкын бөдрә бәти дә аларга ияреп кайтып килә иде.

Ах, бу шаянкай! Халисәнең мәңгелек хатирәләренә үрелеп калыр өчен юри шулай көтүдән качып калмады микән ул? Ник дигәндә...

— Кара син бу наянны...— дип Халисә бөдрәкәйнең башыннан сыйпамакчы булып иелде, аның белән бергә Шаһбаз да иелде, ә бәти, баш бирмичә, сикергәләп чабып китте. Халисә дә, Шаһбаз да, көлешә-көлешә, аның артыннан йөгерделәр.

Җир җиләге исле тау асты буйларын күңелле пар көлү яңгыратып торды.

— Бәтине җайлап кына күтәреп алгач, тау аслары тынып калды.

— Әйдә, әнисе янына кайтарып куйыйк инде без моны, — диде Шаһбаз, нигәдер шыпыртлап кына.

Шулай ярым пышылдап кына сүз алышкалап, тыелып кына көлешкәләп, алар Халисәләрнең бакча артларына күтәрелделәр, бил тиңентен әрекмәннәр ерып, лапаска үттеләр.

Әрекмәннәр чыклы-салкынча иде.

Лапас яңа кайтарып аударган печән белән тулы.

— Их, печәнегез дә печәнегез! — диде Шаһбаз, бәтине абзарга кертеп җибәргәч.— Рөхсәт булса, шушында гына ятып таңны каршылар идем мин. Ә син, Халисә, бар кер. Тыныч йокы, тәмле төшләр!

Шуннан соңгылары, чыннан да, татлы бер төш сыман.

Фәрештәдәй җиңеллек белән очып кына болдырга күтәрелгәч, туктапып калды ул. Гел елмаясы-көләсе килә, ишегалдын тутырып, бөтерелә-бөтерелә очынасы-сикергәлисе килә, тагын әллә ничекләр бер тилерәсе килә иде...

Үзенә ишеттереп «леп-леп» тибүче йөрәген тыярга теләгәндәй, кулларын күкрәк турысына кушырып күпмедер басып торгач, тын гына болдырдан төште дә лапас ягына таба юнәлде.

Төнге күбәләкләрне, тәти кондызларны да өркетмәстәй тавышсызөнсез генә атлап килгән иде килүен. Такта ишек ярыгыннан ай нуры белән бергәләп, ул да Шаһбазга тагын бер кат күз төшерергә генә ниятләгән иде. Кинәт лапас ишеге ачылды да, бик мул ромашка исе, тукранбаш исе, баллы чәчәк исе бөркелде. Шунда ук кызның бит очларын, беләкләрен кайнар иреннәр яндырып-яндырып алды. Нидер пышылдагандай йомшак кыштырдаучы печән әллә үзе болар өстенә ишелде, әллә, кинәт бөтен дөньясы әйләнеп китеп, шулай печән эченә калдылармы алар?

— Җырланмаган җырым син минем, Халисә!.. — Бу сүзләрне гүя баллы чәчәк исле дөньясы үзе пышылдый кебек иде. — Ә хәзергә... Бар, кер инде син, Халисә, иртүк торасың бардыр. Кер...

Үзе куа, ә кайнар иреннәр аның саен иңбашларны, чигә чәчләрен, муен, изү турыларын яндыра бирде, яндыра бирде...

— Җырлыйсы иде ул җырны... Җырлыйсы иде!

Таң сандугачлары күңелдәгене болай да бик матур җырлап биргәннәр иде кебек тә бит...

Иртәгесен кичкә тагын шул тал төбендә очрашырга сүз куешканнар иде.

Очраша алмадылар.

Иртән радио коточкыч хәбәр китерде: сугыш!

Төн урталары узганчы, авыл советында җыелыш барды ул кичне, Шаһбаз шунда утырды.

Көн аралаш диярлек военкоматка барып йөрсә дә, аны алай тиз генә алмадылар. Ә күпмедер көннәр үткәч, сугышка башка китүчеләрне станцага озаткан олауларның берсе туп-туры Шәһбаз Кәримович фатирда торган йортның капка төбенә килеп туктады. Тимер хут арбада аякларын җайсыз гына бөкләп, гөмбәгә охшаш кызыл башлык кигән яшь кенә, чибәр генә бер хатын утыра, янындагы кызгылт чемодан өстенә исә, кулына абзыйның чия саплы чыбыркысын кысып тоткан җете кара күзле бер малай менеп атланган иде.

— Шәһбазның аерган хатыны белән малае кайткан. Сугыш җирләреннән, кырык үлемне кичеп кайтканнар ди, бичаралар.

— Алай законный аерылышып та бетмәгәннәр ди бугай ди инде үзләре... Шәһбаз армиядә хезмәт иткәндә танышкан да...

— Ни генә булмасын, җанкисәгем, үз кәефең генә кәеф түгел шул инде бүгенгесе көндә. Сыеныр кешең булганда бик сыенырсың!

Халисәгә бу сөйләшүләр каядыр бик еракта яңгыраган кебек кенә ишетелә, ә зур коңгырт күзләре нигәдер гаҗәпсенгән, нәрсәгәдер үпкәләгән сымаграк караучы ул хатын, җилфер тасмалы матрос чәпләшкәсе киеп алган ул җете күз малай бирегә китап битеннән сикереп төшкән кебегрәк тоелды. Хәтта исемнәре үк сәер: хатын — Земфира, малай — Роберт атлы икән.

Бик авыр кара болытлы иде микән ул көн, әллә эңгер-меңгер чаклар идеме? Һәрхәлдә, кояшлы түгел иде. Шуннан соңгы көннәрдә дә тиз генә күренмәде әле кояш. Тик шул караңгылы-яктыда Шәһбазның балкышлы елмаюлары күренеп-чагылып китә, әмма, никадәр балкышлы булмасын, моңсу-сагышлы иде, гаепле-әрнүле иде хәзер бу елмаю... Аның шул кояшсыз көннәрдә әйткән сүзләре тагы да әрнүлерәк булып күңелдә уелып калган. «Аера да, кавыштыра да икән бу сугыш, Халисә,— дигән иде ул.— Менә миңа да һич көтелмәгән кавышу китерде бу сугыш. Һәрхәлдә, көтми идем инде мин Земфираның кайтуын. Ә менә... бик көтеп алган, озак эзләп тапкан бәхетемнән, кавышмас борын аеруы бугай бу сугышның. — Нык-җыйнак куллар Халисәнең беләкләрен авырттырып ук кысты да, кинәт хәлсезләнеп калгандай, аска салынып төште.

Көтелмәгән... Барысы да көтелмәгән иде шул ул көннәрдә: озатулар, әле бер, әле икенче шәһәрне калдыру турында Информбюро хәбәрләре, теге-бу эшкә кеше җибәрергә кушып, идарәгә явып торган кәгазьләр, матәм язулары, кичә генә чем-кара чәчле апаның чал толымнары... Барысы да көтелмәгән иде.

... Кичләрен көтүләр кайтып, урамнар талгын гына тынып калган арада, Земфира, кулына кечерәк ак бидон тотып, Халисәләрнең күршесе Мәхмүзә әбиләргә сөткә килә иде. Яшел бәбкә үләнле сукмакта аның биек үкчәле туфлиләре сөртенеп-сөртенеп ала, каршына хәтәр ысылдаучы казлар очраса, бу аларны әллә кайдан уратып уза. Кай көнне хатын җете күз улын да ияртә, малай исә, ысылдык казларны күргә, кулындагы тал чыбыкны бик батыр айкый-чайкый, һөҗүмгә ташлана, әмма әнисе аны, русчалатып шелтәли-шелтәли, читкәрәк сөйри иде.

Бервакыт, Мәхмүзә әби өйдә юк иде бугай, Земфира, ак бидонын күтәреп, Халисәләргә килеп керде. Кичке савымны базга куеп кына менеше иде Халисәнең, Земфира кызара төшеп кенә сүз катуга, кызый күзен дә йоммыйча: «Сөтне әни сипаратка алып китте»,— диде дә, кырт борылып, лапаска таба йөгерде.

Капка акрын гына шыгырдап ябылды, Халисә йөгерә килә-килештән печәнлеккә үк менеп китте, ромашкалы, тукранбашлы печәнгә капланып, үкси-сулкылдый елап җибәрде. Ромашкалар, тукранбашлар,

баллы чәчәкләр нәкъ теге кичтәгечә хуш исләләр иде, югыйсә... Әмма бигрәк каты, шырпылы-чәнечкеле иде хәзер печәнлек.

Кыш үзенең зәмһәрир суыкларын, күз ачкысыз бураннарын, чын усалланып, бик иртә алып килде ул елны. Шаһбаз Кәримовичны озатканда да шулай буранлы, суык көн иде. Аңа карамадылар, укытучыны озатырга бөтен урам кузгалды. Шул бик хәтердә: барысының да кашкерфекләрен ап-ак кар сырган, ә Шаһбаз Кәримовичның мунчадан яңа чыккандай кызарган йөзендә ник бер бөртек кар кунып торсын, кайнар тир тамчыларыдай тәгәрәп төшә торалар иде.

Төркем янына артлы чанага җигелгән кыңгыраулы ат килеп туктагач, Шаһбаз хатынының карлы иңбашларыннан кысып тотып алды.

— Шулай, Земфира... Син гел-гел матур уйлар гына уйла. Менә кыш, салкын... Ә син иң ямьле язларны, чәчәкле болыннарны, җиләкле аланнарны күз алдыңа китер. Әйтәм ич, Земфира, чын матурлык иң матур уй-хыяллардан туа. Матур булырга тиеш минем кызым... я улым. Бик матур! Матур уйла, гел матур уйла, Земфира, яме.

Буран шавы, төркем гөҗләве астында ярым пышылдап кына әйтелгән бу сүзләрне, ихтимал, читләрдән берәү дә ишетмәде бугай. Ләкин Халисә аерымачык ишетте аларны. Ишетүен ишетте, әмма сүзләрнең мәгънәсе һичничек зиһененә сыймый иде. Зиһен бүтән уй-сүзләр белән тулы иде бу вакытта: «Аера да, кавыштыра да... Көтелмәгән кавышу... көтеп алган бәхетемнән аера... Аера!»

Усал буран артлы чананы бик тиз үз эченә йотты. Тик дугадагы кыңгырау тавышы гына бик озакка кадәр яңгырап торды: «Аера... аера... Матур уйла... матур. Аера...»

Халисә кайтып җитәрәк, казларын караштырырга дип, бакча артларындагы кечкенә буага сугылып, сәер бер күренешкә тап булды. Олы гына гәүдәле бер ир-егет яр читенә чүгәләгән дә, зур кара портфеленнән алып, су эчендәге казларга нидер ыргыта. Җим-мазар сибә булса кирәк, су өстендәге чәчрәүле урыннарга казлар муеннарын суза-суза узыштан йөзеп киләләр. Пинжәк якасына ук төшеп торган эре бөдрәләренә караганда, кунакка кайткан берәр студент-фәләндер инде бу.

Ул арада казлар нидәндер өректеләр дә, каңгылдаша-каңгылдаша канатларын җилпеп, кызыл тәпиләре белән су өстендә йөгерешкәндәй чуалыша башладылар. Ул да булмады, бер оя каз, канатлары белән сызгырулы аваз чыгарып, һавага күтәрелде. Алар артыннан икенче, өченче оя казлар очты.

Егет, һавадагы казлардан күзен алмыйча, аяк өсте басты. Аннары ул Халисәгә таба борылды, аның кара тутлы йөзен сабыйларча якты елмаю балкытты. Елмаюы сабыйларча булса да, яше өч дистәдән өстә иде бугай инде аның, алай студент халкыннан түгелдер. Шушы кеше чак кына елмаеп карап торгач, Халисәне тәмам шаккатырып, аңа исеме белән дәште:

— Саумысыз, Халисә апа! Кайтып килешме?

— Бәй! Танып бетерә алмыйм... Кем дип әйтим? Исәнмесез!—«Кызлар әйткән корреспондент егет әллә шушы инде?» дип күңеленә килде аның.

— Йорт казларының болай биек очуларын беренче күрүем. Ни булган аларга, Халисә апа?

— Сез танып сөйләшәсез дә бит... Безнең генә хәтерләр тишек чиләк белән бер хәзер.

— Теге вакытларда болай очмыйлар иде бит ул казлар, Халисә апа. Хәтерегездәме, ничек акыллы гына булып, тәпи-тәпи йөз чакрымлап юл үтteләр алар?

Халисә, үзе дә сизмәстән, арткарак чигенеп куйды.

— Роберт! Энем жаным... син түгелме соң?

— Шул үзе.

Халисә, колачын җәеп, алга омтылды. Роберт та, атылып килеп, олы гәүдәсе белән аның кочагына бөтенләе белән сыеп бетте. Үз гомерендә бераү белән дә, якын туганнары белән дә, болай кочаклашып күрешкәне юк иде Халисәнең.

— Һай, энем җаным... Ахыр заманда, кемне уйласаң шул каршыңа чыгып басар, ди. Шуның ише, әле генә сезләрне уйлап кайтып килә идем. Чыннан әгәр менә!

— Бу казлар мине шул елларга алып китте, Халисә апа.

— И гомерләр... Исәннәр бер күрешә. Казлар дигәннән, ул елларны канатлары барын да онытканнар иде шул алар, әйтерсең аларны да ил кайгысы баскан иде. Ә хәзер, тамаклары тук булгач, күккә, биеккә ашкыналар.

— Менә бит!.. Ә син ахыр заман дисең. Көннән-көн канат кагар чаклар хәзер.

— Күңел гел унсигездә дә бит... Гел канатлы дигәндәй...

— Менә бит! Бер дә үзгәрмәгәнсең син, Халисә апа. Тик әнә... тегермән тирәләрен әйләнгәнгә күптәнме әле?

Халисә Робертның соңгы сүзләрен төшенмичәрәк торды. Төшенеп алгач, көлеп җибәрде. Халисәнең чал чәчләренә ишарәли ич... Шаһбаз да шулай кыектан атып мәзәк сөйләшергә ярата, кайчак аның тел төбен тиз генә төшенә дә алмый идең. Улында да әтисе шуклыгы, күрәсең. Ә төскә-биткә әтисенә әллә ни охшамаган ул. Буйга гына түгел, йөз чалымнары да озынчадан моның. Шаһбаз исә буйга да, йөзгә дә җыйнак, түгәрәк иде.

— Тегермән тарта бирә, он тузаны оча тора, чәчләргә куна тора инде ул, энем җаным.

— Оча, Халисә апа, оча он тузаны. Һәм әнә... Казлар да оча. Кызык бит?

— Кызык дип... — Халисәнең әйтер сүзләре өелешеп тамак төбенә килеп тыгылгандай булды. — Кызык дип, нигә монда басып торабыз соң әле без? Әйдәче, әнә генә бит безнең өй. Һай, ничек кайталар белдең, рәхмәт яугыры. Бер күрешү — бер гомер, ди...

— Әйе, Халисә апа. Самаварны екканчы, тастымалны сыкканчы бер гәпләшеп утырабыз әле. Син кайта тор, Халисә апа, мин хәзер... Талтирәк турыларын бер урыйсым килә.

— Ярый, ярый. Бик озак та юанма тагын. Күңелне кузгаттың, зарыгып бетәрмен.

Ул кайтып кергәндә, кызы Гөлүсә ян өстәлне үзенең китап-дәфтәрләре белән тутырган да, бөдрәрәк куе чәчләре, бөтен игътибары белән шулар өстенә иелгән, Габдрахман да институтка керү имтиханына хәзерләнүче кызына комачауламастай шөгыль тапкан: анысы комод өстендә кайчаннан бирле өй күрке генә булып утырган матур будильникны ботын-ботка, чатын-чатка сүтеп ташлаган, җиң очы белән маңгай тирен, борын очын сөрткәли-сөрткәли, шуны җыеп маташа.

Халисә, өстен алышкан арада, тиздән бик кадерле кунак киләсен әйтте, кухня якка чыгып китте, кире борылды. Йөрәнә бирә... Йөренүен, гадәтенчә, бик җайлы йөрәнә, тик әледән-әле урындыкларга, өстәл читенә сөртенеп уза, эше дә бер дә алга тәгәрәми иде. Чүмеч тотса, ул кулыннан төшеп китә, йомырка алыйм дип шүрлеккә үрелсә, кулы беләзектән онга бата.

Гөлүсә, карандашы белән бөдрә чәч болытларын ике якка аерып җибәреп, аңа көлемсерәп карап торды.

— Әни, бик арыгансың син. Инструктажыңны гына бир дә, ял итеп тор, булмаса.

«Инструктаж»ны тыңлый-тыңлый, Гөлүсә әнисен өйалдындагы кечкенә бүлмәгә озатып та куйды.

Шундагы ятакта аякларын җыеп кына кырын ятуга, Габдрахманы бер бер кулына ялтыр каешлы протез аягын күтәреп, икенче кулы белән стенага ябышкалап титаклый-сикергәли сыңар балагын җилфердәтә-җилфердәтә такта ишек янына килеп туктады.

— Әнисе!.. Эһм... Чәй янына мәе дә кирәк булыр инде аның. Бик кадерле кунак дисең бит.

— Анысын үзең карыйсың инде. Акча, әнә, көзге артындагы зәңгәр тартмададыр.

Халисә торып утырды.

Һай, моны кибеткә җибәрде дә җибәрүен... Бер рюмканы төшереп алса, Роберт белән сүз алышырга да ирек бирмәс инде. Гел шулай бит... Аз гына кабып алдымы, берәүгә-бер аваз ачарга ирек бирмәстән, калын тавышы белән бөтен өйне тутырып, сугышта йөргән-күргәннәрен сөйләп китәр, ул арада, сугыштан ук нярeп кайткан кара кыр сумкасын күтәреп килер, өстәлне Верховный Баш Командующийның аңа атап язган рәхмәт язулары, орден-медаль кәгазьләре белән тутырыр. Шулар янына, әңгәмәдәшен сискәндерердәй котсыз шакылдап, сумкадан җен ташы күк иләмсез кырлы-сырлы снаряд кыйпылчыгы килеп төшәр... Сөйләр сүзләре күбен бик күп тә инде бахырның...

Халисә кинәт туңып киткәндәй булды да үрелеп кенә шундагы чөйдән шәлъяулык алып иңнәренә салды.

Габдрахман дисең син... Үзең соң, үзең! Ул еллар турында сүз чыкса, әллә үзеңнең сөйләп сүзләрең бетәсе бармы?

Әйе, очмыйлар иде ул чакларда казлар.

Шаһбаз китүгә, тиздән Халисә үзе дә ерак юлга кузгалды. Пермь ягындагы торф эшенә җибәрделәр аны. Аннан язлар җитеп, карлар киткәч кенә кайтты. Авыл бик үзгәргән иде. Өйләр җиргә сеңә төшеп, кечерәеп калган кебекләр, элеккечә, ашыгып кына пошкырулары, арба дыңгырдаулары белән урамнарны матур яңгыратып, бер генә ат та узмый — алар амбар төбе калдыклары, өстәвенә, хуҗалыклар китергән бәрәңге кабыгы балтушкасы ашап, сабанга чыгарга хәл җыеп яталар. Кичләрен сыңар-сыңар тәрәзәләрдә генә җемелдәгән тычкан утлары бик тиз сүнә, аның каравы, әле бер, әле икенче капка төбендә моңлы җыр яңгырый башлый. Көе дә, сүзләре дә Халисә өчен яңа:

Караңгы төн, болытлы көн
Без аерылган көн бит ул.

Әмма Халисәне иң гаҗәпкә калдырганы Земфира булды. Урамда очраткач, Халисә аны башта танымый да торды. Кая киткән аның зифалык-чибәрлекләре? Аягына ыштырларын ямьсез итеп чорнап, аннан-моннан олы чабата бәйләгән, хәлсез күзләре эчкә баткан...

Халисә кичен шакмаклы тастымалга ярты ипи төйнәп, бер чүлмәк сөт алып Земфираларның фатирына барырга җыенды. Җыенып беткәч, нигәдер хәле киткәндәй, шап итеп урындыкка килеп утырды.

Колак төбендә Шаһбазның сүзләре яңгырагандай булды. «Аера да, кавыштыра да... Гел матур уйла!»

Кулындагы төенчеккә шып-шып күз яшьләре тамып төште.

Аннары кисәк урыныннан торды.

Земфира түр караватта ятып тора, Робертның исә авызы колакларына җиткән, ул чуар сөлгене алъяпкыч итеп биленә бәйләп алган да, җиңнәрен сызганып, агач кашык белән мискидә шык-шык камыр изә иде. Колхоздан ярдәм итеп, күпмедер он биргәннәр икән үзләренә. Халисә кергәч, Земфира да торып утырды, һаман да шулай нигәдер га-

жәпсенгән, нәрсәгәдер үпкәләгән сыман караучы күзләре моңсу гына елмайды.

Тиздән Халисәне күрше Олы Дүндәр авылындагы заготскот пунктына эшкә алдылар. Эше бик мәшәкатьле иде аның: тирә-як колхозлардан, хуҗалыклардан йөкләмәгә җыелган терлек-туарны болар, җәяүләп, Казанга куып китәләр. Көннәре дә, төннәре дә талчыктыргыч юлда үтә.

Шулай да, бер вакыт табып Земфира янына кереп чыкты. Земфира бик ябык булса да, күзләре теге вакыттагыча хәлсез карамый, өс-башы да пөхтәдән иде. Ә түр караватта бала, кыз бала йоклап ята. Халисә балага карап кына алды да, күзем тимәге дип, тизрәк читкә борылды, тагын карады.

Тикмәгә генә теләкләр теләмәгән икән Шаһбаз. Матур иде, сокланып туймаслык матур иде аның кызы. Юк, әтисенә... янсә әнисенә охшап та түгел, үз чибәрлеге белән чибәр иде бала. Ул дугай-дугай озын керфекләр, ул бөрмә алсу иреннәр, кыйгач кара кашлар!.. Исемен дә, бик туры китереп, Гүзәл дип кушканнар.

Йоклый иде шул Гүзәл... Әгәр уяу булса, шәйләми калмас иде Халисә: дөм сукыр иде ул кыз бала.

— Исәнлек-саулык, иминлек-тынычлык бу өйгә! Шатлык-куанычлар өйгә дә сыеп бетмәсен! Бәхет гөле мәңге шау чәчәктә утырсын!

Роберт бусагадан ук шулай шаулап килеп керде. Кәрә-керешкә зур портфеленнән өстәлгә үзенең кучтәнәчләрен — пачка-пачка цәйлүн чәе, лимон, тәм-томнар өеп куйды. Әнисенең «инструктаж»ын төгәл үтәп, Гөлүсә өстәлне хәзерләгән иде инде. Роберт ишегалдындагы насослы коедан үзе су чыгарып, салкын суны өстенә коя-коя юынып кергәч, табынга утырыштылар.

Бу вакыт Гөлүсә, капканы ачып, ишле бер оя казларын куып кертте. Тәрәзәдән моны күреп алуга, Роберт тагын казларга бәйләнешле истәлекләрне кузгатып җибәрде.

Яңа кала алулар, дошманны камап-камап тар-мар итүләр хөрмәтенә бик еш салютлар яңгырап тора, инде менә Олы Җиңү салютлары да яңгырар көнне зарыгып, ашкынып, өзелеп көткән чаклар иде.

Халисәне заготскот конторына чакырып алды да әйттеләр:

— Бу юлы, сеңелем, Казан мясокомбинатына казлар илтәсез. Малайларыңа да әйт, хәзерләнә башлагыз.

— Бәй! Кайда соң ул казлар? — диде Халисә. Ул заготскотның бупбуш абзар-лапасларын яңа гына әйләнеп кергән иде.

— Казлар хәзергә хуҗалыкларда. Участок авылларын йөреп чыгып, үзең җыясың. Менә исемлек. Хуҗалыкларга тиешле йөкләмә кәгазе җиткерелгән. Малайларың иярт тә, бүген үк җыя башлагыз.

Авыр, ай, бик авыр булды ул казларны җыеп алулары. Дөрес, «тизрәк җиңеп кайта гына күрсеннәр, бездән берни дә җәл түгел» дип, оядан иң симез, иң зур дигән казларын сайлап бирүчеләр бар, әмма бар шундыйлар... Казларын әллә кая, басу түренә үк куалар да «казларыбызны суеп бетердек, базарга да чыгардык, калганы, әнә, абзар артында чәчәк аталар» дип күзләрен челәйтеп тик карап торалар. Булмады түгел, «сабыйларыма ит затыннан бердәнбер карап торган малыбыз иде» дип күз яше сыгып алучы апалар да булды.

Ә менә күрше Мәхмүзә әбинең сүзләре, ирексездән, Халисәнең үзенең күз яшьләрен сыгып чыгарды. Өч фронтовик анасы буларак, аңа йөкләмә кәгазе дә юк иде югын. Кара бүрекле, эре нәселле ала казын күтәреп, әби үзе аларның каршына чыкты.

— Кыз язмышы — каз язмышы, диләр иде безнең заманда, Халисә сеңелем,— диде ул яшьле күзләрен чет-чет йомгалап.— Аннары килеп, болай диярләр иде: кызлар күз яше, кызлар рәнҗеше төшкәннәрнең кул-аяклары бөрешер, аңдыйлар кабергә кергәч тә ләхетләрендә җиде кат әйләнеп ятыр, диярләр иде. Шуның өчен, кызлар күз яше булып китүләредер хәзер инде бу казларның. Бер дә бүтән түгел. Мондыйга калгач, бик тиз бөрешер немеснең кул-аягы, Гитлер мәлгуньнең дә чәнчелеп катыр сәгатьләре җитүедер. Бер дә бүтән түгел. Мә, кызым, кабул күреп ал бүреккәемне. Картым әйтмешли, гуардин каз бу. Ярар. Гитлер мәлгунь башына! Бисмиллаһи...

Шуннан соң Халисә һәр капканы ачып керүгә, сүзне, иң әүвәл, Мәхмүзә әби әйткәннәрдән башлап җибәрә торган булды да, «гуардин» каз артыннан бүтәннәрне ияртү шактый җиңеләйде.

Өч көн дигәндә казларны җыеп бетереп, заготскотның бер абзарын гаң-гоң гаңгылдау, каурый-мамык бураны белән тутырып куйдылар. Иртәгә таңнан юлга чыгып китәсе.

Вазифасының иң кыенны инде үтәлгәнгә санап, балтыр итләре сулык-сулык сызлаган аякларына бераз хәл алу өчен, Халисә конторадагы киң эскәмиягә сузылып кына яткан иде, бик кисәк ишек ачылды да, ярдәмчеләреннән берсе Хәбир килеп керде. Үзе елмайгандай итә, үзе бераз каушаганга да охшый иде.

— Халисә апа!.. Мин сезнең белән бара алмыйм бит. Армиягә китәм. Повестка килде. Сугышны бетереп кайтам.

Ярдәмчеләре арасында иң өлкәне, Халисәнең уң кулы иде Хәбир. Аның яшьтәшләре җәй көне үк армиягә киттеләр, моны бүсеренә операция ясатыр өчен больницага салдылар да, шуның белән генә калып тора, үзе иптәшләреннән калышуына бик көенә иде.

— Ай алла! Хәерле юллар булсын инде. Исән йөреп, исән кайта күр. Үзең әйтмешли, сугышны бетереп кайт! — диде Халисә, ә эченә пошаман төште. Бик җайсыз килде бит әле бу. Ике малай белән генә юлга чыксаң, йөз казыңны йөз якка таратырсың да бетерерсең. Колхоздан кеше сорасаң, барыбер бирәр хөрәсәнне генә бирәчәкләр. Чынлап эшкә ярардай малайлар, хатын-кызлар үзләреннән артасы юк. Нишләргә соң?

Шунда келт итеп Роберт исенә килеп төште. Яшькә яшьрәк булса да, бик елгыр, бик үткен малай, булдырмый калмас. Аннары, ни генә әйтмә, үзенә дә файда. Азмы-күпме акчасы тия, юлда тамагы да тук булачак. Директор юлда бер казны суеп ашарга рөхсәт итте.

Халисә шунда ук дүрт чакрымдагы Мөндешкә кайтып китте.

Ярым караңгы өйгә килеп керүгә, түр караватта Земфираның тын гына ыңгырашуын ишетеп, ишек катында туктап калды. Аннары, нигә болай соңлап йөрүенең сәбәбен аңлатыр өчен генә, йомышын сөйләп бирде.

— Бар, улым, барып кайт. Бүген дә сиңа аркаланып кына яттым. Син югында торып йөрим мин үзем, — диде Земфира Робертның сүзсез генә, күзләре белән генә рөхсәт соравына җавап итеп.

Көзге иртә болытлы иде, салкын җил исә иде.

Казлар, абзардан чыгуга, бик ачы кагылдашып, канатларын киң җилпи-җилпи, тагын мамык-каурый бураны очырып алдылар. Авыл урамнары буйлап та шулай каңгылдаша-каңгылдаша, кагына-кагына чыктылар алар. Әле берсе, әле икенчесе тегe-бу капкага борыла, һәр тыкрык, һәр сукмак саен өелешеп-төртешеп шул якка каералар, һәр тарафтан аларга, тагы да ачыграк каңгылдап, оядашлары җавап кайтара иде.

Басу юлына чыккач, казлар гөр-гөр килеп кенә, тыныч кына атлый башладылар. Гуртчыларның хәйләләре дә шәп иде шул. Алдан, казлар көтүеннән аз гына алдарак, җигүле ат бара. Арбада солы капчыклары.

Капчык өстенә менеп атланган Роберт учлап-учлап юлга, көтү алдына солы сибеп бара. Казлар солы чүпли-чүпли, гөңгелдәшә-чөңгелдәшә атлый бирәләр...

Яктыра төшкәч, җил басылды. Алда офык чите җилфер-җилфер килүче бик олы кызыл әләмне хәтерләтә, өскә таба саф зәңгәрсу буй сузыла. Көндезгә аязырга чамалый, ахры.

Комбайн белән урган җирләр буеннан үтәләр бугай, басу вак-вак чүмәләләр белән чуарланган. Мондый басулар сирәк очрый хәзер. Кул белән, лобогрейка белән урсалар, көлтәләрне хәлдән килгәнчә тизрәк юлчылар күзеннән эчкәрәк кибәннәргә куярга, я әвен янына ташырга тырышалар.

Халисә малайларга авыз ачарга да өлгермәде, алданрак барган Габделхак арбага бер кочак салам алып салды. Аннары тагын бер кочак: Зиннур да аннан калышмады.

Бик тырыш, бик хуҗалыкчан малай шул Габделхак. Пәкесе, инәҗебе, бау йомгагы һәр вакыт янында булыр аның, кул-аягың киселептырналып китсә, күкрәк кесәсеннән чип-чиста чүпрәген дә чыгарыр. Тик менә буйны гына кызганыбрак биргән аңа ходай. Инде уналты яше белән бара, ә егет кысып бәйләгән биле белән — нәкъ пөхтә генә бер арпа көлтәсе.

Зиннуры исә гәүдәгә буйчан, әмма ялкаурак. Аның каравы, теле ару-талуны белми. Тукталышларда, тыңласаң тыңламасаң да, аның хикәятләре өзлексез яңгырап торыр (әллә җен дигәннәре бар микән — башлыча шул турыда әллә ниткән серле-хикмәтле вакыйгалар сөйләргә бик ярата), юл буе җыр сузар, такмак әйтер. Әнә хәзер дә җырлап атлый ул, тик, йокысы туеп бетмәгәнме, тавышы үз яныннан әллә ни ерак китә алмый.

Ә салам дигәннән... Үзеннән-үзе Хәбирне хәтерләтә ул салам. Тагын биш-алты чакрымнан Пашкау урманы буеннан үтәчәкләр. Бик хәтәр урын ул, бүреләр оясы анда. Шунда кирәк булуы бар саламның. Ә ничек кирәклеген Хәбир өйрәтте. Эш болай булды. Әле яңараккына мал җуып йөри башлаган чаклары иде. Сарык көтүе илтә барышлары. Шул урман буена җитәрәк, алдагы атта баручы Габделхак ачыргаланулы-калтыраулы тавыш белән кычкырып җибәрде:

— Бүреләр!.. Әнә, бүреләр!

Көтү алдыннан баручы Халисә, үз-үзенә хисап бирмәстән, алга ыргылды. Искәрмәстән тез астына китереп суккандай, туктап калды, җиргә чүкте. Әнә алар, бер өер бүре... (Ничәү алар? Өчәү, дүртәү... ун, егерме? Бу турыда әле дә араларында бәхәснең тукталганы юк.) Бүреләр урманнан юлга таба чыгып киләләр, нигәдер бер дә ашыкмыйлар, янәсе, сарык көтүе алар авызына таба үзе тәпи-тәпи килә ич...

Ләкин сарыклар да кинәт тукталып калдылар, гел бергәрәк оешканнан-оеша баралар. Халисә бар көченә кычкыра-кычкыра, чыбыркысы белән бик үтемле сыптыра-сыптыра, көтүне басу ягына таба куа башлады. Юк, тыңламыйлар малкайлар, һаман бер-берләренә сыенганнан-сыеналар.

Шул чак Халисә шарт-шорт мылтык аткан тавышка күтәрелеп карады. Күтәрелеп карауга эченә җылы йөгерде. Мылтык атмыйлар икән атуын, Хәбир юл буендагы саламга ут төртеп җибәргән дә, үзе учакның бу ягында чыбыркы шартлата икән. Ул арада Зиннур да килеп җитеп, бүреләр юлына яңа учаклар кабыза башлады. Малайларның мондый тапкырлыгы Халисәнең дә зиһеннәрен ачып җибәрде. Ул, йөгереп, учактан башы янып торган бер көлтә салам алып килде, шул утлы чыбыркы белән алдагы көтү башы тәкәгә бер-ике сыпырган иде, теге алып-биреп чабып китте. Ана бөтен көтү нирде. Шундый хутлы чабып киттеләр сарыклар, бар көченә йөгергән Халисәне ярты чакрымлап артта калдырдылар.

Бераздан, атны кушаяклап чаптырып, аны малайлар куып җитте. Ат та бүреләрдән өркеп, басуга таба дулап киткән булган, шунда аны Габделхак тотып алган икән.

Әмма бүреләр дә тиз генә тәмле ризыктан мәхрүм калырга теләмәделәр. Аларның инде икенче яктан — басу буйлап ыргылып килгәннәре күренде. Малайлар арбадагы печән беткәнче, алдагы авылга житкәнче, юлга утлы көлтәләр ташлый-ташлый, чыбыркы шартлата-шартлата бардылар.

Шушы вакыйгадан соң алар, басуда очрыймы-юкмы дип, юлга арба тутырып салам төяп чыга торган булдылар. Бу юлы, Хәбирне озату сагышыннанмы, салам турында онытканнар иде. Ярый әле, очрады.

Хәбир, Хәбир! Күңелләр үк тыныч иде синең белән, ышанычлы юлдаш, барыбызга да таяныч идең.

Хәзер ул да юлдадыр... Ак юл сиңа, егеткәй!

Тиздән тагын әнә шул хәтәр урыннарны үтәчәкләр. Сарык ите белән генә түгел, каз ите белән дә сыйланырга яраталар бит ул бүреләр. Чыксалар, нишлиселәр булыр?

Әлегә тыныч кына, гөр-гөр сөйләшеп кенә атлый бирә казлар.

Инде тәмам яктырып бетте. Кояш хәзергә болыт астында, әмма көнбатыш күк йөзе чалт аяз.

Баядан бирле ишетелер-ишетелмәс кенә көйләп-моңаеп барган Зиннур кычкырып ук җырлый башлады.

Китә казлар, китә казлар,
Китә казлар кайларга?..

Китәләр шул, китәләр, бичаракайлар. Мәхмүзә әби әйтмешли, кызларның рәнҗүле күз яшьләре булып китәләр...

Көтү ягыннан баручы Зиннур, туктап, Халисәне көтеп алды.

— Халисә апа! Бу казлар кайтмаска китә инде. Безнең Хәбир әйләнеп кайтыр микән?

— Авызыңнан җил алгыры! Нигә кайтмасын? Сугышны бетереп кайтам диде ул.

— Миңа да шулай дигән булды да... Хәбирне генә көтеп торганнар ди анда.

Зиннур, чыбыркысын аллы-артлы болгый-болгый, бик каты шартлатып куйды.

— Таныйсыңмы, Халисә апа? Хәбир чыбыркысы бу. Миңа истәлеккә биреп калдырды.

Шушы чыбыркы, Зиннурның аны Хәбир кебек үк оста шартлатуы Халисәнең шөбһәле күңеленә кинәт тыныч бер җылылык салды.

— Беләсеңме, Зиннур, чын-чын күңелдән әйтелгән теләк һәр вакыт чынга аша ул. Хәбир, минемчә, сугышны бетереп кайтам дип чын күңелдән әйтте.

— Һе! Бер солдат сугышны бетерә ди...

— Хәбир генә сугышны бетерә димим мин дә. Теләге кабул булып, ул баруга, сугышы да бетеп куйса?

Зиннур, казларны әсәрләндереп, чыбыркысын тагын бер шартлатты да алгарак атлады. Тагын җыр суздьі.

...Вак кына, куак кына,
Күпсенмәгез, күп тормабыз,
Без монда кунак кына.

Халисә үзалдына гына елмаеп куйды. Янәсе, син гел Хәбир дә Хәбир дисең бит... Тиздән ул, Зиннур да, ерак юлга кузгалмагае. Күзбасстагы ФЗӨ мәктәбенә кеше җибәрүләрен сорап авыл Советына язу килгән. Егетнең шунда китәр исәбе бар. Җыры белән шуны аңлатуы.

Ә чын күңелдән әйтелгән теләк кабул була дигәннәре, чыннан да, хак сүз. Монда Халисә Шаһбаз теләгән теләктән иманы какшамаслык итеп ышанды. Кара инде, Шаһбаз теләгәнчә, чибәрнең дә чибәре бит Гүзәл. Тик... Күзләре генә күрми бичаракайның. Ничек алай булды икән соң ул? Туганда сукыр түгел иде диләр бит аны. Җаен-ибен табып кына Роберттан бер сорашасы иде.

Ә Робертның бу вакытта куллары юлга солы сибә, уйлары исә әллә кайларда гизә иде.

Зиннур белән Габделхакның әледән-әле чыбыркы шартлатулары, туктаусыз арба дыңгырдавы хыялга бай малайны сугыш кырларына ук алып китте. Гөрс тә гөрс снарядлар ярыла, автоматлар, пулеметлар тырылдый икән. Ут-төтен, кара сөрем эченнән солдатлар атакага бара. Иң алдан, пистолетыннан ата-ата, солдатларын алга әйди-әйди, аның командир этисе йөгерә.

Сугыш беразга тынып кала. Ап-ак башлык кигән повар солдат хәйләкәр генә елмаеп әйтә:

— Иптәшләр, әйбәт сугыштыгыз, беләсезме, мин хәзер сезне нәрсә белән сыйлыйм? Юк, зрәгә баш ватмагыз, барыбер белә алмыйсыз. Ка-аз ите белән сыйлыйм мин сезне хәзер. Мондый тәмле ит ашагач, көчегез сразы икеләтә артыр. Менә күрерсез.

Шунда аркасына бик калын сумка аскан почтальон солдат килеп килеп житә, боларга хат өләшә. Өлкән лейтенант Шаһбаз Гайсинга да хат бар. Роберт улыннан.

Тиз генә хатны укып чыга да өлкән лейтенант Гайсин, урыныннан сикереп торып, кулын күтәрә.

— Иптәшләр! Беләсезме, бу каз итен безгә кем җибәргән? Минем якташларым күчтәнәче икән ул. Ә минем Роберт улым, ул казларны йөз чакрым куып илтеп, безгә юллаган. Белеп ашагыз!..

Ат янына Габделхак килеп, Робертның уй-хыялларын бүлде.

— Син, сыбызгы, чамалабрак сип солыны. Әле барасы юл ерак,— диде ул бик ачулы тавыш белән. Үзе кулын атның камыт астына тыгып карады, ат барган көйгә генә аркалыкны күтәребрәк бәйләргә тотынды. — Син әрекмән колакка ышансаң, атны да эштән чыгарырсың әле. Ыңгырчагың бушап беткән монда, момент чиләнеп чыга бит хәзер ат сырты.

— Габделхак абый! — диде Роберт, мөмкин кадәр ягымлырак итеп дәште. Тегесе ишетмәмешкә салынды. — Габделхак абый, синең этиеңнән дә һаман хат юкмы?

— Юк, малай, һаман хат юк, — диде дә Габделхак юлдан читкәрәк каеручы казларны куарга йөгерде.

Юк шул, Робертның этисеннән дә күптәннән хат юк. Инде менә бу казлар турында язачак хатын да кушып исәпләсән, Роберт этисенә утыз дүрт тапкыр хат яза. Бәлки монысына җавап килер?

Башкасы башка, этисе Гүзәлнең фоторәсемен алды микән, юк микән? Шуны бик беләсе килә Робертның, ә үзе хат саен «зинһар, кызымның фотосын җибәрегез» дип үтенеп-үтенеп сорап язды ул. Инде менә Гүзәлнең фотосын җибәргәнгә ел тула, һаман да җавап юк.

Җиңел булмады Гүзәлне фотога төшерүләре.

Фоторәсем сорап этисеннән беренче хат килгәндә, салкын кыш иде әле. Ә фотога төшәр өчен унике чакрымдагы район үзәгенә барырга кирәк. Бөтен стенасы кызлар, әби-бабайлар, бала-чага рәсеме белән тулган «Фото. Парикмахерская» дигәннәре бары шунда гына.

Роберт председательдән ат сорарга дип, наряд вакытын чамалап, идарәгә бер барды, ике барды. Барган саен шул: тегеләшкә, бу эшкә дип, бригадирлар председательдән ат даулыйлар, үзара талашып бе-

тәләр, Роберт, бугаз төпләре ачыта башлаганчы тәмәке төтене иснәп, бер читтә утыра-утыра да, йомышын әйтергә кыюлыгы җитмичә, кайтып китә иде.

Ә этисеннән көн аралаш хат килеп тора ул чакта. «Кызымның рәсемен күрсәм, өйгә кайтып килгән күк булыр идем», ди. «Кызым туганын белгәч, фоторәсемен инде бөтен рота зарыгып көтә башлады», ди.

Февраль ахырларының яз исе аңкып торган, чут-чут тамчылар да тамгалый башлаган кояшлы көне иде. Роберт, Гүзәлне кечкенә чанага төреп утыртып, юлга чыгарга булды.

Әйе, барганда да, кайтканда да бик җылы иде, матур иде көн. Роберт үзе әледән-әле бүреген салып, парланып торган юеш чәчләрен кояшта киптерә-киптерә кайтты. Бара-бара да, чананы бик чалулатмаска тырышып кына дөп-дөп юыртып та китә иде.

Әмма куанычыннан битәр үкенечкә булган икән бу сәяхәт.

Гүзәл иртәгесен ут янып авырый башлады. Роберт бу юлы Олы Дүндәрдән врач алып килергә председательдән атны бик кыю сорады. Председатель дә аңа берсүзсез үзе утырып йөри торган күк айгырның дилбегәсен тоттырды.

Атна дигәндә Гүзәлнең хәле әйбәтләнеп, элеккечә чырык-чырык көлә, караватт башына тотынып дырык-дырык сикерә, карамый торсаң, салкын идәнгә төшеп, мүкәләп тә китә башлады.

Ә ике көн үтүгә, тагын урын өстенә ятты ул. Хәзер инде алай ут янмый, елап та бик интектерми иде, ләкин тамагына бер нәрсә капмады, бары әнисенең буш имиен генә суырды.

Җәйләр җитеп, җирләр кипкәч кенә Гүзәл тернәкләнде. Хәле әйбәтләнүгә, бик шәп тәпи дә йөреп китте. Тәпиләвен бик әйбәт тәпили, ләкин нигә гел ике кулын алга сузып атлый соң ул? Уенчыкларын да капшанып-капшанып кына таба?

Гүзәлнең сукраюына врач килеп карагач кына ышана алдылар. Тирән чишмә суыдай саф, күкчәчәктәй матур күзләр... күрмиләр. Моңа һич тә ышанасы килми, бәгырьләрне өзәрдәй авыр иде.

Урман буена җитәрәк, Зиннур да, Габделхак та көтүнең сул ягына чыктылар. Зиннур, әллә шүрләвен басар өчен инде, тагын җыр сузды.

> Алып бирим ал тасма, шул,
> Бәйрәмнәрдә тагарсың,
> Алсу күлмәкләрен киеп,
> Сагынганда карарсың.

Юк, алай шүрләү-фәлән сизелми тавышында. Карале, әллә ни булды әле ул Зиннурга бүген. Гел шаян җырлар гына җырлап бара иде ул моңарчы. Бүген җырлары да, тавышы да моңлы. Әллә Хәбир дусты киткәнгә моңлана, әллә инде берәр сылукай йөрәгенә юл салды микән?

Сагынганда карарсың... Халисә дә карый. Юк, бүтән кызлар кебек, бүләк баш яулыгы, янсә, әнә җырдагыча, ефәк чәч тасмасы алып карамый ул. Үзе чиккән батис яулыкка төрелгән җыйнак кына төенчекне кулына ала. Шаһбазның газета битләреннән кисеп алынган ике шигыре, ике дистә мәкаләсе, аннары, барыннан да кадерлерәге — өчпочмаклап төрелгән алты хат монда. Халисә аларны берәм-берәм яңакларына кыса. Ә кабат укып торуның кирәге юк. Шаһбазның һәр хатын яттан белә ул. Соңгы хатындагы сүзләрне исә, төенчекне алып карамасаң да, күңелдә кабатланмаган көне юк. «Хәтерендәме, Халисә, җырланмаган җырым син минем, дигән идем мин сиңа. Үзем дә гаҗәпләнеп куям, һич көтмәгәндә, туктаусыз туплар шартлап торган-

да, ул җыр туды! Киләсе хатымда мин ул шигырьне үзеңә дә язып җибәрермен. Хәзергә кайбер сүзләрен тагы да матуррак итеп әйтәсем килә».

Инде менә көтә башлаганга тиздән ел тула, ул җырлы хатның һаман да килеп җиткәне юк.

Кинәт Халисәнең шул өчпочмаклы хатларны тагын берәм-берәм яңагына кысасы килә башлады. Нигәдер, шулай итсән, күңелләр җиңеләебрәк киткәндәй була.

Кара инде... Бер бүләк күлмәге дә бар бит, югыйсә. Шул... Шәфикъ биргән булган иде. Анысын Халисәнең ни кигәне, ни алып караганы юк. Әрәм ятканчы, әллә берәр ятимәгә бирергә микән?

Әй, болай бик нечкәреп барсаң, бүреләр чыгып, акылга утыртмагае үзеңне. Әлегә казлар бик тыныч кына, һаман бер көйгә гөңгелдәшеп атлый бирәләр. Хәтәр барын сизсәләр, тынычсызланырлар, кычкырырлар иде. Бик сизгер җаннар бит алар, казлар.

Шаһбазның сөйләгәне бар иде бит. Моннан ничәмә мең еллар элек, Рим шәһәренә җиде төн уртасында дошман явы басып кермәкче булган. Шунда казлар бик ачы каңгылдаша башлап, гаскәрне дә, халыкны да уятканнар. Шуннан бирле казлар: «Без Римне коткардык», — дип гел горурланып йөриләр икән.

Шуның шикелле, бу тирәдә дә абайрак-саграк була күрегез, җаңкисәкләрем!

Хәзергә ул-бу юк. Урман тыныч кына, маһәбәт кенә шаулый. Зиннур һаман җыр суза, Габделхагы аннан аз гына да калышмас өчен ашыгып, терт-терт атлый. Робертның исә бу тирәләрнең хәтәрлеге турында гамендә дә юк, нидер сөйләнә-сөйләнә, юлга солы сибүен белә.

Һәм кинәт...

Алдагы бер казның бик ачы кычкырып җибәрүе Халисәнең күкрәк турысына хәнҗәр булып кадалды кебек. Бөтен көтү гаңгылдашып чуалыша башлады, Зиннур белән Габделхак, чыбыркы шартлата-шартлата, урман ягына йөгерделәр. Роберт арбага торып баскан да, кулын болгый-болгый, аларга нидер кычкыра калды.

Халисә кесәсеннән шырпысын алып, арба янына йөгерде. Юл читенә салам ташлап ут төртим генә дигәндә, Габделхак йөгереп килеп җитте.

— Халисә апа, кирәкми... Бүре түгел, төлкеләр ул.

— Ай, чукынчыклар! Каз ите ашыйсылары килгән икән, кара син аларны!.. Зиннур кайда соң?

— Төлке куа, — диде Габделхак турсаеп кына.

— Йөрсен инде! Ул төлке куганда, монда бүреләре килеп чыксын тагы!.. Әйдәгез, җәһәтрәк үтәсе иде бу тирәләрне. Син алгыларны кызулат, мин арттан куам. Роберт, атыңны хутлырак атлат.

Зиннур аларны урман буен узып, шактый ара үткәч кенә куып җитте. Сулулары капкан, үзе тирләп-пешеп чыккан иде.

— Их, Халисә апа... Куып җитеп... булмады. Куып җитсәм, шушы чыбыркы белән ярып... тәки берәрсен үтерә идем.

— Синең үзеңне ярам әле мин чыбыркы белән. Көтүне ташлап йөргәнең өчен ярам. Бир әле Хәбир чыбыркысын!

— Я инде, Халисә апа... Күрәсең ич, бүрекнең бер рәте калмады. Берәр төлке тотсам, бүрек тектерер идем.

— Син бер уңайдан күпләбрәк тотарга кара инде ул төлкеләрне. Тунга да җитәрлек булсын, — диде Габделхак, һаман да турсаеп кына.

— Нигә, туны да мишәйт итмәс иде. Бишмәтнең кырык ямавы, кырык бер тишеге... Бер нарушны киләм әле мин бирегә. Төлке ауларга.

— Ярар, шулай итәрсең. Бер төлкене миңа якалыкка дип атап тотарга да онытма, — диде Халисә. — Әйдәгез, шушы хут белән бар-

сак, тиздән Чиканаска җитәбез. Ашап алырбыз да, аннары Бутаманны ничек тә якты көздә үтәсе иде.

Халисәнең болай әйтүенең сәбәбе бар иде.

Югары Бутаманда алар моңарчы Гөлчирә түтиләрдә тукталалар иде. Һәр вакыт якты йөзле, тәмле телле, ару-талуны белмәс Гөлчирәттәй инде аларның якын бер туганнары кебек булып бетте. Боларның көтүләре чаттан борылуга, Гөлчирәттәй капка ачарга йөгереп чыга: «Килеп җиттегезме, наныйларым? Юл газабы — гүр газабын ничегрәк үттегез?» — дип сөйләнә-сөйләнә, малларны төз лапаска урнаштырырга булышып йөри. Еш кына юлда, яңгырларга, юеш карларга очрап, боларның өс-башлары манма чыланган була. Андый чакларда Гөлчирәттәй, өй эче майдай җылы булуга карамастан, шунда ук тагын мичкә ягып җибәрә, һәр вакыт елык-елык ялтырый торган җиз самавары ни арада гөҗләп менеп утыра! Иртәгесен барысының да копкоры киемнәреннән рәхәт җылы бөркелеп тора, аякчулары хәтта кырлы бәләк белән таслап-йомшартып ук куелган була.

Яшь аралары ике елдан артык булса да, игезәкләрдәй бертигез, пар карлыгачлардай бер-берсенә охшаган ике малае бар Гөлчирәттәйнең — Шамил белән Камил. Халисә аларны туган энеләре кебек сагынып килә, сабыйлар да тәмам үзенә ияләнеп беттеләр. Ишектән керәкерешенә ике яклап муенына асылыналар, аннары, матур апаның икесе ике тезенә утырып, кучтәнәч шикәр шакмагы белән тәмләп чәй эчәләр.

Гөлчирәттәй барысының да гаиләләре-тормышлары белән яхшы таныш, килгән саен алар турында бәйнә-бәйнә сораша, сәламнәрен җиткереп тора. Аеруча Габделхакны якын итә ул. Сөезешү батыры булarak авылда мәшһүр кара кәҗәсенең куе сөтеннән үз малайлары белән рәттән Габделхакка да өлеш чыгара. «Мәле, бәләкәчем, эчеп җибәр, тагын бер карышка үсеп китәрсең, — ди. — Әйдә, әйдә, кыстатыпкөязләнеп маташма, киявем буласың юк. Кыз табарга өлгерә алмый калдым шул, нихәл итәсең...»

Гөлчирәттәйнең иреннән дә, Габделхакның әтисе кебек үк, күптәннән хат юк.

Бер Халисәләр генә түгел, бу ягымлы өйдә бүтән юлчылар да була. Стена буйлап ястыгы, мендәре тезелеп киткән, иплән толыбы-бишмәтләре җәелгән идәндә барысына да урын җитә.

Юлчылар изрәп йокыга китүгә, бирегә, кул эшләрен алып, күрше хатыннар керә, кызлар җыела, кайчакларны сугыштан кайткан ирләр дә кереп утыралар. Алар юлчыларны борчымас өчен акрын гына сөйләшәләр, тыелып кына көлешәләр, соңрак, тыенкы гына моңлы җыр сузыла башлый.

Халисә үзенә ике яклап сыенышкан Шамил белән Камилне кочаклаган килеш изрәп йоклый, йокы аралаш тигез генә быдыр-быдыр сөйләшү, моңлы җыр да ишетелеп тора. Бик рәхәт аңа шулай ике сабый кочаклаган көйгә моңлы җыр канатында тирбәлүләре.

Бер вакыт — әле Халисә ятарга өлгермәгән иде — ишекне тыйнак кына ачып, рөхсәтен дә сорап, бер ир-егет килеп керде, бик ягымлы сәлам бирде. Өстендә хәрби кием моның, кулында кыска таяк, шуңа таянып, гәүдәсен бер якка янтайтып-янтайтып, авыр гына атлый. Сугыштан яраланып кайткан солдат, күрәсең. Юк, өстендәге шәп гимнастеркасына, көзгедәй ялтырап торган хром итекләренә караганда, гади солдат кына да түгелдер бу, офицер ук булмагае.

Егет, өйдәгеләрнең сүзенә әллә ни катнашмый гына, бер читтә көлемсерәп утырды. Берничә тапкыр каш астыннан гына Халисәгә карап-карап куйды. Соңгы каравында Халисә сискәнеп китте. Ах, әллә

генә кайсы яклары белән Шаһбазны хәтерләтә түгелме соң бу? Кара кашларымы, әллә көлемсерәвеме? Юк, көлемсерәве охшамаган. Шаһбаз күк, шулкадәр дә нурлы-җылы итеп, бүтән берәү дә елмая-көлә алмас. Ә шулай да... шулай да әллә кай төшләре генә Шаһбазга тартым.

Егет озак юанмады. Ул чыгып киткәч, кич утыручылар сөйләшеп алдылар:

— Тәмам кеше булды бит бу, ә!

— Шулай ул сугыш. Берүләрне юк итә, юкларны бар итә.

Шул көннән башлап, егет бу өйгә Халисәләрнең һәр тукталуларында килеп керә торган булды. Гөлчирәттәйдән янсә бүтән берәрсеннән атап сорашырга уңайсызланса да, Халисә сөйләшүләрдән аның кемлеген болай да белеп алды. Биредәге участок ветпунктының мөдире икән ул. Алар эшенә дә бик якын, бик зур кеше икән ич. Мал докторы булыр өчен институтында да укып кайткандыр. Исеме — Шәфикъ. Безнең ишеләр генә түгел икәнсең син, Шәфикъ абзыкай!

Ә үзе — кара инде! — нииндиен тыйнак, инсафлы. Һәр вакыт шулай ишеген сак кына кагып, рөхсәтен сорап кына керер, урын күрсәткәч кенә килеп утырыр. Мөдир кешенең эше бик күптер инде, еш кына бөтен юлчылар йоклап беткәч, кич утыручылар да тарала башлагач кына килеп керә ул. Гаҗәп, ни арып-талып килүенә карамастан, Шәфикъ кереп чыкмыйча торып, Халисәне йокы алмый башлады. Пышылдашып кына диярлек юл хәлләрен, тегесен-монысын сөйләшеп утыралар алар. Чаманы бик белә егет. Кич утыручыларны озатып бетереп, Гөлчирәттәй почмак якка кереп китүгә, Шәфикъ та урыныннан кузгала. «Ярар, юл кешесенең йокысын урлап утырмыйм», ди дә, Халисәнең кул аркасын сак кына сыйпап куеп, таягын шакылдатмаска тырышып кына атлый-атлый ишеккә юнәлә.

Аларның бер юллары бик мәшәкатьле, бик тә борчулы булды. Бутаманга җитәргә әле биш-алты чакрымлап бар иде, берәм-берәм сарыклары авырый башлады. Ни хәл бу? Шулай берәм-берәм тәгәрәп үлә дә башласалар, ничек җаваплар бирерсең дә хакларын ничекләр түләп бетерерсең? Ярый ла, түләтеп кенә калсалар...

Бара-бара кайбер сарыклар бөтенләй аяктан егылдылар. Андыйларны атка салырга, арбага сыймаганнарын иңнәргә күтәрергә туры килде.

Алар Бутаманга җиткәндә инде караңгы төн кунган, һәммәсе эштән чыгып арыганнар иде. Малайлар, хәтта чәй дә эчеп тормастан, идәнгә җәелгән толыпка тәгәрәштеләр.

Халисә, ике тезе өстенә Шамил белән Камилне утырткан килеш (алар, матур апалары килүгә, яткан җирләреннән сикерешеп тордылар), мәлҗерәп утыра бирә, ә эчендә утлар яна иде. Нишләргә соң? Әллә ветпунктка барып, Шәфикъка әйтеп карарргамы? Җиде төн уртасында кешене уятып йөрүе бигрәк уңайсыз инде. Үткән-барган малларны карау аның вазифасына да керми торгандыр. Әлегрәк тә килеп җитә алмадылар, ичмасам. Бәлки, гадәтенчә, бирегә кереп тә чыккандыр ул.

Гомере озын булгыры, шул чак бик таныш-тыйнак ишек кагып Шәфикъ үзе килеп керде.

— Нигә бик соңладыгыз? Бер-бер хәл булдымәллә? — диде ул, хафалы тавыш белән, гадәттәге сәламен дә бирергә онытып.

— И Шәфикъ абый... Бәлагә тарыдык шул. Башкайларыбызга җитә, ахры, бу сарыклар.

— Нәрсә булды, Халисә? Әйт тизрәк.

— Сарыкларыбыз авырый. Кайберләре барып җитә алмас, тәгәрәшерләр, ахры.

— Сон, Халисә... Авыру малларны дәвалаучы каршында басып тора түгелме соң? Әйдә, карыйк әле.

Шәфикъ, авыру сарыкларны карагач: «Мин тиз генә пункттан дарулар, шприцлар алып килим дә, хәзер терелтәбез аларны. Тамчы да кайгырма, Халисә»,— дип сөйләнә-сөйләнә, капкага таба юнәлде. Төн карасы гына житмәгән, аяк асты да тайгак-былчырак иде. Халисә, йөреп килеп, егетнең җиңеннән тотты.

— Шәфикъ абый... Булмаса, үзем генә барып килим. Ачкычыңны биреп, даруларның кайда икәнен әйтсәң... Сезгә бик кыен бит болай.

— Һи! Мондыйларны гына күрмәгәнме без!

— Анысы шулай да... Анысы бит аның сугышта, сәламәт чакта.

— Без тылда да солдат.

— Алайса... Әйдә, иптәшкә мин дә барам.

— Бик шат булыр идем дә... Бик тә арыгансың син, Халисә. Мин әйләнеп килгәнче, ял итеп торуың хәерлерәк булыр.

— Арыганнар онытылды әле монда, Шәфикъ абый.

Ветпункт авылдан читтә, барыр юл шактый ерак иде. Никадәр сер бирмәскә тырышса да, Шәфикъның авырткан аягы таеп-таеп китә. Бер сөрлегүендә ул чак кына егылмады, Халисә аның таяксыз кулыннан култыклап алды.

— Сезгә бигрәк мәшәкать ясадык инде, Шәфикъ абый.

— Нигәдер, миңа бу мәшәкать рәхәт кенә. — Шәфикъ Халисәнең үзен беләгеннән тотып барган бармакларын култыгында кысканнан-кысты. — Ике дә уйлама, Халисә, аякка бастырабыз малларны.

— Баса гына күрсеннәр... Бар ышанычсиндә генә, Шәфикъ абый.

— Абый да абый... Шул «абый» диясе берәр төштә «җаный» дигәнен дә ишетсәң икән ул.

— Алай әйтүчеләр дә бардыр.

Шәфикъның аягы тагын таеп китте.

Дарулары, уколлары бик тә килеште аның, көтүне югалтуларсыз тапшырдылар.

Малларга гына түгел, Халисәнең йөрәгенә дә әллә нинди шифалар салды, ахры, ул кичне Шәфикъ. Һич ару-талуны белмәстән, җилкенеп килә ул хәзер Бутаманга, юлда, Зиннурга кушылып, җырлап та җибәрә. Шәфикъ та бу өйдән кермәс борын чыгып китәргә ашыкмый. Әллә ни дә сөйләшмиләр үзләре, әмма егетнең назлап кына кулдан сыйпаулары, чак кына тәмәке исе, нииндидер дару исе аңкып торулары Халисәгә рәхәт-күңелле.

— Әллә теге кичтәге кебек култыклашып кына бер әйләнеп киләбезме, Халисә? — ди Шәфикъ еш кына. — Бик бөркү монда.

— Ай, бик арыдым шул, Шәфикъ абый. Икенче бер вакыт, яме?

— Алайса, икенче тапкырга ат җигеп киләм әле мин. Тарантаска киерелеп утырып кына әйләнербез.

— Алай кылана күрмә, Шәфикъ абый. Кеше әллә ни әйтер.

— Кеше дисең син... Ә менә бу йөрәктә нинди ялкыннар дөрләгәнен белсәң икән.

Октябрь бәйрәмен алар юлда каршыладылар. Ул кичне Шәфикъ гадәттәгедән соңрак — өйдә инде утырдашлар да таралып беткәч, Гөлчирәттәй дә үз урынына барып яткач кына килеп керде. Кулында җыйнак кына төргәк иде.

— Бәйрәм белән котлыйм, Халисә, — диде ул ничектер каушап кына. — Менә монысы, теге... Сиңа бәйрәм бүләгем.

Төргәктә затлы күлмәк иде. Халисә ни әйтергә дә белмәде.

— Ачулансаң ачулан, Халисә, мин ат җигеп килдем, — диде Шәфикъ, һаман да шулай ашыгулы-каушаулы. — Өстәлем тулы сый-нигъмәт, әйдә, бергәләп бәйрәм киче итик, ә, Халисә?

— Ошамаганны! Китче инде, Шәфикъ абый... Нигә алай итәсең? Үзегез генә күңелле итеп утырыгыз, мәҗлесегез ямьле булсын!

— Үзегез генә... Их, Халисә! Беркемем дә юк минем. Кирәкми дә. Халисәдән башка миңа берәү дә кирәкми.— Һәм ул куллары белән башын тотып урындык артына капланды.

Халисә, үзе дә сизмәстән, егетнең башыннан сыйпап, чуалган чәчләрен рәтләп куйды. Бик кызганыч та иде аңа Шәфикъ, шул ук вакытта ул әйткәнгә күнәргә һич тә күңеле тартмый иде. Шунда, бигрәк аермачык булып, күз алдына Шаһбаз килеп басты да, Халисәнең бөтен тәне буйлап яшен тизлеге белән кайнар бер дерелдәү үтте. Ул арада Шаһбаз ут-төтен эченә кереп тә югалды.

— Шәфикъ абый... — диде Халисә әсәрүле пышылдап, — сугышта бик куркынычмы? Сөйләгәнең дә юк.

— Нәрсәсен сөйлисең инде аның?.. — диде Шәфикъ башын күтәрми генә. — Курыксаң, куркыныч инде ул...

Бераздан ул, башын күтәреп, каядыр читкә генә караган килеш уйланып утырды, үзе, әллә кайлардан йөгереп килгәндәй, еш-еш сулый иде.

Аннары ул сөйләп китте. Тавышы башта тотлыгулы-карлыккanрак яңгыраса да, сөйли-сөйли тәмам остарды. Иң куркыныч маҗаралар белән тулы дәһшәтле бер әкият сыман иде аның сөйләгәннәре... Моңарчы тыйнаклыгы белән генә сиздерми йөргән, күрәсең, әнә нинди дәһшәтләр аша кичкән, кырык үлемне җиңгән каһарман егет икән ич ул Шәфикъ!

Халисә аны капка төбенә кадәр озата чыкты.

— Үпкәләп китә күрмә инде, Шәфикъ абый. Мин бит белмәдем.

— Нәрсәне, Халисә?

— Ниләр генә кичми солдат башыннан! Сөйләмәгәч, каян беләсең?

— И Халисә!.. — Шәфикъ бик авыр көрсенеп куйды да беразга сүздән калды.— Халисә, әнә шул чат башына кадәр генә булса да, яныма утырып барсаң икән, ә?

Чат башын кай арада узып киткәннәрдер, күзгә чалынмый да калды. Тик шунысы бик хәтердә: тарантастагы печәннән ромашка исе, баллы чәчәк исе аңкый иде. Бигрәк күңелгә якын, таныш хуш ис...

Кайтышлый тукталуларында тагын ат җигеп килде Шәфикъ.

Тарантаста шул ук хуш исле печән иде.

Ах, ичмасам, шул печәне генә булмаса соң!..

Бер иртәне Гөлчирәттәй әле почмак якка, әле бу якка үтеп, сүзсез генә тызынлап йөренде дә бик кырыс әйтеп куйды:

— Бу өйнең бусагасын да атламас итәм әле мин ул Җаклы Җапыйны. Эзләрен суытам!

— Кем ул Җапый, Гөлчирәттәй?

— Кем дип... Шул Шәфикъ инде. Бездә аның ишеләрне Җаклы Җапый диләр. Имеш, сугышның уртасында йөргән, имеш, немецнең танкларын яндырган... Үләрсең шапырынуына! Сугыш дигәннең «с» хәрефен дә күргәне юк бит ул бичараның.

— Ничек инде?.. Ул бит... яралы.

— Малай чакта аттан егылып төшеп имгәнде ул, сеңелем җаным. Кая аңа солдат булулар! Сугыш чыкканчыга кадәр ветсанитар булып йөрде дә, мал докторыбыз фронтка киткәч, урынына моны куйдылар. Болай, чирле малларга кулы бик килешә үзенең. «Доктор иптәш» дип җакландырып та җибәрсәң, ярты үлеп беткән малыңны да терелтә. Әмма ләкин... Беркөнне, сугыштан кайткан солдат сыман кыланып, сиңа шапырынып утыруларын ишеткәч, йөрәккәйләрем дулый башлады. Торып, авызын шап ябыйммы дигән идем, өй тулы юл кешесенең татлы йокыларын тәмсезлисем килмәде. — Гөлчирәттәйнең тавышы чын ярсулы яңгырый башлады. — Ни хакы бар аның безнең ут эчендәге

ирләребез исеменнән сөйләшергә? Ни хакы бар?! Кара син ул мөртәтне! Солдатлар анда ил өчен кан койсын, ә бу алар даны белән ат казанмакчы! Арт сабагын укытам әле мин аның, ул Саручий базардан сатып алган солдат киемнәрен салып ыргыттырам!

Халисәнең чигәләре шаулый, йөрәге сулык-сулык тибә, берара бөтенләй тибүдән туктап калгандай була, чак кына кыймылдаса да, гөрселдәп идәнгә авар шикелле иде.

Кыр-болын чәчәкләре яңгыр яумаса чык тамчыларыннан да балкып ачылырга әзерләр. Тик үтә саф булсын, бөртек тә тузансыз булсын ул тамчылар! Тузанлы тамчыларны назлы-нәфис чәчәк таҗлары күтәрә алмый.

Мәхәббәт гөле өчен андый тузанлы тамчылар — ялган. Ялганның тамчысы да иң әлы-гүзәл гөлләргә дә үтергеч агу. Андый тамчыларны гөлләр, әрни-сызлый, тизрәк иңнәреннән селтәп атарга ашыгалар.

Барыннан да бигрәк яралы солдат булып, ут эченнән, Шаһбаз янынннан кайткан егет булып Халисәнең күңелен яулаган иде Шәфикъ. Олы хис иде, изге хис иде бу.

Әнә нинди изге-нәфис чәчәккә тузанлы тамчы тамды.

Саф тамчыларга мондый тузанны нинди рәхимсез җилләр ташлаган соң әле?

Мәхәббәт ялкыны, сорап кабынмаган кебек, сүнгәндә дә ниндидер сорауларга җавап эзләп маташмый.

Сораулар соңыннан, шактый соңлап кына күңелне газаплы-әрнүле тырный башлый. Ә хәзергә...

Икенче тукталуларында тагын керде Шәфикъ. Бу юлы гимнастеркадан түгел иде инде үзе... Бусагадан ул атлауга, Халисә, үзен кая куярга белмәстән, ишеккә атылды. Артта нидер гөрселдәде: әллә ишек янагына бәрелде теге, әллә егылып ук калды...

Шуннан соң Шәфикъ бу өйдә күренмәс булды. Әмма бер килүләрендә Гөлчирәттәй сөйләп алды:

— Сиңа гына күренмәгәч тә, бире сугылмаган көне юк ул мескеннең. Үкереп җыламый гына!.. «Белмәдем шул, Гөлчирәттәй, уйнап сөйләгәнне болай чынга алырын белмәдем», дип өзгәләнә... Туп-туры күзенә бәреп әйттем үзенә. «Уен сүзнең бер чиге була аның, мин әйтәм, шул чикне уздыңмы — я упкын, я ут. Ничу ут белән уйнарга!»

Шулай да Гөлчирәттәйнең шәфкатьле күңеле ачу саклый белми иде. Бер керүләрендә, тагын җай гына Шәфикъ турында сүз чыгарып, сөйләп утырды:

— Аның кордашлары армиягә киткәндә, сугыш чыкмаган иде әле. Шунда бу бичараның ничекләр боегып, нәүмизләнеп, иптәшләрен озатып калуын күз алдыма китерәм дә егетнең күңелен аңлагандай булам. Үз ишләре шикелле солдат була алмагач, моның шулай хыялында гына сугышып йөрүедер бәлки. Аннары, үз ялганына үзе ышанып дигәндәй, хыялларын чын итеп сөйләведер... Шулайдыр ул.

— Ут белән уйнамыйлар дисең бит, Гөлчирәттәй.

— Уйнамыйлар, сеңелем, уйнамыйлар. Анысы хак. Ул ягына гомер кул куясым юк.

Шәфикъның үкенүле сүзләрен Гөлчирәттәй Халисәгә моннан соң да берничә мәртәбәләр җиткерде.

Ә үткән тукталуларында Гөлчирәттәй Халисәнең ялгызын гына өйалдына дәшеп алды да уйга да килмәгән хәбәр җиткерде.

— Карале, сеңелем, теге тагын кергән иде. Шәфикъны әйтәм. Ни ди... Мин аның малларын авырудан йолып калган шикелле, бер селтәнүдә юк та итә алам, кемнән йөз чөергәнен белеп торсын, ди... Берүк, сак була күрегез, сеңелем. Күзләрендә иблис чаткылары шәйләдем. Әйтәләр бит... Дәрт-гыйшык дигәннәре ул кеше күңеленә күгәрчен дә оялата, шакалын да сыйдыра, диләр. Сак була күрегез.

Мондый янаулы сүзләрне Халисә иң башта Хәбиргә ирештерде. Егет, көтмәгәндә, бик куанычлы көлеп җибәрде. Аннары каш аралары ачулы җыерчыкланды.

— Болай итәрбез, Халисә апа. Бутаманда тукталулар бетте моннан ары. Әле Дүртөйледә, әле Каенлыда кунарбыз. Эзне саташтырырга. Күләгәсе дә күренмәсен безнең тирәдә!

... Бүген иртән юлга чыкканда, Хәбир әйткәнчә, Каенлыда кунарга сөйләштеләр.

Чиканаста әбәтен ашап, бер-беренә сыенышып кына арбадагы саламда баш төртеп тә алгач, малайларны алмаштыргандай булды. Зиннур тагын үзенең шаян җыр-такмаза капчыгын чишеп җибәрде.

Өстәлләрдә пар бәрәңге,
Янында ипи дә булса!
Безгә ипие нәрсәгә,
Табаклап ите торса.

— Бигрәк килештереп җырлыйсың, хәерсез, — диде Халисә, көлемсерәвен яшереп кенә.

— Нигә, Халисә апа, туры килә ич. Каз ите бик тәмле булды, шунда, вак-вак кабып кына, теш арасына кыстырып җибәрергә ипие дә булса...

— Ит куәтне ипигә караганда күбрәк бирә ул, энем. Кайгырма бер дә.

— Кайгыручылар без түгел. Әнә немец кайгырсын хәзер. Безнекеләр үз җирләренә бәреп кергәч, башларына уй төшкәндер нибуч.

— Син, Зиннур абый, җырлый-җырлый гына очып китә күрмә тагын, — дип, Роберт та сүзгә катнашты. — Канат ите ашадың бит.

— Әйдә, бот ите ашаган малай, йөгерүеңне бел.

— Йөгерергә була. Син оча-оча гына сугыш җиренә үк барып житсәң, безнең этиләргә дә сәлам әйтергә онытма диюем.

Чыннан да, шәп йөгерә Роберт. Әбәттән соң, солы сибеп кенә атта барудан баш тартты ул. Олауга Габделхакны утыртырга туры килде. Сафтан тайпылырга чамалаган казларны тәртипкә чакырып, көтү буйлап тәгәрәп кенә йөри хәзер Роберт, ул арада, Зиннур абыйсы белән көч сынаштан, ду килеп көрмәкләшеп тә алалар.

Малайларның шуклыкларына, шаян сүзләренә катнашкалап, күңелле генә атласа да, Халисәнең күңеле тыныч түгел иде.

Я Дүртөйледә, я Каенлыда кунып, эзне яшерербез, дип, җиңел генә әйтте дә әйтүен Хәбир... Ай-һай, әгәр тегенең мәкерле нияте бар икән, атына утырып кына өч-дүрт чакрымны үтү ни тора аңа? Барыбер Бутаман аша үтәсе бит, күреп калыр да... Әгәр инде, Бутаманга кермичә, урман юлыннан әйләнсәң, бик караңгыга калына. Өстәвенә, һаман шул бүресе, төлкесе...

Бара-бара Халисәнең пошмаган күңелен тагын бер нәрсә кыбырсыта башлады.

Көн үзәгендә, чалт аязып бетмәсә дә, рәхимле кояш, болыт өерләрен аралап үтеп, шактый вакытлар битләрне рәхәт җылытып бара, андый чакта әче җиле дә буйсынулы тынып кала иде. Көн авышкач, болыт өерләреннән таулар хасил булды, җил элеккечә яннан түгел, башларны идереп, каршыга бәреп исә башлады.

Җылы якларга очып китәр өчен канат ныгытырга чыккан кара каргалар төркеме, ашыга-ашыга, бер-берсен уздыра-уздыра каркылдашып, бөтенләй түбәннән генә очып үттеләр.

Бер дә бүтәнгә түгел, яңгырга бу. Каргаларның шуңа хәбәр салулары.

Тагын җеп бөртекләренә кадәр чыланасылары, телләрне тешләгәнче

дерелдиселәре бар икән әле. Каенлыда ниндирәк фатирга туры килерләр инде? Гөлчирәттәйнең якты йөзен, җылы мичләрен, аның кырлы бәләге аша үткән коры-йомшак аякчуларны, һай, бик тә сагынырга туры килмәгәе.

Ләкин бәла бөтенләй көтелмәгән тарафтан сагалап торган икән аларны.

— Әйдәгез, егетләр, җәһәтрәк атлатыйк әле боларны. Караңгыга калсак, кусаң да атламый башларлар, — дип, Халисә ярдәмчеләрен искәртеп алды.

Малайлар җитдиләнделәр. Габделхак атны чаптырып көтүдән шактый алгарак китә дә, аннары гына, «дөгә-дөгә-дөгә» дип, казларны чакырып солы сибә башлый. Казлар, муеннарын сузып, ирексездән кызулыйлар. Зиннур чыбыркысы да еш-еш шартлый. Тик Роберт кына — сабый түгел диген! — һаман да шуклыгын итә. Көтү тирәли дә гел тәгәрәп йөрүе генә җитмәгән, ул арада, елгыр колындай, басу буйлап та чабып китә, әллә кайдагы куакларны әйләнеп килә.

Шулай бер әйләнүендә ул көтүдән шактый артта калды. Йөгерә-йөгерә дә, эчен тотып, акрынлый, тагын йөгереп китә. Бик юргалый торгач, эченә кату чыкты, ахры, балакайның.

— Роберт энем, син алай бик шәбәрмә әле,— дип, малайны шелтәли генә башлаган иде Халисә, сүзеннән кинәт туктап калды. Коры шуклык кына түгел, ахрысы, бу. Төсләре киткән, иреннәре үк күгәргән ич моның.

— Энем җаным, әллә берәр җирең авыртамы?

— Әй, чепуха, Халисә апа. Менә... азрак эчнең рәте китебрәк тора.

— Каячы, әйдә, атка утыр беразга. Хәл алганчы гына булса да.

— Юк, юк, кирәкми, Халисә апа. Үтте инде. Бер җирем дә авыртмый хәзер.

Ләкин алай «үтте инде»гә бик охшамый иде. Аяк атлаулары сөйрәлүле сүлпәнләнде, сиздермәскә-күрсәтмәскә тырышып кына һаман эчен тоткалый.

Ай-ваена карамыйча, арбага яткызасы иде моны, дип, Халисә аңа таба килә башлаган иде, Роберт тагын юлдан читкә йөгерде. Халисә бераздан Зиннурны аның янына җибәрде.

Кире килгәндә, Зиннур Робертны култыкламакчы була, тегесе аның кулын читкә этәрә, шулай тарткалаша-тарткалаша килеп җиттеләр.

— Роберт энем, әйдә, арбага ятып бар, тыңла әйткәнне.

— Только солыны үзем сибәм,— диде Роберт, күм-күк иреннәрен ялап алып.

Җил көчәйгәннән-көчәя, хәтта казларның да ни шома сырт йонналарын кабартып-җилфердәтеп үтә, биткә эре-эре тамчылар да чәпәштерә башлады.

Халисә арба янына килгәч, эчләре жу итеп китте. Робертның солы сипкәндә куллары калтырый, ияге дерелди, үзе еш-еш сулый иде.

— Роберт энем, менә моны киеп ал әле, туңгансың син,— дип, Халисә сырма өстеннән кигән кожанын сала башлаган иде, Роберт аякларын арба читенә сузды.

— Кирәкми, Халисә апа. Алайса, мин җәяү барам.

— Энем җаным, тыңла әйткәнне. Авырып китсәң, әниеңә мин ни җаваплар бирермен?

— Төшеп йөгерсәм, хәзер җылынам мин.

— Йөгерсәң! Күп карышсаң, камчы белән сыртыңа менеп төшәрмен әле менә! Ят тыныч кына!

Әле караңгы төшәргә иртәрәк иде, шулай да, күк йөзен тоташ салынкы болыт каплаганга, күзләр бәйләнә башлады. Казлар да адымнарын акрынайттылар. Ардылар да бугай, караңгылык та эчләренә

шом сала булса кирәк. Артыграк куа башласаң, күкрәкләрен киереп алалар да, алга түгел, берәм-берәм читкә тайпылалар. Янәсе, алай бик кызулатсагыз, без үз ягыбызны үзебез карыйбыз, бигайбә...

Сирәк янгыр бер туктый, аннары битләрне тагы да чеметтеребрәк чәпи башлый.

Халисә арба ягында тыелып кына ыңгырашу ишетте.

Һай, үкенечләргә генә алып чыкмаган булса ярар иде баланы.

Үзем дә инде... Күптәннән эләккәне юктыр дип, малайны каз ите белән артыграк сыйлап ташладым бугай шул.

Хәзер инде Халисәнең бар теләге тизрәк Бутаманга җитү иде. Каенлыга кадәр барып, белмәгән-күрмәгән фатир эзләп йөрүне уйлыйсы да юк хәзер. Үзенең янәу ниятләре белән чәнчелеп китсен Шәфигы. Ачу килгән чак — кулда пычак дигәндәй, алай-болай янибызга юрый калса, кирәген алмагае.

Янгыры алай үтәли чылатырлык яумаса да, әче җиле юеш киемнәр аша үзәкләргә кадәр үтләште.

Бутаманга каранргыда гына барып керделәр.

— Халисә апа!.. Бер генә бит кәгазь табып булмас микән? Миңа иске китап бите булса да ярый, юл араларына язам мин аның.

— Табарбыз, Роберт энем, табарбыз. Бүгенгә тыныч кына йокла да, торуыңа кәгазь янында булыр. Йокла, кадерлем.

— Әтигә хат язмакчы идем. Шушы... казлар турында.

— Бик әйбәт булыр, иркәм. «Молодец синең улың» дип, мин дә шунда бер читенә язып куярмын. Йокла хәзергә, яме, кадерлем.

Өй эче тулы кеше булса да, тагын тып-тын булып калды. Алар кергәндә бик яман гырылдап йоклаган юлчылар да бүрәнә сөйрәтүдән туктадылар.

Гөлчирәттәй кулына ап-ак, шоп-шома кәгазь бите тотып килде.

— Менә, баш очына куй җанашымның. Габдуллаҗаныма хат язармын дип саклаган идем... Хәл эчендә булса да, һаман әтисе турында уйлап ята балакай.

Алар килеп кергәндә, башын сөлге белән кысып бәйләгән Гөлчирәттәй, аркасын җылы мичкә терәп, йон эрләп утыра, кәефе юклыгы әллә кайдан сизелә иде. Болар ишектә күренүгә, сикереп торды да элеккечә йөгереп йөри башлады, башындагы сөлгесен кайчан чишеп атканын күрми дә калдылар. Ни арада Робертка кипкән шомырт кайнатып китерде, мәтрүшкә чәе эчерде.

Инде менә баш очындагы кәгазьне үрелеп кенә капшап карагач, Роберт тынычланып йоклап китте.

Ишекне сак кына ачып, әле Зиннур, әле Габделхак кереп-чыгып йөриләр, Халисәнең сораулы карашына баш кагып кына җавап бирәләр.

Аларның болай сүзсез сөйләшүләрен Гөлчирәттәй дә төшенеп утыра икән.

— Син бер дә хафаланма,— дип, пышылдабрак әйтте ул Халисәгә.— Мин күршеләргә дә әйтеп куйдым, казларың янына якын да килә алмас Шәфигы. Ике дә уйлама!.. Менәтерәк, бала гына сихәтләнә күрсен. Эштән кайтышына, әтисенең куенына атланып куаныр гына чаклары да бит нарасыйның... И дөньялар!

Йоклый Роберт. Ике учын да өсле-өсләп янак астына куйган. Битләре кайнар кызарып торса да, сулыш алулары тигез хәзер. Кипшергән иреннәре кыймылдап-кыймылдап куя. Әтисенә язар сүзләрен кабатлыймы, әллә, төшендә күреп, аның белән сөйләшүме микән?

Кайларда йөрисең дә ниләр уйлыйсың икән син шушы минутларда, Шаһбаз!

Мыштым гына Габделхак керде, кулларын угалап, мичкә елышты. Нидер исенә төшепме, Гөлчирәттәй ашыгып кына лочмак якка үтте. Габделхак аның артыннан күзләрен тутырып карап калды. Гел Робертны кайгыртып, Гөлчирә апасы аңа бүген бик игътибар итә алмады, шуңа нәүмизләнүе инде бу юлы сабыйның.

Халисә, сырмасын иңбашларына гына салып, ишегалдына чыкты.

Җил басыла төшкән, ләкин һаман да бик болытлы бугай, дөм караңгы.

— Халисә апа, син уйлама, мин моннан барысын да күреп ятам. Күз, ябалакныкы кебек, нәләшеп бетте. — Зиннурның калтыраулы тавышы әллә кайдан, баздан ишетелгән кебегрәк яңгырый, үзен шәйләп булмый иде.

— Син кер, Зиннур, җылынып чык. Кайда соң син?

— Монда мин. Оҗмахта.

Арбадагы салам, төнге тынлыкта олы тавыш чыгарып, кыштырдый башлады. Әнә кая кереп чумган икән егетең.

Халисә лапаска үтте. Казлар, бәбкә тавышлары чыгарып, йомшак кына чеңгелдәшеп алдылар.

Теге чакта, сарыклары чирләгән кичтә дә, шушылай дөм караңгы җилле иде.

Шәфикъ, төн йокыларын калдырып, авыру сарыкларны дәвалап йөрде ул чакта.

Инде менә шул ук кеше малкайларга үлем белән яный.

Йа алла, нәрсәсен генә Шаһбазга охшаттың соң син ул егетнең? Кай якларын?

Аркасы буйлап салкын йөгерде, ә битләренә кайнар кызыллык бәреп чыкканын тойды. Кемнәрнедер үзенә охшатканы өчен Шаһбаз аңа, Халисәгә, үпкәләп, якында гына басып торадыр кебек тоелып китте.

Зиннур чыгып аны тагын җылы өйгә куып кертте. Халисә, йоклап китмәс өчен, яңагына таянып кына Роберт янына килеп яткан иде, тагын күз алдына Шаһбаз килеп баскандай булды. Бу юлы аңа үпкәләп карамый Шаһбаз. Гадәтенчә, нурлы-җылы елмая. «Тиздән җырлы хатым сиңа барып җитәр, Халисә, көт!» ди. Ә баш очыннан, биек-биектән торналар очып бара. Моңсу гына кыйгаклыйлар торналар. Чу! Нигә бик шомлы-шөбһәле каңгылдаша башладылар соң әле ул торналар?

Халисә сикереп торып тышка атылды, лапастагы казлар арасына ук барып керде. Казлар тагы да ачырак каңгылдаша башладылар. Халисә баганага эленгән корымлы фонарьны алып, бик җентекләп аслыкны караштыра башлады: агу-фәлән ташлап китмәгәннәрме? Юк, ул-бу сизелми. Нигә тынычсызланалар соң болар?

Капка ачылды да, уфылдап-мышнап Зиннур килеп керде.

— Халисә апа!.. Ну, кирәген бирдем... Туйганчы ярдым чыбыркы белән.

— Кемне ярдың? Ни булды?

— Кем булсын... Шәфикъка ялланган берәр бәндәдер инде. Урам яктан лапас тактасын кубарып маташа иде. Ну, казлар да бик сизгер. Алар аваз салмаса, бәлки мин абайламый да калыр идем. Әй, ярдым да соң үзен! Әллә өй биеклеге сикергәндер, валлаһи. Бәхете, качып котылды.

— Молодец, Зиннур энем! Хәбир чыбыркысын юкка гына сиңа ышанып калдырмаган болай булгачыннан. Рәхмәт, энем җаным! Әйдә, бар, юлга кузгалганчы, инде бераз йоклап ал.

Казлар һаман да тынычланып җитмиләр иде әле. Бер ала каз бөксәсен киереп алгарак чыгып баскан да, Халисәгә нидер әйтергә теләгәндәй, барысыннан да уздырып, ачы-ачы каңгылдый. Мәхмүзә әбинең бүреккәе ич бу!

Шунда әллә ни булды. Йөрәк бик авырттырып кысылып-кысылып куйды. Керфекләр кинәт чыланды... «Кызлар күз яше булып китүләредер бу казларның» дигән иде бит Мәхмүзә әби. Бигрәк килештереп, үзәк бәгырьләреңә җиткезеп тә әйтә беләләр соң бу әбиләр!

Халисә шәл чите белән күзләрен кызу-кызу сөртеп алды.

Юк, юк! Күз яше булып түгел, игелекле мал булып китсеннәр алар, казлар. Күз яше булып түгел, Мәхмүзә әби җаным!

Казлар акрынлап тынычландылар.

Нәрсә булды соң әле бу? Зиннур әйтмешли, чыннан да, «Шәфикъка ялланган берәр бәндә» йөриме, әллә инде очраклы бер үтүчегә генә тавыш кубаруларымы ул казларның?

«Дәрт-гыйшык дигәннәре кеше күңеленә күгәрчен дә оялата, шакалын да сыйдыра» дия дә бит Гөлчирәттәй... Кай ягы беләндер Шаһбазны хәтерләтүче егет күңеленә андый шакал ничек сыя алсын икән?

Шаһбазны хәтерләтте шул, Шаһбазны. Аннары, әнә, ромашкалы, баллы чәчәкле печән исе... Аһ, бөтен кызлар да шулай минем кебек тиле микән?

Никадәр корытып сөртсә дә, керфекләр һаман чылана торды, чылана торды...

Калган юлны хәвеф-маҗарасыз гына үттеләр.

Хәер, бер маҗара сыманы булып алды. Инде Казанга җитәргә дә әллә ни күп калмаган иде, көпә-көндез, ялан кыр уртасында көтү янына әллә кайдан гына тагын ике төлке килеп чыкты. Боларны иң беренче Роберт күреп алды. Зиннур көтүнең икенче ягында Габделхакка кызып-кызып нидер сөйләп бара, кулларын селти, селтәнгән көйгә чыбыркысын да арбага ыргытып калдырган иде. Төлкеләр күренүгә, Роберт әнә шул чыбыркыны алып йөгерде. Шул кадәр дә томырылып чаба малай, менә-менә мәхлукларның койрыкларына басар кебек иде. Хәтта арттагы төлкегә чыбыркысы белән сыптырып та алды. Ләкин шул чак, аягы сөртенепме, мәтәлчекле тәгәрәп китте. Төлкеләр коры елгага җитеп күздән югалдылар.

— Их, үзем булсам! Үзем булсаммы! — дип өзгәләнде Зиннур, күзләрен алартып Габделхакка карап куйды. — Син бозауга сөт имезәм дигән булып... Күрми калдым.

— Син булсаң, тотмый калмас идең шул. Боларның койрыклары да озынрак иде бугай, — диде Габделхак турсаеп кына. Роберт һаман да исенә-һушына килеп җитми иде әле.

— Мин... Зиннур абый... сиңа бүреккә булыр дигән идем. Бүләк итмәкче идем.

Зиннур ачу белән Роберт кулыннан чыбыркысын тартып алды да кызу-кызу гына атлады.

— Халисә апа, Саручи базар мясокомбинаттан еракмы? — диде ул, шактый ара сүзсез генә баргач.

— Трамвайга утырсаң, нибары биш-ун минутлык юл. Нигә әле сиңа базар?

— Ачуым ачу, Халисә апа, бу бүрек белән авылга кайтмыйм. Яңа бүрек алам.

— Ал, энем җаным, ал. Иң матурын сайлап ал. Акчаң җитмәсә, үзем биреп торырмын.

«Тәгаен генә бер сылуы күңелен кузгаткан моның, — дип уйлап алды Халисә. — Аллага шөкер, болай йөгерерлек булгач, Роберты да тәмам тазарган».

... Шул көнне кичкә табарак Казанның Татарстан урамы сәер генә парад сымак бер тамашага шаһит булды. Таш урамны тутырып, ак казлар сафы бара, һәммәсе муеннарын горур гына дугайлап, өскә сузганнар, әле берсе, әле икенчесе башларын кыңгырайтып, багана очлагындагы ялтыр лампочкаларга ниләрдер җилфердәгән балконнарга ка-

рап-карап алалар, үзләре артык шауламый гына гаң-гоң сөйләшәләр: «Бу ни гаҗәп бу? Бу фани дөньяның менә нинди хикмәтләре дә бар икән әле аның».

Ак колоннаның башындагы күк ат исә бернигә исе китмичә ялкау гына пошкыргалап атлый бирә, ә солыдан, саламнан бушап калган арбага дилбегәне кулларына чорнап торкан Роберт аягүрә менеп баскан. Чыбыркыларын иңбашларына салган Зиннур белән Габделхак янъяктан атлыйлар, шәһәргә җитүгә чыбыркысын арбага ыргыткан Халисә казларны куллары белән генә әйдәп бара, малайларга әйтер сүзләрен дә кул изәп-ишарәләп кенә аңлата.

Урам чатларында милиционерлар, машиналарны, олауларны туктатып, казлар сафына юл бирәләр, үтүчеләр, барыр юлларыннан туктап, аларга карап калалар, кайберләре кул болгый.

Комбинат артындагы биек агач коймалы мәйданга да казлар шулай муеннарын горур дугайландырып кына килеп керделәр. Әмма мондагы бихисап сарык, үгез-тана көтүләрен күрепме, бар мәэлдәү, мөгрәү авазларын басарга теләгәндәй, бик ачы каңгылдаша башладылар.

Аларның шулай үзләрен озата килүчеләр белән саубуллашулары булгандыр инде бу...

— Казлар китте. Шуннан соң, Халисә апа, теге җырдагыча: «Мин үзем дә уйлап торам, шул казлардан калмаска», дигән кебек, без дә бит авылдан киттек.

— Хәтердә, бик хәтердә. Радиодан Донбасс җирләре азат ителүен ишеткәч, тәмам күңелләре кузгалды Земфираның.

— Кузгалыр да... Эһм. Шулай ул туган туфрак. Кузгата ул күңелләрне. Эһм... Кая соң, Роберт, булмаса моны тотып куйыйк. Ул елларише моннан ары мәңге кабатланмасын дип берне күтәрик.

Халисә белән Робертның берсен-берсе бүлә-бүлә, икесенең дә күңелләренә уелып калган юл хатирәләрен уртаклашып, телдән әйтмәгәннәрен эчтән генә кичереп утыруларына Габдрахман гаҗәп тынычлык күрсәтте, аларның сүзләренә катнашмады. Инде менә шулай тамак кыргалап сүз кыстыруы, аның үзенә дә тел яза башларга вакыт җиткәнлеген аңлатуы иде.

Ләкин аңа рюмкага сузылган кулын тагын кире алырга туры килде. Роберт урыныннан акрын гына торып, түрдәге комод янына килеп басты, өстенә чигүле челтәр япкан баянның ялтыр төймәләрен сыйпап куйды.

— Әнә шул туган туфрагы тарткан да инде әнкәйне. Әбиләргә кайтып, ике ай үтүгә, әнине җирләдек.

— И бичара! Күңелләре үк сизенеп ашкынган икән.

— Менә бит! Шулай ул күңел, сизә ул. Эһм... Әйдә, булмаса...

— Беләсезме, Габдрахман абый, Халисә апа! Мактанып әйтүем түгел, әнкәй өзелгәч тә, зиратта да мин күз яше күрсәтмәдем, үземне ирләрчә тота алдым. Ләкин икенче көнне... еларга туры килде. Әнкәйнең мендәр җаймәсе эченнән әтинең хәбәрсез югалуы турында язу табып алдык. Безгә күрсәтмәгән аны әни.

— Бичаракай... — Халисә кинәт башын күтәрде. — Хәзер инде әйтергә дә була, Роберт. Саубуллашканда Земфира миңа күрсәткән иде ул язуны.

Роберт урынына акрын гына килеп утырды.

— Исемдә... Бик елашкан идегез шул.

— Еларсың да... Карачы, баядан бирле сорыйм-сорыйм дип утырам. Ниме... Гүзәлнең язмышы ничегрәк? Кайда ул хәзер?

— Гүзәл Тольяттида. Музыка мәктәбендә укыта. — Роберт тагын комод өстендәге баянга күз төшереп алды. — Халисә апа, Габдрахман абый, рөхсәт итсәгез, мин бер көй уйнап күрсәтер идем.

Ир белән хатын бер-берсенә карашып алдылар. Габдрахман күз иярмәслек тизлек белән алдындагы рюмканы бушатып куйды.

— Эһм... Халисә, алып бир Шаһбазның баянын, — диде.

Роберт кинәт урынынннан күтәрелә төште.

— Халисә апа!.. Мин ялгыш ишетмәдемме?

— Олы малайныкы. Себер якларыннан кайтып, хәзер КамАЗда эшли. — Халисә баянны Робертка сузганда, берәр төймәсенә орынды-мы, ыңгырашулы нечкә аваз чыңлап китте.

Роберт, баянны тезләренә куйгач, күзләрен тәрәзәгә текәгән килеш, беразга тын гына утырды, аннары бармаклары баянның бөтен сәдәп-ләре буйлап йөгереп узды.

— Халисә апа, Габдрахман абый! Беләсезме... «Китә казлар» ди-гән көй бу. Тыңлап карагыз әле!

Бүлмәдә моңлы-сагышлы аһәңнәр салмак кына агыла башлады. Салмак агым сиздермәстән генә дулкынлана башлый, көчәя... Моң һәм ярсу, ашкыну һәм сагыш дулкыннары берсен-берсе куып чайкала, ур-гылып-бөтерелеп ала, шул ук вакытта ачы-нечкә сыкрану да ишете-леп-ишетелеп китә... Бик таныш та кебек бу көй, әле беренче генә ише-түләре дә сыман.

Китә казлар...

«Кызларның күз яшьләре булып китүләредер бу казларның».

Халисә кинәт кенә авырттырып-ачыттырып кычыта башлаган күз-ләрен угалап алды.

Авырттырып ачыта, кычыта күзләр, әмма керфекләр коп-коры иде. Тамасылары тамып беткәндер шул инде ул күз яшьләренең...

Әйдә, таммасыннар гына инде... Ә менә хатирәләр, хатирәләр! Күз яшьләресез генә сыза алар хәзер күңелдә. Баян моңыдай.

... Казларны озатып авылга кайтуга, Шәфикътан хат килеп төште. Тулы бер дәфтәр. Һәр бите үкенү, гафу үтенү, ялвару белән тулы. Гөлчирәттәй егетнең күңелен дөрес сизенгән икән, хатта мондый сүз-ләр бар иде: «Сабый чакларда ук төшләремдә җилдәй җитез аргамак-та кылыч айкап дошман өстенә ыргыла идем мин. Өнемдә исә язмыш миннән ачы көлде. Илгә кара яу килгәч, миңа бала чак омтылышла-рымны хыялымда гына тормышка ашырырга калды. Аңласаң икән син мине, Халисә бәгырем!»

Аңлашыла да кебек иде, әмма ничек дип тә җавап язарга кулы бар-мады.

Хатлар тагын, тагын килде. Шунысы истә: сирәк яңгырга эләккән-дәй, таплы-таплы иде ул хатлар. Укыганда, Халисәнең үз күз яшьләре тамды микән аларга, әллә килгәндә үк шулай иделәрме?

Аннары хатлар килмәс булды. Соңрак хәбәре ишетелде: сугышлар бетүгә, ветеринария институтына укырга киткән Шәфикъ. Үзенең эти кеше булачагын белми китте ул.

... Малай туса, исемен алдан ук кушып куйган иде инде Халисә. Үзен көткәндә керфекләр артык еш чылангангамы, Шаһбаз шактый чырсыз бала булды, бер елый башласа, туктатыр әмәлләр юк иде.

Мәхмүзә әбиләргә кунакка кайткан егет ниндидер йомыш белән аларга килеп кергәндә дә, Халисә әллү-бәллүләп ишекле-түрле бала-ны юатып йөри иде.

Кунак егет авылда туса да, Магнитогорск каласында үскән, армия-гә дә шуннан киткән, сугыш бетәр алдыннан гына Германия җирендә каты яраланып, бер аягын калдырган, инде менә туган авылында сә-

ламәтлеген дә бераз ныгыту нияте белән Мәхмүзә туганый апасына кайтуы иде.

Һич онытыласы юк. Егет балага иелә төшеп: «Нигә дулый икән бу кеше? Һайт сине!» — дип сүз катуга, Шаһбаз елаудан туктап, нәни кулларын ят абыйның күкрәгендәге ялтыр медальләргә сузды.

Күкрәге тулы орден-медаль, ә үзе бөтенләй үсмер чырайлы, какчаябык гәүдәле иде кунак егет. Аз гына яшькелт-коңгырт күзләре моңсу һәм сизелер-сизелмәс рәнҗешле карый, суырынкы яңакларына исә зәгъфран сарысы чыккан иде. Шунда Гөлчирәттәйнең «Ил өчен сугышып яралану, аттан егылып төшү түгел ул сиңа» дигән сүзләре аермачык яңгырап киткәндәй булды.

Ни гаҗәптер, шуннан соң да кунак егет кулына алдымы, ни ярсып елаган бала бик тиз тынычлана торган иде. Мәхмүзә әби инде бик какшаган, еш кына, йөрәк чире кузгалып, көннәр буе урын өстендә ята, мондый чакларда бу өйдә ашарга пешерү, идәннәр юу, тегесенмонысын карау Халисә өстенә кала, ә кунак егет бала белән мәш килә иде.

Көзгә таба Мәхмүзә әби дөнья куйды.

Габдрахман Магнитогорскига кайтып китмәде.

Сабый да сабый, бу да сабый диярсең. Халисә Габдрахманның тәмәке тартканын да бергә яши башлагач кына сизде. Анда да әле, лапаста көйрәтеп торган чагына Халисә килеп чыкса, бу тизрәк тәмәкесен артына яшерер иде.

... Шаһбаз инде тәпи йөри, Габдрахман аны еш кына үзе белән тимерчелеккә алып бара, баланың бишектә чактагы елаклыклары күптән онытылган иде. Бер кичне, фермадан кайтуына өйдә үксеп-сулыгып бала елавын ишеткәч, Халисәнең тез буыннары йомшарып, чигәләре жуылдап китте. Болдырдан ничек менгәнен дә сизмәстән, ишекне шар ачып җибәрүгә, бусагада туктап калды.

Бөтен бите шоколад белән, яшь эзләре белән буялып беткән бала идәндә ауный-тәгәри елый, аның янына Шәфикъ чүгәләгән дә, үзе дә елар дәрәҗәгә җитеп, юату сүзләре әйтә... Ә күзләре тоныкланып калган Габдрахман, бернигә исе китмәгәндәй, өстәл артында стаканын учына кысып, мәлҗеп утыра иде.

Ирен беренче мәртәбә салмыш килеш күрүе иде Халисәнең.

Бу өйдә беренче һәм соңгы тапкыр күренүе булды Шәфикънең. Хәзер ул ветинститутта студентларны укыта, профессор ук булмаса да, доцент-фәлән бугай.

Һай, Гөлүсә кызым, нигәләр дип кенә нәкъ шул институтка керергә уйладың соң әле син?

Музыка тынып калды, ә сихри аһәңнәр булмәдә, күңелләрдә һаман да тын гына тибрәнә иде әле.

— Гүзәл үзе язган көй бу. Ә исемен, дөресен генә әйткәндә, мин шулай дип атадым. «Китә казлар»... — Роберт бу сүзләрне үз алдына гына караган килеш, акрын гына әйтте.

— И-и!.. Бигрәк моңлы бала иде шул, җанашым. Язмышлары ук моңлы дигәндәй... Сәламәтлеге ничек соң хәзер?

— Әйбәт кенә... Әни үлгәч, Гүзәлне Одессадагы сукырлар өчен махсус детдомга алдылар. Мин һөнәр мәктәбенә киттем. Шулай итеп, үскәндә үк очрашулар сирәк иде безгә. Ә очрашсак, Гүзәл миннән гел әти турында сөйләтә, авыл турында сораша, миннән гел татар көйләрен уйната. Аннары тагын, бу көйнең тууына менә нәрсә сәбәп булды...

Роберт урыныннан торып, идән буйлап кызу гына бер әйләнеп килде.

— Әнинең ул мендәр җәймәсендә калын гына бер шигырьләр дәфтәре дә бар иде. Әтиемнең үзе язган шигырьләре. Очрашсак, Гүзәл аны да кат-кат укыта иде. Ә соңрак... — Робертның бугаз төене кызу-кызу уйнаклап алды. — Беләсезме, шушы шигырьләр безгә хәбәрсез югалган әтидән хәбәр дә алып килде.

— Һай! Нинди хәбәр? — Халисә шактый каты кычкырып җибәрүен сизми дә калды.

— Болай булды. Түмәндә мине алдынгы бер нефтьче белән таныштырдылар. Безнең гадәт шул инде, кешенең бөтен эше-тормышы, бөтен гомер юлы белән кызыксынасың. Себердә туып-үскән, бик авыр сугыш юллары үткән кеше икән. Әсир калып, күп концлагерьлар үткән, аннан качып, Франциягә кадәр барып җиткән, Каршылык отрядларында сугышып йөргән. Соңрак кына белдем, күрше группа командиры ватандашым, татар егете булып чыкты, ди, үзен, французчалап, Жан дип йөртәләр иде», — ди. «Шигырьләр сөйләргә бик оста иде Жан», — дип, хәтерендә калган берничә шигырь юлларын да әйтеп күрсәтте. Беренче юллар ук мине сискәндереп җибәрде:

> Сагынуымны җырга салып,
> Каеннарга килеп таянам.
> Җырдай илем, синең өчен
> Гомеремне дә аямам.

Бу бит әтием шигыренә бик тә охшаган! Тик кайбер сүзләре генә...

— Охшаган гынамы соң! Шаһбаз шигыре бу. Анықы! Анықы! — Халисә кинәт ике куллап күзләрен каплады, бармак очлары шунда ук җылымса чыландылар. (Юк, корып бетмәгән икән әле күз яшьләре) — Шаһбаз шигыре бу! Бервакыт клубта да сөйләгән иде. Ул кеше бик дөрес отып кына бетермәгәндер. Шаһбаз сүзләре...

— Бик ихтимал. Бәлки әтием үзе үк аны шулай үзгәрткәндер. Ачыклыйсы нәрсәләр күп, әлбәттә.

Халисә күзләрен тиз-тиз сөртеп алды.

— Шуннан... шуннан тагын нинди хәбәрләр сөйләде ул кеше Шаһбаз турында?

— Тагын аның миңа мондый шигырьләрен хәтерли:

> Яраланган киек каздай,
> Чит җирләргә егылып төшсәк тә,
> Без тугрылыклы сиңа, Туган илем,
> Тәмуг газаплары кичсәк тә.

Аннары:

> Чын сөюләр яу эчендә
> Тагы да дөрли икән,
> Тынгылар бирми икән,
> Җиңелү белми икән.

Болары әтиемнең дәфтәрендә юк. Бу юллар инде... әтиемнең үзе турында Туган илгә җырга салып җибәргән хәбәредер.

— Менә бит! Эһм... Хәбәрсез югалды дип йөр син безнең солдатны! — Габдрахман, үзе дә сизмәстән бугай, рюмкага үрелә башлаган иде, кулын кире алды.

— И дөньялар!.. Шуннан, ничек соң инде? Ул кеше ничек әйләнеп кайта алган да, Шаһбаз белән кайда аерылышканнар соң?

Роберт исә боларны ишетмәде дә бугай, урыныннан торып, озын чәчләрен артка сыпыра-сыпыра, тагын идән буйлап йөренеп китте.

Аннары кинәт бүлмә уртасында тукталып калды.

— Тарихның бу сугыш турында иң олы язмасы бик кыска — безнең Җиңү. Әмма шушы ике сүз миллионлаган батырларның каны белән язылган. Дөрес, меңләгән батырлар турында Тарих аерым-аерым да язып калдырырга өлгерә алган, ә тагын меңләгән-меңләгән батырлар турында язарга Тарихның вакыты булмаган. Алары соңыннан, менә утыз ел буе инде языла... Кызганычка каршы, әтиемнең хәбәре дә миңа бик соңлап килеп җитте.

Роберт, урынына утырып, баянны кулына алды.

— Сентябрьдә журналист путевкасы белән Франциягә китәм. Бәлки әтиемнең сугышчан эзләренә төшә алырмын.

— Юлларың уң була гына күрсен дә, матур хәбәрләр алып кайтырга булсын!.. И дөньялар... Карале, Роберт, теге көйне тагын бер уйнап күрсәтәсеңме әллә? Гөлүсә, кызым, кил, син дә тыңлале! Отып кала алмассыңмы?

— Ерактанрак тагы да матуррак ишетелә ул, әни,— Гөлүсә әллә өйалдыннан, әллә ишегалдыннан җавап бирде.

Бүлмәдә тагын моң һәм ярсу, ашкыну һәм сагыш дулкыннары бер салмакланып, бер ургып-бөтерелеп агыла башлады.

«Менә кайчан килеп җитте синең җырлы хатың, Шаһбаз!».

Халисәнең бите буйлап мөлдер тамчылар тәгәри, ул аларны сөртми... Сизми дә иде бугай.

1975—1976.

## Роберт Әхмәтҗанов

# УЯНУ

Хәтер дәрьясының
зәңгәр яры

I

Китәм дигән идем
кара төнне ярып —
мәхәббәттә куркак...
Китеп булмый, булмый гомер буе—
истәлекләр уртак!

Ак тирәкләр арасында
йөри синең җырың...
Хәтеремнең зәңгәр ярларында
калды Сөю елы.

Ә ул шәһәр алган чаклар!
Ә ул диңгез төсе!
Үткәннәрдән Хәтер дәрьясының
ярына килә Кеше...

II

Дулкын-дулкын сагыш тауларыдай
ярга килә күк су.
Ишетелә там-там авазлары,
көтү, чакыру, үксү!

Ап-ак күбек... Төпсез мәңгелектән
гүя көлү кебек.
Я ишетелә сөю, яну,
тәүбәләр һәм өмет!

Гүя көтә сине шушы ярда
яшьлек белән кавышу...
Кабырчыктай йөрәгемдә тора
диңгез тавышы.
Яшьлек тавышы!

III

Син — минем зәңгәр иртәм дә,
син — минем көндезем!..
Диңгезең бар, һаман шаулый-дулый, —
синсез бит диңгезең...

Өркеттеме әллә күкләр уты,
төпсез упкын шавы?
Тау-тау дулкын арасында йөзә
диңгез акчарлагы...

Йөри күченеп ерак ярдан-ярга
синең бер сүзең, —
күзләремә карап, көпә-көндез
әйттең бит син үзең:
«Акчарлаклар шомлы давылда да
ташламый диңгезен».

Ә үзең?..

IV

Диңгезгә су чәчрәтә!
Үзе куана, көлә!
Баш очында Кояш җырлый,
яшьлеге шау чәчәктә!

Әллә шуңа бер сәбәпсез
көлә диңгез — тиңсездән:
көлә-көлә су чәчрәтә
учы белән — диңгезгә!

Диңгезе — әле тездән.

## Топольләр җилгә каршы...

I

Таң алдыннан тәрәзәмдә
топольнең таныш шавы:
имин икән җилләр, кошлар,
ерак йолдызлар — бары...

Таң алдыннан өй түрендә
бер торып шаулап ала:
әйтерсең яфраклар аша
гомерләр шаулап ага...

Җил исеп куя да кинәт
таң киләсе яклардан,
өй түремә хәтер ява,
моң түгелә яфраклардан.
Моң түгелә яфраклардан...

II

Әйләнде безнең гаиләгә,
башыннан кичте бар да...
Сыенды безнең кыекка
күкрәүле яңгырларда...

Тәрәзәдән карап торды
туган йортның миченә.
Мөнәҗәт әйтеп керде ул
төнге җилләр эченә...

Тора ул, шаулап тора ул
елларда, еракларда...

Туган өйнең тәрәзеннән
ут төшкән яфракларга...

III

Калды яшең — бөҗраларда,
түземлегең — давылларда,
сурәтең калды — яшеннәрдә,
истәлегең — елларда,
сулышың калды — яңгырларда,
шавың калды — җилләрдә,
яшьлегең — тамырларда.

IV

Без, тополем, бергә!
Йолдыз яңгырлары астында
кичеп чиксез еллар дәрьясын,
кешеләр һәм топольләр барысы
ялан аяк, ялан баш,
һәрчак
баралар — җилгә каршы.
Күк утлары, зилзиләләр уты аша,
кулга-кул тотынышып,
кушылып зур төркемгә,
баралар...

Гомерләр һәм туфрак иркендә.

## Көзге кичке кояш

*Мансур ага Мозаффаров ядкаре*

Кичке Идел өсләренә коела
болыт артларыннан нур көлтәсе.
Иделен, болытларын, офыкларын —
килә тоташ бер җыр итәсе!..

(Шундый якты нурлар төшә иде
бала чагым киноэкранына!)
Кеше, туктап, бер яктыра җирдә
гомер кояшы баер алдыннан.

Бер тукталып яктыра ул шундый! —
фанатик ул — хәтта җыр яза!
«Яз!» дип тополь кышын яфрак ярса,
күзен кайтса «Яз!» дип кыр казы —
чагыштыру мөмкин шуның белән, —
миндә, ди ул, яшьлек уртасы!

Ә бит, юкса, аяк очына тиеп,
уелып ага Әҗәл елгасы...

Ул Җыр язды Идел өсләрендә,
калды моңы янып күңелдә —
шәфәкъ булып балкый кичләремдә,
кояш җыры — таңгы Иделдә!

Калды ул җыр — йөри чиктән-чиккә,
офыклардан күчә офыкка...
Идел өсләрендә, тынга калып,
аны тыңлый кичке болытлар.

## Бер фәлсәфә

Агач гомерен билгелиләр — боҗралардан,
атның яшен билгелиләр — карап тешенә...
балыкныкын — тәңкәдәге сыры белән,
кеше гомерен — җырлый торган җыры белән,
салган эзе, юлы белән.

Бәялиләр — карап эшенә...

## Бер әдәби бәхәстән

Һәр ягыңда, Илем, җырда гына
әйтеп булмый торган матурлык.
... Берәүләрнең анда әйтерсең лә
тауда яшәүләре — батырлык!

Үз түбәсе бар бит һәркемнең дә,
алар горур, биек төс белән
кычкыралар үзәндәгеләргә:
«Без югары ничек, сез — түбән!..»

Юк шул бездә таулар, җирләр — яссы,
бөтен киңлек монда — җилнеке.
Идел! диеп бер кычкырыр идек,
Идел дә бит бөтен илнеке!..

# Очышка!

Бар, оч, туган,
син — һава кешесе,
егылма, тотын!
Күккә карап күгәрде күзләр!
Син моны яуладың
яндырып
сабырлык утын!

Очу ул — бер көнлек, диделәр,
көлделәр —
Мәңгелек атына
ябышкан агайлар!
Ике кулыңны җәеп,
сикердең ярдан, —
төшләреңдә йолдызга
сикерде малайлар!

Очтылар малайлар —
хыялда, төшләрдә.
Ә өндә — әйләнеп
кайттылар галәмнән!
Очу ул — бер көнлек,
купшылар темасы —
шул сүзләр түгелде
скептик каләмнән.

Очыш мәйданында
күкләргә ыргылып,
ничә мегатонна
куәт тора ярсып...
Ычкындыр тезгенен! —
безнең азат гамәл
яңа галәмнәргә
сәлам алып барсын!

Оч, туган, туйганчы,
йолдызлар артына, —
бу хакны яуладың
гасырлар буе!
Оч, әйдә, гали зат,
икарлар оныгы,
кояшлар утына
җиткәнче буең!

Оч, әйдә, сөюдә,
оч, әйдә, җырларда,
өметле язмышта,
бәхетле минутта;
иң якты сәгатьтә,
иң гүзәл сәнгатьтә,
табынып максатка —
иң изге бер утка!

## Өлкән таллар урамы

Өлкән таллар урамында
узган җәйнең моңы тора.
Иң чал тал да кыштырдамый,
тын утыра.

Урам өстенә иелеп
уйлый таллар, чумып моңга, —
ә уйлары сузылып ята
күләгәләр булып юлга.

Өлкән таллар урамында
кызыл йолдызлы капкалар.
Эңгер төшсә, ачыла-ябыла:
хәтерләр кайталар...

Кайта башлый кайтмаганнар,
кайта хатирәләр, сагышлар...
(Өлкән таллар урамында —
онытылган тавышлар!..)

Кисеп чыга юлны ак өметләр —
кайталар —
яшьли киткән егетләр.

Аксакаллар тамак кыра, күршеләр...

Кемдер буш нигездә көрсенә.

Көннәр сәлам бирә бер-берсенә...

Йөри анда, кыймый гына,
киленнәрнең көләчлеге.
Чагылып китә, моңлы төштәй,
әниләрнең яшьлеге!..

Аналар хәләл сөтен имезгән —
кайталар бар да туган нигезгә:
кайталар улларыннан яшь аталар,
аталарын узып чалланган уллар...

Эңгер төшүгә,
өлкән таллар урамына кайталар —
бер-бер артлы
еллар!..

# Уяну

Шәһәрдә чүпләр яна —
узган җәйнең үләннәре...
Төшә тургай тирбәлеп,
сайрый яңа шәһәргә
язгы хәбәрләрне!..

Син дә инде ялыктың,
сүрән кышның куенынннан
тартылып яз утына,
чыктың якты урамга —
нурлы яз туена!

Ялыккандай, сөймәгән
ят яр белән яшәүләрдән.
Чыктың — күңелең җилбәгәй —
сорый наз һәм азатлык
синең бөтен гәүдәң!

Газонда яна утлар,
сузылып якты болытларга...
Ягасы иде иске
тутыкларын күңелнең
салып шул утларга!

Чүксен иде көлләнеп
шаулап торган көн каршында, —
хөрләнеп көлсен күңел,
ягасы иде чыгарып
мәйдан уртасына!

............

# Фаил Шәфигуллин

## Ник кайтмый?

Моңа кадәр ишетелмәгән
Матур көйгә
Шәһәр буйлап тальян уйнап
Бераү килә.
Йокымсырап, изрәп торган
Таш биналар
Берәм-берәм сискәнешеп
Уяналар.
Иген шавын ияртеп килә
Гармун чыңы.
Сандугачлар озатып килә
Гармунчыны.
Асфальт буйлап ромашкалар,
Миләүшәләр
Матур көйне отыйк, диеп
Йөгерешәләр...
Ә гармунчы какмаларга
Баса ныграк.
Җиз телләрдән аһлар, зарлар
Чыга сыкрап.
Ә гармунчы какмаларга
Һаман баса.
Үкси башлый тальян кинәт,
Гөлләр кача...
Тавыш килә язгы ерак
Ташулардан:
«Нәрсә җуйган бу гармунчы
Таш урамда?!.
Нигә кайтмый бу гармунчы
Басуларга?!.»

## Акбүз ат

*Жыр*

Бала чагымның хыялы — акбүз аткаем,
Нәрсә сөйләп озатып калды сине ак каен?

Таң нурында ялкынланып янды ялларың,
Күпме йөгерсәм дә сине тота алмадым.

Эзләреңнән йөзләремә энҗе сибелде,
Өметме син, бәхетме син, яшьлек идеңме?..

Җанны назлый якты бер моң — исемә төшми:
Кайдадыр таулар артында акбүз ат кешни.

Акбүз ат,
Кайтырсың, дип көттем сине
Озак, бик озак...

●

Туган авылыма кайтам да мин
Тау буена киләм.
Бала чакта биек иде таулар,
Хәзер инде иңгән.
Таулар хәлсезләнгән,
Таулар иңгән...
Аңлый алмыйм, нидән?..

Һаман горур, һаман бик биектә
Йөзеп йөри тилгән...
Канатлары аның элеккечә
Болытларга тигән.

●

Ярдәм итми инде уколлар да,
Сүлпәнләнә бара тибеше. —
Вак борчулар гына туздырды бит
Йөрәгеңне синең, и кеше.

Вак борчулар һәм мин-минлек чире,
Көнчелек һәм данга кызыгу.
Мәңге яшәрмен күк булсаң да син,
Тормыш дигән нәрсә кызык ул...

Зур эшләргә сусап типкән иде
Әле кайчан гына зур йөрәк.
Йөрәк кадерен кеше белмәде шул,
Ни файда соң хәзер зар елап.

## Бала чак кайтавазы

*Усал малай сүзләре*

Гамьсез көннәр уздырганбыз,
Уйнап кына туздырганбыз
Кош ояларын.
Шуңа, ахры, кайсыбызның
Бүген күңел күле бозлы,
Буш хыяллары.

Гөл өстенә ут якканбыз,
Күл өстенә ук атканбыз
Бәләкәй чакта...
Кинәт мылтык телгә килсә,
Җиргә аккош зары иңсә,
Уйлыйм шул хакта...

Яңа шатлык — олыгайгач,
Яңа кайгы — олыгайгач,
Мәшәкать яңа...
Тик бер үзең генә калгач,
Төнге утлар янып аргач,
Хәтер уяна.

Бала чакта, еракта без
Каеннарны елатканбыз —
Бар гаеп бездә.
Бер үк сүзне кабатлый җил,
Бер үк сүзне кабатлый җир:
«Бер гаепсезгә!»

**Гариф Ахунов**

# ИДЕЛ КЫЗЫ

РОМАН

**БИШЕНЧЕ БАШЛАМ**

## I



Өйләнү, тормыш кору Солтан Айдаровның холкына әллә ни үзгәреш кертә алмады. Ул әүвәлгечә җитди, нык, ил ни кушса, шуны үтәргә әзер иде. Ләкин өйләнү, дөресен әйткәндә, Солтанга шактый ук зур мәшәкать алып килде. Мәшәкатьнең иң зурысы — беренче нәүбәттә — сыйнфый тигезсезлеккә кайтып кала иде.

Өйләнү хакында этисенә кайтып әйткәч, Садыйк карт алагаемга бер күтәрелеп бәрелде:

— Шәмсениса остабикә кызынамы? Аллам сакласын! Шуннан да җүннерәк тагын берәр нәрсә уйлап чыгар син, булмаса. Яле, туп-туры карап әйт әле: муллаларның ач күзен туйдырырлык туй бүләге каян аласың? Мәхдүмәне көйләп торырлык сабырлык каян килсен?

— Ул бит мәхдүмә түгел инде, эти. Ул бит Габбас мулладан баш тартты, — диде Солтан, чәйле тәлинкәсен өстәлгә куеп.

Садыйк карт та чәй эчүдән туктады, Солтанга таба иелә төшеп, гыжылдавык тавыш белән тезеп китте:

— Менә шунысы начар да аның! Җүнне кеше газиз атасыннан баш тартамы? Кая яраган эш бу? Кайчан булган эш? Сәвит шулай өйрәтәмени? Ата чаклы атадан баш тарт, димени?! Бүген атасыннан, иртәгә иреннән, аннары... дененнәнме? Юк, Солтан, мәхдүмә дип авызыңны да ачма, мулла кызына өйләнергә рөхсәт итмим!

— Туктале, эти, ул бит инде ничә еллар Казанда яши, совет мәктәбендә укып белем алды...

— Нәрсә син мине әгъвәләп торасың? Әллә мин белмимме, әллә мин дөньяның ачысын-төчесен татымаганмы?! Су белән майның беркайчан да кушылганы юк.

---

Ахыры. Башы 1, 2, 3 саннарда.

— Бер казанга салып кайнатсаң — кушылыр.

— Минем рөхсәтем юк. Теләсәң нишлә. Ата-ана сүзен тыңламый торган җүнсез бала икәнеңне бер күрсәттең бит инде син.

Солтан, сүзне беткәнгә санап, урыныннан торды.

— Ярый, әти, синең рөхсәттән башка гына өйләнербез! — Чөйдән күн тужуркасын алып киде, башына кепкасын каплады, саубуллашмый гына чыгып китте.

Зартугай урамы буйлап, кулын кесәсенә тыккан килеш, үз алдына сызгырынгалап, озак барды. Халык печән эшендә булгангамы, урамнарда кеше-кара күренми, ялан аяклы, киндер штанлы ике малай гына су буеннан ашарга сорап менгән үрдәкләрне чыбык белән киредән инешкә таба куалар иде. Әнә шул ялан аяклы, кара борынлы малайлар Солтанның буй җитмәс бәхете булып тоелды.

Үсмер чак хәтирәләренә бирелеп, ул мулла йорты һәм мәчет яныннан узды. Мулла йортының сары буяулы биек урыс капкасыннан урамга күләгә сузылган, анда ала бозау күшәп ята; мәчет буена мул булып кычыткан үскән, мәчетнең буяулары уңган-үңгәргән, күрәсең, хәзер аны махсус карап торучы юк, элекке заманнардагы шикелле, мәчет картлары, мәхәллә мөритләре мәчет дип атлыгып тормыйлар; әмма юан биек манарасы, манара башындагы урак сыман ае белән ул Солтан күңелендә бик еракта тормышларны яңарта, кайчандыр ишеткән азан тавышларын колакта чыңлап торгандай итә; әтисенең үҗәтлеге әнә шул ерак азан авазларына кушылып, күңелдә ризасызлык уята иде.

Кояш инде мәчет манарасыннан күп өлеш югарырак күтәрелгән, аның җәй башы икәнне сиздереп торган мул җылысы күн куртка аша кыздыра, талкынган, туңып каткан җанны җылытырга җитә иде. Каравыл йортының биш-алты торыклы тәбәнәк лапасында тәртәләрен югары күтәртеп куйган арба, камыты, ыңгырчагы, дугалары белән, дәү корсаклы иске мичкәсе белән коргаксып тора; ярты лаш корыган каен башында колак тондырып чарылдашкан чәүкәләр, тыкрык буйларында авып яткан иске читән, җил-яңгырдан карайган, баганалары кыйгайган утыртма коймалар — болар барысы Солтанның яшьлеге, авыл малае күңеленә гомергә сеңгән, аерылмаслык булып береккән газиз күренешләр. Шушы йортлар исән-имин булсын өчен, ындыр артыннан ук башланып киткән корама юрган төсле басуларда ярлы-ябагай иркенләп иген иксен өчен, аның абыйсы Шәяхмәт авыл кулакларына, алпавытларга каршы сугышып йөрде, авылларда совет урнаштырды, ярлылар комитеты төзеде, үлем баржасының тончыктыргыч сасы, юеш трюмнарында ятты, партизаннар килеп коткармаса, аның җәһәннәмгә җаны олаккан иде инде, ярый әле, Алабуганың карагайлы куе урманнарында яткан партизаннар — Бондюг заводы эшчеләре булды; Шәрифҗан мөгаллимне, яркәм башлыгы Вәҗине, аның әнисен ак гвардиячеләр хурлыклы үлемгә дучар иттеләр. Озакламый монда яңа тормыш башланачак. Җирне күмәкләп эшкәртү, ширкәтләр, коммуналар кору. Җир төзү техникумында аны җир хакындагы белемгә өйрәттеләр: межалар тарихын, чәчү әйләнешен, Россиядә булып узган җир дауларын, бунтларны миенә сеңдерделәр. Ул әтисе Садыйк карт кебек кешеләрнең тормышы ямьле булсын дип, ярь-яшь көенә сугышып йөрде, техникумга кереп укыды, инде менә әтисе аны аңларга теләми, күңел тарткан, җан яраткан кешесе белән тормыш корырга рөхсәт итми.

Бара торгач, Солтан уйга кала: әллә әтисе хаклымы? Әллә мулла кызы Нурия белән аларның тормышлары барып чыкмасмы?

Авыл урамын ике мәртәбә урап килгәч, ул, ниһаять, Габбас муллаларга керергә батырчылык итте. Чыннан да, нигә икеләнеп торырга? Каршы килә икән килсен, аңардан Солтанның ныклы карары үзгәрмәячәк. Ул бабасы булачак кешенең нинди уйлар, нинди тойгылар белән яшәвен белер, аның тормышын үз күзе белән күреп чыгар...

Капкадан керүгә аны бөрешеп беткән бер карт каршылады. Җәйге челләдә башына колакчын бүрек, аягына киез итек киеп алган бу кешене, әгәр аркасында бөкресе булмаса, Солтан һич кенә дә Бөкре Гафият дип танымас иде.

Гафият абзый башта, кулын каш өстенә куеп, Солтанны озак кына танымый торды. Солтан аның исемен әйтеп сәламләгәч тә әле, аптырап:

— Кем соң син? Әллә кала җиреннән килгән түрәме? — диде.

Солтан үз алдына елмаеп куйды.

— Нәрсә, түрә кирәк идеме әллә, Гафият абзый?

— Кирәгие шул. Ник дибәйтеп әйтсәң, ике бозауга кибәк аерып бирә торганы кирәгие. — Солтанга аның майламаган арба тавышы төсле шыгырдап чыга торган тавышын тыңлап тору бик әллә ни күңелле түгел иде, әмма мулла йортында гомерлек хезмәтче булып торган бу кешенең җитди гозере булуы мөмкин иде, шуңа күрә сабырлыгын җыеп тыңлап бетерергә булды.

— Сөйлә, Гафият абзый, — диде ул өшәнгән ат төсле башын иебрәк торган картка.

— Сөйлә дибәйтеп нәрсәсен сөйлисең инде аның. Габбастан үземә тиешлене дауларга дип килгәнием.

— Ә ул бирмим диме?

— Нишләп алай дибәйтеп әйтсен, бирәм, ди. Әммәкәди аның бирәм дибәйтеп әтүеннән миңа ни файда...

— Нәрсә бирергә тиеш соң ул сиңа, Гафият абзый?

— Ничек нәрсә бирергә? Ат бирергә тиеш. Ат бирмәгәченнән ник мин аңарга егерме биш ел буена бил бөктем, ат абзарында тирестә аунадым?

Солтан, сүзнең асылына һаман барып җитә алмаганга үртәнә биреп, өзеп сорады:

— Мулла бирәме сезгә атны, юкмы?

— Бирәме дип, бирмәскә хакы юк. Мине өйрәтеп җибәрделәр, үзеңә тиешлене сутка биреп ал, муллаларда калдырма, диделәр.

— Син судка бирдеңме? — диде Солтан, ниһаять, сабырлыгы бетеп.

— Нишләп сутка бирим? Мөселман башым белән кешене сутка биреп йөримме соң?

«Акылына зыян килгән булса кирәк. Моңардан рәтле җавап ишетеп булмастыр...» — дип уйлады Солтан, тиз генә саубуллашып китә башлады.

Гафият картның кайдадыр тирәндә, төптә утырган күзләренә җан керде, алар чаткылар чәчрәтеп кинәт кабынып киттеләр:

— Качасыз! Гафиятне тыңламыйсыз! Гафиятнең кирәге калмады!

Солтан аның зур киез итекләрен шыштырдатып, капкага килгәнен күрде, капка келәсен күтәргәч тә әле ул беркавым уйланып торды, тик шуннан соң гына авыз эченнән мыгырданып китеп барды.

Солтанның бөтенләй кәефе кырылды, ул инде Габбас мулла янына керми генә китәргә дә исәпләгән иде, тик шул мәлне чолан ишегеннән Шәмсениса абыстай килеп чыкты:

— Кунак бар икән, — диде, авызын яулык чите белән каплагандай итеп.— Садыйк абзый малае түгелме? Син түгелме, Солтан гөлкәем? Менә син тамаша, күршене танымый торам лабаса! Әйдә, өйгә кер, Казаннан кайттыңмы. Нурия исән-саумы? Ни эшләр бетереп ятасыз?

Габбас мулла Солтан белән корырак исәнләште. Чәй янында да бик әллә ни җәелеп китмәде.

Уртага салып сөйләшер сүзне Солтан башлап җибәрергә тиеш иде. Ләкин капка төбендә мулланың элекке хезмәтчесе белән очрашу әле һаман Солтанның күңелендә ямьсез булып утырып тора иде, шуңа күрә ул Гафият карт мәсьәләсенә ачыклык кертми торып Нурия хакындагы сүзне башламаска карар кылды.

— Гафият абзыйны очраттым. Әллә ул бераз ниме? Җиңеләя төшкәнме?

Габбас мулланың таушалган, сакалы җитен сүсенә әйләнеп бетә язган чыраеннан күләгә узып китте.

— Көн дә саен бер кереп чыга инде ул, бичара. Ат сорап килә.

— Бирәсезме соң?

— Бирәм. Ике атның берсен сайлап ал, дим. Миңа дисә — җаны теләгәнен алып китсен.

— Алмыймы?

— Алмый шул. Көн дә саен килә. Атлар янында көне буе кайнаша. Ялларын тарап үрә, сугара, башак болгатып ашата, әйләнә-тулгана, кәефемне бозып бетерә. «Алып кит атның берсен, бүтән килеп йөрмә»,— дим. Юк. Теңкәмә тиде инде. Алмый. Әллә инде, гомер буе атсыз яшәгәнгә, кайсын сайлап алырга белми аптырый, әллә инде бүтән планнары бар — белмәссең аны...— дип, тонык тавыш белән сүзен очлады Габбас мулла.

— Инде, Габбас абзый, төп сүзгә күчик. Мин сездән Нурияне сорарга килдем. Күреп торасыз, яшьтән үк күршеләр идек, бергә үстек, бергә укыдык, икебез дә Казанда, бергә яшәргә рөхсәт итегез.

Габбас мулла аны дәшми-нитми тыңлады. Башын селкеп куйгалады, сакалын чеметкәләде, кара бәрхет түбәтәен артка чигереп, башын кашып торгалады. Солтан аның ризалашуын аңлады, әмма күңелендә нинди уй-тойгылар асрап калуын белә алмады.

«Кая бара бу дөнья? — дип уйлый иде Габбас мулла. — Минем кызымны сорап килер йолкышмы бу? Кучер булып йөргәненә әле кайчан гына бит. Элекке заман булса, ил өстеннән җил-давыллар узмаган булса, минем Нуриямне сорап, бай балалары килерие. Килгәннәрие дә бит. Маһәренә йөге-йөге белән мал, алтын-көмеш вәгъдә итәрләрие. Мин әле ялындырырыем. Гарәп аргамагы, келәтлек бура, төлке толып сораган булырыем. Дөнья бетереп сатулашырыек, кул сугышып килешериек. Аннары кызның бирнәсен әзерләргә керешериек. Кубарые Зартугай, кубарые күрше-тирә авыллар, Габбас мулла кызын кияүгә бирә! Пар атлар белән кыр җыенына чыкканнар! Дугаларда көмеш кыңгырау! Кияү егете булып фәлән бай малае утырган, туйга фәлән пар кунак чакырганнар! Инде менә хәзер мин бердәнбер кызымны киребеткән Садыйкның иманы качкан бер малаена бирергә тиеш. Садыйклар нәселе белән нәселемне кушарга тиеш. Кая бара бу дөнья?»

## II

Университет тәрәзәләреннән Воскресенский урамы күренә. Каршы яктагы ике катлы йортның нәкышлы кәрнизләрендә кояш нуры уйный, шул нурлар Нуриягә рәхәт җылы булып тоелалар. Ул инде медицина факультеты студенты икәнен, аңар хәзер бик тә җитди булырга кирәген онытa; Солтан белән бергә Иш суы буйларында йөргән чакларын искә төшерә, язгы гөрләвекләр, яр читендә тирбәлгән саллар күз алдына килә, пароход артыннан ак болыттай өерелеп, чыелдап, акчарлаклар оча. Ул, истәлекләрен куып җибәрергә теләгәндәй, битен кулы белән сыпырып алып, күршесе Кәшифәгә карый. Кәшифә әле яратуга газапларын, ирле-хатынлы булып яшәү сөенечләрен үз башыннан кичермәгән, моңсу-уйчанлыкның ул ни икәнен дә белми, кулы белән иягенә таянып, кафедра ягына төбәлеп утыра. Кафедрада — Виннер. Политэкономиядән белем бирүче френчлы, обмоткалы шул солдат, әйтерсең, Кәшифәгә тиз көннән бәхет вәгъдә итеп, фал китабы ача. Виннер студент яшьләрнең колагына кермәгән өр-яңа сүзләр әйтә, ул сүзләр, кояшлы көз көнендә тугайларда очып йөргән тожымнар шикелле, бер

генә мәлгә хәтергә эленәләр дә булмаган да төсле тагын каядыр китеп югалалар. Нурия бәлки Виннерны тыңламас та иде, әмма солдат киемендәге бу кешенең аның үзен ике-өч ел моннан элек кенә рабфакта саклап калу фактлы аңа карата күңелдә ирексездән ихтирам уята, тыңламас җиреннән тыңларлык иттерә.

Залда — чуар халык. Кайсы тыңлый, кайсы тыңлаганга салышып утыра. Әнә иң алгы рәттәге Алько Дыхно — көнбагыш сабагыдай озын буйлы, сары чәчле студент — утыра торгач әллә арып, әллә шукланасы килеп, урындыгын терәкле ягы белән укытучыга таба борды да, атка атланган кебек, урындыгына атланып утырды. Нурия бик сәерсенде. Дыхноны профессор малае дигәннәр иде, профессор малае булгач, ул бит инде тәртипле, итәгатьле булырга тиеш иде. Күрче, ни кылана профессор улы!

Тукта, чү! Виннер сөйләүдән туктады, күзлеген борын өстеннән алып, кафедрага куйды, үтә дә сабыр, әмма эчтән тулышкан гаҗәеп бер киеренке кыяфәт белән Алько Дыхнога төбәлде. Лекторның кинәт туктап, тынып калуына гаҗәпсенгән студентлар, муеннарын сузып, Дыхно ягына таба карана башладылар.

Виннер кулын алга сузып:

— Иптәшләр, бер генә минутка тынлык. Аудиториядә башсыз җайдак пәйда булды. Сабыр гына көтик: башсыз җайдак атыннан төшсен, хәл алсын, иплән утырсын — аннары сүзебезне дәвам итәрбез — диде.

Зал тынды. Көтә башлады. «Җайдак» урыныннан кузгалырга уйламый да — урындыкка ничек атланып алган булса, шул хәлендә утыра бирә. Виннер да үзсүзле булып чыкты: лекциясен дәвам иттерми. Кем кемне җиңәрдән бик сабыр басып тора.

Студент халкы шаулый башлады: Дыхноны тәртипкә чакыралар. Исендә дә юк «җайдак»ның, авызны колакка кадәр җәйгән, рәхәтләнә елмаеп! Тавыш күбәя бара. Кинәт тавышлар эченнән Колчак Хәсән калыкты. Буй озын, җилкәдә — шинель. Кызылармеецларча тәгәл адымнар белән, чакылдатып басып, «җайдак» янына килде, иелеп колагына бер сүз әйтте — күз ачып йомганчы якасыннан йолкып алды, бик каты итеп бер селекте, аннары... тып-тын калган зал уртасыннан чаптырып алып китте, ишекне ачып, Дыхноның билдән түбәнрәк төшенә тезе белән җинелчә генә төртте дә шап итеп ишекне япты.

Колчак Хәсән «башсыз җайдакның» колагына ни әйткәндер, белүчемазар булмады, чөнки Хәсәннең мактану, эшләгән эшен сөйләп йөрү гадәте юк иде. Әмма шуннан соң урындыкка атланып утырып, көннең герое булып күренергә теләүчеләр бетте. Белемгә сусаган пролетар балалары галимнәр сүзен тын һәм тыныч аудиторияләрдә тыңлый башладылар.

Нурия белән Кәшифәнең ике-өч ай уку белән үк яраткан һәм яратмаган профессорлары барлыкка килде. Анатомия профессоры Верновский кара костюм, крахмалланган якалы ак күлмәк, кара штиблет кия, сөйләгән чакта Пушкиннан, Гогольдән учлап-учлап цитата сибә, аның лекцияләрен тыңлау үзе бер рәхәт. «Менә бит нинди кешеләр бар дөньяда,— дип уйлый Нурия.— Медицинаны да биш бармагы кебек белә, әдәбиятны да су кебек эчә. Мин дә шулай була алырмын микән?»

Профессорга төбәлеп, аның әйткән бер сүзен тыңлап, күңел салып утыра башлый Нурия. Тик аның уйлары тагын ишеткән сүзгә түгел, профессорның үз-үзен тотышына юнәләләр. Ул аның лекцияләргә бик пөхтә киенеп килүенә соклана, мөгаен, зыялылар нәселеннәндер дип уйлый, әнисенең әтисен гел мужик дип тиргәвен, дорфа кыланасың дип гел шелтәләп торуын искә төшерә, Нуриянең күңелендә зыялылык белән мужиклык төшенчәләре тартыша башлый. Кеше әдәпле, мәдәниятле, белемле булырга тиеш. Моны Чехов әйткән булса кирәк. Чехов Нуриянең уйларын төплерәк, ышанычлырак итә. Верновский, күрәсең,

зыялы кеше: лекцияләргә ашык-пошык кына килми, сакал-мыегы тәртипкә китерелгән, дулкын каккан кара чәчләре пөхтәләп таралган булыр. Аудиториягә кереп, кафедра янына баскач, ул баш кагып исәнләшә, дөньясын онытып лекция укый, аннары матур гына саубуллашып, студентларның бер генә минутын да урламыйча, төп-төгәл чыгып китә.

Нурия Солтанның әнә шулай матур киенеп, әнә шулай чиста-пөхтә булып йөрүен бик тели. Кечкенә кеше түгел бит аның Солтаны да! Җир төзүчеләр техникумын тәмамлаган белемле кеше. Әгәр ул да профессор Верновский кебек матур киенеп йөрсә, матур итеп исәнләшә белсә, матур итеп сөйләсә, аның да авызына карап торырлар иде. Нурия нинди егеткә кияүгә чыккан дип сокланырлар иде. Юк, Солтанның кызларны авызына каратып тотуы кирәкмәс. Анысы артыграк булыр. Бәладән башаяк дигәндәй, алла сакласын, берәрсе Солтанны үзенә каратып куйса. Хәзерге кызларга ышаныч юк, ирекле мәхәббәт дип авыз суларын корыталар.

Көнеләнә килгән әнә шул уйдан ул үзалдына елмая: Солтан йөрәгендә Нуриядән башка бер генә кешегә дә урын юк. Әгәр урын булса, Солтан әллә кемнәргә өйләнә алган булыр иде, әтисе белән дәгъвага керә-керә Нуриягә өйләнмәс иде...

Нурия бу минутларда көнеләндә Солтанга карата чиксез ярату һәм рәхмәт хисләренең тулышып торуын тоя. Үзләренең Гажур йортындагы бәләкәй генә бүлмәләрендә ирле-хатынлы булып тормыш башлап җибәрүләрен сөенеп уйлый. Туй дигән нәрсәне алар бик гади эшләделәр: Солтан ягыннан Имам Каһарманов, Нурия ягыннан Кәшифә килде. Каһарманов бик җитди итеп, йөзенә бер генә елмаю да чыгармыйча, аларны социализм җәмгыятендә яңа бер гаилә артуы белән котлады. Аягүрә басып калай кружкадан портвейн эчтеләр. Кәшифә исә бу көнне, юаш табигатенә хас булмаганча, күп сөйләде, күп көлде, аларның бәхетенә сокланып туя алмады. Әле Солтанны, әле Нурияне кочаклап: «Бәхетлеләрем минем», «пар күгәрченнәрем минем!» — дип ду килеп йөрде...

... Киләсе дәрес — Милославскийныкы. Гистология. Бу профессор тавышы белән дә, киеме белән дә алдыра алмый. Озын буйлы, чандыр. Менә ул, нәсел-нәсәпләреннән үк килгән дворянлык гадәте буенча, көмеш язулы кара таякны соклангыч матур селтәп, кешеләр игътибар итәр дәрәҗәдә туры, төз атлап, практик дәресләр үткәрә торган бүлмәгә килеп керде. Лекциясен башлап җибәрер алдыннан, студентлардан бик зур итәгатьлек белән рөхсәт сорап, папирос кабызды. Аннары лекциясе беткәнче тәмәке тартудан туктамады. Студентлар аңа «Төтәтүче эпителия» дип исем куштылар.

Нурия аның беренче лекциясен аңламаган кебек, бүгенге лекциясен дә аңламады; янында мыштым гына, аңлаган сыман кыланып утырган Кәшифәгә:

— Мин, малакаем, моның лекциясенә вакыт әрәм итеп килеп тә йөрмим, китаптан укып үзлегемнән әзерләнсәм, мең өлеш әйбәтрәк булыр, — диде.

Милославскийның студентлар, профессорлар арасында дан алуы — дворяннарча таяк атындырып, үрә катып йөрүендә генә түгел, лекцияләрен үзе кебек зур галимнәргә исәп тотып укуында гына да түгел, папирос тарткан саен бик зур паузалар ясап, бер-бер артлы биш-алты шырпы кабызуында да түгел. Аның биографиясендә бөтен университетка шаулаган бер вакыйга бар.

Гражданнар сугышы бетеп, совет оешмалары илдә ныклы тәртип урнаштырырга, гадәттән тыш комиссарлар гаять зур инану белән үз эшләрен башкара башлаган бер дәвердә дворян Лаврентьев, элекке ак офицер, эзәрлекләүләрдән куркып, профессор Милославскийга килде.

— Александр Николаевич, бәла! Язмышым кыл өстендә. Фамильный көмеш ияребезне, кылыч белән алтатарны, зинһар өчен, үзеңдә яшереп сакла, еллар иминләнгәч, килеп алырмын, — диде.

Дворян намусы — Милославскийлар өчен иң зур намус. Аңа тап төшергән кеше алар карашында затлы нәселдән булуын шундук югалта һәм аңа дөньяда яшәүнең бер генә дә кызыгы калмый. Милославский Лаврентьевтан фамильный көмеш иярне, кылыч белән алтатарны алып, медицина факультеты урнашкан бинаның чормасына яшерде. Гөнаһ шомлыгы, факультет бинасын каравыллап, кирәк чакта галимнәргә, тычкандыр, күседер, эт-мәчедер ише җәнлекләр әзерләп торган Максимка бу хәлне сизеп калган, икенче көнне үк тиешле урынына барып әйткән. Гистолог Милославскийны («Төтәтүче эпителияне») янтыкларына наган таккан ике яшь кеше төнлә килеп алып та китәләр. Трибунал. Хөкем карары кыска: контрреволюциянең мөлкәтен һәм коралын яшергәне, шуның белән илгә хыянәт иткәне өчен — атарга. Менә кайчан хурлык килә нәселгә, менә кайчан дворян намусы белән эшчекрестьян намусы кара-каршы килеп бәрелешә. Үлем җәзасын җиренә житкерер алдыннан гистологтан сорыйлар:

— Соңгы теләгегез нәрсә, профессор әфәнде?

— Үлемемнең Володяга билгеле булуын телим.

— Кем ул Володя?

— Владимир Ильич.

— Ильичны каян беләсез?

— Чит илдә бергә яшәдек, ул минем революционер булуымны түгел, галим булуымны теләде, синең юлың, Саша, фән юлы, диде. Әгәр ул минем үлememә риза булса, мин үкенми-нитми стенага барып сөялəм!

Ленин ул хакта ни әйткәндер, моны берәү дә белми, әмма профессор Милославский исән калган, дворян таягын атындырып Казан урамнарында йөри, иң зур галимнәргә генә аңлаешлы итеп лекцияләрен укый, Казан нейрогистологлар мәктәбен житәкләп алып бара, үз янына яңа яшь галимнәр туплый, галимлеге дә, биографиясендәге серле эпизод та аңар хөрмәт белән карарга мәжбүр итә иде.

...Көне буе желекләргә үткән суыктан Нурия, ниһаять, үзләренең Воскресенский урамындагы Гажур йортына, бишенче каттагы сигез метрлы бүлмәләренә кайткач кына котыла. Алар Солтан белән икәүләп мич ягалар, утын пүләннәренең мичтә чытырдап януын карап, берберсенә битләрен куеп янәшә утыралар.

Кызып житмәс борын чи усак пүләннәре ысылдап пар бөркиләр, кибеп житкәч, чатыр-чотыр яналар: ил өстеннән узган яулар, атышлар, Казан Кремле диварлары буенда һәлак булган комиссарлар турында сөйлиләр....

Нурия мичне томалап бәрәңге тәгәрәтә, сөт белән бәрәңге ашыйлар, чәй эчәләр, жылы өйдә сөякләр язылып китеп, бүген университетта һәм Кремльдә булган кызыклы хәлләр турында сөйләшәләр.

Шулай көн артыннан көн узып, университет аудиторияләрендә өшиөши укып йөреп, Кәшифә белән бергә беренче имтиханнарны тапшырдылар. Бу әле анатомиядән беренче бүлекләр генә иде: сөякләр, итләр, сеңгерләр бүлеге. Суык кыш узып, май кояшы жылыта башлагач, Нурия, бала анасы булырга жыенганын белеп, бик хәтәр куркуга төште. Икенче курсны башлаган чакта инде аның авыры зур булачак, мичкәдәй корсагың белән яшь егетләр, яшь кызлар алдында ничек күренмәк кирәк. Жәй буе врачларга консультациягә йөрде, аңа бик матур киңәшләр бирделәр. Бала анасы булу ул чиксез бәхет икән, бала багуның үз рәхәте, үз серләре бар икән. Моны аңа озаклап аңлатырга тырыштылар, ләкин булачак яшь ананың күңеленә, мин барыбер баладан үләм, дигән ямьсез бер уй кереп утырды. Башта ул уй аны куркытса да, киемгә иялəнгән кебек, Нурия ул уйга да ияләнде, тик

япь-яшь көе табутта ятачагын, иптәшләре аны кызганачагын күз алдына китереп, Солтан югында, рәхәтләнеп бер елады; аннары, күнеле бушангач, үләр алдыннан ике төрле җитди эш эшләүне кирәк тапты. Иң әүвәл деканнары профессор Воробьевтан бер ел укымый торырга административ ял алды. Калын гәүдәле, кара сакаллы профессор бәләкәй куллары белән корсагын яшерергә азапланып утырган Нуриягә, аның бөтен битен тутырып төшкән сары туткылга, калынаеп, күпереп киткән сабый иреннәренә бигүк төбәп карарга базмыйча, иплəп кенә:

— Студентка Уразаева, ирегез кем? — дип сорады.

— Солтан, — диде Нурия.

Профессор ирен кырые белән генә елмаеп:

— Ә фамилиясе? — диде.

— Айдаров.

— Кайда эшли?

— Кремльдә.

— Кем булып? — диде профессор, ниһаять, кирәкле сорауга барып җиткәч, иркенләп бер сулу алды.

Нурия башын кырынрак салып, балаларча бер караш белән, шуны да белмисезмени дигәндәй, карап торды да:

— Наркомземда... — диде.

— Алай икән, — диде Воробьев. — Наркомземда эшли икән. Кечкенәгез дә булырга тора икән...

Нурия аның, үз-үзе белән сөйләшкәндәй, шулай аның хакында озаклап тәфсилләвенә уңайсызлана калды: бит алмаларының ут янып тора башлавын тойды.

— Квартирагыз кайда соң? — диде Воробьев урыныннан торып.

— Гажурда.

— Алай икән, квартирыгыз Гажурда икән...

— Ә нигә?

— Бәләкәчне карарга кешегез булырмы соң?

— Кешебез юк.

— Алай икән, кешегез юк икән... Дәресләргә ничек йөрерсез икән соң, студентка Уразаева?

— Балалар бакчасына бирермен.

— Сезнең янда бакча бармыни?

— Бар.

— Яхшы, алайса, Уразаева, секретарьдан административ отпускы алуыгыз турында кәгазь тутыртыгыз, миңа китерерсез, кул куярмын...

Нәкъ бер елга ял алу аңа тынычлык китерде. Ул хәзер берәүгә дә күренеп йөрмәячәк, берәүне дә мәшәкатьләми генә үлә алачак.

Икенче җитди эше аның бала табу йортын сайлауга бәйле иде. Соңгы сулышында ул Солтанны күреп үләргә тиеш. Бер мәртәбә булса да! Солтан аңа авыр булган минутларда, дөнья белән саубуллашкан чакта, Кремльдән чабып чыгып, аның янына сәгате-минуты белән килеп җитәр. Шуңа күрә Нурия Кремль буе урамындагы беренче бала табу йортын сайлап алды...

Таң алды идеме икән, әллә төн урталары гына узып киткән идеме, ул бик хәтәр эче бора башлаганга уянды. Моның нигә икәнен шундук сизенеп, күрше хатыны Мәликә апаны уятты.

— Апам, минем вакытым җиткән, ахрысы, мине больницага илтешеп куй инде, яме... — диде.

— Ирең өйдә юкмыни? — диде Мәликә апа.

— Өйдә юк шул, командировкага киткән иде.

— Кая дисең? Анысы нинди җир тагын?

— Командировкага. Эгерҗегә... а-а-а, — диде Нурия, сыгылып төшкән хәлдә эчен тотып.

Мәликә апа, әлегә кадәр биргән сорауларының мәгънәсезлеген аңлап, ашыга-кабалана башлады:

— Белмичә дә торам, кара инде мин мәгънәсезне... беренче балаң бит әле... Хәзер, иркәм, хәзер, әзрәк кенә түз, матурым. Барырлыгың бармы? Булмаса Сәйфелмөлекне ат җигәргә җибәрәм...

— Ат... җигәргә?..— диде Нурия, тулгагы туктаган арада, сәерсенеп, күрше хатынына карады.

— Суң инде, нәрсәсе бар аның, Сәйфелмөлек абзаң олаучы бит. Кәнүшниеннән җигәр дә апкайтыр атын. Утырып кына барырсың... Беренче бала бик тә кыен анысы, бик тә кыен... Күлмәк-мазарың бармы чисталыкка? Әзерләп куйганыеңмы? Кайда дип соравым...

— Комодта, аскы тартмасында... — Нурия тагын сүзен әйтеп бетерә алмыйча сыгылып төште.

Мәликә апа, комодтан актарып, чиста күлмәк, яулык, җәймә алды, аларның барысын бергә төйнәде, Нурияне иплэп кенә киендерде дә, белгән догаларын авыз эченнән укып, бик озаклап аскы катка алып төште.

Таң әле беленә дә башламаган, күзгә салкынча урамда кеше-кара күренми, багана башындагы фонарьлар тонык сары нур сибеп сүлпән генә яналар, кайдандыр, Проломный урамы ягыннан, трамвай чылтырап узганы ишетелеп куя иде.

Урамнан бик әкрен генә бардылар. Нуриягә, Солтаны өйдә булмагач, кайсы больницага барса да барыбер иде, ләкин ул Кремль буендагы больницаны сайлаган иде шул инде.

Ике күчсез кеше, ике хатын-кыз төнге аулак урам буйлап шунда таба үрмәләделәр.

Алар алдыннан, озын булып, ике кара шәүлә сузылып барды.

Бала табу йортының алгы бүлмәсендә тонык кына, сизелер-сизелмәс кенә булып ут шәүләләнә. Ишеге эчтән бикле. Мәликә апа ишек кагарга тотынды. Төнге аулак урамга бу бик хәтәр яңгырап ишетелә иде.

— Әкренрәк, Мәликә апа. Куркып ачмый тормасыннар. — Нурия, әчен тотып, стенага сөялде.

Мәликә апа шактый үткен хатын булып чыкты.

— Таяк белән каксаң да таманга килер әле. Беләм мин аларны, булнискә беренче генә килүем түгел, аллага шөкер, җиде бала таптым...— дип, тагын да ныграк шакырга тотынды.

Эчке яктан шылтырап килә төшкән тавыш ишетелде, аннары олырак яшьтәге йокымсыраулы хатын-кыз тавышы:

— Әкренрәк кылансагыз булмыймәллә! — дип мыгырданып ишекне ачты.

Нурияне эчкәрге якка алып кереп киттеләр.

Шул сәгатьтән башлап, беренче баласын табачак яшь ананың күңеленнән мең төрле шөбһә, борчу, баласының исән-имин туууына булган өмет — барысы бергә буталды.

Иртәнге сәгать алтыдан кичке сәгать тугызга кадәр сузылган һәм акыл ирешә алмас озак, мәңгелек булып тоелган газаплы гомер узды: Кыз бала дөньяга аваз салды.

Нурияне бала имезергә өйрәттеләр.

Ул үләргә юраган язмышын оныткан. Дөньяга өр-яңа кеше китерүенә нишләргә белми сөенгән, шул ук вакытта ире Солтанның — кирәк бит!— хатыны бала табар чакта гына командировкага китеп баруына рәнҗеп, аермачык газаплар, билгесез өметләр эчендә яна, тетрәнеп, гасабиланып, иренең кайтып җиткәнен көтә; тора торгач, ул гомердә дә кайтмас, ул аның мең газаплар белән җир йөзенә нәни кеше китергәнен белмәстер кебек тоела башлый; бер сөенеп, бер көенеп, очрашу,

кавышу, кызын этисенә күрсәтү минутларын бетмәс-төкәнмәс зарыгулар белән көтә иде.

Беренче булып аның янына хәл белергә Кәшифә килде. Дусының базардан сатып алган алмасын, бер шешә кайнаткан сөтне һәм дәфтәр битенә язган хатын китереп тоттырдылар. Кәшифә аны баладан котылуы белән котлаган, кызыңа матур исемнәр сайлашырмын, тизрәк терел, Солтанга телеграмма суктым, дип язган иде.

Хатны укыганда Нурия хәлсезләнеп китте. Күзенә мөлдерәп яшь тулды. Ахирәт дусының килүе, ире Солтанның килмәве аның күңелендә давыл кузгатып алды.

Әгерҗедән кайтып житү өчен нибары ике-өч көн вакыт кирәк иде, югыйсә, Солтан өч көннән, биш көннән соң да күренмәде. Нурия баласы белән өйгә кайтып, бер көн торганнан соң гына кайтып житте.

Ишектән керүгә ул, чемоданын идәнгә ташлап, хатыны белән бәләкәченә ташланмакчы иде, Нурия аны бик тиз туктатты:

— Иплән, иплән! Балама суык тидерәсең. Юлдан кайткан көйгә кулларыңны юып килсәң дә бик таман булыр.

Солтан, өстенә салкын су сипкәндәй, кире чигенде, үпкәләмәкче булды, ләкин хатынының сулып калган ап-ак йөзен күрүдән, хәлсез тавышын ишетүдән туган тойгылары бергә буталып, ул тиз-тиз кулын юды, өстен алыштырды, тик шуннан соң гына, караваты янына барып, башта хатынын үпте, аннары:

— Я, кызымны да күрсәт инде,— диде.

Нурия биләүсәдә яткан баланың битенә каплаган җаймасен ачты, Солтан йодрык чаклы кып-кызыл бит күрде, сөенеченнән нишләргә белмичә:

— Гел дә мин булган! Борыннарына чаклы төймә борын, иреннәренә чаклы үземнеке!— дип, әллә ниткән зур әчке бер сөенеч белән кычкырып җибәрде.

— Шаулама, аю! Иплән кылансаң булмыймәллә? Кызымны курка торган итсәң...— дип сөйләнде Нурия.

Ул һаман да шул хәлсезрәк тавыш белән, чуар халатының чабуларын әйбәтләп ябып, әледән-әле кызчыгына күз төшереп, бала табу йортына Мәликә апа алып барганлыгын, кайтканда олаучы Сәйфелмөлек абзыйның сиртмәле арбага ястык салып алып кайтканлыгын сөйләде. Тавышы аның тигез, бәхете дә тигез, кызының этисе соң булса да кайтып җиткәнгә, йөрәк түрендәге рәнҗеш инде югалган, чыраена алсулык чыккан, күзләре дөньяга нурланып карыйлар иде. Әни кешегә бәхетле булу өчен күпме кирәк соң: баласының этисе янында булса, шул җитә!

Беренче атналарны ул Солтанын эштән көтеп ала алмыйча, сагышлы газап эчендә үткәзде. Төннәрен нәние елап уянса, гел дә менә дөнья беткән төсле булды, ими кабарга теләмәсә, авырып китмәдеме икән дип ут йотты. Күршеләре Камилә апа, үзенә хас дорфа бер изгелек белән аны ләгәндә бала коендырырга, тәнен авырттырмаслык итеп биләүсәләргә, бот аралары пешексә, пудыр сибәргә өйрәтте.

— Һаман саен кулда күтәреп йөртмәгез. Шуңа өйрәнер кызыгыз. Кем дип кушасыз атын?

— Эльмира,— диде Нурия.

— Әй, ходаем, табасыз инде тузга язмаганны! Сания дип кушсагыз, я Мәрьямбикә дисәгез, ичмасам, бер авыз тутырып әйтеп булырые, үскәченнән дә исемен әйтергә хурланып йөрмәсие. Табасыз! Сездә гене инде алтын бишектән төшкән бала...

Эльмирага дүрт айлар чамасы тулганда Кәшифәләр, Колчак Хәсәннәр икенче курс өчен имтихан тапшыра башладылар. Кәшифә ахирәте көн саен әле бер, әле икенче фәнен я дүртлегә, я өчлегә биргән булуын әйтергә керде. Нуриянең күңеленә шом төште. Тукта, бала

бишеге янында утырып калуы түгелме? Кәшифә ахирәте шулай мактаныш чыгып киткәннән соң баласын тирбәтә-тирбәтә, сүзсез генә, авыз эченнән моңаеп җырлый, аннары тынычлана, кызым, син язга дәү булырсың, без сине балалар бакчасына бирербез, синең әниең дә җиң сызганып укый башлар, аллаһы боерса, Кәшифәләрне, Хәсәннәрне куып та җитәр, узып та китәр, дип үз-үзен юата торган булды.

Балага җиде ай тулганда әтисе Солтанны тагын Әгерҗе төбәгенә, бу юлы инде атналап-айлап кына түгел, шунда ел буе торып эшләргә җибәрделәр. Ярый әле, ул киткән чагында Нурия, ире белән бергәләп, баланы үзләреннән ерак түгел, Черек күл бакчасы буендагы бер яслегә урнаштырып өлгергән иде. Анда эшләүче өлкән медсестра Полина баланы да, баланың әнисен дә бик үз итте. Солтан киткәннән соң Нурия, япа-ялгызы бер бүлмәдә яшәргә теләмичә, үзе янына медсестраны да чакырды.

— Полина, кил безгә, миңа булышырсың, бергә-бергә яшәрбез кыш чыкканчы,— диде.

Полинаның торыр урыны юк — ул бик ишле гаиләле бер туганнарында ишек төбендә диярлек кунып йөри иде, сөенеп риза булды.

Солтанга алар икәүләшеп: «Менә кызчыгың нинди матур үсә!» дип карточкасын җибәрделәр.

Солтаннан хат бик көттереп килде, ул анда авылларда өр-яңа тормыш башланачагын, кырларның корама юрганнан арыначагын язган, гаиләсенең ничек яшәвен хат ахырында гына сораган иде. Бу хәл Нурияне тагын бер мәртәбә рәнҗетеп, күңелсез уйларга батырды. Шулай да бу түзәрлек иде әле. Нуриянең йөрәген аеруча телеп алган хәл бераз соңгарак булды.

Эльмира, ун ай тулып, теле ачыла, «әннә», «мәммә» дигән сүзләрне әйтә белә башлаган чакта бик кинәт авырып китте.

Врачлар, диагноз куеп, балада менингит икәнен ачыкладылар. Үзе дә врач булырга әзерләнеп йөргән Нурия өчен бу башына күсәк белән сукканнан ким булмады. Бала я үләчәк, я гомерлек гарип булып калачак. Нурия йокыдан язды. Аның төннәр буе баласы янында утырып чыгуын, эчендә җәһәннәм утлары бар кебек кайнар сулыш алуын күрү Полинага да авыр иде. Көндезен Полина вакытын ясленә үткәреп, эштән чыгып арыса, төннәрен Нуриягә булышып, аны кызганып үткәрә иде, шунлыктан, күтәрәмгә калган ат кебек, аягын сөйрәп кенә йөри башлады, йокысы туймаганга күрә күзләре кызарып, күз төпләренә капчыклар асылынды.

Баланың авырып китүен әйтеп Солтанга ашыгыч хат яздылар. Бу юлы хат көттереп килмәде. Ләкин әти кеше тиз генә кайта алмавын әйткән, «тормыш булгач бала авырмый тормас инде»,— дигәнрәк юату сүзләре язып җибәргән иде.

Нуриянең иренә коточкыч хәтере калды. Ул аңар бүтән хат язып тормады, кызының көннән-көн сыза барган организмына әчке бер сызлану белән карап, сабыйның хәлен җиңеләйтергә теләп кенә яшәде. Көндезләрен ул лекциядә үткәргәнгә күрә, баланы иртән һәм кичен генә, больницага барып кына күрә ала, барган саен елап кайта, кичен Полина белән бергәләп елашалар иде.

Тагын бер айдан бала үлде. Телеграмма бирсәләр дә, Солтан кызын күмәргә кайтмады. Хәтта хәбәр дә язмады. Нурия, ирен күрәлмәс дәрәҗәдә рәнҗеп, ул мине яратмый, мулла кызына өйләнгәненә үкенә дип нәтиҗә ясады, тормышын Солтаннан аерым итеп, бергә бөтенләй дә яшәмәгән төсле итеп күрә башлады.

Тагын бер атнадан Солтаннан хат килде. Ул Нурия кайгысын уртаклашып: «Үзеңне бик бетермә, без әле яшь, тагын балабыз булыр»,— дип язган иде.

Бала табарга больницага илтеп куймавы, нәкъ шул көннәрдә Әгерҗегә чыгып киткән булуы, инде менә хәзер баласы үлеп киткәч тә кумәргә дә кайтмавы — бала хәсрәтеннән саргаеп калган яшь ананы өнсез итте. Ичмасам, юату сүзләре дә язмаган бит. «И кызым, безне ташлап киттеңмени?» дип тә көенмәгән, борчылмаган, бигрәкләр дә таш йөрәк, бигрәкләр дә каты бәгырь булыр икән. Әйткән иде аны әнисе, чыкма Садыйкныкыларга, аларда иман юк, олы абыйсы байларны кылыч белән турап йөрде, монысы да синең кадереңне белмәс дигән иде, тәки дөрескә чыкты.

Үләр чиккә җитеп рәнҗегән Нурия хатны вак кисәкләргә ертып ташлады, аның белән генә риза булмады — идәндә чүп булып аунап яткан хәлдә дә хат кисәкләре аның өчен агулы елан белән бер иде, барысын бергә җыеп, дөрләп янган утка атты.

Шуннан соң бушанып китте: бугазына килеп бөялгән ачы төен тарьлекле күз яшьләре булып мендәренә акты...

### III

Дөньяда вакыт дигән табип бар. Вакыт күз яшьләрен киптерә, әрнеп янган йөрәкләрне шифалы кулы белән сыйпый, төзәлмәс яраларны төзәтеп бирә.

Нурия иренә айлар-еллар буе үпкәләп, ачу саклап йөри алмады. Узган вакыт яраларны ялгады, үпкәләрне оныттырды. Ул иртән иртүк лекцияләргә йөгерә, лекциядән чыккач, базарга барып, бәрәңгедер, кәбестәдер ише нәрсәләр күтәреп кайта, ашарга әзерли, өйне ягып җылыта, аннары Полина белән бергәләп үзенә шарф бәйләргә, бияләй яки кофта бәйләргә утыра. Кечкенәдән кул эше тотып үскәнгә, ул бәйләүне карамыйча да эшли ала, шуңа күрә аның күзләре буш, күзләре патологик анатомия дәреслеге өстеннән йөгерәләр.

Бу — патологик анатомия дигәннәре гаҗәп бер фән булып чыкты бит әле. Аңар тотынганчы студентлар үзләрен чын-чынлап медик итеп, булачак врачлар итеп сизмиләр иде. Бу кафедрада төрле-төрле чирләрнең кеше организмында нинди гамәлләр кылып йөрүләрен, ягъни кеше тәнендәге тере күзәнәкләрне ничек итеп җимерүләрен микроскоптан карап беләсең икән. Нуриянең чахоткадан, үпкә яки бөйрәк шешүдән үлгән кешеләрне ишеткәне бар иде. Патологик анатомияне өйрәнгәнче ул чирләр һавада эленеп торган сүзләр генә иде әле. Инде менә кеше тәнендәге катлаулы үзгәрешләрне үз күзе белән күреп белә башлау сукыр кешенең күзе ачылудан бер дә ким булмады.

Нуриягә чын дуслар табарга кирәк иде. Аның белән бергә укый башлаган студент иптәшләре аңардан бер ел алга китеп барганнар, алар белән бер өстәл янында, бер аудиториядә бергә укып йөрмәгәч, аралары шактый ук ерагаеп китте, хәзер аңар иптәшкә керәшен кызы Шура Турчанинова, чуваш егете Тимоша Охливанкин һәм Колчак Хәсән торып калдылар. Болар барысы да беренче курстан күчә алмый калган авыл балалары, аларга русчаны такы-токы белүләре комачаулаган, авылда, ачлы-туклы яшәгән дәвердә алган белемнәре дә чамалы иде. Ләкин авыл баласының гаҗәеп бер хасияте бар — тырышлыгы. Эшнең асылына бер төшенеп алдымы — китә эшләр уңайга. Көннәрне атналар, атналарны айлар, айларны еллар алыштыра, тоташ агым булып барган тырышлык көннәрдән бер көнне авылның крестьян баласын кеше күзенә күренерлек итә. Башта аның тырышлыгын таныйлар, сәләтен танымыйлар; әмма тырышып тапкан белем үз артыннан яңадан-яңа мәгълүматлар ияртә торгач, бер дә бер көнне авыл баласының тирәндә йоклап яткан аңы, акылы, зиһене уяна — китә шуннан, мин сиңа әйтим, булдыклылык, сәләт сыйфатларын тану!

Керәшен кызы Шура белән дә, чуваш егете Охливанкин белән дә, Колчак Хәсән һәм мулла кызы Уразаева белән дә шулай булды. Патологик анатомиядән башка бер генә дә кызыклы фән юк дип исәпләгән профессор Загуляев башта Шураны күреп алды, аннары Нурияне үз итте, алар янына Хәсән белән Охливанкинны тартып китерде. Ул әле практик дәресләр беткәннән соң да бу студентларга озаклап микроскоптан күрсәтә, озаклап аңлата, Нурия хәтта дәрестән соң урам буйлап кайткан чагында да тирә-юнендә ни булганны маңгай күзе белән күрмичә, күңел күзе белән күреп, микроскоп аша карап кайта иде. Профессор Загуляев аңа дөньяда иң бәхетле кешедер, үзе теләгәннең барысына ирешкән зур галимдер кебек тоела, ул нинди юл белән, нинди алымнар белән шушы югарылыкка иреште икән дип фикер йөртә башлый.

Ул арада диагностика кафедрасында студентларны кешенең күзәнәкләре белән генә түгел, авыруларның үзләре белән дә таныштыра башладылар. Нурия Уразаева алдында аускультация һәм перкуссия дигән хикмәтле нәрсәләр ачылды. Гаҗәп сәер исемнәр белән йөртелә торган бу могҗизалар бактың исә татарча: бармак белән сугып тыңлау, колак куеп тыңлау дигән гади генә сүзләргә кайтып кала икән. Врач булырга, хәстәләрне терелтергә теләгән кешенең холкы әйбәт, күңеле киң, акыл-фигыле йомшак булырга тиеш икән. Шуның өстәвенә, әле врачка яхшы күрә ала торган үткен күз, яхшы ишетә ала торган колак, житез-өлгер кул кирәк икән. Болар Нуриягә тагын Солтанын искә төшерделәр. Ул әнә җир төзүче булып алды да Әгерҗе якларына китеп ничәмә-ничә ай кайтмый ята. Анда врач җаны юк шул инде, йөрәге дә врач йөрәге түгел аның, таш йөрәк! Кайтып кына керсен әле менә: ул аның йөрәген аускультация-перкуссия белән тыңлап карар, ул аңа җанында берничә ай буена җыелганның барысын чыгарып аударыр.

Ләкин Нуриянең ярсынып-ярсынып хыяллаганнары тормышка ашып җитми калды. Авыру әнисе янына Зартугайга кайткан Кәшифә туганүскән якларыннан кызыклы хәбәрләр алып килде.

— И-и малакаем, — диде ул, Нурия каршысына утырып. — Без синең белән Солтанны икәүләп эт итеп тиргибез, таш йөрәк тә таш бәгырь дибез. Бактың исә аның хәле синнән-миннән дә хөртирәк икән. Авылда җир бүлеп йөргән чакта крәстияннәр аңа сәнәк белән кадаганнар.

Нурия чырыйлап кычкырып җибәрде дә битен кулы белән каплады. Аңын җыйгач:

— Исәнме? Хәле ничек? — диде.

— Ике атна Әгерҗе больницасында ятып чыккан, Эльмира үлгән көннәрдә больницада булган икән, мескенем, синең хәлең авыраер дип кенә әйтмәгән.

— Мин аны барыбер гафу итмим. Больницадан чыккач та кайта алган булыр иде. Һич югы, юату сүзе яза алган булыр иде. Сезнең ул Солтаныгыз — таш йөрәк! Аклап маташма син аны, яме, — диде Нурия, үзенең бите буйлап кайнар яше ага иде.

— И Нуриякәем, син алай дисең дә бит, ул бит коммунист, кая кушсалар, шунда бара, синең белән безнең кук үз кайгысын гына кайгыртып йөри алмый. Беләсеңме, Зартугайда Имам абый Каһармановны күрдем, шул бик мактап торды иреңне...

— Нәрсә дип мактый?

— Син, Солтан, нишләп эшкә Нурия белән кайтмадың, нигә яшь хатыныңны япа-ялгыз калдырып аздырасың, дип сораган иам, ди, бер дә аптырамады Солтан, ди, ике сүз белән генә авызымны каплады да куйды, ди.

— Нәрсә дип әйткән булды икән чучка? — Нурия кызыксынудан һәм ярату хисләре кабынудан кинәт юашланып калды, бит алмаларына алсу тибеп чыкты.

— Мин әле аның хәзер минем иптәшем булып торуына шатмын, дигән Солтан. Врач булып чыккач, минем белән торырмы ул, профессорга кияүгә чыгармы, анысын күз күрер, аңар кайчан гына карасаң да, кеше күзе төшәрлек, бөтен өязгә бер ул, аннан да булдыклы, аннан да чибәр, аннан да моңлы баланы көндез чыра яндырып эзләсәң дә таба алмассың, дигән.

Тәмле телле Кәшифәнең аңа байтак кына сүзләрне юату өчен, үзе уйлап чыгарып әйткәнен белә иде Нурия, шулай да бу юлы ышанасы килде.

— Чынмы? Мине юатыр өчен генә әйтмисеңме?

— Билләһи әгәр, ипидер. Баскан урынымда чәчрәп үлим, бер генә сүзем ялган булса. Солтан бөтен авылны дер селкеткән. Теге заманда аклар үтергән Вәҗиләрнең, Шәрифҗаннарның туганнарын кайгыртып йөри, кулак куштаннарының койрыгына баса икән. Монысына да ышанмыйсыңмы?

Нурия ахирәте Кәшифәнең кечкенәдән дингә, хорафатларга ышанучан йомшак табигатьле, хәтта бераз куркаграк та кыз икәнен белгәнгә, бүтән ант иттереп тормады, аның сүзенә шундук ышанып, кулыннан тотты.

— Кайчаннар кайтыр икән? Уф! Уйласам, йөрәкләрем жу итеп китә, явыз адәмнәр аның башына җитмәсләр микән, Кәшифәкәем? Ярасы төзәлгәнме? Әллә үзем Әгерҗегә китеп барыйм микән?

— Сабыр итик, Нурия. Кайтыр, үзе дә жанын кая куярга белми торгандыр инде...

Самавыр кайнатып чәй эчтеләр, моңаешып, әкрен генә җыру җырладылар. Кәшифә, кайтырга җыенып, юка ак шәлен иңенә сала башлаган иде, ишек шакыган тавышка тукталып калды.

— Керегез! — диде Нурия.

Ишек төбендә кулына кара чемодан тоткан, күн курткалы Солтан пәйда булды.

— Әнекәй генәм! Бу нинди могҗиза?!

Бите җил-яңгырлардан яргаланган, ябыгып, суырылып калган, яңакларын каты төкле сары сакал баскан Солтан аларның икесен берьюлы кочаклады. Аңардан тәмәке исе, кыр-басулар исе, ир-атка хас тир исе килә иде.

Күрешүдән соң алар өчесе берьюлы тынып калдылар. Бигрәк тә Кәшифә уңайсызланды. Аңа хәзер үк чыгып китәргә, айлар буе аерым яшәгән, бер-берсен күреп туялмастай сагынган яшь гаиләне ялгыз гына калдырырга кирәк иде, ләкин ул үзе дә Солтанны сагынган, шуның белән бергә тагын ул Солтаннан башка аның газиз кызын күмешкән кеше, ул Нурияне Солтан янында япа-ялгыз калдырырга курка иде.

Шулай да ул, тойгыларын җиңеп, башына ак шәлен бөркәнде.

— Ярар, сабакташлар, мин... кузгалыйм әле...

Нурия белән Солтан, сүз куешкандай, икесе берьюлы, аның шәлен иңеннән тартып төшереп, урындыкка утырттылар.

— Син алай бик чәчрәмә әле, Кәшифә ахирәтем. Безнең әле Солтан алдында җавап бирәсе бар. Бергә яшәдек, Эльмираны бергә җирләдек, җавабын да икебез бергә бирербез, — диде Нурия.

Кәшифә аларда куна калды.

И яшьлек! Нинди саф син, нинди тилемсә син! Синең бар булган байлыгың, бар булган матурлыгың әнә шул сафлыгыңдадыр да инде! Күпме еллар үткәч, зиннәтле фатирларда яшәп дәрәҗәле кешеләр белән генә кунакларга йөрешә башлагач һәм көннәрдән бер көнне сине

дәрәҗәле дустың бик арзан хакка сатып җибәргәч, үзәкләрне өзеп, яшьлек, син искә төшәсең!

Утын белән генә ягып җылытылган, сигез генә метр зурлыктагы бәләкәй бер куышта сабакташ өч дус төн үткәрергә калдылар.

Таңга кадәр күзләренә йокы кермәде. Ниһаять, Кәшифә арып-алҗып, йокыга киткәч, Нурия Солтанга әйтте:

— Торыйк әле.

— Ник?

— Әйтер сүзем бар.

Тордылар. Нурия Солтанны өстәл янына алып килде. Күлмәген күтәреп, күкрәген карады. Солтанның күкрәге марля белән уралган иде.

Нурия куркып, агарынып китте.

— Үпкә тирәсенә тимәгәнме?

— Әзрәк бар, — диде Солтан, ыңгырашып җибәрмәс өчен тешен кысты.

Атналар, айлар буе нахакка рәнҗеп йөргән булуы Нуриянең күңелен яндырып алды.

## IV

... Башта Солтан төшендә әтисен күрде. Әтисе «әрме» атына атланып, межалар бүлеп йөри. Кулына ике җәплекәле аршын таягы тоткан Имам Каһарманов сөреп ташланган бик зур басу буйлап, йомшак туфракка тездән бата-бата, бик тиз атлый, Солтан аның артыннан өлгерә алмый, аның аягында киң кунычлы кызылармеец итеге, баскан саен итек кунычыннан йомшак җылы туфрак тула, Каһарманов инде әллә кайларга китеп барды — ул ялан аяк, аның итек кунычына балчык туласы юк. Кемнәрдер табут күтәреп баралар. Табутта Эльмира — Солтанның кызы — чырык-чырык көлә. Солтанга куркыныч, ул бит аны күрми калган иде, ничек терелгән соң ул кызыкай?.. Төрле яктан утлар яктыртып, баш түбәләренә шахтерлар лампасы төсле лампалар беркетеп куйган кызылармеецлар оркестр уйнап баралар, матәм маршы да түгел, дәртле марш та түгел, күңелне баса торган моңлы марш. Шлемнарында прожектор уты, шул уттан Солтанның күзләре камаша, берни күрмәс була һәм ул тирләп-пешеп уянып китә. Караса — күзенә тәрәзәдән төшкә кояш бәрә, ишекне каты гына дөбердәтәләр икән...

Чалбарын тартып киеп, майкадан гына килеш, ишекне барып ачты һәм бик күптән күрмәгән дусты Шөкер Лимашны күреп сөенеч белән кычкырып җибәрде:

— У-у, Шөкер дус! Ничә җәй, ничә кыш күрешмәдек! Әйдәле, уз әле, минем майкадан гына булуга исең китмәсен. Нинди җилләр ташлады сине безгә?

— Мин утырып тора алмам, Солтан дус, менә «Зәңгәр шәл»гә ике билет китердем. Нурия белән бүген барып карый алмассызмы?

Солтан Казанны, театрларны сагынган иде, Шөкер дустына ул рәхмәтен ничек итеп кенә әйтсә дә аз тоелды.

— Туктале, минем кайтканны каян белдең син? Театр сагынганны каян белдең? — диде ул, Шөкер Лимашның кара күмердәй көйрәп кабынырга торган күзләренә, шакмаклы аксыл кепкасына, бөрмәләп тектергән, чия төсендәге озын толстовкасына күз төшереп.

— Кайда идең соң син? — дип сорады Шөкер Лимаш үз нәүбәтендә.

Солтан, их син, шуны да белмисеңмени дигәндәй, Әгерҗе якларында крестьян ширкәтләре өчен җир бүлеп йөрүен, төрле гаугалы хәлләргә очравын сөйләп бирде.

— Син ашыкма әле, Шөкер дус, без хәзер чәй куеп эчәбез, шунда беррәттән дөнья хәлләрен дә сөйләшеп алырбыз, — диде.

Тиз генә юынды, өстен киенде, корымлана башлаган калай чәйнеккә су салып, керосинка өстенә куйды, бүлмәгә бик хәтәр керосин исе таралды.

Стенага кадаклаган ак буяулы бәләкәй шкафтан бер түтәрәм ипи, йодрык кадәрле бер шакмак шикәр, такта чәй калдыгы таптылар.

— Май-мазар юк икән, — диде Солтан аклангандай.

— Ярар, анысы кичен булыр, — диде Шөкер күзләрен уйнатып. — Бүген бит минем бенефис.

— Шулаймыни? Кемне уйныйсың?

— Ат карагын, — диде артист, аның кара күмердәй күзләре бу юлы көйрәп яна башлагандай булды.

— Мәйсәрәне кем уйный?

— Кушловская.

— Әйбәт уйныймы?

— Әйттең сүз: Кушловская да булсын, әйбәт тә уйнамасын!

— Салих аганың кәефе ничек? — дип, бик җитдиләнеп сорады Солтан.

— Салих аганың кәефе менә диган. Кәрим агайныкы анардан да шәп: «Сүнгән йолдызлар» триумфальный уңыш белән бара, «Җилкәнсезләр»гә халык котырып йөри. Безнең бәхетебез бит ул татар тамашачысы, гел дә менә аркасыннан сөеп торырга тиешле тамашачы! Их, менә шушы көннәрне Габдулла Кариев кайтып күрсен иде!

— Бәйрәм килде дисең, алайса, театрга? Бик шәп, Шөкер дус, бик шәп, театрыбызның, әдәбиятыбызның, музыка сәнгатенең чәчәк атар көннәре алда әле. Кстати, Һадиның хәлләре ничек, Казандамы ул, берәр яры китеп бармадымы? Я, тагын берне эч, көйсез кодагый кебек, көйләтеп утырма әле.

— Булды, Солтан дус, артист кешегә, үзең беләсең, фигураны бозарга ярамый, артист кешегә күбесенчә ач тору мәслихәт. Һади диденме әле? Һади өйдә торды бу арада, көн саен яшьләр алдына чыгып шигырь укыды. Энтузиазм ул мишәр егетендә: салам чәчне бер селкеп ала да китә, мин сиңа әйтим, шигырь сөйләп! Менә, ичмасам, сөйли, сөйләп тә карый соң! Сәхнә өчен яратылган бит ул Һади. Минемчә, ул бу араларда Донбасска җыена, татар шахтерлары янына. Кәрим абзый котыртты аны, пьеса язарга үгетләде, үзем куеп бирәм дип ышандырды.

Солтан әдәбият-сәнгать дөньясыннан соңгы ярты ел эчендә хәбәрдар түгел диярлек иде, күптәнге дусты Шөкер килеп, тау чаклы яңалык әйтеп киткәнгә ул тыны-көне бетеп сөенде, хәтта күкрәгенең чәнчешеп торуын да онытты. Нурия укудан кайтканчы Кремльгә барып, Җир эшләре халык комиссарына озак командировкадан кайтуы турында белдерде һәм «Зәңгәр шәл»гә бару өчен Нурияне көтә башлады.

Көтеп-көтеп тә кайтмагач, ул университет ягына үзе китте. Карасa — хатыны республика китапханәсеннән чыгып килә, янында — бер төркем егет. Солтан Нуриясенә читтән генә сокланып карап торды, бала тапкан яшь ана да димәссең, кызларга биргесез: әз генә кылтайтыбрак кигән берет-кепка астыннан ташып килеп чыккан ике толым кара чәч, билләрне өздереп, гәүдә ыспайлыгын ачып җибәргән нечкә билле зәңгәр пальто, баян төймәләре кебек тезелеп менгән элэктергечле озын кунычлы сары ботинка — юк, Нуриякәй җиргә түгел, егетләрнең йөрәгенә басып килә. Солтан бәхетсезлеккә очрап, больницага эләгүенә хәтта үкенеп куйды: мондый гүзәллеге белән Нуриякәй-Нөркәй бимазасыз гына ятты микән өйдә? Әрсез егетләр аның тәңкәсенә тимәделәр микән?

Шуларны уйлап бетерергә өлгермәде, яшьләр төркеме, кинәт кенә Воскресенский урамына таба борылып, Солтанга таба килә башлады. Солтанга бер кая да ышыкланып калыр урын юк иде, ул үзе аларга каршы китте.

— Падишаһым-Солтаным, иске чабата олтаным, мине каршы алырга чыктыңмыни?! — дип, Нурия барлык игътибарын иренә күчерде һәм шуның белән Солтан күңеленә җыела башлаган шик-шөбһәне бөтенләй алып ташлады.

Нурияның сабакташлары — Охливанкин, Колчак Хәсән, Шура Турчанинова — Солтан белән матур итеп кенә исәнләштеләр һәм, артык азапламыйча, юк-бар сораулар белән аның башын катырмыйча, әдәпле генә саубуллашып, үз юлларына китеп бардылар. Әлбәттә, Колчак Хәсән Солтан белән озаграк та сөйләшеп тора ала иде, ни дисәң дә рабфакның салкын баракларында алар икәү бергә туңып-өшеп яттылар, күрәсең, иптәшләреннән аерылып каласы килмәгәндер инде, бәлки күн тужурка, галифе чалбар, ыспай күн итек киеп алган землемер аңар инде чит-ят кеше булып та күренгәндер. Ни булса булды, алар китте, Солтан озын-озакка сузып тормастан: вакытның бик чикле икәнен, хәзер үк театрга барып җитәргә тиешлекләрен Нуриясенә белдерде, һәм алар театр ягына таба бик кызу китеп бардылар.

## V

... Залда ут сүнде. Караңгы зал бер генә мәлгә кыштырдап, пышылдап алгач, тынды. Партеры, балконы, бельэтажы шыплап тутырылган һәм инде менә тынып калган театрда моңлы бер көй агыла башлады. Шул моңга ияреп тамашачылар сәхнә ачылганын, саллы авыр пәрдәнең ике якка шуышып кереп җыелганын да сизми калдылар. Күз камашырдай якты, нурлы сәхнәдә Мәйсәрә җырлап килә иде. Җырга сусаган кешеләр, матурлыкка, иреккә сусаган кешеләр Мәйсәрә сылуга карап таң калдылар. Аннары Булат кайтты. Үзе белән авыл егетләрен, авыл кызларын ияртеп керде, шахтерлар санын меңәрләп кенә санаган чит-ят җирләр турында, тирән күмер базлары турында җыр җырлады, сөйгәненә күз явыңны алырлык зәңгәр шәл бүләк итте. Алардан соң Мәйсәрәнең явыз агасы Җиһанша сәхнәдә котырынып йөрде, Ишан хәзрәт: «Алла сакласын, алла сакласын, күкрәгеңә җен оялый күрмәсен!» — дип, Мәйсәрә тирәсендә бөтерелде. Булат белән Мәйсәрәне, аларның керсез хисләрен һәм шул хисләр алиһәсе булган зәңгәр шәлне хәтерендә саклап, халык тәнәфескә чыкты.

Театр фойесында халык бик чуар иде: чачаклы-чуклы итеп киенгән бистә мещаннары буфетка йөгерделәр; яңа экономик политика чорында кесәләрен калынайтырга өлгергән нэпманнар алдан ук өстәлләр әзерләтеп куйганнар икән, ашыкмый гына шунда барып утырдылар; фойеда зыялы театраллар белән анда-монда барырга мөмкинлекләре булмаган эшчеләр, совет учреждениесе хезмәткәрләре торып калды, дөресрәге, алар карусель кебек гел әйләнеп тордылар, бүгенге тамашадан алган хисләрен уртаклаштылар, театрга матур киләчәк юрадылар.

Солтан белән Нурия янынннан Кәрим Тинчурин узып китте. Ул кара костюмнан, галстуктан, штиблеттан иде, мәһабәт олы гәүдәсе белән сизелер-сизелмәс иелә төшеп, ягымлы елмаеп, ике яшь кешенең хөрмәт белән сәламләүләрен алып китте. Нурия белән Солтан шагыйрь Такташны күрмәбезме дип тә хыялланганнар иде, тик бүгенгә аны күрү бәхетенә ирешә алмадылар.

Спектакльнең икенче пәрдәсе, сәхнә ачылу белән үк, халыкны үз ихтыярына буйсындырды. Тормыштагыча чын, хәтта аннан да чынрак

итеп эшләнгән кара урман, җил исеп куйса, шаулый башлар кебек тоела; төрле яктан утлар белән яктыртылганга, күнелдә әллә ниткән зур уйлар кузгата, залда утыручыларның урман белән, елга-сулар белән, сахра-кырлар белән бәйле истәлекләрен берьюлы кабыза иде — күренешкә гөрләтеп кул чаптылар.

Аннары качкыннар җыры башланды. Татар музыкасы күгенә күтәрелеп килгән яңа йолдыз — Сәйдәшнең таланты залдагыларны әсир итте, үз аһәңенә, үз ритмына буйсындырды, һәркем үзе җырлардай булып, ярсынып-дәртләнеп утырды.

Инде шуннан да ныграк таң калдырып булмас, инде шуннан да күбрәк кабызып булмас кебек иде халыкны, әмма Шөкер Лимашның ат карагы халыкны тагын бер мәртәбә ярсытып алды.

— Их, егетләр, белмисез ат урлауның рәхәтен, ләззәтен белмисез, — дип, тырпайткан бармакларын алга сузып, күзләрен йома төшеп сүз башлады ат карагы Миңлегали, сүзен ул ничектер серле итеп, пышылдап диярлек сөйли иде: — Менә караңгы төн, ди. Ындыр аркылы корсак өстеннән килеп, сырт капканың алдына туктыйсың... Йортта эт өрә башлый, син тыныңны чыгармыйча, күләгә төсле тын торасың. Шул арада аргамак җанием абзарында пошкырып куя, йөрәкләр тиздән кавышуны сизгәнгә кытыкланып китә, сулышлар кысыла башлый. Капка астын казып, йортка керәсең дә, салават укып, агуланган икмәк, ит кисәкләрен эткә ташлыйсың. Бер ярты сәгатьтән аллага тапшырып эт тончыга. Аргамакның ишегендә чабата хәтле бикләнгән йозак була. Бисмилла әйтеп, отмычка белән келт итеп бер борасың да, йозак шалт итеп борынын күтәреп куя. Абзар ишеге ачылуга, кара бодай басуындагы төсле, хуш исләр аңкып китә. Аргамак җанием, кияз кызлар төсле, кызыл билле прәннек кимергән кебек, шыгыр-шыгыр печән кимереп ята, сылу кызлар көлгән төсле көязләнеп пошкырып куя. Барып ялыннан тотып сыйпагач, бәгърем килдеңме, дигәндәй, пуф итеп бер сулап ала. Шуннан иренен боргычлап, акрын гына сырт капкадан чыгарасың да, әгузе бисмилла әйтеп атланып, әйдә.... Тфф! — Ат карагы Миңлегали колакларны ярырлык итеп сызгырып җибәрде дә янында гына яткан бер качкынның сыртына менеп атланды.

Халык кинәт алга сөрлекте. Ат кугандай һай-һулап кычкырып җибәрде, ашкынып-шашынып кул чабарга, бис кычкырырга тотынды. Парчалы кәзәкин, укалы кәләпүш киеп алган нэпманнар залның төрле ягыннан сәхнәгә таба йөгереп, «Шәкә, маладис, Шәкә!» — дип кычкыра-кычкыра, сәхнәгә акча янчыклары ыргыта башладылар.

Шөкер Лимаш, кулыннан ычкынган камчысын ат өстеннән иелеп кенә алган төсле, акча янчыкларын берәм-берәм җыеп, куенына тыга барды — ул осталыкка да халык хуплап кул чаба иде.

Ишан хәзрәтнең йортын яндырып, «тукмачка куерган абыстайларны», ягъни мулланың дүрт хатынын берьюлы көлкегә калдырып, пәрдә ябылгач, артистларны, пьеса авторы Кәрим Тинчуринны, композитор Салих Сәйдәшевне, рәссамны һәм режиссерны сәхнәгә чакырып, аяк өсте торып тагын бик озак алкышлагач, халык, шау-гөр килеп, әле кайтып китәргә бер дә теләмичә, артистларны күреп туймаганлыкларын әйтеп, әкрен генә тарала башлады.

— Әйдә, Шөкер дусны котлап чыгыйк инде, — диде Солтан Нурияне кулыннан алып.

— Юк, әйем, мин анда керергә оялам,— диде Нурия.

— Театр караганда оялмадың бит,— диде Солтан хатынына.

Алар сәхнә артында бераз адашып йөргәннән соң, артистларның киенү-чишенү бүлмәләренә килеп чыктылар. Монда Нурия бөтенләй югалып калды: ул әле генә сәхнәдән сөеп караган Мәйсәрәләр, Булат-

лар, Миңлегалиләр, кайсы ярым шәрә, кайсы өстенә шыксыз кара халат киеп алган хәлдә, битләрендәге гримны мамык белән сөртеп маташалар иде.

Алар ашыга-ашыга кире чигенеп барганда, артистлардан усал телләре Нурия исеменә төртмә сүзләр дә әйтеп, моның белән аның сәхнә артына менәргә карышуының дөрес икәнен ышандырдылар.

Ни булса булды, алар Шөкер Лимашның киенеп чыкканын көтеп алдылар. Өстенә сары төстәге кыска каеры тун, башына бәрән бүрек киеп алган Шөкер Лимаш арыган-талчыккан чырай белән чыгып килә иде, боларны күргә кояш кебек балкып:

— Килдегезме, матурларым? Карый алдыгызмы?— диде.

— Карадык. Шөкер абый, күздән яшьләр атылып чыкканчы көлдек,— диде Нурия.— Сез бигрәкләр дә матур уйнадыгыз. Рәхмәт инде сезгә!

Батыр йөрәкле чая артист чибәр яшь хатынның мактавыннан югалып калды, бераздан соң гына хәл җыеп:

— Сезнең кебек гүзәл ханымнар әйткәченнән гел уйныйсы килеп китте бит әле. Үзегезгә рәхмәт,— диде.

— Ярый, Шөкер дус, без йөгердек,— диде Солтан, аның кулын кысарга үрелеп.

Артист Солтанның кулын тотып алды:

— Дусларым, безнең мәҗлес сыман бер нәрсә бар. Бенефистан соң без шулай җыелып, күңел бушатып алабыз. Мин сезнең дә мәҗлескә баруыгызны үтенер идем.

«Бу тагын нәрсә инде?» дигәндәй, Нурия томыраеп бер иренә карап алды. Солтан эшне озакка сузып, боламык измәс өчен:

— Була, Шөкер дус, син әйткәч, без җир читенә барырга да риза,— дип, тиешсезгә көлеп куйды.

— Хәзер, алайса, сез, дусларым, өстегезгә киенегез дә театр ишеге төбенә чыгыгыз, анда минем «Барабыз»ларым булыр, утыра торсагыз да ярый. Алдан ук кисәтеп куям, качып китәргә уйлый күрмәгез, гомерлек дошманым булырсыз,— диде.

Шул минуттан башлап Солтан белән Нурия артист дусларының кунакларына әйләнеп, ул ни кушса шуны гына үтәп тордылар.

Алар өсләрен киенеп, театр ишеге төбенә чыккан чакта анда егермедән артык олау — «Барабыз»лар килеп туктаган иде. Артистларның киенеп чыккан бере шул олауларга төялеп китә торды. Шөкер Лимаш дусларын үзе янына утыртты һәм кузгалырга торганда ишектән килеп чыккан Салих Сәйдәшевне үз янына чакырып алды.

Аягына кара ботинка, өстенә юка гына көзге пальто кигән Салих Сәйдәшев юка гәүдәле, үтә дә чибәр йөзле, кара кашлы бер кеше иде.

— Тукта, тукта, Шөкер әфәнде, син соң театрга яңа артистлар да табып алгансың түгелме?— диде ул, таныш түгел ике яшь кешегә баш иеп.

— Болар, Салих абый, серьезный кешеләр. Синең белән минем ише генә түгел, берсе булачак врач, икенчесе җир төзүче, Кремльдә эшли, так шту сүзеңне чамалап сөйләш,— диде Лимаш.

«Барабыз»лар бер-бер артлы тезелеп, Проломный урамындагы «Казанское подворье» ресторанына килеп туктадылар. Вакыт соң иде, стена сәгате төнге уникене узган, беренче ун минутны күрсәтә иде, Солтан белән Нурия, көтелмәгәндә артистлар арасына эләгүләреннән шаккатып, дулкынланып, үзләрен төш эчендә йөргән кебек сизеп, мәҗлес буласы залга керделәр.

Иңнәренә ак тастымал салган, кара түбәтәйле, кара мыеклы илле яшьләрендәге ике татар, Шөкер Лимаш ярдәмендә, кунакларны табынга утыртып чыктылар.

Иң түргә Лимашның үзен утырттылар, аның бер ягына Кәрим Тинчурин, бер ягына... Сәйдәшне чакырып караганнар иде дә, ул якын да килмәде; иренен бөрештерә төшеп, авыл кызлары кебек кызарынып:

— Бүген синең бәйрәм, үзең генә күкрәк киереп утыр әле яме,— диде.

Шуннан соң үзе янына Шөкер Лимаш, ай-вайларына карамастан, Солтан белән Нурияне утыртты. Моның белән артистлар шундук килештеләр, чөнки аларның кунаклары яшь һәм матур, уңайсызлану-оялудан икесе дә алсуга капканнар, күз явыңны алырлык чибәрләр иде.

— Әфәнделәр, рәхим итеп таныш булыгыз, болар минем сабакташ дусларым, бик серьезный кешеләр: берсе булачак медицина йолдызы, берсе җир эшләре профессоры,— дип, Шөкер Лимаш дусларын тагын бер мәртәбә оялтты.

Ләкин, бәхеткә каршы, шуның белән бетте: артистлар арыганнар, ачыкканнар иде, алар шундук ипигә, колбасага, сырга үрелделәр, өстәлләргә тезеп куйган арзанлы шәрабтан авыз иттеләр.

Телләр чишелде, күңелләр язылды, берәү дә артыгын таләп итмәде, мине күрмисез, дип үпкәләмәде, иң якын туганнардай чүкердәшеп утырдылар.

Гаҗәп сәер хәл: Солтан үзен бу атаклы кешеләр арасында чит итеп сизми, күптәнге якыннары итеп сизә, аның хәтта җыр да җырлыйсы килә иде. Ләкин моны ничек башларга һәм ничек белдерергә? Моның үзеңне күрсәтү түгел, ә бәлки шушында җыелганнарга чиксез ихтирамың икәнен ничек аңлатырга? Гомумән җырлау турында ничек сүз кузгатырга?

Утыра торгач, ул моның хәйләсен дә тапкандай булды. Әгәр Нурия рояль уйнаса? Әнә бит — почмакта шәмдәл утларын чагылдырып, капкара рояль тора. Нурия кебек чибәр яшь хатынның шул рояль уйнавы начар булырмыни? Ул, кыюланып китеп, шул хакта хатынына пышылдап кына әйткән иде, Нуриянең йөзе көл кебек агарды, ул хәтта: «Кит, кит, булмаганны!» — дип, кулларын ук буташтырырга керешге. Әнә шул кул бутау аны харап итте дә.

— Ни булды?— дип сорады Лимаш, аптырап.

— Юк, Нуриядән рояль уйнамыйсыңмы, дип сораган идем.

— Ә ул уйный беләме?

— Габәши абыйдан өйрәнде бит. Ике кыш.

— Нигә моңарчы дәшми утырасыз? Хәзер хәбәр итәбез аны!— Шөкер Лимаш аяк өсте басты, матур итеп елмайды.— Әфәнделәр, әгәр мин ялгышмасам, бәйрәмдә бенефис хуҗасының теләге үтәлә шикелле.

— Әлбәттә!

— Әйт сүзеңне!— дип, табын халкы Шөкер Лимашның сүзен көтәреп алды.

— Алайса, бик яхшы, минем теләгем шул: менә безнең арада яшь һәм чибәр ханым Нурия Уразаева, минем сабакташның хатыны, минем белүемчә, ике ел буе Солтан абыйдан музыка дәресләре алды. Сорыйк әле, рояль уйнап күрсәтсен әле.

— Сорыйбыз, сорыйбыз!— дип ду килде мәҗлес халкы.

Нурия уңайсызланып урыныннан торды, коточкыч үпкәләп Солтанга күз сирпеде, мәҗлес халкына карап, Сәйдәшевне, Тинчуринны күздән үткәреп, ут кебек кызарды, бит алмаларының көне буе мич каршысында торгандай кызыша баруын тойды, әмма мәҗлес теләген үтәми торып котыла алмаячагын аңлады.

Рояль янына китте, барышлый коточкыч дулкынланганын, йөзләгән күзнең аның аяк атлауларына кадәр карап-күзәтеп торуын аркасы белән сизде, ярый әле — аның бәхетенә — мәрхәмәт иясе Салих абыйсы ярдәмгә килеп җитте.

— Нинди көй уйныйбыз әле без, акыллым?— диде.

— Каршы килмәсәгез, сезнең «Качкыннар»ны уйнар идем.

— «Качкыннар»!— дип халыкка ягымлы итеп белдерде Салих абыйсы.

Шул чагында Нурия рояль яныннан торып:

— Алайса, Солтан җырласын, мин ул җырлаганда гына уйный алам,— диде.

Солтанның үзенә бу юлы ут кебек кызарырга туры килде, шулай да ул, артистларның бик теләп кул чабуларын күргәч, Нурия янына килеп басты.

Икесе дә бик дулкынланганга башта җыр белән моң бергә кушылып китә алмады, әмма бераздан алар тынычлана төштеләр: Нуриянең озын ак бармаклары рояль клавишалары өстендә бии, Солтанның баритон тавышы бик саф, бик чиста булып, патшаларны, законнарны, прокурорларны, урядникларны юкка чыгара иде. Артистлар җырның дәртле өлешенә кушылып, күмәк тавыш белән күтәреп алдылар. «Казанское подворье» залларында «Качкыннар» җыры язгы Идел кебек ярсып ага башлады.

Салих Сәйдәшев Солтанны кочаклап үпте, Нуриянең озын ак бармаклы матур кулын үз кулында тотып, гашыйк күзләре белән аңа карап торды. Үз җырларын аның профессиональ җырчы булмаган кешеләрдән беренче тапкыр ишетүе иде — бу аны, чын талант иясен, әйтеп бетергесез дулкынландырган иде. Мәҗлес беткәнче ул сөйләшмәде, гел моңсу гына елмаеп утырды.

Иртәнге сәгать бишләр тирәсендә «Барабыз»ларга чыгып утырдылар.

Шөкер Лимаш олаучыларның башлыгына бер генә сүз әйтте:

— Яңа бистәгә!

Егермедән артык олау, артистларны төяп, татар зиратына барып җиткәндә, көнчыгышы ягыннан таң беленә башлады, кар өсләре, зиратның борынгы карт имәннәре караеп күренде.

Каравылчы Мөхәммәтгарифка капканы ачтырып, зиратның эченә керделәр. Тавышланып сөйләшүче булмады.

Солтан, авылда өйрәнгән гадәт буенча, Нурияне зират эченә алып кермәде, килүчеләрнең максаты ни икәнен белмәү дә аның күңеленә бер шом салып тора иде.

Иң алдан Шөкер Лимаш бара, аңа ияреп Салих абыйсы белән Кәрим Тинчурин атлый иде.

Тегеләр туп-туры, эзләнеп-нитеп тормастан, Тукай кабере янына килделәр. Алар белән бергә, бераз читтәнрәк атлап килгән Солтан Шөкер Лимашның:

— Менә без килдек, Габдулла абый!— дип әкрен генә әйткәнен ишетте.

Аннары алар Фатих Әмирхан, Габдулла Кариев каберләрен йөреп чыктылар, анда сүз-мазар әйтүче булмады, тын гына басып тордылар.

Килүчеләрнең барчасы, төркем-төркем булып, зиратны йөреп чыккапознан соң, Шөкер Лимаш мәҗлескә түләүдән калган барлык акчасын олаучыларның башлыгы Хәтмулла картка биреп, рәхмәт әйтте.

Өйләренә җәяүләп таралдылар.

...Нурия, Солтанның кулын тоткан көе, тын гына атлый. Шәһәр өстенә сирпелә башлаган таң нурлары аның җанындагы моңсулыкны көчәйтәләр. Шундый олы кешеләр — артистлар, композиторлар алдында рояль уйнарга батырчылык итүенә ул торып-торып уңайсызлана, зал уртасыннан япа-ялгызы рояль янына баруын, үткен һәм сынаучан күз карашларының аңа төбәлүен күз алдына китергәч, тәннәре чымырдап китә. Тик Салих абыйның: «Без нәрсә уйныйбыз әле, акыллым?»— дип үтә дә якын итеп, үз итеп, үзәкләрне өзеп әйткән сүзе аңа тыныч-

лык китерә, ул аңа шул минутта нинди рәхмәтле иде һәм... гашыйк иде... юк-юк, моны хәтта күңелдән генә дә уйларга ярамый...

Солтан да сүзсез кайта. Җаны тулы уй. Аның уйлары җай гына акмый. Өермәләнә, бөтерелә, чонгыллар ясый. «Без иске культураны себереп түгәчәкбез!» дигән кешеләр белән бәхәскә керә. Тукай искә төшә: безнең халык та үз Толстойлары, үз рәссамнары, үз музыкантлары булуга мохтаҗ! Карасана бүгенге көн — спектакль дә, мәҗлес тә — тарих булып калачак бүгенге көн бөек түгелмени? Килер заман, татарның кеме бар дип сорасалар, Тукае бар, Сәйдәше бар! дип әйтергә мөмкин булыр.

Таң нурларыннан балкыган Казан бу минутларда Солтанның күңел күгеН ачып, киңәйтеп җибәргәндәй булды. Шәяхмәт абыйсының, корал коючы Мөхәммәтша абыйсының һәм үзенең яңа дөнья өчен көрәшүе бушка китмәгәнлеген аңлады. Тән иреге өчен генә түгел, акыл һәм җан иреге өчен дә, мәдәниятләр иреге өчен дә сугыштылар бит алар.

Моны аңлау Солтанны чиксез бәхетле итә иде.

## VI

Әгерҗе. Больница. Больницаның аргы башына урнашкан кечерәк кенә бер бүлмә. Кырык биш яшьләрендәге врач хатын, борынын кысып торган алтын кысалы пенснесын төзәтеп, нурлы яшькелт күзләрен тәрәзә артындагы такта каралтыларга төбәп:

— Менә, күгәрченкәйләрем, сезгә шушында яшәргә туры килер, — диде. — Хәзергә әйбәтләп урнашыгыз, Әгерҗе белән танышыгыз, тимер юлны карап килегез, сез эшлисе больница — тимер юлчыларныкы, шуңа күрә барысын да алдан ук белеп тотыну хәерлерәк булыр...

Тавышы аның калайны калайга ышкыган кебек чыкырдап тешкә тия, ягымлы чибәр йөзенә берничек тә туры килми иде.

Чая холыклы Шура алгарак чыкты:

— Гафу итегез, без сезгә ничек дип дәшик?

— Сез миңа Ольга Васильевна дип дәшәрсез. Фамилиям — Пономарева. Әгерҗедә бер ел эшлим, Мәскәүдән килдем. Шулар сезне канәгатьләндерәме?

— Бик тә канәгатьләндерә, — диде Шура белдекләнеп.

Ольга Васильевна өстенә ап-ак халат кигән иде, сылулыгын югалтмаган төз гәүдәсен чайкалдыра төшеп, биек үкчәле туфлие белән идәнгә шык-шык басып китеп барды.

Шура белән Нурия, ул киткәч, һичбер сәбәпсезгә көлешеп алдылар. Яңа урынга килеп төшүләренә, икесенә бер бүлмә эләгүенә, өстәвенә, ул бүлмәнең больница бинасында ук булуына кәефләре килде, ахрысы.

Стенаның ике ягына куелган тимер караватларга үзләре белән алып килгән җәймәләрен яптылар, сөлгеләрен кәрзиннәреннән алып, чөйгә элделәр дә сүзсез калдылар. Иртәгесен алар авырулар белән очрашырга, мөстәкыйль эш башларга тиешләр, шуңа күрә хәзер врачлык практикасын уйлап каушабрак утыралар.

Яман ачы сызгыртып һәм больница тәрәзәләрен дырылдатып, товар поезды узып китте.

— Менә, Уразаева, без врач булдык. Иртәгә операциягә авыру китерсәләр, нишлибез инде? — диде Шура.

Ләкин авыруны иртәгәсен түгел, шул көнне кич ук китерделәр. Авыру — аңын җуйган тимер юл эшчесе иде. Кара бушлаттан, тезенә ямау салган кара чалбардан килеш, ул топчанда чалкан ята, тырпайган үрдәк борыны, уч төбе хәтле киң мыегы күзгә чекерәеп ташлана иде. Больницаның ир врачы Борис Львович Осповат тимер юлчыга мамык белән нидер иснәтә иде. Осповат Ольга Васильевнаның ире икән.

Мәскәү тормышыннан туеп, җанлы эшкә, халык арасына килгән. Юкса, илдә рядовой врачлар җитмәгәндә профессор чаклы профессор Әгерҗегә тәтер идемени?! Осповат баш түбәсендә бер бөртек чәче дә калмаган, ике якка асылынып төшкән зур җирән мыеклы, җете зәңгәр күзле кеше. Аңа, хатыны белән бергәләп, көненә бишәр операция ясарга туры килә икән. Алар үз эшләрен шул тикле дә намус белән үтәргә өйрәнгәннәр, каты авыруларны җиде төн урталарында да кереп карыйлар икән.

Борис Львович авыруны бил тиңентен чишендереп, бармак чиртеп һәм колак куеп тыңлаганнан соң, Нурия белән Шураны да чакыртып китерде.

— Тыңлап карагыз әле, кызлар.

Тыңладылар.

— Нинди диагноз куябыз?

— Үпкәсендә ялкынсыну булырга тиеш, — диде Шура.

Нурия тиз генә әйтмәде, уйга калды.

— Ә сезнеңчә, чибәркәй?

— Минемчә дә шулай.

— Сәбәбе?

— Үпкәсенә салкын тигән.

Авыру саташа иде. Койкасыннан ыргытыла башлагач, аны бәйләп куярга кирәклеген аңлатты Осповат. Нурия белән Шура беренче тапкыр тере кешене койкасына бәйләргә дип, озын сөлге тотып, авыру янына килделәр.

Дудин аларны якын җибәрмәде, кулына орынуга:

— Уйди, собачья морда, пусть ко мне подходит моя хохлушка! — дип кычкыра башлады.

Авыруның хәлен җиңеләйтү өчен, бер төн эчендә дүрт мәртәбә укол кададылар. Шура белән Нурия, алар белән бергә ирле-хатынлы Осповатлар авыруны каравыллап чыктылар.

Иртән сәгать алтыда Дудин үлде.

Нуриянең җаны тетрәнде. Керфек какмый, исәр кеше сыман, ул мәетнең очлайган иягенә, кан качкан битенә карап торды. Үксеп елыйсы килә, әмма тамакка менеп утырган каты бер төен еларга ирек бирми иде.

Көн яктыргач, тимер юлчының хатыны килде. Башында — зур шакмаклы шәл, аягында киез итек. Приемный бүлмәсенә керде дә ишек төбендә туктап калды. Нуриянең йөрәге өзелеп төшкәндәй булды. «Ничек әйтә инде моңа Борис Львович иренең үлгәнен?» — дип уйлады, хатынның чыраен күрмәс өчен тәрәзәгә таба борылды. Ләкин алай тору да мөмкин түгел иде.

Менә Борис Львович, ак халаттан, чаплашкадан, йомшак кына басып, хатын янына килде, аның йөзенә туры карап:

— Ирегез үлде... Аны коткару мөмкин түгел иде, — дип иренен кысты.

Нурия тимер юлчы хатынының:

— Доктор! — дип җан ачысы белән әйткән сүзен ишетте, сын кебек катып калуын күрде. Менә аның бер ноктага төбәлгән нурсыз күзләренә мөлдерәп яшь тула башлады, ул бите буйлап аккан яшен бирчәйгән кара бармаклары белән яңагына сылый-сылый:

— Алы-ыыс! — дип кычкырып җибәрде, такмаклап елый башлады: — Кемнәргә калдырып киттең син безне? Биш бала белән мин кайларга барыйм инде? Туендыручым, йорт башым, а-а-а!! Иа ходай, ник күпсендең син аны бездән, ник алып киттең аны кара гүргә? Минем балаларымның әтисе кем булыр? Кем аларны еласа юатыр, кем аларга үгет-нәсихәт бирер? Кая куйыйм бу башларымны? Поезд астына ташланыйммы, суларга төшимме? А-а-а...

Нурия анар стакан белән су китереп бирде, такмаклап елаган чакта хатын башыннан шәлен тартып төшергән иде, аны бөркәтте:

— Тынычланыгыз, зинһар тынычланыгыз, хәзер инде елап кына ирегезне кире кайтарып булмый бит,— дип юатырга тырышып карады.

Хатын аның саен ярсый, аның саен илерә, үрсәләнә иде.

Дудинны больницадан алып китеп, Әгерженең аргы зиратына илтеп күмгәннән соң да Нурия тиз генә тынычлана алмады. Ашаудан, йокыдан калды. Аның уенча, биш баласы булган кешене врачлар ничек тә коткарып калырга тиешләр иде. Беренче мәртәбә аның күңелендә медицинага, врачларга карата, ышанмау белән бергә, күңел рәнжеше туды. Шура Турчанинова бу үлемне ансат кичерде:

— Кодайның тәктире шулайдыр,— дип юатты ул Нурияне.

Нурия бу сүзләргә янә бер мәртәбә рәнжеп һәм аптырап сабакташы белән көне буе сөйләшмәде, врач Осповатлар янына да кермәде. Шура, киресенчә, ул көнне больницада, Осповатлар квартирында йөреп үткәрде. Кичен үзен караңгы, боек чырай белән каршы алган Нуриягә:

— Ай-гай, аңсыз кеше син, Уразаева, Дудинны мин агу эчертеп үтермәгән бит, нәрсә син миңа авыз-борын төяп йөрисең? — диде.

— Ә нигә үлде соң ул? Бәлки аның диагнозы дөрес куелмагандыр? Бәлки без ялгышканбыздыр? — диде Нурия, ни эшләргә белмичә.

— Дөрес куелган. Борис Львович авыру тарихына «осложнение-менингит» дип язды. «Бик хафаланмаска тырышыгыз, балакайлар, без гаепле түгел. Дудин эчәргә яраткан, салкын аракы эчеп, үпкәсенә суык тидергән, гаиләсе аны безгә бик соң китерде. Аны дөньяның иң бөек могҗиза ияләре дә коткарып кала алмаячак иде», дип әйтте. Ул безне үзенә чакырды. «Иптәш кызыңа әйт, кич икәүләп безгә кереп утырыгыз», — ди. Барабызмы, Нуриякәем?

Алар икәүләп врачлар өенә бардылар. Борис Львович сөйләргә ярата торган кеше икән, ул гражданнар сугышы вакытында хәрби госпитальләрдә булуын, кызыл сугышчыларны коткарган чакта медикаментлар җитмәвен, ике бүлмәле казна квартирларының түр ягында ишекле-түрле йөреп, вакыт-вакыт теше сызлагандай, йөзен җыерып сөйләде. Аның сакалы юк, ике якка асылынган зур җирән мыегы кечке саргылт лампа утында ялкын теле төсле тоела иде. Ольга Васильевна ул сөйләгән чакта аш бүлмәсендә кайнашты, ире сөйләп бетергәч, кызларны эремчек ватрушкасы белән сыйлады.

Практикант кызлар врачлар өендә икенче көнне дә, өченче көнне дә булдылар. Борис Львович операция вакытында нинди кызыклы һәм авыр хәлләр булуын сөйләде. Нурия белән Шура аның сөйләгәннәрен авызларын ачып тыңладылар, моның белән ирле-хатынлы ике врачның үзләрен операциягә әзерләгәнлекләрен башларына да китермәделәр.

Ниһаять, ун көн чамасы узгач, аларны операциягә чакырдылар. Башта алар моны белеп бетермәделәр. Гадәттәгечә, Борис Львовичның кызыклы хәлләр сөйләвен тыңларга дип килгәннәр иде.

— Бүген, күгәрченнәрем, кич утырырга вакыт юк. Операциягә җыеныгыз,— диде Ольга Васильевна.

«Җыеныгыз» дигәне башта мунча керү, бер мәртәбә дә кимәгән яңа эчке күлмәк кию, кулларны бик һәйбәтләп спирт белән юу, ак халат кию, авызны марля белән бәйләп кую икән. Ольга Васильевна боларның барысын аерым бүлмәдә үзе эшләп күрсәтте, үзе белән бергә кызларның да шуны ук эшләп баруларын таләп итте. Шура шундук чишенеп ташлады. Нурия, олы яшьтәге Ольга Васильевнага тәнен күрсәтүдән оялып, бер почмакка барып сыенды.

Ольга Васильевна аны көч-хәл белән генә үгетләп чишендерә алды.

Операцияне утыз яшьләрдәге ир кешегә ясадылар. Аны башта чалбарына чаклы калдырып чишендерделәр, беләгенә наркоз уколы кадап

йоклаттылар, кулын бәйләделәр, авыз-борынына ясалма сулату өчен кислород аппараты куйдылар. Бу эшләрне Нурияләрнең күргәзмә дәресләрдә кабатлап караганнары бар, әмма тере кеше белән эшләгәннәре юк иде әле.

Кислород аппараты белән эш итүне Борис Львович хатыны Ольга Васильевнага тапшырды, Нурия белән Шура кайнар судан алган инструментларны операция ясаучы Осповатка биреп торырга тиешләр иде. Гадәттә мондый эшне бер генә ассистент башкарганга күрә, кызлар бүген инструмент бирергә ике кеше куелуын, шуның өстәвенә, больницаның үз хезмәткәре дә булуын күреп, бераз аптырабрак калдылар. Әмма врачларның бу эшне уйлап эшләгән булуын шундук төшенделәр. Борис Львович кулына юка резин перчатка кигән, күзен генә калдырып, борыны белән авызын марля белән каплаган, башына ап-ак калфак, өстенә, арттан китереп бәйләп, ак халат кигән иде. Аның тәненнән дә, сулышыннан да авыруның ярасына инфекция-мазар керерлек калмаган иде.

Нурия авыруга якын ук тора, Шура арырак, ул эмаль таздан алган пинцетны, скальпельне турыдан-туры Борис Львович кулына тапшырырга тиеш иде.

Менә Борис Львович йодка манган мамык белән авыруның тигез генә сулыш алган корсагы өстенә күкрәк чокыры тирәсеннән башлап кендек аркылы сыек деготь белән майлаган төсле бер сызык үткәрде, кендек турысын да кат-кат майлап, таяк башындагы мамык белән түгәрәк ясап торды, аннары аска — туры сызыкка аркылы китереп, тагын бер сызык сызды. Нуриягә таба ым какты, тегесе аңар скальпельне сузды; хирург пычакны кара сызык өстеннән бик тырышып үткәрде. «Бу мал суя торган пычактан үтмәсрәк була икән», — дип уйлап өлгерде Нурия, нигә алай булуын уйлап торырга вакыты юк иде, Борис Львович аскы сызыкны да скальпель белән сызып бетереп, пинцет сорап алды. Пинцет белән яраны ачты, тире астында ап-ак май катламы күреп, Нурия йөзен чытты, чирканып куйды; Борис Львович мамык сорап алды, яраны ачкан чакта бөрчек-бөрчек тибеп чыккан канны мамык белән сөртеп табакка ташлады. Тиредәге кан юлларын кыстыргыч белән тиз-тиз беркетә башлады. Нурия бүлмәдә һава җитмәвен, башы әйләнә башлавын тойды. Кан исе аңа бик начар тәэсир итә, сулышы кысыла, ул укшып җибәрергә әзер иде. Борис Львович, хатыны ягына карап, нидер ымлады, Ольга Васильевна, тиз генә килеп, Нурияне култыклап алды.

— Чыгыйк әле без, кадерлем, — диде.

Коридорга чыккач, ул аны ачык форточка янына китерде.

— Суз башыңны, — диде.

Нурия сузды.

— Күп итеп һава сула. Курыкма, курыкма, уза ул, без ул хәлләрне барыбыз да баштан кичергән. Менә шулай. Җиңелрәкме? Хәлең рәтләнгәч тә керерсең.

Ольга Васильевна, тиз-тиз атлап, операция бүлмәсенә кереп китте. Нурия үзенең көчсезлегеннән, Мәскәү чаклы Мәскәүдән килгән атаклы врачларны кыен хәлдә калдыруыннан газапланып, ачык форточка янында басып торды. Бәлки мин врачлыкка ялгыш кергәнмендер, мин ул эшкә бөтенләй дә ярамый торганмындыр дигән уй күңелен яндырып узды. Чиксез үкенү хисе туды. Ләкин ул озакка бармады, һаваны күбрәк сулаган саен, аның кәефе рәтләнә барды, төшенке уйлары күңеленнән чыгып киттеләр. Һәм ул, батыраеп, тагын операция бүлмәсенә барып керде.

Шура, исе дә китмичә, Борис Львовичка инструментлар биреп тора, ул моны бик җитез һәм бик игътибарлы үти. Борис Львович канәгать

булса кирәк, бер генә замечание дә ясамый, ым кагып ни кирәк икәнен генә әйтә иде.

Нуриянең кергәнен беренче булып Ольга Васильевна күрде, практикантның янына килеп, кайнап торган суда пешекләнгәннән суынган инструментлар ята торган таз янына китерде.

— Шурага биреп торырсың, — диде.

Нурия, тагын күңеле болгана башлаудан куркып, операция өстәленә карамый, Шураның ак халатлы аркасына гына карап тора, ул борылу белән кирәк әйберне шундук китереп бирә иде. Шулай ярты сәгатьтән артыграк эшләгәч, ул барыбер борылып карамый булдыра алмады. Карады, күңеле болганмады, ул инде кан исенә иялəшә төшкән иде булса кирәк. Ул операция өстәлендә яткан кешенең эчәкләре тышкы якка чыгарып куелганын күрде. Борис Львовичның үтә күренмәле сары перчатка кигән куллары, җитез бармаклары авыруның кайдадыр яшеренеп яткан нәрсәсен эзли иде.

Нурия күңеленнән барлап карады: әнә шундый җитезлеккә, армыйталмый эшләргә аның көче җитәрме? Монда бит сүтелгән машина түгел, сүтелгән кеше ята; ул үзе аңында түгел, торып торсын әле, иртәгә килеп төзәтеп бетерермен дип икенче көнгә калдыра алмыйсың. Авыру йоклаган, ник сез мине ботарлыйсыз дип әйтергә аның көче юк, зиһене юк, аның язмышы бөтенләе белән врачлар кулында, врачлар намусында.

Нурия уйларын уйлый торды, хирург Осповат үз эшен эшли торды. Ул эшли-эшли тирләп тә китә бугай. Ольга Васильевна марля салфеткалар белән ара-тирә аның маңгаен сөртеп ала иде.

Нурия операция беткәннән соң авыруның ярты ашказанын кисеп алганнарын, түбәнрәк җиреннән тагын җәрәхәт ясап, сукыр эчәгесеннән суалчан сыман үсентесен дә алып ташлаганнарын белде.

Авыруны арба белән аерым бүлмәгә кертеп салгач, Борис Львович, шәфкать туташы Никитичнаны чакырып, авыруның җәрәхәтләренә салкын куярга кушты, ә үзе врачлар кабинетында операциянең нәтиҗәсен язарга утырды.

Егерме минутлар чамасы узгач, ул Нуриягә авыру палатасына барып килергә кушты.

— Әгәр авыру аңына килсә, ул ыңгыраша башлар, аның шул вакытын сагалабрак тор, яме, практикантка Уразаева, — диде.

Нурия бүлмәгә керде. Авыру ыңгырашмый. Нурия борчыла башлады. Менә доктор үзе килеп керде, чиста ак җәймәне ачып җибәрсә, артына егылып китә язды: җәрәхәтләргә салкын куясы урында Никитична грелка китереп куйган!

Борис Львовичның төсе качты. Грелканы күтәреп идәнгә бәрде дә, ашыгып-кабаланып, кабинетына барып керде. Нишләргә кирәген белә алмыйча, Нурия Уразаева да аның артыннан иярде.

— Ольга, үтенеп сорыйм синнән, Никитичнаны ныгытып бер орыш әле. Ул нәрсә, акылыннан язганмы әллә, җәрәхәткә салкын куясы урынга грелка китереп куйган. Ачуыңнан шартларсың, билләһи! Ярый әле, үзем кереп җиттем, авыруны һәлак итәргә мөмкин бит алай... — Доктор, читлеккә ябылган арысландай ярсып, ишекле-түрле йөренә башлады.

Ольга Васильевна аны бик зур ихтыяр көче белән, сабыр гына тыңлап торды да:

— Тынычланыгыз, Борис Львович, — диде. — Бәхетебез, әле сез күреп өлгергәнсез. Бу сестрабызның яше олыгая барган саен акылы зәгыйфьләнә дип әйтиммe? Борчылмагыз, мин аны бик каты ачуланырмын.

Борис Львович авыруның җәрәхәтенә салкынны үзе илтеп куйды,

авыру аңына килгәнче аның янында утырып, Мәскәүдән монда ничек эләгүенең тарихын практикантларына сөйләп бирде:

— Юлга чыкканда ук әйттем, Ольга, дидем, син я больница башлыгы, я баш врач булып керсәң генә глубинкага барабыз, дидем. Бигрәк бер дә ачулана алмыйм шул кешене, җебегән бер адәм булганым өчен үзем-үзем ачуым килә...

Авыру әкренлек белән терелде. Аның ярасын көн саен эфир белән юып, яңадан бәйләделәр. Беренче көннәрне бу эшне практикантлар күзәтеп кенә торганнар иде. Аннары Ольга Васильевна ул эшне кызларның үзләренә тапшырды. Иң элек Шура батыраеп тотынды, аны карый торгач, Нурия дә күнегеп алды.

Авыру утыз биш яшьләр тирәсендәге куе кара кашлы, кара тут йөзле кеше, паровоз машинисты иде. Кызлар яраны ачып юганда, ул тешләрен шыгырдатып ыңгыраша, татарчалатып сүгенеп тә җибәргәли иде. Бер көнне практикант кызларның эшен карарга кергән Борис Львович аны бик сәер итеп оялта башлады:

— Йа аллам, оят түгелме сиңа, чибәр егет? Җитмәсә әле, үзең рабочий класс, Россиядә диктатура урнаштырган кеше, паровоз машинисты. Чебен тешләгән чаклы яраң бар, шуңа дөнья бетереп ыңгырашасың. Мине шундый чибәр кызлар дәвалый торган булсамы — пыяла кисәге белән булса да корсагымны ертып куяр идем.

Паровоз машинисты операциядән соң беренче мәртәбә йөзен чытып елмайды.

Тагын ике атнадан аның ярасы төзәлеп җитә язды. Ул кызларны коридорда очратса бик яктырып исәнләшеп китә, инде тизрәк өйгә кайтаруларын сорый; кызлар аңа, иртәрәк әле, дисәләр, кара тутлы чибәр йөзенә моңсу күләгә куна иде.

Кызлар өчен ул бик тә кадерле кеше. Ул аларның үлемнән йолып алып калган кешеләре. Бу хәл аларны чиксез дулкынландыра, алдагы көннәренә өмет уята иде.

Авыруны өйгә җибәрәсе көнне атлы чана белән, толып һәм ястык алып, Имам Каһарманов килде. Нурия аны күреп таң калды:

— Имам абый, авыру сезнең кемегез була?

— Агай-энем.

— И-и, без әле сезнең энегезгә операция ясаганбыз икән. Менә син тамаша! Нишләп соң мин аны беркайчан да Зартугайда күргәнем булмады?

— Аның Зартугайдан киткәненә егерме ел булгандыр инде. Әтиләре бәхет эзләп Себер ягына киткәннәр иде, революциядән соң гына әйләнеп кайттылар. Мансур Себердә үсте, шунда машинистлыкка өйрәнгән, — диде Каһарманов һәм үз чиратында гаҗәпләнеп: — Ә син соң әле, Нурия, врач булып та житештеңмени? Менә син, ә! Солтанның хәле ничек? Операциядән соң дип әйтәм? Өйгә кайтып җиттеме?

— Кайтты, рәхмәт. Зарланмады.

— Солтан зарлана торганнардан түгел, имәндәй нык аның характеры. Әйбәт егеткә кияүгә чыктың син, сеңлем. Котлыйм, бәхетле булыгыз, — диде Каһарманов, энесен толыпка төреп чанага утыртты, атка чөңгереп китеп барды.

Ирле-хатынлы хирурглар, Уразаева белән Турчаниновaның беренче мәртәбә операциядә катнашуларын искә алып, аларны кичен үзләренә чакырдылар. Кызлар Ольга Васильевнага табын әзерләргә булыштылар: Нурия йорт тукмачы басты, Шура өйне җыештырды, бәрәңге әрчеде.

Өстәл янына утыргач, Борис Львович уймак хәтле генә рюмкаларга су белән сыеклатылган спирт салып, кызларга һәм үзләренә куйды.

— Ягез, күгәрченнәрем, чиркәнчек алуыгыз белән!

Шура ялындырмый-нитми рюмканы кулына алды, Нурия башта

куркыбрак калган иде, кыланчык дип әйтүләреннән шикләнеп, эчеп җибәрде, ут капкандай өтәләнеп, ике кулы белән берьюлы авыз тирәсендә селтәнә башлады.

Борис Львович белән Ольга Васильевна аның кыланышыннан рәхәтләнеп көлештеләр.

— Кәбестә кап, кәбестә, үзем тозладым. Әгерже халкын кәбестә тозларга өйрәтәм әле,— диде Ольга Васильевна.

— Башта әйт, яшелчә үстерергә өйрәтәм, диген.

Уймак чаклы гына рюмка Нуриягә кыюлык кертеп җибәрде. Аның көләсе, җырлыйсы, сөйләшәсе килә башлады. Бу ике кешегә изгелекле булганнары өчен рәхмәт әйтәсе иде, тик бу минутта гына матур сүзләре телгә киләмени аның — Нурия сорау бирүдән ары китә алмады:

— Борис Львович, операция вакытында авыру кычкырса, ыңгырашса, нишләргә кирәк?

— Кайчан ничек бит. Кайвакыт кычкырмаганга караганда кычкырганы шәбрәк. Моннан дүрт айлар элек мин бер егеткә операция ясадым. Тешен кыскан, тынын да чыгармый. Әллә үлдеме, дим, юк — уртын чәйнәп ята.

— Каян ул, кем?

— Землемер. Казаннан, терелеп кайтып китте инде — сәнәк белән кадаганнар иде.

Нуриянең битенә шаулап кан йөгерде.

— Фамилиясе Айдаров түгелме?

— Так точно: Айдаров. Ә сез каян беләсез?

— Ул бит Нуриянең ире,— диде Турчанинова, түземсезләнеп.

— Ну?! Кара син аны! Кем уйлаган минем клиентымның хатыны миндә практика узар дип. Хәле ничек соң иреген? Исән-сау кайттымы ул Казанга?

— Кайтты, рәхмәт. Мин сездән сорамакчы идем әле, Борис Львович, сорарга уңайсызланып кына йөри идем: аның хәле бик куркыныч түгелме? Ул бит, сез әйтмешли, шундый тешләк, минем хәлем әйбәт, диде. Авызы тулы кара кан булса да төкерми ул. Әйтми йөреп, хәле начарланып китмәгәе дим...

— Операциясе уңышлы чыкты. Сәнәк очы үпкәсенә дә эләккән иде. Мин хәзергә бер генә киңәш бирә алам: салкын тидерүдән сакланырга кирәк. Бигрәк тә үпкәсенә. Үпкә авыруына әйләнергә мөмкин: туберкулезга...

Нурия мөлдерәтеп Борис Львовичка карап торды, күзен әчеттереп керфек төбенә кайнар яшь килүен тойды, табын янындагыларга күрсәтмәс өчен, кашыгын куеп, китеп барды...

## VII

Никадәр генә очсыз-кырыйсыз булып, исәпсез-сансыз булып тоелмасын — студентлык еллары да бер узып китә. Төннәр буена күз бетәштереп хәреф чүпләүләр, ягылмаган бүлмәләрдә авыздан бөркелгән җылы пардан өзлексез дымланып торган микроскоп окулярын сөртеп интеккән чаклар да артта кала. Барысы онытыла, онытыла, сине эш көтә, эш көтә!

Нурия Габбас кызы Уразаева медицина институтын тәмамлап чыккан чакка Солтан Айдаровны Казан җир төзүчеләр техникумының директоры итеп күтәрделәр. Бу бер караганда нур өстенә нур кебек иде. Хатыны — әле генә институт тәмамлаган яшь врач, ире — әле генә техникум директоры итеп билгеләнгән яшь белгеч. Сөенергә кирәк моңа, сөенергә!

Сөенергә. Туктап тор, туганым, диерләр. Сөенергә ашыкма. Нурия Уразаева Казанда ничәмә ел укыган дәвердә гел Казанда булып килгән җир төзүчелек техникумын Казаннан җиде чакрым ары — авыл

хужалыгы институтының фермасы янына күчереп куймасыннармы! Туктап тор, туганым, дип тагын бер тапкыр әйтерсең. Җиде чакрым ары күчү белән генә калмады бит әле, Солтан Айдаровка нәкъ шунда, техникум урнашкан төбәктә ике бүлмәле өр-яңа квартир да биреп куйдылар. Ничәмә еллар гомер кичергән сигез метрлы уңайсыз фатирдан барлы-юклы нәрсәләренне олаучы абзый арбасының төбенә сал да өр-яңа урынга күчеп кит!

Алай тиз генә күчеп китеп булмый икән шул. Атаклы профессор Милославскийның, Казанның гистологлар мәктәбен җитәкләп барган кешенең күңеленә Кама иделе буенда үскән татар кызы Уразаева ошар да, ул аны үзенең ассистенты итәргә нияг кылыр дип кем уйлаган?!

Нурия Уразаева кулына аттестат алырга кергән җирдә Александр Николаевич та сакалын учлап утырып тора иде. Аның лекцияләренә бик әллә ни тырышып йөрмәгәнлектән, йөрергә теләмәвенең сәбәбен кайбер иптәшләренә дә әйткәнлектән, Уразаеваның эченә шөр йөгерде. Әгәр шуннан бу дворян профессоры аяк өсте басып, тәмәке кабызып җибәрсә, аннары шыгырдавыклы коры тавышы белән: «Аһа, Уразаевамы? Ул аттестат алырга лаек кеше түгел, ул бит гистология дигән иң кирәкле фәнне тырышып укымады, гистологияне укымаган кеше врач була алмый» дисә, ни хәлләр итәрсең? Битеңне кулың белән каплап чыгып йөгерерсеңме?

Юк, йөгермәде Уразаева. Йөгермәде, чөнки Александр Николаевич тәмәке дә кабызмады, шыгырдавыклы коры тавышы белән аттестат бирмәскә кирәк дип тә әйтмәде. Комиссия җитәкчесе:

— Врач Уразаева, сез кайсы районга китәргә теләр идегез? — дип сорагач, профессор гадәтенчә бик тә итәгатьле итеп, дворяннарча бер зыялылык белән:

— Хөрмәтле коллегалар, әгәр дә бу эшне мөмкин дип санасагыз, врач Уразаеваны гистология кафедрасы карамагына калдыруыгызны сорар идем, — диде.

Моңа Нурия генә түгел, комиссия членнары да аптырашып калдылар. Ник дисәң, институт бетерүчеләрне эшкә билгеләү берничә ай алдан хәстәрләнеп куела, аспирантурага, ассистентлыкка, лаборантлыкка калучылар исемлеге күптән комиссиягә тапшырылган була бит инде! Уразаева хакында студентканың ни үзеннән, ни кафедра җитәкчеләреннән институтта калдыру турында заявка кермәде. Нишләргә?

— Хөрмәтле Александр Николаевич, без сезнең үтенечнең максатын аңлап җиткерә алмадык бит әле,— диде комиссия председателе, уңайсызланып. — Гафу итегез, институт тәмамлаучы Уразаеваны институтта калдырырга теләвегезнең сәбәбе нәрсәдә соң?

Комиссия председателе, институт директоры булуыннан файдаланып, моңарчы бик тә вәкарь белән генә сөйләшеп утыра, кирәкле-кирәкмәс якка башны бормый, кара костюм, чытыр ак яка, матур төенле галстук аны аеруча дәрәҗәле итеп күрсәтә иде. Менә хәзер ул профессор Милославский алдында йомшак, хәтта төчерәк бер тавыш белән сүз башлагач, озын өстәл янында тезелешкән галимнәр үзләрен уңайсыз сизә башладылар.

Милославский аларга мәшәкать тудыруын сизде бугай, ул чандыр озын гәүдәсе белән урыныннан торды, председательгә карап түгел, каушап басып торган Уразаевага төбәлеп:

— Мин гистология кафедрасына аспирант урыны алуга ирештем. Шунда иң булдыклы бер татар кызын алмакчы булам. Миңа Уразаеваның озын нәфис бармаклары бик ошый! — диде.

Картның вакыт-вакыт иләсләнеп китү, үзенә калса, бик нечкә итеп шаярту гадәтен белгәнгә күрә, комиссия членнары «озын нәфис бармаклардан» ирен чите белән генә елмаеп куйдылар.

Елмаюын елмайдылар, әмма Милославскийга каршы авыз ачып

сүз әйтә алмадылар. Александр Николаевичның авторитеты бик зур иде шул, намуслылыгы да зур иде, күрәсең. Шундук һәммәсенең күңелләрендә Ленинның аны үлемнән саклап алып калган булу факты яңадан калыкты. Ленин чаклы Ленин аның тормышын кайгырткан икән, Милославский Советлар иленә кирәкле кеше. Менә шул кирәклелек мәсьәләсе комиссия членнарына аның үтенечен үтәргә куша иде.

Шул бәхетле минутлардан башлап Нурия Уразаева, Зартугай балаларыннан беренчесе булып, медицина фәненә аяк басты.

Ләкин Казаннан җиде чакрым ары бирелгән уңайлы, ике бүлмәле фатир белән аспирантураны ничек бергә бәйләргә? Казанда машиналар бик аз, трамвай техникум фермалары янына кадәр бармый, ә Уразаева дигән аспирантка көн саен институтка килергә, Милославский дәресләренә әсбаплар әзерләргә, микроскоп белән үткәрелә торган практик дәресләрне мөстәкыйль рәвештә башкарып чыгарга тиеш!

Әнә кая таба китте Кама иделе буенда үскән татар кызының эшләре!

Менә шунда гына Нурия кияү буласы кешесен дөрес сайлаганын белеп алды. Солтан аны ферма янына күчеп килергә кыстамады, Нурия баш-күз алганчы дип, Солтан янына Шәмсениса абыстай вакытлыча күченеп килде һәм ул яраткан кияовен бик зур тырышлык белән карап-багып тора башлады.

Гаҗәп бер тамаша булды бу аларның аерым-аерым яшәүләре. Бер атна эчендә Нурия Солтанны өзелеп-өзелеп сагына. Шимбә көн кич житкәнне ул түземсезлек белән көтеп ала да фермада ат караучы Саттар абзыйның Солтан җибәргән олавын эзләп, толыпларын күтәреп, Суконный базарына юнәлә. Ә дүшәмбе көнне аңар иртүк, сәгать биштән үк кузгалырга туры килә. Солтаны белән ярты төн уртасына чаклы чүкердәп, назланып ятканга күрә, иртән ул мендәрдән башын күтәрә алмый, күз кабаклары ачылырга теләми аптыратып бетерә, бөтен тәнендә рәхәт-татлы бер оеганлык сизә, Солтанының җылы кочагына сеңә бара, сеңә бара. Ләкин дөньяда балаларының бәхетен баш очында ук басып саклаучы аналар бар. Шәмсениса абыстай Нуриянең эшкә соңга калуын һич кенә дә теләми, шуңа күрә ул Нурия торып чыкмыйча ишек төбеннән китми: әкрен генә ишек чиртеп, йомшак көйле тавыш белән, һаман да бер үк сүзне кабатлап тора:

— Нурия, бәбкәм, тор инде, үскәнем, тор. Алла сакласын, соңга калып куюың бар. Тфү, тфү, әстәгафирулла, әйттем исә кайттым, эшеңнән куып чыгарулары бар.

Иртәнге алтылар тирәсендә, бәрән толыпка төренеп, Нурия Казан каласына, профессор Милославский янына юнәлә. Толыпларын я Гажурдагы квартирына, я булмаса (соңрак кузгалган көнне), лабораториягә генә куеп тора. Сәгать сигездә төп-төгәл башлана торган немец теле дәресенә өлгерергә кирәк аспирантка Уразаевага. Институтта укыган дәверендә ул чит тел дәресләренә бигүк игътибар биреп бетермәсә дә, хәзер кебелә кебек ябышты. Ул аспирантурада укыйсы йөзләгән китап — медицина гыйлеме — немецча иде.

Профессор Милославский бер көнне аны үзенең иште ассистентларыннан берсе, озын буйлы, ак халатлы кеше янына алып килде дә:

— Нуруся, сине медицинада галим итәчәк кеше менә шушы булыр. Син аны Николай Григорьевич дип олылап дәшсәң, аның дәшкән саен күңеле булыр, һәм ул сине теләбрәк өйрәтер, — диде.

Профессор Милославскийның Нурияне русча Марусяга җайлаштырып Нуруся дип әйтүе Голосовка да ошап китте, шуңа күрә мединститутның кечерәк бер лабораториясендә ике кешенең үзара: «Николай Григорьевич!» — «Ау, Нуруся?» дигән сүзләрен бик еш ишетергә була иде.

Иртән сигездә башланган эш төнге сәгать уннарда гына бетә. Нурия

күндезләрен лаборатория техникасын үзләштерә, чит телләрне өйрәнә, Аннары тәрҗемәгә утыра. Нәкъ менә Нурия аспирантурага кергән елны институтларда татарча дәреслекләр булдыру бурычы куелган иде.

Кафедра саен берәр-икешәр сибелгән татар врачларына булдырса-булдырмаса, теләсә-теләмәсә дә русчадан медицина дәреслекләрен тәрҗемә итү бурычы йөкләтелде. Вакытын да бик аз бирделәр — нибары бер ел!

Александр Николаевич көндезге сәгать уникеләрдә, көмеш башлы кара таягына таянып, лабораториягә килеп керде. Буй — озын, сакал—чөй. Тавышны шыгырдатып сүз башлады:

— Балакайларым, Николай Григорьевич, Нуруся, минем сезгә әйтер сүзем бар. Кафедраларга татарча дәреслекләр кирәк. Нуруся гистология дәреслеген тәрҗемә итәргә тиеш, ә син, Николай Григорьевич, моңа шартлар тудырырга тиеш. Аңлата алдыммы?

— Бик тә аңлаешлы булды бу, Александр Николаевич, — диде Голосов, халат җиңнәренең төймәсен каптыра-каптыра,— димәк, сез Нурусяны миңа бер кулыгыз белән бирдегез, икенче кулыгыз белән тартып аласыз?

— Кем әйтә алам дип?

— Нуруся көне буе термин эзләргә, сүз ясарга, бер ел эчендә тәрҗемә итеп бетерәмме, юкмы, дип, ут йотып йөрергә тиеш. Шул эшләр белән йөргән чагында аның микроскоп янына килергә дә, бакалар, тычканнар, этләр ярып карарга да вакыты булмаячак, — дип, методик бер көйгә салып, корыч логика белән сөйли башлады Голосов.

Бу методик көйлелекне профессор Милославскийның шыгырдавыклы тавышы бозды:

— Күгәрченем, Коленька, Владимир Ильич миңа тормышымны бүләк иткән икән, ул моны мин совет власте үткәргән чараларга каршы төшеп торсын дип бүләк итмәгәндер дип беләм. Совет властена врачлар кирәк. Милли кадрлардан кирәк. Совет власте миннән татарча дәреслек әзерләп бирүемне таләп итә һәм совет власте әйтә, ассистент Голосов бу эшкә аяк чалмастыр дип беләм, ди.

Голосов — акыл иясе, кире беткәнлек аның холкында юк. Тәрҗемә эше аспирантка Уразаеваны төп эшеннән аерганны белә ул, әмма бу этапта аның тәрҗемә эше ил өчен кирәк икән, эшләсен. Ләкин гистологиядән кем дәреслеген тәрҗемә итәргә?

— Ничек кемнеке? Андый сорауның куелуы дөрес түгел. Әлбәттә, Аварзинныкы!

— Ә ни өчен Милославскийныкы түгел?

— Әйе шул, — дип, Нурия дә сүзгә килеп кушылды, әмма, моны тыйнаксызлыкка санап, шундук телен тешләде.

Профессор урындыктан торды, таягы белән идәнне тукылдатып:

— Аварзинныкы, ишеттегезме, Аварзинныкы! Бүтән кабатлаттырмассыз дип ышанам, — диде һәм саубуллашмый-нитми чыгып та китте.

— Картлачның кәефен алдык, ахрысы, — диде Голосов, ул чыгып киткәч.

— Үпкә саклый торган кеше түгел ул,— диде Нурия, җитәкчесен тынычландырырга теләп.—Беләсезме, Николай Григорьевич, профессор Милославскийның әзерләп чыгарган укымышлылары егермедән артык, диләр. Ә нигә аның китаплары аз?

— Аз дигәнен ничек аңларга?

— Дүрт-биш кенә китабы бар.

— Дүрт-биш китап аз түгел ул, Нуруся. Чын галим үз гомерендә бер китап яза, шуның белән үзен аклый. Ләкин ул китап — фундаменталь хезмәт булырга тиеш. Биш фундаменталь хезмәт безнең шефыбыз Александр Николаевичның бик зур галим икәнен әйтеп тора түгелме?

— Ә бит башкаларның хезмәтләре егермедән арта.

— Бар андый хәл,— диде Голосов, кашларын җыерып.— Бар. Ләкин алар барысы да үзләре язган хезмәт түгел, кул астында эшләгән яшь галимнәр язган хезмәт, алар әнә шуңар да кул куеп, соавтор булып йөриләр. Безнең шефыбыз андый кеше түгел, ул бары тик үзе язган хезмәтләргә генә имзасын куя һәм шул хезмәтләрне генә үзенеке дип таный.

Нуриягә хәтта күңелсез булып китте. Ул бит А. Н. Милославский дигән бөтен илгә атаклы галим белән янәшә Н. Г. Уразаева дигән фамилия дә күрергә теләгән иде. Болай булгач булмады инде!

Ләкин безнең Нуриябезгә борын салып йөрергә вакыт юк иде. Тәрҗемә эше тәҗрибәсез кеше өчен болай да бик авыр эш булса, шуның өстәвенә, медицина терминнарының эшләнмәгән булуы, әдәби тел кагыйдәләрен Нуриягә эзлекле рәвештә укырга туры килмәү — аны кыен хәлгә китереп куйды. Аның уенча, инде башка кафедраларда тәрҗемәнең яртысын эшләп бетергән булырга тиешләр иде, эшли алмавын ул үзенең булдыксызлыгыннан күреп, Солтанга күрсәтми генә бер-ике мәртәбә балавыз да сыгып алган иде, әмма көннәр үткән саен зарлану авазлары барлык кафедралардан да ишетелә башлагач, тынычлана төшкәндәй булды.

Эшләрнең ерып чыга алмаслык тупикка килеп терәлүен институт җитәкчеләре дә сизеп алдылар. Көтелмәгән зур бер чара күрергә кирәк иде. Тәрҗемәгә тотынган татарларны һәм җитәкчеләрне җыйгач, иң әүвәл терминология комиссиясе төзәргә, аннары, татар врачларының татар теле һәм әдәбиятыннан бик сай белемле булуларын искә алып, тел-әдәбият курслары ачарга дигән ныклы фикергә килделәр.

Озак та узмады, исеме Татарстанга билгеле тәнкыйтьче Гомәр Гали врачларны татар теленең нечкәлеген, борынгыдан ук килә торган әдәби хәзинәләрнең зурлыгын аңларга өйрәтә башлады.

Болар барысы аспирантка Уразаевага бик зур мәшәкать өстәделәр, ләкин ул хәзер үзен ныграк, көчлерәк итеп сизә, чөнки ул хәзер сукыр суфи кебек капшанып бармый, тел кануннарын белеп эш итәчәк иде. Шуның өстәвенә, Уразаева тәрҗемәне тизләтүнең яңа бер чарасын да эзләп тапты. Шул көннәрдә генә Алабугадан Казанга кайтып урнашкан Зәйтүнә Уразаеваны — мөгаллимә апасын ярдәмгә чакырды. Зәйтүнә апасының исә тел-әдәбият кануннарын өйрәнеп торасы юк, ул аларны биш бармагы кебек белә иде.

## АЛТЫНЧЫ БАШЛАМ

### I

Аксагыз таулары ягыннан таң беленә башлаганда, Шәмсениса абыстай гөлдерәп кенә Хәнифәне уятты:

— Әллә торасыңмы, яшь бикә? Көтү куасы бар, башка эшләр дә муеннан.

Хәнифә имчәк баласы белән түбән өйдә ялгызы йоклаган иде. Эчке күлмәктән, ялан аяк, аңгы-миңге килеп, идәнгә төшеп басты. Олы абыстайның тавыш-тынсыз түбән өйгә керүен дә берничек тә башына сыйдыра алмый, вакытның иртәме-кичме икәнен дә белми, ярты төнгә чаклы елаган баласын көч-хәл белән юатканнан соң, ул, мәрткә киткән кебек, дөньясын онытып йоклаган иде. Менә хәзер аның каршында кара трико күлмәк, кама кырпаулы яшел камзул кигән, баш түбәсенә энҗеле кара калфак кадап, муенына тавык күкәе чаклы сары гәрәбә таккан остабикәгә тәмам алҗып, хәйран булып карап тора иде.

— Нәрсә, мулла абыстай, кунакка барасызмы әллә?— диде ул, ниһаять, аңына килеп.

Шәмсениса абыстайның маңгайга терәп биргән сораудан кәефе кырылды. Нәзакәтле булырга, кешене кыен хәлдә калдырмаска дип күпме өйрәтә инде ул аны, булмаса да булмый икән бу үксез бозаудан...

— Кунакка тикле эш бик күп әле, гөлекәем, — диде Шәмсениса абыстай. Көндәшенең соравын өнәп бетермәвен «гөлекәем» сүзенә күчерде.

Хәнифәнең ашыгырга нияте юк иде. Ак матур кулларын баш артына күтәреп, тавышланып киерелде, юка батист күлмәк аркылы имиләре шалкан кебек төртеп чыктылар; ул, авызын кулы белән каплап исни-исни, олы абыстай артыннан ишекне шапылдатып ябып калды.

Кичтән үк комганга су салып, мич алдына куйган иде. Талыккан жылымса су белән озаклап юынды, таһәрәт алды, иртәнге намазга утырды.

Шәмсениса абыстай ярты сәгать көтте, бер сәгать — көндәше юк. Сабырлыгы төкәнеп, тагын түбән өйгә төште. Чигүле намазлыкны кыйбла якка турылап, бик рәхәт җәелеп утырган яшь остабикәгә аеруча үтемле, татлы тел белән аңлатырга керешә:

— Син, гөлекәем, намазыңны тизрәк тот әле бүген. Әйберләрне җиләтеп керәсе булыр. Көне бик матур булырга тора.

Хәнифә аңа каршы авыз күтәреп сүз әйтмәде, бәйләнчек чебенне куып җибәргәндәй, кул гына селтәде дә, фани дөнья хәлләре белән исәп-хисабы юк кеше сыман, шул исәптән дөньяда Шәмсениса остабикә барлыгын да онытып, тагын намазга оеп китте...

«И ходаның бер рәхмәте, иллә дә үзсүзле соң!» — дип уйлады олы абыстай, әмма, зурга китүдән куркып, Хәнифә көндәшенә бүтән сүз катмады.

Келәткә кереп, Габбас мулланы уятып чыгарды:

— Тор, хәзрәт, тор, атыңны кара, башак болгат, барасы җир ерак, юлда арып калып хур булмыйк тагын!

Хәзрәтнең ачуы чыкты:

— Нишләп әле син таң тишегеннән кытаклап йөрисең? Күкәй сала алмаган тавык кебек. Кунакка беренче генә баруыбыз түгел ләбаса!

— Барыгыз да бик остарасыз әле бүген! Тегесе, эш кушкач, намазлык өстенә менеп кунаклады, ярлы тәкәббер! Үзенә күрә генә түгел, сәвит ирек чыгарганнан бирле койрыкны тәмам сыртка салды. Кәнсәләрдән котыртып кайтарганнардыр, ахры. «Асрау булып торган чаклары өчен мулланы судка бир, үзенә тиешлесен каертып ал да яшь кияүгә чыгарсың», дип әйтәләр, ди. Беләм мин, бергә өелеп сөйләшәләр, су чокырга җыела...

Габбас мулла, өстеннән ак җәймәне алып ташлап, күзен уа-уа урыныннан күтәрелде:

— Нишләп әле син, Шәмсениса, кояш чыкмас борын көфер сүз сөйли башладың? Ичмасам, эш эшли торырыең. Әнә сыер мөгрәп тора, җилене тулгандыр, бихисап оста булсаң, шуны сава башла.

Бүген ул төшендә әтисе Җамалетдинны күрде. Зур төпле киндер ыштаннан, чабаттан, күз явыңны алырдай кама бүректән, балаларын үз янына җыйган да калач өләшә. Аппак калач. Малайлар калачны алалар да югалалар, алалар да югалалар. Габбас берүзе торып калды: аңа калач юк. Ул да түгел, Габбаска эләкмәгән калач, әтисенең кулыннан ычкынып, күккә менеп китте, зурайды, зурайды, нур чәчә башлады, күк гөмбәзеннән йөгертеп килеп, тегермән буасындагы суга барып төште, су кандай кызыл төскә керде. Җамалетдин карт әнә шул калач эрүдән кып-кызыл булган суны кушучлап эчә башлады.

Таң алды йокысында изрәп, уяныр-уянмас хәлдә, нигә шундый төш керүен, монын яхшылыккамы-яманлыккамы икәнен белергә теләп, әтисенең нишле бала арасыннан бер аны гына өлешсез калдыруына үпкәли

биреп, уйланып-тәшвишләшеп ята иде, монда тагын дөнья мәшәкате белән Шәмсениса кортка килеп тыгылды. Бака ботын кыстырган күк...

Габбас мулла Габделхәлим кайнагасының кунакка чакырганын исенә төшерде. Абзый кеше юлаучы артыннан хат җибәргән: «Картайдым, хәлем дә бетеп бара, дөньялар да бик болгавыр, исән чакта бер күреп калыйк дисәгез, җомга көнне Шәмсениса белән килеп китегез».

Картның «хәлем бетеп бара» дип әйткәне хәйлә генә. Тук халыкны, сату-алу белән кайнашкан нэпманны совет бик каты китереп кысты, шатырдатып налог сала башлады, я җилкә күтәрмәстәй салымны түләп, сәүдәгәрлекне дәвам итәргә, я ирекле баштан казакъмы, үзбәкме арасына чыгып таярга кирәк. Әнә шуңа көйсезләнә Габделхәлим абзыйлары, укымышлы кешеләр дип, Габбас белән Шәмсенисадан киңәш-табыш итмәкче була. Әллә ни кыдырата алмаслар алуын, шулай да барып кайтырга кирәк. Бәлкем әйтәсе сүзе, васыяте-мазары бардыр...

Көн-ай җәелгәндә, ниһаять, Хәнифә абыстай да оешып житте. Самавыр куеп, чәй кайнатып китерде, табын әзерләде: сыерны савып, сөтен марлядан сөзеп, кар базына төшереп куйды, тавыкларга җим сипте. Шәмсениса абыстай рияланып, аны табын янына чакырса да, утырып тормады, балам уянып ятмагае дип, янә дә түбән өйгә төшеп китте. Чынлап та бишектәге бала — тугыз айлык Шәфика инде уянган, еламакчы булып шыңшый да башлаган иде, әнисе аны күтәреп алып, чүлмәккә аяк тоттырды.

— Үскән кызым бит ул минем, кысталган булган бит ул. Менә бит аның әннәсе нинди, вакытында килеп житмәсә, артын җәеп югары өйдә чәй эчеп утырса, балык тотасы икән бит минем кызым.

Хәнифә сабыен тезенә утыртып имезә башлады.

— Я, тешләмә. Кара син аны, мыкыртны. Им, кызым, им, матурым. Мулла абыстай тиздән кунакка китеп барыр, без менә дәү кызым белән икәү генә аулак өй калырбыз. Тып-тыныч кына, өй саклап кына. Сысканыбыз барые башыгызга, диген, кызым. Бик кирәгегез барые, диген. Без үзебез дә бик әйбәт тора беләбез. Йокла, балам, йокла...

Хәнифә Габбас мулладан ун ел эчендә дүрт бала тапты, баштагы икесе гомерсез булдылар. Көне-төне ялчы хәлендә, авыр эштә йөргәнгәме, берсе житлекми туып үлде, берсе кызамык чиреннән вафат булды. Шәмсениса абыстай Хәнифәне төче телләнеп иренә димләгән чакта: балаларыңны үзем багармын, җил-янгыр да тидермәм, дип зурдан кубып вәгъдәләр бирсә дә, вәгъдәсен үтәп житкерә алмады, үз мәшәкате үзенә житкән иде. Шулай да Хәнифәнең үлгән балаларын бик кызганды.

«Бигрәкләр вакытсыз әрәм булдылар шул,— диде.— Ни хәл итмәк кирәк, тәкъдиреңә ни язса, шуны күрәсең. Менә минем дә, гөлекәем, өч баладан икесе үлде, бер Нуриям генә исән калды. Син әле яшь, тагын табарсың», — дип юатты. Тик моңардан Хәнифәгә җиңел түгел, аның җир куенына киткән балалары белән бергә йөрәгенең бер чите кителеп китеп бара, үзенең дә дөньяда торырга теләмәгән көннәре була иде.

— Хәнифәүүү! Син исәнме әле, гөлекәем? — диде Шәмсениса абыстай, тәрәзәдән карап.

— Чыгам, хәзер чыгам, — диде Хәнифә. — Эшсез утырмагае дип йөрәкләре алына, балаң ник үз бәвеләнә үзе буялып ятмый, берсенең бер эше юк, — дип, үзалдына сөйләнеп куйды.

Йорттан әйберләрне чыгара башладылар. Габбас мулла төлке тунны үзе алып чыгып, үзе какты һәм, ак бәскә төреп, киредән ак келәткә кертеп куйды. Хәнифә моңа үпкәләмәде, бер мәшәкать кимрәк дип сөенде генә.

Келәттән өй чоланына тикле бау суздылар. Иң элек аңар стена келәмен элеп, таяк белән тузанын кактылар. Дөресрәге, бу эшне Хәнифә эшләде. Анныары җиләндер, чапандыр, камзулдыр ише әйберләр белән,

кыска тун, озын тун, билле бишмәт, плүш бишмәт, ефәк, атлас, кашимир күлмәкләр белән өч бау тулды: энҗеле калфак, укалы түбәтәй, хәтфә кәләпүш, колакчын бүрек, кама бүрек, тәкыя ише баш киемнәрен аерым-аерым, берәм-берәм селектеләр, каз канаты белән, щетка белән сыпырдылар, хәситә, чулпы, беләзек, тамчылы көмеш алка, муенса ише алтын-көмеш бизәнү әйберләрен берәм-берәм барлап, шкатулкага салып куйдылар. Болар барысы бикле капка эчендә эшләнде. Заманалар бик болгавыр, тычкан таяк белән йөри торган вакыт, шул тикле байлыкны яман күзгә күрсәтү җүнлегә илтмәячәк. Шәмсениса абыстай гомер буе җыйган байлыгын кеше-карага күрсәтми генә күздән үткәреп, төрен төргә аерып, сандыкларга салып куярга тели иде.

Ул үтә дә тәмле тел белән Хәнифәне өйрәтеп торды:

— Ипләп кенә как, яме, гөлекәем. Болар барысы сиңа каласы. Ике катлы ташпулат салырга җитәрлек мөлкәт бар монда. Кадерен белеп тоткан кешегә. Гыйматдин хәзрәт үтә дә чыккан мал җанныклы кеше ие, хаҗга киткәнче берәмтекләп җыйды, Мәкәрҗә ярминкәләреннән алып кайтты. И дә кечелекле ие соң, Шәмсе-кояшым дип кенә дәшәр иде миңа. Урыны җәннәттә булсын, телгә дә бик оста, халыкка вәгазь сөйли башласа да, сары майлар кебек эретә торганые. Авыл халкы белән дә бик тату яшәде, аллаһы тәгалә риза булсын, сәдаканы бер дә генә кызганмый китерә торганнарые...

Шәмсениса абыстай никтер үтә дә ачылып үз итеп җибәрде бит әле Хәнифәне.

— Габбас хәзрәт, рәхмәт яугыры, мал кадерен белеп бетерми, гөлекәем. Затлы нәселдән түгел, һаман да үзенең мажиклыгына тарта. Малны бит аны табу белән генә түгел, саклый белергә дә кирәк. Җәйгесен кышка кергәндә, кышкысын җәй башында җилләтәсең. Югыйсә, көя дигән хәшәрәт бер җәй эчендә ашап бетерә аны. Элегрәк елларны сабак укучы кызлар йонымны егерләп, суымны китереп, бакча чүбемне утап бирәләрие. Хәзер ярамый шул инде, заманасы башка, закуны башка... Ярар, гөлекәем, әллә нәрсәләр сөйләшеп, гөнаһлы булмыйк тагын, монда сөйләшкән монда калсын, үзең генә бел, менә сиңа өч тәңкә көмеш, күчтәнәч алырсың, мампаси-мазар, я Шәфикага курчак,— диде ул, аннары шыпыртрак тавышка күчеп, ачыклабрак әйтте: — Без бүген Габделхәлим абзыйларга барабыз, сырхаулап тора икән, килсеннәр дип әйттергән, без югында берүк өйдән чыгып йөри күрмә, явыз күздән алла сакласын, я әйберләрне урлап чыгарлар, я үч итеп ут төртерләр, өйдә генә тора күр, яме, гөлекәем. Без ике көннән артыгын тормабыз, урак өсте җитә...

Габбас мулла тарантаска кара айгырны җикте, яшел печән салды; Хәнифә бизәкле зур ястыкны алып чыкты, аны зәңгәр палас белән төрде; хәзрәт белән абыстай, мамык ястыкка аркаларын терәп, икәү бергә кунакка китеп бардылар.

Хәнифә аларны капка ачып, капка ябып озатып калды.

Аның үзенә мулла хатыны була торып та бер генә мәртәбә дә хәзрәт белән янәшә тарантаска утырып йөрергә туры килмәде. Хәер, бер тапкыр килгән икән. Печәнлеккә печән өйгән чакта Хәнифәнең аягына тимер сәнәк кадалды. Печәнлектән төшкәнгә күрә сәнәк аның аяк йөзен аркылыга тишеп чыккан иде. Зартугайда табип-мазар юк иде, аякны чиста су белән юып, чиста чүпрәк белән бәйләп куйдылар. Аяк төне буе сызлады, көне буе сызлады, оялудан Хәнифә ул хакта мулла абыстайга да, хәзрәткә дә бер сүз әйтмәде. Өченче көнне аягының сызлавына түзәр хәле калмагач, өйдә һава җитмәгән сыман сизеп, баскыч төбенә чыкты, бусаганы атлаганда, ялгыш абынып, авырткан аягына китереп басты һәм, сыны катып, авып китте: шешкән аягыннан кара кан һәм үлек ага башлады.

Хәнифәнең кычкырган тавышына Габбас мулла йөгереп чыкты,

Шәмсениса абыстай йөгереп чыкты; баскыч төбендә авып яткан Хәнифәне, идәндәге канны күреп, төсләре качты; аякның чупрәген чишеп, йөзләрен чыта-чыта, яраның канын, үлеген сөрттеләр; Габбас мулла кара айгырны тарантаска җигеп, яшь хатынын Салагыш фельдшерына алып барды.

Ул хәлләргә ун елга якын вакыт узды бугай инде, әмма авыл чыкканнарын Хәнифә бик яхшы хәтерли, ник дисәң, күрше-колан, карткоры капкадан башын тыгып, үтә дә сәерсенеп сөйләнеп калган иде.

— Рамазан хәерче кызын кырантаска утыртканнар!

— Бу ни әкәмәт?

— Мулла яшь катыны белән кунакка бара!

— Сугышлар бетеп, дөньялар иминләнергә булсын!

— Әссәләмәгаләйкүм, хәзрәт, сәфәрләрегез уң булсын!

Мулла абзый бик ачулы иде, авыл картларының сәламен дә алып тормастан, кара айгырны җан-фәрманга чаптырып киткән иде.

Шуннан бирле Хәнифәнең ире белән янәшә тарантаска утырганы юк. Заманында Шәмсениса абыстай: «Бары да син дигәнчә булыр, гөлекәем,— дип,— бал-майда гына йөздерермен, остабикә булып кыңгыраулы пар атларда дөнья гизәрсең»,— дип кызыктырса да, пар ат дигәннәренең олы абыстайдан бер дә генә артканы юк.

Тормыш Габбас мулла өендә гел дә элеккечә калды. Хәнифә асрау кыз чагында да түбән өйдә яши иде, хәзер дә түбән өйдә. Хәтфә келәмле, терәкле чаналарда, түшәк салган тарантасларда элек тә Шәмсениса абыстай йөри иде, хәзер дә ул йөри. Хәнифә аңа элеккечә үк «мулла абыстай» дип, «олы абыстай» дип дәшә, аш-суны элеккечә үк ул пешерә, мал-туарны да карый, өй-кураны ул җыештыра; Казанга китеп барган Нуриянең өс-башын юу, чәчен тараулар да кайчандыр аның өстендә иде бит әле.

Хәнифә дөнья тигезсезлеге турында озаклап уйлый белә торган җиңгә түгел иде — уйлап карый белергә аны берәү дә өйрәтмәде. Патша хезмәтендә ярты гомерен үткәреп кайткан Рамазан картның ишле гаиләсендә ул соң дәрәҗәдә фәкыйрь иде, яшь-җилкенчәк уеннарына да катнаша алмады, аның өзелеп сөйгән егете дә юк, егет белән егетне аерырлык, арадан берсен сайлап сөярлек танышлыгы да юк иде. Беренче аңар күз аткан кеше Габбас мулла булды, беренче мәртәбә аңар бала итәкле ал сатин күлмәк, репс камзул, аягына биек үкчәле чәмчәле читек, башына алма бизәкле яшел батист яулык, чуклы ефәк шәл бөркәндергән кеше Шәмсениса абыстай булды. Шушы икедән бүтән кешене ул күрмәде дә, белмәде дә, хаҗга китеп вафат булган Гыйматдин хәзрәтнең чарлаклы, ике катлы йортында, биек коймалар, урыс капкалар эчендә бикләнеп калды.

Ләкин кеше күңеленә табигать салган сәламәт орлык, яшәү һәм сайлану инстинкты барыбер үзенекен итми калмый икән. Бер генә егет тә күрми, бер генә яшьтәше белән дә аралашмый яшәсә дә, соңгы көннәрдә, Шафикасын тапканнан соң, аның күңелендә дә эзләнү башланды. Ул зарыкты, төннәрен төшендә елаганын күреп уянды; аның күңеле генә түгел, сәламәт, дөрес тормыш белән яшәгән тәне дә зарыгып нидер көтә, дөресрәге, кемнедер көтә, әмма көткән кешесенең кем икәнен тәгаен генә белмәү аны тагын да сагышлырак уйларга батыра иде.

Габбас мулла белән Шәмсениса абыстай кунакка китеп баргач, ул сабыен, бәби арбасына салып, ишегалдында тирбәтеп йөрде, җырулар җырлый-җырлый тирбәтте, йоклап киткән баланы лапас күләгәсенә илтеп куйды. Озын толымнарын баш тирәли урап, яулык белән бәйләде, күлмәк итәген ыштан бөрмәсенә кыстырып, аягына калош киеп, югары өйнең, болдырның идәннәрен юып чыгарды, битен-күзен юып, чәй кайнатып эчте. Ул арада көтү кайтты, сарыкларны берәм-берәм санап абзарга япты, унбиш бәрәннең унбише дә кайткан иде, күрше-коланнан

әвләп йөрисе булмады, моңа ул күнеленнән тын гына сөенде. Коба сыерның сөтен савып, кайнатырга куйды, мулла абзыйлар кайтканчы яңа сөзмә ясап куярга ниятләнде. Башмак тана әле беренче генә бозавын бозаулаган иде, җилененә кагылуга чамасыз кытыклана иде, аның алдына бәрәңге юып куйды, арт аягын бау белән бәйләде.

— Түгәнәем, түгәнәем, — дип, йомшак сүзләр әйтеп, сөтен савып алды да анысын да казанга салып кайнатты, казан төбенә утырган касмагын бака кабырчыгы белән кырып, казанны юды, тик шуннан соң гына йокларга әзерләнә башлады. Ләкин — ни хикмәт бу? — утны сүндерүгә аның күңеленә шом төште, ул ялгызлыктан курка башлады, кызын бишектән алып, үз янына салды, ул да курку-шикләнү тойгысын басмады. Ә бит аның мулла абыстайлар кунакка киткәндә ничәмә-ничә еллар өй саклап калганы бар иде, ялгыз өйдә кунам бит, ай-һай лабаса дип, ул уена да кертеп карамый иде.

Шикләнү-шөбһәләнүләрен җыңә алмагач, ул күрше карчыгы Кафия әбине аулак өйгә иптәшкә алып чыкты, аны такта чәй белән, балга катырган бавырсак белән сыйлады. Аннары алар, йоклар алдыннан укый торган догаларын укып, ачык савыт-сабаның өстен бисмилла әйтеп ябып, йокларга яттылар — җиделе лампаның утын бөтенләй сүндереп бетермәделәр, кучкарга куеп, филтәсен кысып кына калдырдылар. Гадәт буенча, быдыр-быдыр авыл хәлләрен сөйләштеләр, күбрәк Кафия әби сөйләде, Хәнифә аның сагышлы әкрен тавышыннан изрәп йоклап китте.

Ул кемнәрнеңдер тамак ертып кычкырган тавышларына сискәнеп уянды. Уянган мәлгә ни булганын аңлый алмый тәрәзәләргә каранды: урамда, тәрәзә артында кызыл шәүләләр биешә, кычкырган шомлы тавышлар отыры көчәя бара иде:

— Пожар! Пожар! Янабыз!

— Ни булды? Ни булды? — диде коты алынып уянган Кафия әби. Ул ачык изүен кулы белән каплаган хәлдә, сәкедә урын өстендә чабалана башлады. Ниһаять, эшнең нидә икәнен аңлап алды:

— Йа аллам, бер тәңрем, минем йортым яна түгелме соң?! — дип, ашыгу-каушау сәбәпле нишләгәнен белештермичә, сәкедән идәнгә егылып төште.

Хәнифә, җан ачысы белән кычкырып, кызы Шәфикага ташланды, аны күкрәгенә кыскан көе, бер кат эчке күлмәктән ишегалдына чыгып китте. Капка ачу аның башына килми, читлектәге җанвар кебек, ул бөтен ишегалдын бер итеп чабып йөри иде, аның яныннан мүкәли-мүкәли Кафия карчык узып китте. Капканың бастырыгын тартып ачарга карчыкның көче җитми иде, Хәнифә белән икәүләп көч-хәл белән ачтылар, Кафия карчык, алдына-артына карамый, өйләренә элдертте.

Ул Габбас муллалардан өч кенә өй аркылы иде. Чиләк-көянтә күтәргән хатын-кыз, озын саплы багор, балта-көрәк тоткан ир-ат, түбән очныкылар булса кирәк, мышный-мышный, шаулашып-кычкырышып, янгын сүндерергә чаптылар.

Кафия карчыклар йортыннан түшәк-ястык, кием-салымны урамга чыгара башладылар. Урамны кыңгырау тавышына күмеп, атлы арбалар, мичкәләр чабышты, олаулар кузгаткан тузан, төтен белән аралашып, әйләнә-тирәне каплап алды.

Хәнифәгә дә өйдән әйберләрне ташый башларга кирәк иде, ләкин ул әле һаман да, баласын күкрәгенә кыскан көе, капка төбендә басып тора. Җил белән килгән көлтә чаклы ут инде Габбас муллаларның йорт түбәсен яндыра башлады.

Нишләргә? Нишләргә?

Иң әлек сыер абзарын ачарга кирәк. Менә син, хәерсез, абзарны ул кичтән йозак белән бикләп куйган икән. Ачкычны кая куйганын үтерсәң дә хәтерләми. Ул ишегалдында чабулап йөргән арада ихатага ха-

лык тула башлады. Хәнифәне баласы-ние белән жилтерәтеп алып чыгып киттеләр. Ул, ни эшләгәнен белештермичә:

— Өйдә песи калды, песи калды! — дип кычкыра һәм бармаска теләп карыша иде.

Аны югары очка, үзе туып-үскән йортка алып кайттылар, — беркая да чыгармаска кушып, янында олы апалары Банат белән Бануны калдырдылар.

Халык килеп җиткәндә инде мулла йортын ут чолгап алган, өйне тышлаган коры такта чатыр-чотыр яна, кандай кызыл шәүләләр биешкән күк йөзенә беләк буе утлы кисәүләр очып, буяулы калай түбәгә шапылдап килеп төшә иде; мулла йорты янына җыелган халык янгын сүндерүчеләргә тиешле-тиешсез киңәшләрен кычкырып тора иде.

Туксан яшьлек Зиятдин карт кәкре артыш таягына бөтен гәүдәсе белән яткан:

— Ут — ходай тәгалә биргән каза, су белән генә сүндереп булмый аны. Кара тавык йомыркасын ыргытырга кирәк. Кемдә кара тавык йомыркасы бар?

Өч яшьләрендәге күк байталны чаптырып, Нажия Уразаева килеп җитте, җинел сиртмәдән җиргә сикереп:

— Р-разойдись! Кемгә әйтәләр?! — дип кычкырып җибәрде. Нажиянең башсызлыгын белгәнгә, халык, бәладән башаяк дип, артка чигенде, бала-чага күрше як койма башларына, капка төбәләренә үрмәләде; Салагыштан, Яуморзадан, Машик-Пилгадан килеп җиткән янгынчылар өч насостан берьюлы ут өермәсенә су коя башладылар, атлы мичкәләр тегермән буасына су алырга дөбер-шатыр чапты; акылына килеп өлгергән ир-ат, өй эченә кереп булмаслыкны абайлап, абзардагы мал-туарны коткарырга ташланды; котырып үкергән коба сыер белән башмак тана лом белән каерып ачкан абзар ишегеннән атылып килеп чыктылар да, күзләренә ак-кара күренмичә, кырга чыгып чаптылар. Урам тулган халык, тапталудан куркып, ике аякка ауды. Әмма сарыкларны абзардан чыгару берничек тә мөмкин булмады. Алар ишекне дә, капканы да күрмиләр, дөрләп янган утка ыргып сикерәләр дә, дары мичкәсе кебек шартлап, егылып төшәләр иде. Шуны күреп торган бер хатын, битен кулы белән каплап, акылдан язган кешедәй, ачыргаланып кычкырып җибәрде.

Таң атып килгәндә янгынны туктаттылар. Төнге пожар, җиде йорттан кара баганалар һәм тырпаеп торган морҗалар гына калдырып, сүнде. Көл өеменә әйләнгән йорт урыннарыннан әле һаман кисәү исе аңкып тора, су парлары белән кушылып, аксыл төтен пыскый иде.

Көн яктырганда Габбас муллалар кунактан кайтып төште. Шәмсениса абыстай, йорт урынына көл өемен күргәч, кычкыра да алмыйча, тораташ катты. Габбас мулла тарантастан төште, кара күмер булып калган йорт урынын бер әйләнеп чыкты, бик мескен хәлдә бөгәрләнеп яткан комган калдыгын читек башы белән әйләндереп карагач, үзләре янына җыела башлаган халыктан:

— Хәнифә кайда? Балам исәнме? — дип сорады.

Мулла белән абыстайны Хәнифәләргә алып киттеләр. Хәнифә аларны, баласын күтәргән килеш, капка төбендә каршылады. Габбас мулла белән Шәмсениса абыстай, тарантастан төшеп, аның белән сүзсез генә исәнләштеләр. Алар хәзер өчесе дә бертигез: Шәмсениса абыстайны Хәнифәдән аерып торган мал-мөлкәт төтен булып күккә очкан иде.

Хәер, Хәнифә хәзер алардан өстенрәк: аның кул көче бар, яшьлеге бар, эшлисе дә ашыйсы, шуның өстәвенә, күз нуры булган Шәфикасы, күңел юаткычы үзе белән калган иде.

Тагын бер атнадан Шәмсениса абыстай Казан каласына, кызы Нурия янына китеп барды, аннан ул хат та язмады, хәбәр-хәтерен дә ирештермәде — суга төшкән кебек югалды.

Уттан зыян күргән кешеләргә йорт салыр өчен авыл Советы урманнан диләнкә бүлеп бирде. Тик Габбас Уразаевка гына, мулла булганы өчен, диләнкә эләкмәде. Моңа ул бик гарьләнде, ник дисәң, авылның диндар картлары аны, кызын Пәнҗәрдә рус мәктәбендә укытканы өчен, кяфер дип, кызыл мулла дип күзен ачырмасалар, инде менә бәлага тарыгач, авыл Советы башлыклары да аның хәленә кермәде, аны буржуй сыйныфына яздылар. Монда аеруча тырышканы аның туганы Нажия Уразаева булды. Габбас мулланы яклап, аның гражданнар сугышы заманында берәүгә дә зыян китермәгәнен бик тырышып сөйли башлаган Әфләтүн абзыйга ул авыз ачарга да ирек бирмәде.

— Бу ниткән әкәмәт? Бу ниткән көпә-көндез мулла-мунтагайны яклап утыру? Кайсыгызның ике катын асрарлык хәлегез бар? Кайсыгызның кара туры айгыр җигеп, тарантаска кырын төшеп, кунакка йөрер хәлегез бар? Кем дә кем Габбас мулланы яклый, ул безнең өчен контра! Габбас Уразаев мужиктан чыгып, гошер садакасына корсак күпертте, мулла булды, пожар аны авыл ярлылары белән бер рәткә китереп куйды, менә хәзере ул тагын шул хәлне үз шкурасында татып карасын әле.

Авылда башлангыч мәктәптә балалар укытып йөргән Зариф Сарбулатов, халык телендә йөргәне — «Усал Зариф», мөгаллимнәргә хас сабырлык белән урыныннан торды, сул күз астында тартыша башлаган тамырны басарга тырышып, беркавым дәшми торды, аннары мәрҗән тезгән кебек йомры-йомры сүзләрен тезә башлады.

— Иптәшләр, ил агалары, без тагын бер мәртәбә уйлап карыйк әле, яхшыны яманнан, уңайны киредән аерып карыйк. Габбас Уразаев егерме ел буена Зартугай балаларына белем бирде, бүгенгесе көнне мин үзем дә, наркомзем булып эшләгән Ибраһим абзый да, Казанда күренекле урыннарда утырган Габидулла абзыйлар да, барыбыз да Габбас Уразаев шәкертләре бит. Казна акчасы алып, жалуньяга укытмады бит ул безне, мужик ни китерсә, шуңа риза булып укытты. Бирик без аңар диләнке, мулла бу дип бер яклы гына карамыйк.

Нажия Уразаева икенче кабат урыныннан сикереп торды:

— Мин Сарбулатов иптәшне аңламыйм! Аңлаудан баш тартам. Син түгелме, Усал Зариф, Зартугай буйларында ак әфисәрләрнең йөрәгенә шом салган кеше? Син түгелме Усал Зариф, Таминдар Тураев мәдрәсәсеннән бунт ясап чыгып киткән кеше? Син түгелме Нәбкәй старосталарның, кулак куштаны Кысык Минҗаннарның Шәрифҗан-активистны кыйнап үтергәннәренә шаһит булучы, и шулай ук безнең пролетар сыйныфының нахакка түгелгән каннарын ак әфисәрләрнең каны белән түләтүче? Инде бүген мулла-мунтагайны, гошер-фытыр козгыннарын яклап утырасыңмы? Син безгә, ярлылар комитетына, туп-туры әйт: башымдагы кызыл йолдызлы шлемым хәрәм диген, салдырып алыгыз, диген, мин үзгәрдем, мин буталып беттем диген, ул чагында мин сине аңлармын, Усал Зариф, мин сиңа безнең белән бер юлдан атламаучы итеп карармын, и шулай ук авыл крәстияннәренә балаларын укытырга сиңа китермәүләрен үтенермен!

Бәлки мөгаллим Сарбулатов үзендә Нажия Уразаеваны җиңә алырдай көч тә тапкан булыр иде, әмма шул мәлне авыл Советы башлыгы, унсигезенче елдан ук коммунист Мәрдән Мурзин Нажия-милиционерны яклап чыкты.

— Кем дә кем Габбас муллага булыша, кем дә кем аны кызганып күз яше түгә, ул безгә юлдаш түгел! Халыкка әйтегез, кем дә кем шундый эш эшләргә, буржуй сыйныфын арттырырга өстенә ала, кәнсәләргә чакыртып, иманын укытам!

Мәрдән Мурзинны авылда элеккерәк елларны алай ук кансыз, ми-

һербансыз кеше дип белмиләр иде. Чехлар килгән заманда тирә-як авылларда түгелгән кан-яшь аның бәгырен таштай каты итте. Кысык Минжанны, Нәбкәй старостаны ул үз кулы белән Алабуга чекасына илтеп тапшырды. Шунлыктан йортсыз калган Габбас муллага ярдәм итәргә ашкынып торучылар бигүк күренми, дин-шәригать юлында шәһит китәргә әзер торган берничә кеше генә, авыл йоклагач, җиде төн уртасында яки таң әтәчләре кычкыра башлаган чакларда гына, Габбас мулла яшь хатыны белән яшәгән келәткә килеп, садакаларын биреп китәләр иде. Күбрәк Габбас белән Хәнифә икесе эшләделәр. Йорт урынын атна буе көлдән, күмердән әрчеделәр; бәхетләренә ак келәтнең бер стенасы гына күмерләнеп калган, түбәсе дә, өч стенасы да исән иде, көннәр әле җылы булганлыктан, болыннан чабып алып кайтып киптергән коры печән өстендә йокладылар,— хәзер инде хәзрәтне нәүбәт саклмауда гаепләрдәй кеше янда юк, ул тавыш-тынсыз Казанда ята иде...

Көннең-көн буе көл өеме, күмер өеме актарганга, алар берәр сәгать эшләү белән үк җен кебек каралалар, бер-берсенә комганнан су салып торган чакта, көлмичә һич кенә түзә алмыйлар иде.

Көтелмәгәндә килгән бәла-каза аларны бик тиз туганлаштырды. Икесе тиң крестьян баласы, икесе тиң буразнада аунарга яратылган кеше, көне буе эшләп арыгач, бәләкәчләре Шәфиканы урталарына алып, ак келәттә, яшел печән өстендә дөньяларын онытып йоклап китәләр иде.

Ниһаять, йортның үзен кайгыртыр көн дә җитте.

Габбас мулла ак келәттә сакланып калган төлке тунны, коба сыерын сатты. Ул гына да җитми иде, җаны сыкрап булса да, кара айгырны сатты. Айгырның даны тирә-күрше авылларда күптән йөри иде — анысын Габделхәлим абзый алды, кара айгыр бәрабәренә ул иске йортын һәм, тояк урынына тояк булсын дип, җирән биясен бирде. Авыр көнендә Габбасны да хур итмәскә кирәк. Ни генә дисәң дә, Шәмсениса, Гыйматдин хаҗидан тол калгач, Габбас белән көн күрде бит. Ләкин мондый уйлар кызыл малчы Габделхәлимнең үз күңелен юатып рияллануы гына иде. Чынында исә аны яңа заманның аяусыз законнары стенага китереп терәде: хәзер ул бер генә йортлы, бер генә атлы булып калырга, тагын бер атын шыпырт кына сатып җибәрергә тиеш иде.

Төлке тунны да Габбас мулла аңа сатты. Кара айгырга алыштырган җирән биягә утырып, төлке тунны ул Габделхәлим кайнагасына үзе алып барды. Кызыл малчы аны элекке заманнардагыча яктырып каршыламады. Дегет белән майлаган күн итектән, постау курткадан, туры якалы кара сатин күлмәктән, кара түбәтәйдән иде.

«Киемне алыштырган бу, хезмәтчеләре киеменә якынайта төшкән, карт төлке», — дип уйлады Габбас мулла. Ул аның әле күптәнмени туры итеп тегелгән парча җилән, парча камзул, атлас күлмәк киеп, башына алтын ука белән чиккән кәләпүшне кырын салып йөргән заманнарын хәтерли, әфлисун төсендәге ут янып торган киң ыштан балагын бизәкле читек эченә тыгып йөргәнен хәтерли. Татар миллионерларын Таминдар Тураевларда ниндирәк каршылаган иде! Ә хәзер үзенең олаучысы Гарифулла бабай киемнәрен өстенә чәпәгән. Дөнья аның битенә дә үз бизәкләрен өстәгән: калфак чугына ярарлык чем-кара мыек, түгәрәк кара сакал урынына бүре йонындай сорыланып һәм киезләнеп калган сакал-мыек ябыштырып куйган.

— Әссәләмәгаләйкүм, еллар имин булсын! — дип сәлам бирде Габбас мулла.

— Шулай булсы-ы-ын,— дип ыртәгәндәй, иренеп кенә әйтеп куйды кайнагасы.— Нинди бәла-каза сине безнең якларга китерде, менла кем Габбас?

— Бәла килгәндә кем дә килер, Габделхәлим кайнагай, мин әле, аллаһы тәгаләнең ризалыгы белән, сине баетырга дип килдем.

— Бик хуп, бик хуп, менла кем Габбас. Әллә, мин әйтәм, казалы булгачыннан, соранырга килгәнсеңме дип торам, хи-хи-хи, баетырга исәп тотып йөргәч, бик хуп. Әйдә, өйгә керик, чәй янында иркеннәбрәк сөйләшербез...

Самавыр кайнап чыкканны көткән арада Габделхәлим кайнагасы шактый ук төче телләнеп сөйләп алып китте:

— Әдәм әйтеп әдәм ышанмас, янып китүегезгә бик тә кайгырдым, менла кем Габбас. Үзем янганнан да болайрак кайгырдым. Үземне синең алда гел дә менә гаепле санап йөрим. Мөселман кардәшемне юри бәлагә тарттырган кебек. Әллә, мин әйтәм, безгә кунакка килмәгән булсалар, янмыйча да калган булырларые дип фикер йөртәм. Чарлаклы, ике катлы йортыгызны кызганып үләр чиккә җитәм. Уйлыйм-уйлыйм да тагын бер тапкыр: сабыр итәргә кирәк дип уйлап куям. Киләсе каза булса миңа килмәсәгез дә килерие. Ходаның кодрәте киң: тели — бирә, тели — кире ала. Шәмсениса ни хәлләрдә соң, бик жыламыймы?

— Белер хәл юк,— диде Габбас мулла, аермачыгын әйтмичә.

— Туктале, син бик томанлы сөйләшәсең? Әллә кайтмадымы әле Казаннан?

— Кайтмады шул.

— Хәбәр-хәтере дә юкмы?

— Юк. Күрәсең, минем аңа кирәгем калмагандыр инде. Нурия белән икәү генә яшәргә исәп тота торганнардыр.

— Ала-а-ай...— диде кызыл малчы Габделхәлим. Йөзе бик кинәт, күзгә күренеп кырысланды, бүре йоны төсле соры мыегы тырпаебрак китте. Сүзен ул өзеп әйтте:— Кая, баетырга дигәнең нәрсә? Күрсәт!

Габбас ак бәзгә төргән төлке тунны тарантастан алып керде.

Кызыл малчы Габделхәлим төенчек чишкәнне бер дә исе китмәгән кыяфәт белән, сабыр гына көтеп торды; Габбас мулланың уалып китәргә торган әйберен тоткандай, өф итеп кенә тотып торган кулыннан дорфарак бер хәрәкәт белән тунны алып, шундук җиңнәрен әйләндерә, җиң төпләрен бармаклары белән капшый башлады, итәк очларын сыпырып, тартып-йолкып, берәм-берәм тикшереп чыкты, урыны-урыны белән йонын чеметеп карады, янә дә җиңнәрен кире әйләндереп, исе китмәгән кыяфәт белән тунны хуҗасына кире кайтарды.

— Нәрсә, ошамыймәллә?— диде Габбас мулла, сабырлыгы бетеп.

— Ошамый,— диде кызыл малчы.

— Иске дисеңмени?

— Юк.

— Нигә?

— Төлке хәзер фасунда түгел. Сусар булса алырыем.

— Һе,— диде Габбас мулла, хәтере калып. Тунны сүзсез генә кире дән ак бәзгә төрде, тарантас башына илтеп тыкты да, печән ашап торган атының аркалыгын күтәреп, йөгән тезгенен дугага бәйләргә тотынды. Кызыл малчы ул кадәресен сабыр гына күзәтте, эш аркалык күтәрүгә килеп җиткәч, шул ук гамьсез тавышы белән сорады:

— Торып тор, нигә сатасың тунны, кайнагай?

— Йортка кирәк.

— Мин бит инде сиңа йорт бирдем. Ат урынына ат бирдем.

— Йортны бит аны, кайнагай, салдырасы бар әле.

— Ну, ярый, миннән булсын яхшылык: калдыр. Ике йөз тәңкә бирәм.

— Ике йөз?!

— Ә нигә шаккаттың?

— Әллә син көләсеңме миннән, кайнагай? Мин бит аны теге заманнарда өч йөз тәңкәгә алдым. Исеңә төшереп кара әле, ул чакта өч

йөз тәңкәгә мин сиңа биргән төсле нәсел айгыры алып буладырые, хәзерге ике йөз тәңкәгә нәрсә алып була?

— Ул чакта бит ул! Ул чакта, менла кем Габбас, минем сандык-сандык кызыл малым барые, Гарифуллаларым, Шәрифуллаларым барые. Мине яклап йөрүче Таминдар бай барые. Кайда алар хәзер минем олаучыларым? Мине яклаучыларым? Я, кайда?— диде ул, алдында кан дошманы торгандай кычкырынып. Аннары, кызып киткәнен аңлап, йомшый төште:— Менә сиңа өч йөз тәңкә көмеш, санап ал да яхшылап, йортыңны салдыра башла, шуннан артыгы бер тиен дә юк, монысын да кайнагай булганың өчен бирәм, миннән булсын бер яхшылык.

— Мин сиңа, Габделхәлим абзый, гозер белән килдем, гозер белән килгән мөселман кардәшеңне талау яхшы эш түгел, аласы булсаң, чынлап торып сөйләшик тә мин кайтып китим.

— Ярый, синең бәяңне ишетеп карыйк.

— Тун, Габделхәлим абзый, кимендә ике мең ярым тора. Ул әле өр-яңа. Кунакка киеп чыкмаганда минем аны алып та караганым булмады, келәттә төреп куйган килеш торды да торды. Менә шуңа күрә...

— Син миңа аңлатма, Габбас, яратмыйм мин озаклап аңлатканны. Син тиярен генә сора. Күпме бирим?

— Миңа йорт салдырырга мең ярым акча кирәк. Өстәлдер, савыт-сабадыр ише нәрсәләргә өч йөзләп кирәк булыр: барысын яңабаштан башлыйсы бит. Шулай итеп, җәмгысы — бир син миңа бер мең дә сигез йөз тәңкә акча, мин, аллага тапшырып, үз юлыма китеп барыйм.

— Ярый, менә сиңа түп-түгәрәк бер мең тәңкә! Калганын сорама да, рәтем дә юк, риза булсаң бир кулыңны!— Габделхәлим алтын балдаклы уң кулын югары күтәрде, сул кулы белән Габбас мулланың кулын тотып алды.

Тегесе, кулын тартып алып, бик кискен баш чайкады.

— Юк, кайнагай, булмый. Пычаксыз суйма син мине, көпә-көндез кычкыртып талама,— диде Габбас мулла, уңайсызланып. Аның борын очы тирләп чыкты. Сакалын учлап, башын түбән иде. Озак кына шул хәлендә басып торды, аннары башын күтәрде:— Син ходаның рәхмәтле бәндәсе, алланы бар дип вә бер дип белсәң, башың белән уйлап кара, минем пожардан калган бердәнбер мөлкәтем шушы лабаса! Инде аны да шалкан бәясенә биреп кайткач, мин кая барам? Яле, әйтеп кара, кайнагай, йортны нәрсә белән салдырам? Осталарга акча каян алып түлим?— Габбас мулланың тавышы калтырап китте, күзләре дымланды.

— Авыл халкы булышмыймыни?— диде Габделхәлим, йомшый төшеп.

— Булышмый...— Сүзсез торгач, өстәде:— Авыл Советы рәисе миңа булышканнарны Себергә олактырам, ди. Нәҗия булып Нәҗия хәлемә кермәде. Туганнан туган сеңлем бит, югыйсә. Кулына пугач тотып, халыкны куркытып йөри. Имансыз, затсыз кавем. Ул бит безне, әйләнә-тирә муллаларын, унтугызынчы елны Алабугага куып китереп, айт-двага бастырып йөртте, ай буе кар ерып урман кистерде. Кемнәр белән диген? Поплар белән!

Кызыл малчы Габделхәлим чаларган көлсу сакалын бармаклары белән аралаштырып, кашларын җыергалап, Габбас мулланы бик житди рәвештә тыңлады. Тыңлап бетергәч, хәленә кереп сорады:

— Банкыга салганың бер дә югыемыни соң?

— Банкыдагысын революция алып калды бит. Совет чорында садака бирергә бик атлыгып тормыйлар, чамалап кына бирә башладылар.

Аннары... мин бит, кайнагай, дөресен әйткәндә, гомерем буе үз күчем белән дөнья күргән кеше. Гыйматдин хаҗидан калганнары төтен булып күккә очты...

Кызыл малчы, ул тирәдә сүзне озынга сузмаска теләп, кисәк кенә бүлдерде:

— Ярый, менла кем Габбас, күңел булганчы сөйләштек. Бигайбә, эш кешесенең эштә булганы мәслихәт. Мин сиңа тиярен бирдем, бүтән бирә алмыйм. Үзем дә бөлеп беттем, сәвит көн саен налукны арттыра тора, бу исәптән үз теләгең белән Себер китәрсең, валлаһи! Әнә Саранбайлар, Яуморзалар, Тәмәк-Чүрәкәйләр иле-йорты белән кузгала, ди. Мал-мөлкәтен сатып Себергә, Уралга китә. Байлар түгел, урта хәлләр. Ник диген? Нажия Уразаева кебек имансызлар, аркага мылтык терәп, күмәк хуҗалык ясыйсылар, имеш. Халыкны күмәк итеп бер йортка тутырасылар, болын чаклы бер юрган ябындырасылар, кем катыны кем белән була — бер хода гына белә. Менә шундый болгавыр заманда мин синең төлке туның белән нишлим?

Габбас мулла, сатулашуның соңгы ноктага килеп җиткәнен аңлап, ялварулы тавыш белән әйтте:

— Габделхәлим абзый, мин сине мал-мөлкәтле кеше дип кенә түгел, кайнагай итеп тә килдем. Туннан башка минем кыртышым да юк. Хәлемә кер, үтермә, мөмкинчелек бир миңа, йортны салып керим, минем дә, дөнья булгач, кирәгем чыккан чаклар булыр, дөнья — кулаcа, бер басмаса бер баса... Арттыр тагын биш йөз.

Бер мең дә өч йөзгә килештеләр. Кызыл малчы Габделхәлим, алданудан куркып түгел, Габбас мулланың бүтән беркая да борын төртә алмаслыгын белеп, шул сумада тәрәлде дә калды: бер генә тиен дә арттырмады да, киметмәде дә.

Габбас мулла юл буе кайнагасының комсызлыгын, кычкыртып таларга әзер торуын уйлап кайтты. Нинди айгыры китте аның аңа, нинди сыеры китте. Төлке тунны, кешенең соңгы киемен, ярты бәясенә алды бит, комагай зат, бәке авыз. Ачуы килеп, җирән биягә кычкырып җибәрде:

— На, үләт ялагыры, Габделхәлим йолкышы! Бер аягыңны алганчы икенче аягыңны эт ашый.

«Кунак-кунак уйнаулар, Салагыш базарына килешли, күчтәнәч алып килүләр картаеп тол калган Шәмсенисага түзгән өчен генә булган икән. Күрербез менә хәзер, Шәмсениса минем йортка аяк басып карасын!» — дип ярсынып уйлады. Ул байлыкның кешеләрне затлы һәм затсыз нәселгә бүлеп йөрткәнлеген менә хәзер тагын бер мәртәбә — бу юлы үз җилкәсендә татыды.

Осталар аңа ике көннән йорт салырга керештеләр. Йортны, элекке кебек үк дәү, элекке кебек үк бизәкле булмаса да, Имам Каһармановка һәм имансыз Нажиягә үч итеп, ике катлы, болдырлы итеп салдырды. Авылның балта остасы Мәснәви, дин юлында җаннарын фида кылырга торган тагын берничә карт, өмә ясап, хәзрәт йортын бер ай эчендә җиткезеп бирделәр.

Соңгы эшләрен хәзрәт үзе күз-колак булып эшләтте: биек урыс капка куйдырды, өй түре койманың өч торыгын челтәрле рәшәткә белән бизәттерде. Өч төп канәфер куагы, сәрби һәм шомырт үсентеләре утыртты. Килер заман: өй алды бакчасында шаулы яфраклар эчендә таң кошлары сайрар...

Хатыны Хәнифә белән бәләкәче Шәфиканы югары очтан алып кайтты. Муллалыгын бөтенләй диярлек ташлап, башкалар кебек, сука сукалап, тырма тырмалап, чәчү чәчеп, яңа нигездә яңача көн күрә башлады.

## III

Имам Каһарманов, балаларын урамга чыгарып җибәреп, шыңгырдавыклы зур сандыкны ачты. Идәнгә тезләнгән хәлдә, ярты гәүдәсе белән сандык эченә тыгылып, башы белән сандык капкачын терәп, үзенә кирәкле кәгазьләрне эзли башлады.

Шыгырдап ишек ачылган тавыш аны сандык эчендә казынудан туктарга мәҗбүр итте, ләкин әле ул сандыктан башын тартып алырга ашыкмады. «Кызларымның берсе кергәндер»,— дип фикер йөртте. Ләкин ни хикмәт — керүче дәшми. Әгәр аның Хуриясе яки Һәдиясе кергән булса, күптән инде әтисе янына йөгереп килер, җилкәсенә менеп атланыр, муеныннан кочаклап:

— Әти, әти!— дип тәкатьсезләнә башлар иде.

Имам сандык эченнән чыгып, бер кулы белән сандык капкачын терәде. Ишек төбендә үк, бармагын авызына кабып, ялан аяклы биш яшьләрендәге кызый басып тора. Ул, күрәсең, өстендәге алма бизәкле яңа кызыл күлмәген «котлатырга» кергән, шомырт кара елтыр күзләре белән өй эчен актара — иптәшләре Хурия белән Һәдияне эзли иде бугай.

— Мулла кызы, кем кирәк?— диде Имам.

«Мулла кызы» бармагын авызыннан алды, сандыкка таба килә башлады.

— Има-а-ам, сандык капкачыңны тотып торыйммы?

Каһарманов чак кына көлеп җибәрмәде. Биш яшьлек кызый аңар, кырык яшьлек ир уртасына «Имам» дип дәшә. Абый юк, фәлән юк. Ләкин Каһармановка көләргә ярамый, ул тагын бер сәгатьтән бу кызыйның әтисен — Габбас мулланы раскулачивать итәргә керергә тиеш. Мондый чакта күңелне нык тоту хәерле. Волком вәкиле белән авыл Советы рәисе килеп җиткәнче аның әле тиешле квитанция кәгазьләрен дә табып куясы бар.

Шулай да һәркемгә хас булган кызыксыну тойгысы аның түрәлеген җиңде.

— Ә ник тотып торасың син сандык капкачын? — диде, кызыйның баш түбәсенә күбәләк ясап беркеткән ак тасмага күз төшереп алды.

— Капкач башыңа төшсә?

— Төшсә ни?

— Башың авыртыр бит.

«Ах, син, кәлтә җылан, дөньяга туганыңа күпме генә, ниләр уйлап тора бит!» — Каһарманов, олы кешегә сынап караган кебек, күбәләккызны күздән үткәрде. Коеп куйган әтисе. Күзләр — гел дә Габбас мулланыкы: шешмәк кабаклы, чем-кара, кояш нурыннан җемелдәшеп, чаткыланып торалар.

Каһарманов инде бүген икенче мәртәбә сыйнфый дошман кызына күңеле йомшавын сизеп, кырыс кына дәште:

— Әй, мулла кызы, кил әле якынрак, ябып куйыйм үзеңне шушы сандыкка! — Бер кулы белән сандык капкачын этеп җибәрде. Сандык шап итеп ябылды, бикләре зыңгылдап куйды.

«Мулла кызының» күзләре зураеп китте, сандык ябылган уңайга ул сискәнеп җиргә чүгеп куйды һәм, кычкырып елап, урамга йөгерде.

...Тагын ярты сәгатьтән дүрт кеше Совет йортына җыелдылар. Кызыл гвардияче Кадыйр Гонцов, партячейка секретаре Имам Каһарманов, Совет башлыгы Мәрдән Мурзин һәм җир белгече Солтан Айдаров.

— Иптәшләр, бүгенгесе көнне безнең алга миравай революция китереп куйган бурыч бер генә: Габбас Уразаевны раскулачивать итү. Дин әфиунын халыкка таратучы дошман илиминт буларак, Габбас мулла авылдан куылырга, мал-мөлкәте тартып алынырга тиеш. Мин шулай уйлыйм. Башкалар ничек уйлый? — Каһарманов, зур авызы

белән бергә, аска төшеп киткән ияген ябып, күз йөртеп чыкты. — Кстати, волкомның Шәяхмәт Айдаров безгә, җир бүлү, межалар тарихындагы низагларны хәл итү өчен наркомземнан иптәш чакыртты. Барыгызга да мәгълүм: Айдаров иптәш, ягъни ярлы крәстиән малае — безнең үз авылыбыз Зартугайныкы, шушы җирдә, Иш буенда аунап үскән егет. Азин дивизиясендә ак генераллар белән сугышты. Өстәвенә, совет учреждениесендә югары образование алып чыккан спис. Җир бүлгәндә күрдегез: миравай революция өчен көрәшергә әзер. Габбас Уразаевны раскулачивать итүдә катнашырга теләк белдерде. Как райком вәкиле и наркомземнан җибәрелгән спис буларак, безнең аны үзебез белән алмаска хакыбыз юк.

Буденновкалы, тырпайган каты мыеклы Кадыйр Гонцов партячейка секретаренең юлын бүлеп куйды:

— Сүзем бар сиңа, Каһарманов. Читкәрәк китик әле.

— Әйт сүзеңне, монда чит кеше юк.

— Партийный эшкә барабыз. Чиста эшкә. Айдаровны алып бару килешерме? — диде шаһитлыкка килгән Гонцов.

— Ә нигә?

— Солтан — Габбас мулланың кияве.

— Кияүнең монда ни катнашы бар?

— Туган-тумачалык килеп чыкмасын! Айдаровның ныклыгы житмәсә? Җан тартмаса да, кан тарта дигәне бар бит әле!

Каһарманов, шаһит булып килгән Кадыйр Гонцовның сүзен тыңлап бетергәч, кинәт гасабиланып:

— Давай, егетләр, бүрәнә аркылы бүре кумыйк. Айдаровның кем икәнен сез бик яхшы беләсез. Ике ел буена Колчакка каршы сугышты. Абыйсы Шәяхмәт — кристальный большевик, унөченче елдан РКП(б) члены, үлем баржаларын узган кеше. Айдаров кебек кешенең намуслы булуыннан шикләнү пазур!

— Син бик чәпчемә, Имам. Алып барабызмы, юкмы? — диде авыл Советы башлыгы.

— Барабыз.

— Ул-бу чыкса, син җаваплы. Син — партячейка секретаре.

Алар бүтән сөйләшмәделәр. Каһарманов озын чандыр гәүдәсе белән нелә төшеп, ара-тирә ямьшәйгән иске кепкасын исән кулы белән төзәткәләп алдан атлады, тәбәнәк, базык гәүдәле Мәрдән аның артыннан житешергә теләп, юырттырып барган җирдән, Имамның йөзенә карарга тырыша, әмма тегесе бөгелеп алган да, әллә кәефе китеп, әллә үз уйлары белән, алдына-артына карамый элдертә, пинжәк чабуы җилфердәп ачылган чакта биленә таккан наган кабурасы күренеп кала иде.

Мулла йортының буяулы сары капкасыннан керделәр.

Мулланың яшь хатыны Хәнифә, күлмәк итәкләрен ыштан бөрмәсенә кыстырып, ишегалдына кер юган суны түгәргә чыккан, биш яшьлек кызы Шәфика әнисенең күлмәк итәгенә ябышып килә иде. Кыз бала, Каһармановны күрүгә, шырыйлап өйгә йөгерде.

Хәнифә абыстай, кулына тоткан шакшы сулы ләгәнен җиргә куярга да, түгеп җибәрергә дә белмичә, ялан аякка тирән эчле галош кигән килеш, шәрә ботын ялтыратып ишегалды уртасында басып калды.

— Хуҗа өйдәме? — диде Каһарманов беренче булып.

— Өйдә.

— Чыксын әле, чакыр.

— Нигә?

— Йомыш бар.

— Бәтәч! Көпә-көндез бала-чага куркытып, эт көтүе чаклы булып нишләп йөрүегез бу? Бәндәдән курыкмасагыз, алладан куркыгыз.

Култык астына папка кыстырган Мәрдән алга килеп чыкты.

— Иптәшләр, минем арттан! — Зур-зур атлап, йортның болдырына менде, ишекне каерып ачам дигәндә, каршыларына килеп чыккан Габбас муллага юлыкты.

Әллә берәр җиргә барырга җыенган, әллә көтелмәгән кунакларның киләсен сизенеп, юри әзерләнеп торган — мулла парадный формада чыккан иде. Башында — ап-ак бохар чалма, өстендә — парчалы яшел чапан, аның җилбәгәй җибәргән чабулары аша, атлас казаки, атлас чалбар күренә, аякта — сафиян читек.

Болдырда ул, кайсыдыр театр сәхнәсеннән килеп төшкән артист шикелле, көтмәгәндә пәйда булды. Каушамый-нитми, кулын күкрәк турысына кушырып, горур кыяфәт белән:

— Әссәләмәгаләйкүм, хуш киләсез, кунаклар! — дип, матур, куе тавыш белән сәлам бирде.

Мондый каршылауны көтмәгән кунаклар бер генә мәлгә каушап калдылар. Уңайсыз тынлык булып алды.

Габбас мулла Хәнифәгә өйгә кереп китәргә кушып ым какты. Хәнифә, ләгәнен ишегалды уртасына куеп, юл уңаенда күлмәк итәген тартып төшерә-төшерә, әллә ничек чыгымчы ат кебек, яны белән, яны белән ишеккә таба китте.

— Тукта! — диде аңа Каһарманов.

Хәнифә абыстай эшләрнең уен түгел икәнен хәзер генә төшенеп алды бугай — ире янына килеп басты. Бохар чалмасыннан, атласка, ефәккә төренгән Габбас мулла янында ул хәзер төсе уңган ситсы күлмәктән, артка чөеп бәйләгән ак яулыктан, ялан аякларына кигән тирән эчле галоштан янәшә куеп булмастай контраст булып күренә иде. Ләкин ул хәзер аннан китә дә алмый, чакырылмаган кунакларның авыр күз карашларыннан куырыла төшеп, ул анда басып торырга мәҗбүр иде.

— Хәбәрне әйт! — Каһарманов авыл Советы башлыгына борылды. Мурзин алга чыкты, папкадан кәгазь чыгарып:

— Гражданин Уразаев, сез, авылда дин агуы таратучы дошман элемент буларак, раскулачиваниегә эләгәсез,— диде.

— Йа хода, бер таландым бит инде.

— Бүлдермәвегезне үтенәм, гражданин Уразаев. Сез, авыл Советы һәм партячейка карары белән, ике катлы, чарлаклы йорттан чыгарыласыз. Бүген үк. Мөлкәтегез конфисковать ителә.

Чакырылмаган кунаклар болдырга килделәр.

Габбас мулла тик шунда гына Солтанны танып:

— Кияү! — дип кычкырып җибәрде. — Минем ни гаебем бар? Кемгә минем начарлыгым тигән? Күзләрен наданлык баскан кешеләр ябырылсын да ди, син бит син... син бит укымышлы кеше ләбаса!

— Бу... мин чыгарган закон түгел,— дип, Айдаров йомшаграк тавыш белән сөйләнә башлаган иде, Каһарманов, Солтанга сүзен әйтеп бетерергә ирек бирмичә, барысын берьюлы ашыктырып, өйгә алып кереп китте. Габбас мулла да өйгә керергә мәҗбүр булды.

Команданы Каһарманов биреп торды:

— Биш метрлы ситсы чаршау. Алыгыз!

— Сандык. Эчендәге мөлкәт: кәшимир күлмәк, ситсы күлмәк, шакмаклы йон шәл...

Хәнифә, җан ачысы белән тартышып, сандыктан алып биргән малны бер өемгә салып торган Кадыйр Гонцовның кулына килеп ябышты:

— Бирмим! Үтерсәгез дә бирмим! Мин аларны мулла йортында асрау булып җыйдым. Зартугай хәерчеләренә дигән мал юк монда. Мин үзем хәерче Рамазан кызы! Гомере буена Зартугайга йорт салып, бура бурап торган Рамазан кызы мин. Унсигез елым минем әрәмгә китәргә тиешме? Алай икән, акылыгыз алтын икән. Бик ансат кына килеп, талап китмәкче икәнсез. Монда әле Габбас мулла гына түгел,

мин дә бар. Сез алып чыгып киткәч, кем миңа өс-баш ясап бирер? Кем миңа кәшимир күлмәк алып бирер? Ә минем өстемә кияргә бер кат күлмәгем дә юк чакта сез кайда йөрдегез? Таракан күк ярыкларда посып яттыгызмы?

— Син бит миңа кияүгә чыкмадың. Муллага кияүгә чыктың,— диде Мәрдән Мурзин.

— Ә син мине алам дип килдеңме? Килдеңме? Бәлкем мин мулла абзыйга түгел, синең ише яшь егеткә чыккан булырыем. Рәтең булса. Бәлкем әле син бер тиенгә дә торгысыз печкән тәкәдер.

Идән уртасында сын кебек катып торган Габбас мулла, чамадан тыш уңайсызланып, хатынының җиңеннән тарта башлады:

— Хәнифә, үскәнем, гөлекәем, нишләвең бу? Алар бит барыбер синең хәлеңә кермиләр, алар синнән көләләр генә. Акылыңа кил...

Сыер дуласа — аттан яман. Хәнифә күзенә ак-кара күренмәс дәрәҗәгә җитеп ярсыган иде.

Почмак яктан бәләкәй чемодан алып чыгып килгән Мәрдәнгә очып кунды:

— Кая алып барасың минем кызымның әйберләрен? Атаң малы дип белдеңме әллә аны, хәерче! Кара син аны, табылган акыллы баш! Җыен җүлек, йорт басучы... Салагышыңны тала әнә, Зартугайда синең дәхелең юк!

— Гражданка, тый телеңне, влас вәкилләренә тел тидергән өчен...

— Нинди былач буласыз ди сез. Талаучылар! Көпә-көндез. Менә бусы,— Солтан Айдаровка бармагы белән төртә-төртә өстенә килә башлады:— Менә бусы кабер якасына җиткән Садыйк картны үтерергә тотынды. Иман юк, оят юк! Денсезләр! Ата хәтле атага кул күтәр, имеш. Җирен калхузга талап алды. Садыйк абзый зимнәмир чокырына төшеп яткан. Җирен бирмәс өчен. Ә бу пугачтан атам дип куркыта, ди, тамук кисәве! Иманын каферга саткан, мәлгунь. Чыгыгыз минем йортымнан, күземә күренмәгез. Туктале... мин сезне пумала белән өйкәп чыгарыйм әле!

Башыннан яулыгы шуып төшкән, чәчләре тузгыган Хәнифә мич яныннан көлле пумаланы сөйрәп чыгарып, чакырылмаган кунаклар өстенә китте.

Хатын-кыз белән сугышып тору бөтен авыл алдында абруеңны төшерүдән башкага илтмәячәк иде. Мал алырга килүчеләр дәгъвасыз гына кайтып киттеләр...

Каһарманов Салагыштан атлы ике милиционер чакыртты. Габбас мулланы өйнең бер почмагына, яшь остабикәне икенче почмагына бастырып, бар булган әйберләрнең бөртеген дә калдырмый алып чыкты.

Кичкә таба мулла йортын сүтәргә керештеләр. Каһарманов йортны Совет йорты итеп тау башына салдырды, җилләрдә җилфердәп торсын өчен, йорт башына кызыл флаг кадап куйдылар.

Мулла йортыннан алып чыккан мал-мөлкәтне, каралты-кураны торг белән саттылар.

Зартугай халкы хәзер көн дә саен булып тора торган вакыйгалардан, мәшәкать-гаугалардан арып, йокыга талгач, түбән очның Пәдеш белән Дәүли карт, хәрабә хәленә әйләндерелгән мулла нигезенә килеп, мунча тәрәзәсен чиерттеләр.

Ишек ачарга хәзрәт үзе чыкты:

— Кем әле тагын мондый төндә вакытсыз йөри?

— Без әле бу, хәзрәт. Казаныңны китердек.

Габбас мулланың тавышы калтырап китте:

— Каһармановлар белсә...

— Белсеннәр. Без бит аны урлап алмадык. Үз акчабызга сатып алдык.

Габбас мулла авыз ачып бер сүз дә әйтә алмады, сүз әйтерлек хәле юк — күңеле тулган иде.

Тагын бер атнадан Хәнифә аның бердәнбер исән калган күлмәкыштанын юып бирде, төенчек белән юлга азык әзерләп, Казанга озатып җибәрде.

## IV

Төнге сәгать унберләр тирәсендә ишек шакыдылар. Нурия сәерсенеп караватыннан төште. Бу вакытта аңар шәриктәш иптәшләре дә, туганнары да килми торган иде. Әллә Солтан кайттымы? Йа рабби, алай булгачыннан, нишләп ачмый тора соң әле ул? Кинәт күңеленә килгән шул уйдан, җанын биләп алган сөенеч ташкыныннан зиһене чуалып, берни уйлый алмас дәрәҗәгә килеп, ул ишекне барып ачты, кинәт: «Ай!» — дип кычкырып җибәреп киредән япты. Ишек төбендә мескен бүрекле, билен кызыл пута белән буган чит-ят кеше басып тора иде. Ә ул бер кат эчке күлмәктән чит ир алдына килеп чыкты.

Нурия ашыгып өстенә халат эләктерде, чәчләрен ашык-пошык төйнәп, башына яулык бәйләде. Шуннан соң гына икенче кабат ишекне ачарга җөрьәт итте. Бәлки ачмаган да булыр иде, ишек артындагы кеше бик сак кына, иплән кенә тагын чиертте ишеккә. Авыл мужигының ул кадәр сак кылануы мөмкин түгел, кем булыр бу? Ачаргамы, юкмы?

Ашыгып кына ачып-япкан чакта да кунакның йөзе таныш кебек чагылып калды — авылдашларыннан берседер. Күршеләредер. Бәлки Солтаннан хәбәр китергәннәрдер. Күңеленә Солтан килгәч, ул тагын сак кыланырга кирәген онытып, ашыгып барып ишекне ачты.

Бу юлы аның каршысында — шул ук кызыл путалы, бишмәтле, әмма мескен бүрекле түгел, ак чалмалы әтисе басып тора иде. Ул аны тартып диярлек эчкә кертте, ашыктырып чишендерә башлады.

— Йа рабби, әтекәем, бәгърем, нишләп йөрисең төннең берендә? Киләм дип хат язсаң булмас идемени? Мескен бүректән мин сине танымадым да бит. Исәнме? Нәрсә белән килдең? Поездмы, пароходмы? Ничек килеп чыгасы булдың, авырмыйсыңмы?

— Өйдә кеше юкмы? — диде Габбас мулла, бишмәтен, чалмасын салып.

Нурия аның шыпыртлап әйткән сүзеннән сагая калды.

— Юк, нигә алай дип сорыйсың?

— Әнием кайда соң?

— Аны Бишбалта карчыклары утырмага алып киткәннәр иде.

— Алай икән. Ярар. Утырып бер дога кылыйк.

Габбас мулла көрәктәй дәү кулын бит турысына күтәрде. — Нуриянең җанын айкап, Зартугайлар, Салагышлар, кыңгыраулы атларда килгән Габделхәлим абзыйлары, Таминдар Тураев биләмәләре күңелендә яңарды. Бөтен яшьлеге аның шуның белән тулы иде. Аны кинәт курку алды — узган, сызып ташланылган, киләчәктә кирәк булмаячак тормыш аны куркытты. Ул әтисе янына утырып кул күтәрмәде, әмма әтисен дога укудан да туктатмады. Дога арасына тормыш вак-төяген, көнкүреш хәлләрен китереп кыстырды. Габбас мулла ул сүзләрне вак итеп кабул итмәде, бу аның кызының, бердәнбер баласының тавышы иде, бу тавыш аңа үтә дә газиз иде. Күңеле аның бу йортка иминлек теләде, теле дога сүзләрен әйтте, колагы чишмә чылтыравыдай матур, яңгыравыклы, рәхәт тавышны, кызының тавышын тыңлады.

Дога кылып бетергәч, аңар инде икегә бүленмәскә, ягъни кызының тавышын дога сүзләре аркылы сөзеп алмаска, турыдан-туры ишетергә

мөмкин булды. Рәхәтлек белән бергә, кызының тавышындагы сагаю чалымнары да аның күңеленә инде, бу хәл аны вәсвәсәләндерде.

Нурия примуста чәй кайнатып алды. Сүзсез генә чәй эчтеләр. Аннары Нурия сорады:

— Киявеңне күрмәдеңме? Зартугайга килеп чыкмадымы әле?

— Күрдем. Килеп чыкты.

— Соң? Әйтеп бетер инде. Нигә соң бәгъремне теләсең, әти?

— Минекен күбрәк телделәр.

— Ничек итеп?

— Киявем җиремне тартып алды, Совет — йортымны.

— Моны ничек аңларга?

— Ничек аңлыйсың? Ничек әйткән — шулай аңла. — Габбас мулла чал сакалын учы белән гасабилы угалап, кызының күзләреннән теләктәшлек эзләде. — Имам Каһарманов белән Мәрдән Мурзин авылны таларга керештеләр. Солтан — аларның беренче булышчысы. Җирне тартып алырга кирәк — ала. Газиз атасын да кызганмады. Җир эшкәртү ширкәтен таратырга кирәк — тарата. Күзен дә йоммый. Каһармановларга ияреп, йортымны конфисковать итәргә килде.

— Иттеләрме?

— Итмичә! Сәгате-минуты белән сүтеп алып киттеләр. Мунчада яшибез. Әй бит минем йорттан Гыйматдин хаҗи малын эзләү дөрес микән? Хәнифә белән икәү без күпме интектек! Борыныбыз белән әрчедек пожар кисәвен...

— Инде нишләргә уйлыйсыз?

— Хода белсен. Түләп булмаслык налук китереп салдылар. Беләм мин аларны — Себер җибәргәнче тырышалар.

Нурия әтисенең соңгы сүзләрен Казанга килергә рөхсәт сорау дип аңлады. Һәм ул курыкты. Өч ел рәттән рабфактан чыгарылуы күз алдына килде. Завуч Виннерга ялыну, наркомзем бусагасын таптаулар, җыелышта Нух Галләм сөйләгән ямьсез сүзләр күңелендә яңарды. Әтисе аларга торырга килсә, ул мулла кызы булудан туктамый, нәселнәсәбе аны гомер буе эзәрлекли булып чыга. Әнисе белән алар ничек килешерләр? И каһәр суккан язмыш!

Нурия корымлы калай чәйнектән чәшкәгә чәй агызды. Әтисенең чәй тәлинкәсен тырпайган бармаклары өстенә утыртып, сакал-мыегы эченнән алсуланып сузылган иреннәре белән шул тәлинкәне гүя үзенә тартып китерүен күңеле нечкәрер дәрәҗәдә күзәтеп утырды.

Чәй эчелеп беткәч, сөйләшер сүз дә калмады.

Басынкы, тоныкчырай белән үзалдына карап байтак вакыт сүзсез утырганнан соң Габбас мулла әйтте:

— Менә сиңа килдем инде, кызым, ни диярсең?

Нурия, җаны телгәләнгән хәлдә, калтыранган куллары белән аны муеныннан кочаклады, бите буйлап мөлдерәп күз яше агып төште:

— Әти... Син безгә килми торсаң иде...

## V

Габбас мулла юньле-рәтле йоклый алмады. Төш күрә дә саташып уяна, төш күрә дә саташып уяна. Үзе тагын уянып торып утыргач, нинди төш күргәнен дә хәтерли алмый. Ярты төнгә чаклы шулай саташып чыкты. Аннары төшләр аңа төзегрәк булып керә башлады. Пожарда янып беткән олы йортларын күрде. Чибәр чагы йортның, карап туйгысыз чагы. Ул чарлаклары, ул нәкышле тәрәзә йөзлекләре, ул сары буяулы капкалары! Яз, имеш, тәрәзәләрне ачып җибәргәннәр, сирень-

нәр зәп-зәңгәр, бөтен өйне янгыратып, күкеле сәгать суга, шул ук сәгать граммофон булып уйный; Габбас өстенә сары атлас күлмәк, кара казаки, укалап чиккән кара кәләпүш кигән, зәңгәр атлас чалбарны чигүле читек өстеннән чыгарып салган, Хәнифә янына зофаф кичәсенә керергә җыенып йөри. Керер алдыннан тәсбихын эзли, эзли торгач таба, ул да түгел, зәңгәр атлас чалбары юкка чыга, ап-ак эчке ыштаннан чабулап йөри. Өйнең бер почмагыннан Шәмсениса карчык карап тора. Зур, мәһабәт. Өстендә камзул, башында энҗеле калфак. Габбас чалбарсыз дип көлә. Габбас ояла, бөрешә, якты төшмәсен өчен тәрәзәне авыр кара пәрдә белән капламакчы була. Тәрәзәләрдә — көлтәсе белән ут, әле бер тәрәзәдән килеп керә ут, әле икенче тәрәзәдән... Яңгыр ява, күк күкри. Ләкин берсенең дә тавышы юк. Ут өермәләре генә, яшен булып, бер тәрәзәдән кереп, икенчесеннән чыгып йөриләр. Ул да түгел, Габбас ак ыштаннан, ялан аяк, ялан баш, сакалын сәлперәйтеп, урамда йөри. Урамнар, ишегаллары су белән тулган, су тезгә җитә, су билгә җитә, ләкин үзе юеш түгел. Урамда юллар юылып беткән, яшел чирәм юылып беткән, су кызыл балчык белән кушылып, болганчык кызыл төскә керде, әнә шул болганчык су ишегалдының урта бер җирендәге сиртмәле коеның бураларын җимереп, балчыгын ашый-ашый, чиста сулы коега тулды. Габбас белән Хәнифә икесе бергә, ярым шәрә килеш, коега су тулганны куркынып карап торалар: Габбасның кулында ләгән, ул шуның белән коедан су бушатырга чыккан. Суык, калтырата, кемнәрдер, сәләмә киемле кешеләр, авызларын зур ачып көләләр. Габбас алардан качмакчы була, качар урын тапмый: өйне дә, амбарларны да су агызып алып киткән, капкасыз-нисез лапас кына торып калган, аркылыга-буйга җил йөри, Габбас моннан йөгереп чыгып китмәкче була, аяклары атламый, караса, лапас буенда Имам Каһарманов, — партячейка секретаре — Хәнифәне муеныннан бер кулы белән уратып кочаклаган да суырып-суырып үбә. Габбас йөрәге авыртудан, көнләшүдән иңгырашып куя, Имамның башына ләгән белән доңгырдатып суга да коты чыгып уянып китә...

Уф! Кирәк бит шундый төш керергә! Ул сәке йөзлеге кырыена ак ыштанлы аякларын асылындырып, күлмәк изүе аша тыгылып, йонлач күкрәген ышкый-ышкый, озак кына уйга батып утырды. Мыш-мыш йоклап яткан Хәнифәгә, аның күкрәгенә башын терткән сабые Шәфикага, тәрәзәдән төшкән таң шәүләсенә моңсу гына карап торды. Хатыны белән кызының битләре төтен сыман күгелҗем күләгә эченнән йомшак, күңел кузгаткыч нәфис булып, алсуланып күренә, алар икесе дә, дөньяда гамьнәре юк кешедәй, рәхәтләнеп йоклый алалар. Алар өчен ике катлы чарлаклы йорт ни, мунча сәкесе ни! Нигә соң ул шулар кебек гамьсез була алмый? Дөнья малы шулай ук җан тынычлыгыннан кадерлерәкмени аңа?

Габбас мулла ишекне шыгырдатып ачып, мунча алдына чыгып утырды. Өйне Имам Каһарманов әмере белән сүтеп алып киткәннән соң бүре базы төсле ыржаеп калган кара чокырга карамаска тырышып, төнге салкынча һаваны бөтен күкрәге белән сулап, офык читенә өелешкән шәмәхә-кызгылт болытлар өеменә күзләре талганчы карап торды.

Кайдадыр, тегермән буасы ягында, тартар кычкыра: тарт-пышвыйк, тарт-пышвыйк, тарт-пышвыйк. Бик еракта, Каф таулары артында кебек, каравылчы шакылдавыгы ишетелеп кала.

Дөнья кош сайраулары, каравылчы шакылдавыклары белән яши. Дөньяның үз агымы, аның Габбаста эше юк. Иртәнге салкынча һава калтырата башлагач, ул тагын мунча эченә керде; һава авыраймасын өчен ишекне ачып калдырып, үз урынына барып ятты. Күзенә йокы кермәде: Хәнифәнең тигез сулыш белән, рәхәтләнеп йоклый алуына сәерсенеп ятты, шундук аны аклады: җанында бер генә дә борчу юк шул аның. Шәмсенисаның да бәлки җанында борчу юктыр, Нурия

белән икесе чүкердәшеп кенә яшн торганнардыр. Аңар хәзер Габбас кирәк түгел. Кызыл малчы Габделхәлим аларны бергә кушып бәхетле итмәкче иде. Морза кызы Шәмсениса белән буразнадан күтәрелгән мужик Габбас кушыла алмады: ничәмә еллар бергә гомер итсәләр дә, алар һаман икесе ике дөнья кешесе булып кала бирделәр. Шәмсениса аның белән араны мәңгегә өзү өчен берәр сылтау чыкканны гына көткән икән, өйләре янып китүгә ул калага китеп барды, мәңгегә киткәнлеген, алар арасында бер генә төрле дә уртаклык юклыгын хәбәрсез ятуы белән аңлатты. Ул киткәннән бирле Нурия дә әтисен онытты.

Габбас мулланың моңар да сабырлыгы җитәр иде, ни генә димә, ул әле гаилә бәхетеннән мәхрүм түгел, аның әле үзе төсле үк мужик кызы булган Хәнифәсе янында, багалмадай кызы — Шәфикасы янында, тик менә пожардан соң мең бәла белән җиткергән соңгы йортын тартып алып, үзен мунчада яшәргә калдырулары, киңәш сорап калага баргач, Нуриянең аны караңгы чырай белән каршы алып, бүтән килеп йөрмәвен үтенүе Габбас мулланы тетрәтеп җибәрде. Шул минуттан башлап аның өчен дөньяда яшәүнең кызыгы бетте...

Атна буе ул балтасы суга төшкән кеше кебек йөрде. Моңарчы кичергән гомерен күз алдыннан үткәрде. Җамалетдин крестьянның ишле гаиләсе, мәдрәсә җәфалары, казакъ арасында, далада үткәргән көннәре, аннары Шәмсениса, аннары муллалык... Муллалык дигәннән ул үз акылы белән бер нәрсәгә барып җитте: муллалар өч төркемгә бүленә икән. Беренче төркем — шымчы муллалар. Боларның зур указлары була, болар жандармерия идарәсендә хисапта торалар, болар авыл халкы арасында барган барлык хәлләрне охранкага җиткереп, хәбәр итеп торалар. Болар алланың барлыгына һәм берлегенә ышанмыйлар, болар өчен кеше җанын кыю бер тиен дә тормый һәм болар моны алла исеменнән, патша хәзрәтләре исеменнән эшләп килгәннәр. Зартугайның Сөләйман хәзрәт шундый булган, эшләгән эшләренең Совет власте алдында кичерелмәс гөнаһ икәнен белгәнгә күрә дә ул аклар белән бергә табан ялтыратты. Икенче төркем муллалар — шагыйрьләр. Гасыр саен андыйлар булган: Габделҗаббар Кандалый, Утыз Имәни, Мәрҗани. Боларның укымышы зур. Болар кеше җанының матурлыгына ышаналар, болар халыклары алга китсен, аңы үссен дип гомер буе тырышалар; патша ялчылары аларны эзәрлекли, кайберсенең иманын сындыра, әмма шагыйрьлектән туктата алмый. Әнә Даут мулланы ак офицерлар тураклап киттеләр. Аның язганнары кайчан да булса бер халык кулына тапшырылыр микән? Әллә ул түккән көч, җанын сарыф итеп җырлаган тойгылар мәңгегә тарих диварлары астында күмелеп калырмы? Өченче төркемгә кергән муллалар халык өчен иң зур эшне эшләгәннәр: гомер буе балалар укытканнар, кара халыкны агартырга тырышып яшәгәннәр. Аларга казна акча түләми, алар патша хәзрәтләренең дә сөекле балалары түгел, мәгърифәткә булган ихтирам, башкаларга да дөньяны таныту хисе аларны алга әйдәгән. Монысы — Габбас үзе. Аның шәкертләре хәзер кайда гына юк. Күбесе дөнья өчен дә кирәкле кешеләр булып чыктылар, Казан каласына, китеп, зур урыннарга кереп утырдылар. Алар халыкка азатлык бирдек дип күкрәк кагалар, алар мулла-мунтагай, кулак-куштан дип кычкыралар. Алар Габбас мулла кебекләр өстенә дә кемнәрнедер өстерәп җибәрәләр. Әнә бит аны, йортсыз-җирсез калган байгышны, Бөкре Гафият хәл белешергә килгән булып мыскыллап китте:

— Нихәл, мулла абзый, тимер караватка сузылып, чарлаклы өйдә гәҗит укуы рәхәтрәк иеме, мунча ләүкәсендә сузылып ятып укуы рәхәтрәкме?

— Бик рәхмәт, Гафият, хәл белә килүеңә, бу көнне сиңа бирсен,— диде Габбас мулла.

Карале, хикмәти хода, Габбасның моңарчы күңелен нык итеп тоткан нәрсә икәү булган икән: берсе — кызы Нуриягә булган ышаныч, икенчесе — авыл халкының ихтирамын тою.

Хәзер боларның берсе дә юк. Кызы Нурия аны күңеленнән сызып ташлады. Аңа ата түгел, аңа үз жаны кадерле. Үз куышында тыныч яшәү өчен ул әтисен жир йөзеннән сызып ташларга әзер...

Гафият бөкренең сүзләрен оныта алмыйча, Имам Каһарманов белән Мәрдән Мурзинның йортны, мал-туарны тартып алган чактагы кыланышларын оныта алмыйча, Габбас мулла бик озак вәсвәсәләнеп ятты. Ята торгач, тагын йокыга куергандай булып, берсеннән-берсе ямьсез төшләр күреп саташа башлады.

Кәжән кигән Бөкре Гафият тычкан сагалап утыра: бер тычкан ике булды, өч булды, кисәкләргә бүленеп чәчелеп китте дә Бөкре Гафият тирәсендә тычкан туе башланды. Бөкре Гафият аларны чикмән чабуы астына жыя, алар, терекөмеш тамчылары кебек, бер урынга жыелдылар да кыр куяны чаклы зур бер тычканга әйләнделәр. Бөкре Гафият әнә шул куян чаклы тычканны куа, тычкан әле ләүкә өстенә менеп китә, әле мич артына кереп кача, мунча алдына, чарачага чыгып китә: куа торгач, Бөкре Гафият тычканның койрыгына китереп баса, зур тычканның эченнән кечкенә тычкан чыгып, тәрәзә аша яркана булып очып китә...

Габбас мулла тагын куркудан йөрәге тасырдап типкән хәлдә уянды. Чигәсен ике кулы белән кысып, бик озак уйланып утырды; тәрәзәдән алсу таң шәүләсе үрләгән, мунча тәрәзәсе кечкенә булганга, ул, алсу бер тасма булып, алар яткан сәкегә сузылган, йокыларыннан әле һаман уянмаган Хәнифә белән Шәфика-сабыйның йөзен алсу нурга мана иде...

Көн-ай жәелгәнне Габбас мулла көч-хәл белән көтеп алды. Хәнифә уянгач, комганга жылы су салдырып, озаклап юынды. Юынып сөртенгәч, Габбас мулла пакь күлмәк-ыштан сорап алып киде. Төпченергә яратучан Хәнифә:

— Нәрсә, хәзрәт, әллә тагын Казанга барасыңмы?— дип сорады.

— Юк,— диде Габбас мулла, хатыны самавыр куярга чарачага чыккач, сәке буена килде, юрганнан буынтыклы ак кулларын чыгарып, чайрап йоклаган Шәфикасы өстенә иелде, үбәргә курыкты, сакалы тиюдән баланың сискәнеп уянуы мөмкин иде, кулын күкрәгенә кушырып, бер тын карап торды, борын канатын ачыттырып, бер тамчы күз яше төште дә сакалы эчендә югалды.

Габбас мулла ашыгып, артыннан куып килгәндәй, кабаланып урамга чыкты.

Шул чыгудан ул өйгә әйләнеп кайтмады.

Хәнифә аны өйлә житкәнче сабыр гына көтте. Өйләгә, төшке ашка да кайтмагач, сабырсызлана башлады. Сабыен житәкләп, күршеләренә кереп чыкты, югары очка төп йортка барып кайтты, күршеләрдән, таныш-белешләрдән сораштырды: юк — хәзрәт суга төшкән таштай югалды. Инде бер дә карар урын калмагач, әллә ходаем, үлгән балалары рухына корьән чыгарга киттеме икән дип, зиратка барды.

Чыннан да хәзрәт шунда, буралап салынган чардуган буендагы карт бер каенга маңгаен терәп басып тора иде.

— Әй, мулла абзый, Габбас дим, нишләп торасың анда? Ашым суынып бетте бит, кайт инде!— дип дәште Хәнифә.

Жавап булмады.

— Хәзрәт дим, кайт инде, кайт!

Жавап юк.

— Я инде, хәзрәт, үпкәләдеңме соң? Нигә дәшмәгән буласың?

Хәнифә ялына-ялына дәшсә дә, елар чиккә житеп чакырса да, Габбас мулладан жавап ала алмады.

Кереп, кулыннан җитәкләп алып чыгар иде, хатын-кызга зиратка керергә ярамаганын белә.

Югары очка, төп йортка китте.

— Нәрсә, тапмадыңмы?— диде апасы Банат.

— Таптым ла...

— Соң?

— Зиратта ул, әллә миңа үпкәләгән инде, дәшеп тә карадым, намаз укыган кеше кебек, каен ягына карап тик тора.

Банат тиз-тиз киенде, күршеләреннән өч кешене ияртеп, зиратка китте.

Тагын бераздан Зартугай урамнарында, өйдән-өйгә шомлы хәбәр таралды:

— Габбас мулла асылынып үлгән. Зират каенына!

Зират өстендә козгыннар каркылдашты. Яңа хәбәрне ишетеп аяк-ка баскан Зартугай халкы зират ягына таба агылды.

Мәрхүмнең гәүдәсен каен ботагыннан чишеп алырга бирәү дә ашыкмады. Авыл Советы башлыгы Мәрдән Мурзин белән партячейка секретаре Имам Каһарманов суд тикшерүчесе килми торып халыкны зиратка кертмәскә боердылар.

Габбас мәрхүмгә тагын бер сәгатьтән артык халык күз алдында асылынып торырга туры килде.

## VI

Габбас мулланың авыл Советы бинасы итеп тау башына күчереп салдырылган ике катлы йортында Нажия Уразаева шаһитләрдән сорау алды.

Беренче итеп мулланың яшь хатыны Хәнифәне чакырып китерделәр. Ул, үзләренең ничәмә еллар күреп өйрәнгән борынгы өстәлләре янында тезне-тезгә чәнчеп, тәмәке тартып утырган милиция киемендәге Нажия Уразаеваны ир-атка санап, авызын яулык белән каплап килеп керде дә ишек төбендә тукталып калды.

— Якынрак килегез, гражданка Уразаева, утырыгыз, бирелә кеше ашаучы юк,— диде участковый, өстәл яныннан торып.

Хәнифә аның тавышыннан хатын-кыз икәнен таныды, әмма янтыгына таккан кара наганнан, күн итекләреннән һәм фуражкасыннан бу кешене хатын-кыз дип икърар итәргә базмыйча, өстәл буендагы тирәкле урындыкның читенә генә чүмәште.

— Яхшылап утырыгыз, гражданка Уразаева. Миңа таба борылыгыз, авызыгыздан кулыгызны алыгыз, безнең сүз озак булачак,— диде.

Авыл Советы секретаре, уналты яшьлек Шибай (чын исеме Шиһабетдин), ике хатын-кыз арасында барган шундый әкәмәт хәлгә түзә алмыйча, пырхылдап көлеп җибәргән иде, участковый кул сырты белән тегенең муенына шундый итеп бер сызып алды, Шибай шундук телен тешләп тынды.

— Гражданка Уразаева,— диде участковый, ныклы тәртип урнашуына ышангач,— әйтегез әле: мәрхүм, ягъни асылынып үлгән Габбас Җамалетдин улы Уразаев сезгә кем тиешле иде?

— Соң туктале...— диде Хәнифә, әле һаман авызын ачып җиткермәгән килеш,— син бит соң... Нажия түгелме? Әстәгафирулла! Габбас мулланың туганнан туган сеңлесе бит син, нәрсә белмәгән булып кыланасың?

— Сез сораганга җавап бирегез, гражданка Уразаева: зират каенына асылынып үлгән Габбас Уразаев сезнең кемегез иде?

— Ай аллам... ничек инде кемем булсын? Җәмәгатем.

— Менә шулай дип әйтергә кирәк. Димәк, асылынып үлгән Җамалетдин улы Уразаев — сезнең ирегез.
— Ийе. Унжиде ел гомер иткән ирем.
— Кәсебе буенча ул кем иде?
— Йа аллам, нишләп минем башымны катырасың инде, Нажия? Габбас мулланы бит Зартугайда ыштансыз йөргән балалар да белә. Мин аларда асрау булып тордым, уналты яшемнән. Нурияне карадым, идән юдым, кер чайкадым, киндер бәләкләдем, ашарга пешердем, сыер саудым. Эшләгәнне эшләмәдем дип әйтә алмыйм бит инде мин...
— Дәвам итегез.
— Нәстә?
— Сөйләгез дим, сөйләгез.
— Тагын нәстәсен сөйлим инде аның? Мулла абыстай әйтте: хәзрәтнең сиңа күзе төшкән, синең белән кети-мети...
Шибай тагын түзә алмыйча пырхылдап җибәрде.
Участковый өстәл яныннан сикереп торды, йодрыгы белән өстәл тактасына сугып:
— Конца концов, допрос алырга ирек бирәсеңме син, юкмы, сыбызгы борын?! — дип кычкырып куйды.— Без монда дәүләт күләмендәге эш белән шөгыльләнәбез, ә ул, безобразник, ат кебек кешнәп утыра! Яле, ал кәгазь, ал карандаш, допросны яза бар. Бел аны, жиренә җиткереп үтәмәсәң, корчаңгы этне куган кебек куып чыгарырмын.
Акчалы, мәртәбәле эшкә урнашкан Шибайга кәнсәләрдән куылып чыгу файдалы түгел иде, ул, канаганчы иренен тешләп, допросны яза башлады.
— Та-а-ак, дәвам итәбез, гражданка Уразаева. Мал-туар карадыгыз, идән-сәке юдыгыз, Габбас мулланың сезгә күзе төште...
— Хак әгәр,— диде Хәнифә, авызын яулыгы белән тагын бераз каплап торгач.— Мин аңа кияүгә чыкмаган да булырыем, үземә насыйбы бетмәгән булырые әле, мулла абыстай теңкәмә тиде бит...
— Нәрсә дип теңкәгезгә тиде?
— Кама тамак туннарым сиңа булыр, чәмчәле читекләрем сиңа булыр, алтын-көмеш беләзекләрем сиңа булыр, диде. Мин инде картайдым, диде, озаклармый үләрмен, диде. Нуриягә аларның берсе дә кирәк булмас, диде, хәзер инде башка заман, мал-мөлкәтемне сиңа калдырып үләрмен, диде.
— Калдырдымы?
— И-и, сорап торган буласың! Кисәү таягы да калмый янып беттек бит. Шәфикамны күтәреп урамда калдым. Тугыз айлык баланы... Калганын тартып алдылар: Сәвит башлыгы Мәрдән белән коммун Имами.
Участковый иренен кысты.
— Гражданка Шәмсениса кайда?
— Анысы тагын кем?
— Габбас мулланың олы хатыны.
— Соң шулай дип әйт аны, Шәмсениса абыстай диген, әллә ниткән гражданкин дип маташтырасың.
— Кабатлап сорыйм: Габбас мулланың олы хатыны кайда?
— Кайда булсын, Казанда.
— Кайтканы бармы?
— Нишләсен ул монда кайтып! Исе дә юк. Мин мал-мөлкәт таптырыр дип курка торгандыр. Сорамасыем әле, ут авызы белән бүре авызына киткәнне каян аласың инде аны...
— Нинди бүре турында сүз алып барасыз?
— Сәвит тартып алган йорт турында әйтәм инде, бүре авыз Мәрдәннәр турында. Агач башыннан йөрми ул, әдәм башыннан йөри. Йортыбызны тартып алып, мунчага илтеп япкан булдылар. Атыбызны кычкыртып алып киттеләр, җир чәчәргә симәнә калмады, шатырдатып

налук салдылар. Ат булмасын, сыер булмасын, чәчәргә симәнә булмасын, нәрсә белән түлисең ул налукны, көйрәк кеше ие бит Габбас, төннәр буе йоклый алмый уйлап ята торганые. Уйлый-уйлый да ыңгыраша. «Ни булды?» —дип сорыйм, әйтми, эченә җыеп бара. Эчкә җыярга ярамый, кеше белән бүлешергә кирәк, эчкә җыйдыңмы, кара кан сава, әнә шул алып китте якты дөньядан бәгырькәемне...— дип, Хәнифә монда кергәннән бирле беренче мәртәбә бик хәтәр күнеле тулып, ачы күз яше белән елап җибәрде.

— «Бүре авыз Мәрдән» дигәнен языймы, мильцанер апа?

— Анысын язма, исәр хатын сүзе ул, белеп сөйләгән сүз түгел! Ире үлгән, кайгыдан акылын җуйган. Вот! — Участковый Хәнифәгә таба борылды, аны елавыннан туктатыр өчен, тавышына борыч өстәп:— Йортны нинди акчага салдыгыз?— диде.

— Нинди акчага дип... менә тагын тора торгач торҗагун... Үзебезнең акчага, урлаган акчага түгел. Хәзрәт чаклы хәзрәт, дөньяга даны сатып, урлашып йөрмәс бит инде.

— Нинди акчага салдыгыз дип сорыйм мин йортны?

— Кара туры айгырны сатты. И-и дә әйбәт ат ие, башак болгатырга керерием янына, әһәһәһәй дип келтерәп кенә каршы алырые, ялларын сыпырырыем, битләреннән сөярием... Габбас мәрхүм, урыны җәннәттә булсын, үлеп тә яратадырые айгырны. Мулла абыстай белән парлашып, кара кырандаска кырын төшеп китәрләрие кунакка, артларыннан күзләрем талганчы карап калырыем... Йорт янмаса сатмыйдырые инде ул аны, кирәк кирәкне ега шул...

Нәҗия Уразаева аның моңлы бер сагыш белән истәлекләр дөньясына кереп китүен, бүлдерми-нитми, озак кына тыңлап утырды. Хәнифәнең, мулла йортында асрау хәлендә яшәгән яшь кенә хатынның, җәбер-золым турында бер генә сүз дә әйтмәве, бар булган хәлне шулай булырга тиешле кебек кабул итүе аны уйга калдырды. Авылда кискен көрәш башланган, кулакны сыйныф буларак юк итү бара, факт та аны икенче революция, диләр. Ә менә шушы Хәнифә кебек аңнары үсми калган томана крәстиян белән күмәк хуҗалыкны ничек төзисең дә ничек алга алып барасың? Ай-һай, күп эшләргә кирәк әле авылда...

Хәнифәне ул бүтән азапламады, Габбас мулланың өйдән кайчан, ни рәвешле чыгып китүен, ул көннәрдә аларга кемнәр килүен сорагач, кайтарып җибәрде. Габбас мулланың күршеләреннән берничә кешене — шаһитләрне чакырып сорау алды. Арадан берсе дә мәрхүмне яманламады, аңар тел тидермәде. Тырыш ие, укымышлы ие, халыкны таламады, садаканы да бирсәң алды, бирмәсәң сорамады, ярлы-ябагайның хәленә керә торган кеше ие, үкенечле үлем белән китәр дип кем уйлаган... диделәр. Кызгандылар.

Соңгы кеше булып чакырылган Садыйк карт Айдаров, сирәк сары сакалын сыпыргалап, ара-тирә уч төбенә йөткеренгәләп алды:

— Бәхетсез кеше булды ул Габбас. Үзенә дә юк, кешегә дә.

— Моны ничек аңларга?

— Өйләнде, катыннан уңмады. Муртайган агач кебек карт катын туры килде. Кыз үстерде, кыздан уңмады: калага китте дә әтисен онытты. Әле минем Солтан да шуның Нуриясе белән башы-күзе әйләнеп калада ята. Укый-укый-укый, чиге бардырмы ул уку дигәннәренең, юктырмы, берәр нәрсәгә ярыйдырмы ул уку — хода белсен, зимнәмир булып кайтты әнә Әгерҗе төбәгенә, халыктан кан-яшь түктереп, җир бүлеп йөрдә. Бактың исә, ул башта әтисе белән киңәшергә тиеш ие, тияргәме җиргә, әллә тими торыргамы? Ник дисәң, җир бик кадерле әйбер, аның өчен ничәмә-ничә кешенең хәйран башлары вәйран булган, Себер китеп черегән.

— Калага кайчан барды Габбас Уразаев?

— Ун көннәп булгандыр барганына. Өен талап алгач, закун эзләп

кызы янына киткәние, әллә ни якты чырай күрсәтмәгән шәй, бәк тә сөмсерләре коелып кайтып керде.

— Ни сөйләшкәннәрен әйтмәдеме?

— Әйтте. Кодаларыек бит. «Син, дигән, безгә, дигән, килеп йөрмә инде, эти», дигән. Менә шул. Баланы багасың, актык телем ипиенне ешатып үстерәсең, аннары менә сиңа мә — килеп йөрмә! Бозылды замана: ата улны, ана кызны белми, туган туганны суярга әзер.

Нажия Уразаева, абыйсы Габбас Уразаевның эшен тикшерергә чыккан чакта, ярлылардан берәрсе үчлек белән үтермәдеме икән дигәнрәк уй белән чыккан иде, сорау алганнан соң ныклы бер карарга килде: Габбас мулла, дөньядан гайрәте чигеп, үзен-үзе үтергән. Сәбәбе: барыр юлда яктылык күрмәү, пессимизм. Шуңа күрә ул мәетне суд экспертизасына тапшырмады, күмүне авыл халкының үз ихтыярына куйды. Ул белә: мәет яру элек-электән авыл кешеләре арасында гаять зур ризасызлык, рәнҗеш тудыра, тоташ күмәкләшү башланган бер дәвердә моны эшләү халык күңелендәге икеләнүне тагын да арттырачак һәм тирән бер яра салып калдырачак иде.

Моның шулай икәнен ул икенче бер мисалда да күрде. Габбас мулланы зиратка күмеп кайтканның икенче көнендә участок милиционеры Уразаеваны Салагыш волостеның милиция башлыгы үзенә чакырып алды:

— Зартугайда тәртипсезлек! Ярдәмгә ике милиционер алып, атларга атланып, хәзер үк шунда китегез. Ни булганны миңа, йомышчы җибәреп, хәбәр итәрсең.

Нажия Уразаева, ике милиционер белән, тузан туздырып авылга килеп кергәндә, Зартугай купкан, урам тулы халык мәчет ягына таба агыла иде.

Участковый халыкны аралап, мәчет янына килеп җитте: өстә — билләрен дилбегә белән бәйләгән ике кеше, кулларына пычкы тотып, мәчетнең манарасын кисәргә җыеналар, өченчесе, кулына балта тотып, алар янында басып тора иде. Мәчет тирәсендәге халык, кычкыра-тиргәнә, умарта күче кебек гүли иде.

Участковый Уразаева милиционерларга һавага атарга боерык бирде: өчесе берьюлы — залп белән — һавага гөрселдәттеләр.

Мәчет янында кабер тынлыгы урнашты.

Участковый Уразаева өзәңгеләренә басып күтәрелде дә:

— Хәзер үк түбәдән төшегез! — дип боерды.

Мәчет түбәсендәгеләрнең берсе, башына буденновка кигән Кадыйр Гонцов:

— Безгә Сәвит башлыгы үзе кушты. Искелек калдыгының көлен күккә очырмый төшмибез! — дип кычкырды.

Халык тагын ду килде.

— Кисеп кенә карасыннар!

— Самасут ясыйбыз!

— Деннән көләргә берәүнең дә хакы юк.

— Әй, милиция, нәрсә карыйсыз, үтереш булганны көтәсезме?

— Атып төшерергә кирәк ул имансызларны?!

— Көпә-көндез, изге рамазан аенда...

— Әй, тавыш! Тавыш! — дип тамагы карлыкканчы кычкырды участковый Уразаева. Тавышлар тынгач, тагын өзәңгесенә басып күтәрелде, тыныч булырга тырышып, әмма ярсынуын берничек тә җиңә алмыйча:

— Соңгы тапкыр кисәтәм: төшегез! Боерыкка каршы килү — контрлык дип исәпләнәчәк, — дип буыла-буыла кычкырды.

Түбәдәгеләрнең икесе, билләрендәге дилбегәләрен чишеп алып, төшү ягына кузгалдылар. Кадыйр кузгалмады, япа-ялгызы биленнән бәйләмәгән килеш, балтасын тотып баскан хәлдә торып калды.

— Революция исеменнән боерык бирәм: мылтыкларны на взво-ооді
Чакылдап мылтык затворлары ябылды, мылтыклар мәчет манарасы ягына таба төбәлде, Кадыйр әле һаман манара буенда басып тора, балтасын кулыннан төшермәгән иде.

— Тыңла минем команданы: огонь!!

Берьюлы ике мылтык атылды һәм Кадыйр Гонцов, көлтә кебек авып, җиргә тәгәрәп төште. Халык аһ итте. Кадыйрга ташландылар. Ул исән: тик егылып төшүдән аягын гына имгәткән иде. Чатанлый-чатанлый торып баскач, атлы милиционерларга йодрык селкеп, авызыннан төкерек чәчә-чәчә, ярсулы тойгыларыннан ташып кычкырды:

— Контра! Дин сакчылары! Революцияне саттыгыз! Трибуналда җавап бирерсез!

Тагын бер атнадан Нажия Уразаеваны волкомга чакырып алып аңлатма бирүен таләп иттеләр. Аларга Зартугай коммунистлары Кадыйр Гонцов белән Мәрдән Мурзиннан жалоба килгән иде.

Нажия Уразаева аңлатманы язмача бирде.

«Мәчет манарасын кисәргә менүчеләр хәвефсезлек кагыйдәләрен бозганнар. Киселгән манараның авып төшеп, мәчет янына җыелган халыкны имгәтүе мөмкин иде. Манара кисәргә балигъ булмаган һәм сыйнфый көрәшнең асылын аңламаган үсмер малайлар менгән. Романтика эзләүчеләр. Эш рәтен белмиләр, халык кәефе белән исәпләшмиләр. Башлап йөрүчеләре һәм волкомга жалоба язучы Кадыйр Гонцовның мәсләге юк, партиягә гражданнар сугышы вакытында кереп калган, революциягә бернинди дә файда китермәгән. Сыйнфыйлык ягы: люмпен, аерым бер һөнәре юк, авыл халкы телендә йөргән исеме: ата зимагур. Революцион җаваплылыкны үз өстемә алып, сугышчыларыма мылтыктан залп белән һавага атарга команда бирдем, үзем наганнан гөрселдәттем. Шуның белән чуалыш бетте, Зартугай халкы тынычланды. Социализм строена, совет властена булган ышаныч халыкта сакланып калды. Киргә чыкса, социализм ныгыгач, мәчет манарасын трактор белән тарттырып аударырбыз».

**Беренче китап тәмам.**

*Әгерҗе—Әлмәт—Казан,*
*1962—1976.*

## Мөдәррис Әгъләмов

### Бердәнбер кыз турында бер баллада

I

Иделнең иң гүзәл җирендә
Шәм кебек сузылып үскән ул,
Борынгы җырларда җырланган
Чишмәгә суга дип төшкән ул.

Авылның гармунчы егете
Аны нәкъ шул чакта күргәндер,
Алмадай кызлар күп авылда,
Арада ул гына — бердәнбер.

II

Кичләрен уенга чыкканда
Беркемгә сиздерми чыгарга
Рәешкә киясе кулмәген
Чыгарып яшергән чоланга.

Үзе дә кичергән әнисе
Аның бу хәйләсен белгәндер.
Беркатлы кызлар күп авылда,
Арада ул гына — бердәнбер.

III

Күбәләк шикелле талпынып
Очкан ул бер чыккач иреккә,
Яшьлектә кал икән гомерлек
Уйнап та, җырлап та, биеп тә.

Ул бәлки нәкъ шушы уенда
Яшьлеген озатып көлгәндер,
Һәркемнән узачак ул бәйрәм,
Һәркемнең яшьлеге — бердәнбер.

## IV

Ул кемнән ким әле, ник әле
Яраткан ярына чыкмасын,
Туй белән биргәннәр аны да,
Искечә укытып никахын.

Кем белә, ә бәлки ул чакта
Бу яңа туйлар да кергәндер,
Ак туймы, кызылмы — барыбер,
Ул аның туе бит — бердәнбер.

## V

Аннары бу сугыш. Озату.
Аерылу иреңнән дүрт елга.
(Дүрт елга сузылган сугышның
Газабы барачак күп елга.)

Үпкәдән килгән бу кара кан
Симәнә ташыган үрдәндер.
Ә ире исән-сау кайтачак.
Ул аның ире бит — бердәнбер.

## VI

Зур җиңү килде ул, тик менә
Тын кыса, кимерә үпкәне.
Ире дә исән-сау, янында,
Бу сугыш бетсә дә, үтмәде.

Тәүлекләп игеннәр урганда
Ул аңа чир булып сеңгәндер,
Идәндә сабые үрмәли,
Ул аның сабые — бердәнбер.

## VII

Идәндә сабые үрмәли,
Алырга иде бер кулыңа.
Бу соңгы теләге үтәлми —
Чем-кара күзләре йомыла.

Ә аның шикелле илемдә
Меңләгән хатыннар үлгәндер...
Онытма, кешелек! Ул минем
Әнием иде бит — бердәнбер.

## Куралар

Искә төште көтү көткән чакта
Курай өчен кура алганым.
Куралыктан кура өзәм диеп,
Чак-чак кына батмый калганым.

Авылдашлар тартып чыгардылар
Ярты гүргә кергән җиремнән.
Шул курайдан көй чыгарам диеп,
Канап беткән иде иреннәр.

Бабамнарның кан тамырларында
Минем белән бергә йоклаган
Ул моң миннән, ирен канаса да,
Курай моңы булып чыкмаган.

Бу дөньяның нәрсә икәнлеген
Белмәгән дә хәлдә, ул һаман
Күзе ачылмаган көчек сыман
Якты дөнья эзләп елаган, —

Төшмәк булып тальян телләренә
Яшь түктергән газиз сабыйдан,
Инде мөлдерәмә күзләр генә
Ул көннәрдән миңа карыйлар.

Канга баткан иде иреннәрем,
Ауган идем арып-талчыгып.
Хәзер инде башка — була чаклар:
Йөрәк бетә канга манчылып.

Мин бүген дә менә кураларга
Карап торам, ә ул куралар
Күкрәгендә моңы талпынучы
Малайларны көтеп торалар.

## Гомер иткән карт җыры

I

Тәнгә тулды җегәр,
Кытыкланды җелек...
Уздык бала чакны,
Уздык шундый җилеп,
Җиде чатлы юлның
Сайлап авыр чатын,
Киттек... — егылып калды
Ак кашкалы атым.

II

Тугарылды җегәр,
Уйнакламый җелек,
Инде бәйгеләрдә
Йөреп булмый җилеп.
Кул сузсаң җитәр күк,
Яшьлек шундый якын, —
Буыннарсыз калды
Ак бәкәлле атым.

III

Әнә шулай чорлап
Янды мәшһүр атлар,
Соңгы атым — Акыл
Салмак кына атлар.
Күзләр әле үткер,
Зиһен әле шөкер!..
Акыл атым, мине
Мәркәземә җиткер!

IV

... Үткән кире кайтмас
Хет илереп кычкыр.
Соңгы аткаемның
Төсе кара-кучкыл.

## Баралмасам әгәр

Вәгъдә биреп, вакыт җитеп
Баралмасам сиңа —
«Мәгарәдә ята! — диген,—
Әбүгалисина».

*
* *

... Зур дөньяның ваклыклары
Үзе белән торсын,
Минем алда үз кодрәтен
Ача шигъри тылсым. —
Ачылалар... (Ачылмый ул
Шакымыйча гына.)
Кем ут өргән без җылынган
Шигырь учагына?

Ачылалар үткәннәрнең
Серле капкалары,
Хакыйкатьнең ни гомерләр
Эзләп тапмаганы,
Бәгыремнең дөрләп-дөрләп
Яну сәбәпләре —
Я, ни әйтер Бөек Вакыт
Галиҗәнабләре?

*
* *

Тарала изге теләкләр
Кошлар сыман очып,
Минем алда үз киңлеген
Ача шигъри офык —
Ачыла... (Ачылмый киңлек
Күтәрелми генә.)
Кемнәр менгән иле белән
Офык киңлегенә?

Күкрәкләр киңәеп китә,
Иркенәя сулыш,
Ныгый бара туган җиргә
Горур басып торыш.
Якыная ата-баба
Гореф-гадәтләре —
Я, ни әйтер Бөек Вакыт
Галиҗәнабләре?

*
* *

Ачылып, яктырып ала
Томанланган акыл,
Асыл ирләрне табынга
Җыя шигъри чатыр.
Аралашып китәр өчен
Тиз салына күпер.
Баш күтәрә баш бирергә
Теләмәгән фикер.

Искереп беткән әйтемне
Чөеп кенә ташлый:
«Кылыч кисә алмый, — ди ул, —
Горур торган башны».
Ә ул башның баш бирмичә
Торган сәгатьләре...
Я, ни әйтер Бөек Вакыт
Галиҗәнабләре?

*
* *

Ничек инде чыгып китим
Әнә шундый чакта?
Кызыксынса бер гали зат
Сорап минем хакта,
Әйтер сүзең әзер булсын,
Киңәшем шул сиңа:
«Мәгарәдә ята! — диген,—
Әбүгалисина».

Сагышлы төн. Өстә — зәңгәр күктә
Ай яктыра, йолдызлар яна...
Һәм китәсе килә чиксезлеккә,
Иң ахыргы йолдызга таба.

Сагышлы төн. Зәңгәр күлдә — төптә
Ай яктыра, йолдызлар яна...
Сикерәсе килә мәңгелеккә
Иң ахыргы йолдызга таба.

## Урман яна

*Нажар Нәҗмигә*

Яна урман, урман яна,
Ничәнче көн бу якларда.
Шомлы гүләү авазлары
Ишетелә еракларга,
Ераклардан-еракларга.

Җәнлек кача, кош-корт кача,
Кача исән булганнары,
Хәтерләтеп һәлакәтне
Сугыш барган чорлардагы,
Аннан ерак чорлардагы.

Кешеләрне эзли күзләр,
Бу мәхшәрдә кайда алар?
Алар әнә, полосалап
Наратларны аударалар,
Исән урман аударалар.

Яна урман, әнә шулай
Янар сыман бу дөньялар...
Ә кешеләр аударылган
Агачларга ут ягалар,
Утка каршы ут ягалар.

Ут очраша, җиргә сеңә,
Сүнә-сүнә раслап тора:
Утка каршы ут якканда
Урманнарны саклап була,
Үз илеңне саклап була.

... Җәнлек кайта, кошлар кайта,
Кайта исән булганнары,
Хәтерләтеп хәрәкәтне
Сугыш тынган чорлардагы,
Аннан әүвәл чорлардагы.

## Шамил Маннапов

### Гимнастерка

Нинди генә кием юк дөньяда,
Моданың да бик күп төрлесе.
Тик бар микән өскә ятып торган
Гади гимнастерка төслесе?!

Кидең исә ять-яшь егет итә,
Җырламыйлар юкка: «Яшел ки!..»
Буй-сыныңны, килеш-килбәтеңне
Тулы күрсәтә ул, яшерми.

Солдат киеме чыдам — солдат кебек,
Шуңадырмы аны үз күрдек,
Безне фронтовик абыйларның
Шинельләре җылытып үстерде.

Абыемның кирза итегеннән
Европаның кызгылт тузанын
Кага-кага, авыл урамыннан
Эре генә атлап узганым

Бүгенгедәй әле хәтеремдә.
Танымыйча торган картларга
Фашистларны кыйнавымны сөйләп,
Булды алдалаган чаклар да.

Моның өчен гафу үтенергә
Тапмам инде авыл картларын.
Хәер, соңра солдат дигән олы
Исемне мин барыбер аклаадым.

... Эш киемем белән янәшәдә
Гимнастеркам тора эленеп.
Яшьлек елларымны сагына-сагына
Карыйм аңа хискә бирелеп.

Нинди генә кием юк дөньяда,
Моданың да бик күп төрлесе.
Тик бар микән ир-егеткә килгән
Гади гимнастерка төслесе?!

●

Рәхмәт сиңа матур итеп көлгән өчен,
Көтмәгәндә башым әйләндергән өчен,
Әлегәчә гади булган бар нәрсәне
Әллә нинди сихри ямьгә төргән өчен.

Рәхмәт сиңа төшләремә кергән өчен,
Көтеп алган яңгыр булып килгән өчен,
Сулса әгәр, күңелемдәге гөлләремә
Яшәртүле яшәү көче биргән өчен.

Рәхмәт сиңа иң бәхетле көннәр өчен,
Кавыштырган сихри айлы төннәр өчен,
Рәхмәтемнең иң олысы: мәхәббәтне
Гомер буе саклап кала белгән өчен.

●

Әгәр кайчак мине югалтсагыз,
Әллә кайдан эзләп йөрмәгез.
Менә, дуслар, сезгә шигырьләрем,
Шигырьләрдән мине эзләгез.
Күрешергә хәтта вакыт тапмый
Гаҗәп дөнья төзеп йөрдем мин.
Ялгыз гына төзесәм дә, анда
Башлап сезгә урын бирдем мин.
Галәм бөркетләре,
Нефтьчеләр,
КамАЗ салучылар,
Эшчеләр,
Игенчеләр,
Солдат,
Студентлар
Күңелем аша шунда кучтеләр.
Әти, әни кучте тыйнак кына,
Алып минем бала чагымны.
Белгәндерме, гомер буе шунда
Кучердем мин сөйгән ярымны.
Бормаланып аккан Чирмешәнем,
Печән чапкан болын буйлары,
Нарат егетләре белән бергә
Сакта торган Мәскәү урманы,
Үзегез белгәнсезме,
Сезнең белән
Мин шигырьдә бик еш кавыштым.
Сезнең белән уртак бар шатлыгым,
Сезнең белән уртак сагышым.
Ә сез бәлки мине югалткансыз,
Кая икән, диеп, күренми,
... Ялгыз калып шулай, моңсуланып;
Шигъри дөнья төзеп йөрим мин.

1975—1976.

## Виктор Иваненко

# АРЧА

хикәя



Әле күптән түгел белдем, Урта Азиядә үсә торган ылыслылар гаиләсеннән икән ул арча. Сагызлы матур агач, таза, нык. Арча сүзен ишетсәм, Тянь-Шаньда булган күптәнге бер вакыйга исемә төшә.

Безнең заставада унсигез яшьлек солдат ат караучы булып хезмәт итте. Бу ятим кыргызны, русчалатып, барыбыз да Федор дип йөртә идек. Карчыга кебек җитез иде ул. Гәүдәгә зур түгел, винтовка буе гына булыр, ә үзе чабып барган атны авызлыклый. Атны гынамы соң! Бервакыт аны повар урманга җиләк җыярга җибәргән. Федор шунда колгадай озын буйлы чик бозучыга юлыккан да, коралсызландырып, заставага алып кайткан. Хәер, чик бозучы дигәне браконьер булып чыкты. Ләкин эш анда түгел. Бу явызны егет берүзе тотып кайткан. Эш менә нидә. «Каян шул хәтле көч килгән бу чебешкә?» — дип гаҗәпләнгән браконьер. Ә Федор аңа:

— Кем хаклы, шул һәр вакыт көчле! — дип җавап биргән.

— Утлы агачны түбән иеп карагыз әле, иптәш комиссар, — диде ул миңа, хикмәтле итеп,— ялкыны һәр вакыт өскә күтәрелер. Моны миңа бабам әйткән иде.

Браконьердан сорау алганнан соң, аның күпме зыян китергәнен күрү өчен, атка атланып, Федор белән урманга киттек. Без анда үтерелгән һәм тунап ташланган өч болан күрдек.

Атларны әкрен генә атлатып, кичкә таба кайтырга чыктык. Җәнлек сукмаклары да аз булган биек тау араларында атны үз иркенә кую ышанычлырак. Бу акыллы хайваннарның чик буенда застава начальнигыннан да озаграк яшәгәннәре бар, димәк, аларның кыялар-да йөрү тәҗрибәләре дә күбрәк. Ярларында җил һәм яңгыр сулары калдырган эзләр беленгән тарлавыкка җиткәндә караңгы төшә башлады. Шушы бөркет оясындагы төсләр гаммасы батып барган кояш яктысында әкияттәй матур булып күзне чагылдыра. Тарлавыктан бөдрәләнеп ак томан күтәрелә. Томан артында, еракта, салкын тау башлары күкселләнеп тора. Кинәт Федор:

— Иптәш комиссар, Ленин! — диде.

Бу сүзне ул кычкырмыйча, әкрен генә әйтте. Ләкин Ленин дигән сүз мине өнсез калдыргандай итте.

— Әнә анда, — диде Федор, кулын алга сузып.

— Күрәм! Хәзер күрәм инде!

— Ленин күренеп торса, аның күзен болыт капламаса, курыкмыйча юлга чык, — диде Федор җанланып. — Юлың уңар. Минем бабам — чабан шулай дип әйтә торган иде. Гомерен җәйләүдә уздырса да, Тянь-Шаньның күп серләрен белә иде ул. Җиләк җыярга баргайда мин Ленинны күргән идем. Теге явызны шуңа коралсызландыра алдым... Киттек, иптәш комиссар. Ат абзарын тазартасым бар...

Федор әче итеп сызгырды да атының янтыгына тибеп куйды.

— Тукта! Ашыкма. Ашыкма, егет, — дидем мин аңа, әйләнеп карамый гына.

Табигать тарафыннан иң биек пьедесталга куелган һәйкәлне югалтудан һәм аны яңадан таба алмаудан курыктым. Кар каплаган тау башы уң яктан шома булып, ә сулдан киртләчләнеп тора. Мин аңа төбәп карыйм, биек маңгай, төз борын, әз генә күтәрелеп торган сакал саргылт күк йөзендә караган саен ачыграк беленә бара. Мин аның кысыграк уйчан күзләрен, мыегына яшеренгән мөлаем елмаюын да күргәндәй булдым. Чынлыкта исә ул минем хыялымда туган образ, бай фантазиясе белән Федорның бабасы тудырган Ильич образы кебек, табигать салып бетермәгән сызыкларын күрергә теләвем генә иде.

— Аны, ташлар өеп, Арча ясаган, — диде Федор ышанычлы һәм бераз моңсу тавыш белән.— Арча — ана ул, әни. Минем әнием.

Елмаеп куйдым. Егетнең үзенә бер холыклы булуын белә идем. Без һәркайсыбыз туган анабызның табигатьтән өстен көчкә ия булуына ышанабыз бит. Шуңа да иң авыр вакытларда кеше туган анасын телгә ала. Шуны белә торып елмаюдан тыелып кала алмадым. Егетнең кәефе кырылды.

— Кайтырга кирәк, иптәш комиссар. Вакыт. Минем өчен... Ат абзарын тазартып куймаслар бит...

Колакларын торгызган атлар таш сукмактан әкрен генә югарыга киттеләр. Федор үпкәләгән, дәшми генә миңа таба карап ала, күз карашы салкын һәм ачулы. Әгәр шул вакытны дәшми барсам, кызык бер вакыйганы ишетми калган булыр идем. Бу күптәнге хәлне Федорга чабан бабасы сөйләгән булган.

— Бу һәйкәлне синең әниең салганмыни? — дип сорадым мин, сыннан күземне алмыйча, — Батыр хатын булган икән. Көчле хатын.

— Аксакаллардагы зирәклек, болан җитезлеге һәм бөркет кыюлыгы булган Арчада! — дип, сүземне тиз генә ялгап алып китте Федор.— Кешеләр аны таң йолдызы дигәннәр. Андагыдай нурлы күзләр, нәфис йөз, зифа буй берәүдә дә булмаган. Арча кебек кешеләр йөз елга бер туганнар. Хәзер инде ул җәйләүдәге якты учаклар җылысына әйләнгән.

Бер тын эчендә шуларны әйтеп бетерде дә Федор, тагын сөйлимме икән дигәндәй, ияренә тотынып торды. Яңадан инде ул тоны к тавыш, картларча бер моң һәм хәсрәт белән дәвам итте. Ата-анасын күрми үскән ятим егетнең моңы иде ул.

— Арчага авылның иң көчле егете Исмаил өйләнгән. Йодрыгы белән сугып бүрене үтерә алган балавыздай йомшак күңелле егет булган ул. Капкорсак Кунанбайның көтүләрен көткән. Туй бүләге итеп баеннан тешсез ат алгач, гадел хезмәт итәрмен дип, елый-елый рәхмәт укыган. Мулла да Исмаилга: «Догам кабул булды, ходай тәгалә сиңа иң матур кызны бирде...» — дигән. Һәм егет аның аягын үпкән.

Туйдан соң бакчаларда өрекләр ике тапкыр чәчәк аткан. Ә Кунанбай дехканнарга: «Рус патшасын кафер-большевиклар үтерде. Хәзер

алар мөселманнарга килә. Большевикларның бүрекләре яшел, очлы башлы. Маңгайларында балаларыбыз каны белән ясалган йолдыз»...— дип әйтүдән туктамаган.

Арча да иреннән бу турыда күп ишеткән. Исмаил үзе дә бер тапкыр яшел бүрекле җайдаклар отрядын очраткан. Хатынына зыян салырлар дип курыккан һәм ул, Арча балага авырый башлагач, аны тауларга алып китеп, ташландык сарайга яшергән. Хатынын шулай еракка качырып, Кунанбайның ат менгән егетләре янына әйләнеп килгән.

Ул төнне Арча төне буе газапланып чыга.

— Ай, Исмаил! Ай аллам! Су... Бер генә тамчы су бирсәнә! — дип, иренә ялвара.

Ә Исмаил шул төнне, аннан соң көн озын, Кунанбайның ышанычлы кешеләре белән бергә, аил тирәсендә күренгән кызыл йолдызларның кечкенә отрядын эзәрлекләп йөргән. Хатынының шул төнне малай тапканын да белмәгән ул.

Ә Арча газапланган. Исмаил да, алла да ярдәм итмәгән аңа. Ул кычкырган тавышка озын буйлы, зур мыеклы, очлы башлы яшел бүрек кигән бер рус кергән. Тар авызлы савыт белән су китергән. Ә үзе шундый хәлсез булган, аягында көчкә басып торган, авыр сулаган. Кемдер аның күкрәген кылыч белән яралаган булган. Арча тавышын ишетеп каян, ничек килеп җиткән ул, бары тик күкләр шаһит моңа.

Кояш чыккач, Арча аңа карап тора да:

— Бичара анага су бирүче изге кеше, кем син? — дип сорый.

Русның күп сөйләргә хәле юк.

— Федор мин. Большевик, — ди ул, Арчага кара сакаллы бер кеше рәсемен бирә. — Бу иптәш Ленин. Батыр! Үзеңә ал. Иптәш Ленин ярлыларга бәхет китерә. Ышан миңа, ана. Син аны ярлы кешеләргә күрсәтергә тиеш.

Шул вакыт сарайга Исмаил кайтып керә. Хатыны янында утырган каферне куругә камчысын күтәрә:

— О, шайтан, эттән туган нәрсә!

Ләкин Арча, арага төшеп, иренә болай ди:

— Исмаил! Синең күзләреңне Кунанбайның ялган сүзләре күрмәс иткән. Яхшылап тыңла әле мине... Хәлсез кешегә шайтан булышмас. Бу кеше сусаганда миңа су бирде. Русларның барысы да кыргызларга дошман түгел икән бит. Җәрәхәттән үлеп барган кеше алдамас. Бу большевик егетне безгә Ленин җибәргән. Ә Ленин — батыр, бәлаләрдән йолып алучы кеше, ди. Димәк, большевик безгә кадерле кунак, ә Кунанбайның дошманы булып килгән.

Ярсулы ачу Исмаилның акылын алган. Ул русны тауларга сөйрәп киткән һәм, тынычланып, улын алып сөяр өчен хатыны янына кайткан.

Ләкин Арча толымнары белән улының күзен каплаган да:

— Кит! Син яхшы кешене үтердең! — дигән Исмаилга.— Мин улыма аның исемен кушам. Ә син кит, Исмаил. Улың кеше үтерүче атасын, хатының ахмак ирен күрергә теләми...

Арча иң биек тау түбәсенә йөз көн, йөз төн күтәрелгән. Юлында аңа бөркетләр һөҗүм иткән, соңыннан алар да җәфаламас булган. Җилләр юлына аркылы искән, тора-бара алар да анага баш игән. Кыргый җиләкләр аңа азык булган. Салкын чишмәләр су биргән. Ятар урыны — кояш җылыткан караташ икән. Әмма күңелендәге яхшылык күбәйгәннән-күбәйгән. Таза булып, улы үсеп килгән. Арчаның күкрәгенә яшеренгән карасакал рәсеме анага бетмәс көч биргән.

Арча йөз көн, йөз төн буе таштан Ленинның йөзен ясаган. Аилдан күренеп торырлык һәйкәл салгач, ул большевик Федорның сүзләрен дала җилләренә тараткан.

— Даладагы хәл ерактан күренә, ерактан ишетелә, иптәш комиссар, — диде Федор, караңгыда сөртенеп куйган атының ялыннан йомшак кына сөеп алды да, сүзен дәвам итте: — Яхшы хәбәр кымыздан татлырак. Кунанбайдан җәфа күргән дехканнар әнкәм сүзләрен китергән җилләрне куып җибәрмәгәннәр.

Кунанбай Исмаилны чакырып алган, хуш исле чәй белән сыйлаган да:

— Ирен куып чыгарырга җөрьәт иткән хатынның кайда яшәгәнен беләме бу батыр егет? — дип сораган.

Бай юртага үзен ни өчен чакырганнарын аңлаган Исмаил.

— Нигә белмәскә? — дип елмайган ул пиаласын куеп. — Рәхмәт, бай! Арчаның, ахмак ирен куып чыгарган Арча апаның кайда яшеренгәнен ничек белмим ди инде мин?! Даладагы хәл ерактан күренә, ерактан ишетелә. Синең колакларың гына ишетми аны, синең генә күзләрең күрми. Яшь карганы алдый алмас инде карт төлке.

Кояш баеганда Исмаилны мәчеткә китергәннәр. Зур учак янына дехканнар җыелган. Исмаилга Корьән сузып, мулла:

— Ходай тәгалә үзе ярлыкар! Шәригать кануннарына хыянәт иткән хатын кайда яшеренә, әйт! — дигән.

Мулланың догасы аркасында иң чибәр кызга өйләнүен исенә төшергән дә Исмаил икеләнеп калган. Ләкин артындагы дехканнарның борчылулы сүзләрен ишеткән Исмаил-ата, минем әткәм, башын югары күтәреп, канлы телен җиргә төкергән...

Шул чак Федор үксеп куйды. Мин аңа борылып карадым, ләкин тирә-якны шундый куе караңгылык баскан иде, янымда гына селкенеп барган җайдакның тынгысыз ялтыраган күзләрен генә күрә алдым. Федор, күз яшьләрен сөрткәндәй, җиңе белән битен сыпырып куйды. Бәлки мин ялгышканмындыр. Еракта ерткыч тырнагына эләккән тау кошының илереп кычкыруы, я суга төшкән таш тавышы миңа егетнең үксүе булып тоелгандыр. Әз генә тынып торганнан соң Федор, берни булмагандай, сүзен дәвам итте:

— Исмаил белән булган хәлне җилләр Арчага сөйләгән. Шуннан соң ана улын атасына күрсәтергә теләгән. Улын алып аилга килгән. Тик ул вакытны ат койрыгына тагылган Исмаилның юл тузанында газапланган чагы булган. Егетнең бары тик исеме генә һавада яңгыраган.

— Рәнҗемә, Исмаил! Бәхил бул! — дип ыңгырашкан халык. — Бәхил бул, Исмаил!

Кунанбайның кәкре пычак белән Арчаны чәнчеп учакка атуын берәү дә күрмәгән. Дехканнардан беренче булып Кунанбайның башына китмән белән кемнең сугуын һәм аның кулыннан Арчаның улын кем тартып алуын күктәге йолдызлар гына белгән...

Чынбарлык белән хыял кушылган бу әкият юл буена җитте. Урман, бөркетләрнең кырыс патшалыгы булган кыя тау сыртлары күптән инде салкынча дымлы төн белән капланды. Ә алда, безнең хәрәкәтнең җаена кушылып, илебезнең иң ерак заставасында утлар чайкала иде. Атлар, кайтып җиткәнне сизеп, юртып киттеләр. Федор йөгәнен нык кына тартты. Аты үрә торды, ә сугышчы егет миңа таба борылды да элек әйткән бер сүзен кычкырып кабатлады:

— Утлы агачны никадәр аска исәң дә, ялкыннары барыбер югары күтәрелә. Карт сүзен шулай дип бетерә торган иде, иптәш комиссар. Ул әле күптән түгел генә үлде, җәйләүдә җирләдек.

* * *

Кырык беренче елны, Мәскәү янындагы һөҗүмнәрдә, комиссары мин булган автоматчылар батальоны Панфилов дивизиясе составында сугышты. Урта Азиядә төзелгән бу дивизиядә Көнчыгыш халыкларының бик күп вәкилләре бар иде.

Гитлерчыларның оборона сызыгын штурмлауга бер тәүлек алдан биш егетне дошман тылына «тел» алып кайтырга җибәрдек. Ләкин алар әйләнеп кайтмады. Икенче көнне шул ачыкланды: заданиедән кайтып килгәндә разведчиклар фашистларга юлыкканнар. Атыш киткән. Дүртесе үлгән. Авыр яраланган бишенче солдат Ахунбаевны гитлерчылар блиндажга сөйрәп кергәннәр, газаплаганнар, ләкин үтереп җиткерә алмаганнар. Җәзалардан газап чиккән, өшеп беткән Ахунбаевны блиндаждан санитарлар табып алган. Мине шулар чакырып китерде. Сержант комиссарга намуслы күзләрен тутырып карады.

— Җәзалаудан туктатмасалар, телемне тешләп өзәрмен дип уйлаган идем,— диде Ахунбаев, ни булганын сөйләп биргәч.— Штыклар белән кадаулары бик яман.

Аның сүзләре миңа ат караучы Федорны хәтерләтте. Ләкин ул вакытны истәлекләргә бирелеп торыр вакыт түгел иде, ике кулы да бәйләнгән сержантның иңбашыннан кысып:

— Исемең ничек? — дип сорадым.

— Ваня, — диде ул.

Шул вакыт йөземдә гаҗәпләнү билгеләре чагылып китте булса кирәк, Ахунбаев шуны күреп алды.

— Әнием миңа рус исеме кушкан. Большевик Иван исемен.

— Әниең кайда яши? Батырлыгың турында язып җибәрермен.

Ул күңелсезләнеп башын чайкады:

— Минем әнием һәлак булган, иптәш батальон комиссары.

Шул вакыт мин солдатның сүзен бүлеп:

— Аның исеме Арча түгел идеме? — дип сорадым.

Кискәләнеп, тишкәләнеп беткән сержант Ахунбаев горур рәвештә елмаерлык көч тапты:


— Әйе, әйе! — аның күзләрендә шатлык яшьләре иде. — Әйе, әйе, иптәш комиссар.

Тын алуым иркенәеп, тирән кар ерып йөгерүе ансатрак булып китте. Тирә-ягымда снарядлар ярыла, «пикировщиклар» улый, җирнең асты-өскә килә кебек. Җиңү көненә дә әле ерак, бик ерак. Ә минем ниндидер шатлыгым бар кебек. Кемдер тарафыннан иҗат ителеп, менә ничә еллар инде халыкта яшәгән һәм күңелләрне ялкынландырып торган бу искиткеч хикәят герое Арчаның варислары батальонда тагын бардыр әле дигән уй миңа шулай көч бирә иде.

ЛӘБИБӘ ИХСАНОВА
тәрҗемәсе.

**Дания Дәүләтшина,**
КПССның Лаеш райкомы беренче секретаре, XXV съезд делегаты

# ҮЗГӘРЕШЛӘР ҮРГӘ ИЛТӘ



Үткән ел минем өчен бик истәлекле булды: партиябезнең XXV съездына делегат итеп сайладылар. Коммунистларның шундый зур ышаныч күрсәтүен мин район партия оешмасы эшчәнлегенә бирелгән югары бәя, киләчәктә тагын да рухланыбрак, ялкынланыбрак эшләргә дәртләндерү, җилкендерү дип аңлыйм.

Съездан соң бер елдан күбрәк вакыт узды. Ләкин илебез башкаласында партиянең иң югары форумы барган көннәрдә күңелдә туган уйхисләр тоныкланмый. Киресенчә, көннәр-айлар үткән саен, Кремльнең Съездлар сараенда кабул ителгән тарихи карарларның рухландыргыч көче һаман арта бара, бурычларның зурлыгы ачыклана төшә, конкретрак төс ала. Без инде аларны зур тырышлык белән гамәлгә ашырабыз.

... Съезд көннәрендә мин туган Татарстаныбыз турында күп уйландым. Хыялымда Лаеш якларының тарихи сәхифәләре җанлангандай булды. Ул сәхифәләрдән иске Лаеш өязендә туып-үскән бер хатын-кызның образы калыкты. Моннан күп еллар элек Мәскәүгә делегат булып барган. Ильичны тыңлаган, аның белән очрашкан якташыбыз ул безнең.

Октябрь революциясе җиңүгә әле нибары бер ел гына тулган чак. Мәскәүнең таш урамнары акка төренгән. Кыш ул елны үтә зәһәр суыклар алып килгән. Ил авыр хәлдә. Мәскәү эшчеләренең балалары ачыга. Ләкин революцион рухы ялкынланып торган шәһәрдә тормыш кайный. Урамдагы карларны шыгырдатып, бердәм атлап, эшче дружиналар уза. Тимер юл вокзалларында ыгы-зыгы, һәркайсыннан фронтка солдатлар озаталар. Ә фронт — һәр тарафта: Совет республикасына интервентлар һәм акгвардиячеләр ябырылган.

Шундый хәтәр көннәрнең берсендә Союзлар йортының Колонналы залында эшче һәм крестьян хатын-кызларның беренче Бөтенроссия съезды ачыла. Аңа меңнән күбрәк делегат җыела. Шуларның берсе безнең якташыбыз — Анастасия Павловна Шувалова була. Съездга делегат итеп аны Казанның эшче хатын-кызлары җибәрә.

Авылдан килгән делегаткаларның өстендә бишмәт тә тире тун. Күбесенең аякларында чабата. Эшче хатын-кызларның киеме дә ялт итеп тормый, әлбәттә. Иң яхшы дигәне — фуфайка һәм иске шәл, киндер олтанлы чүпрәк туфлиләр. Һәркайсының диярлек кулында төенчек, ә ул төенчектә — берничә бәрәңге, алабута кушып пешерелгән икмәк кыерчыгы. Аларны авылдан делегаткалар алып килгән, шуны бүлешәләр.

Съездны ВЦИК председателе Я. М. Свердлов ача. Президиумда делегат хатын-кызлар: Н. К. Крупская, Инесса Арманд, Александра Коллонтай... Алар «Гаилә һәм коммунистик дәүләт», «Социаль тәэминат бурычлары», «Балалар хезмәтен бетерү турында» докладлар сөйлиләр. Трибунадан яңгыраган һәр сүз, корылыктан көйгән җиргә төшкән яңгыр тамчысыдай, хакыйкатькә сусаган күңелләрнең иң түренә үтә.

19 ноябрьда съездга В. И. Ленин килә. Залдагылар аны, дәррәү урыннарыннан торып, алкышлар белән каршылыйлар. Анастасия Шувалованың карашы Ильичка төбәлгән. Үзе кул чаба, үзе Лениннан күз алмый. Юлбашчыны беренче күрүе аның. Әнә ул трибуна янына баскан да алкышлар тынганны көтә. Ләкин зал кул чабудан туктамый. Ильич сәхнә буйлап йөренә. Хәрәкәтчән. Менә ул, яңадан трибуна янына басар да, аз гына алга таба иелә төшеп, сүз башлар. Тик алкышлар һаман тынмый. Моңарчы мең төрле изелүдән интеккән, гаиләдә газапланган хатын-кызлар үзләренә хокук алып килгән Октябрь юлбашчысына рәхмәт хисләрен шулай белдерәләр.

Алкышлар, ниһаять, тынды. Ленин сүз башлады. Шувалова аның һәр әйткәнен күңеленә салып торды.

«Әгәр дә социалистик переворотка хезмәт иясе хатын-кызларның гаять зур өлеше җитәрлек катнашмаса, социалистик переворотның булуы мөмкин түгел...» — ди Ильич. Һәм илдә бөтен тормышны революцион үзгәртеп кору өчен көрәштә хатын-кызларның актив катнашуын тәэмин итү максаты белән совет властеныңниләр эшләвен сөйли, тагын нәрсәләрне гамәлгә ашырырга кирәклеген әйтә. «Хәзергә кадәр хатын-кызлар коллык хәлендә яшәп килделәр; хатын-кыз үзенең өй хуҗалыгы белән изелгән, һәм аны бу хәлдән тик социализм гына коткара ала. Без вак хуҗалыктан гомуми хуҗалыкка, һәм җирне бергәләп эшкәртүгә күчсәк кенә, тик шул вакытта гына хатын-кызлар тулы ирекле булырлар һәм коллыктан азатлыкка чыгарлар».

Юлбашчының бу сүзләрендә үзенең газапта үткән көннәрен һәм киләчәк бәхетен күргән Шувалова соңыннан Свердлов исемендәге Коммунистик университетта укый. Бирелә ул В. И. Ленинның дәүләт турындагы лекцияләрен тыңлый. Беркөнне, тәнәфес вакытында, Ильич безнең якташыбыз янына килә дә:

— Сез кайсы оешмадан, иптәш? — дип сорау бирә.

— Казан оешмасыннан, Владимир Ильич.

— Партиядә күптәнме инде?

— Унтугызынчы елның апреленнән...

— Уку авыр түгелме соң?

— Авыр, Владимир Ильич, ләкин миңа булышалар.

— Менә, менә, үзара ярдәмләшү, бер-береңә булышу кирәк. Безнең эштә бу бик әһәмиятле, — ди В. И. Ленин.

Ул чактан соң инде күп еллар үтте. Ләкин Ильичның җирне күмәкләшеп эшкәртүгә күчәргә, үзара ярдәм итешү, бер-береңә булышу кирәк, дип, якташыбызга әйткән сүзләре минем дә күңелемдә яңгырап тора шикелле.

Зур елгалар да кечкенә чишмәләрдән башлана.

Илебез куәтенең башлангыч чишмәләре әнә шул ерак еллар кочагыннан — Ильич яшәгән, иҗат иткән давыллы чордан килә.

Залда утырып, ораторларны тыңлаган чагымда мин шуны да уйладым һәм XXV съезд трибунасыннан Ильичның үзен ишеткәндәй булдым. Партиябез форумының бөтен эше, анда әйтелгән һәр сүз Ленин рухы белән сугарылган иде. Ил экономикасын тагын да үстерү, авыл хуҗалыгын күтәрү, халыкның культура хәзинәсен баету турында кабул ителгән карарлар даһи уйларының дәвамы булып яңгырады. Съезд безнең тормыш пульсын тизләтте. Аның тарихи карарларын үтәү барышында барлыкка килгән яңалыклар инде һәр урында тамырлана, яшь үрентеләр булып калка. Кайбер тармакларда алар җимеш бирергә дә өлгерде.

Зур гомумиләштерүләр ясарга дәгъва итмәстән, мин бары тик үз районыбызда гына туган кайбер яңалыкларга күз салып үтмәк булам.

Лаеш яклары — авыл хуҗалыгы районы. Шәһәр яны төбәге булarak, аның үзенә генә хас үзенчәлекләре һәм бурычлары бар. Партия оешмасының төп эшчәнлеге дә — идарә итүне камилләштерү, сыйфат өчен көрәшне нәтиҗәлерәк оештыру, партия эшен үтемлерәк итү — шулар белән билгеләнә.

Игенче яхшы белә: җиргә яхшы сыйфатлы орлык чәчсәң генә югары уңыш күтәргә мөмкин. Нәкъ шуның кебек үк, идеологик эшнең дә үтемле формада, күңелләргә ятышлы итеп, төпле һәм эзлекле алып барылганы гына рухи хәзинәләргә яңа байлыклар өсти ала. XXV съезд билгеләгән зур бурычларны — һәр колхозда, совхозда, предприятиедә фәнни-техник прогрессны тизләтү, фән казанышларын һәм алдынгы тәҗрибә ысулларын практикада куллану кебек төп эшләрне — партия оешмалары оештыра һәм җитәкли. Хезмәт коллективларында микроклимат — дуслык, үзара ярдәмләшеп эшләү, иҗади эзләнү мохиты тудыручылар да алар.

Партоешмалар алдында торган бурычларның һаман катлаулана баруы авыл хуҗалыгындагы үзгәрешләр белән бәйләнгән. Колхоз производствосы көннән-көн киңәя, интенсиврак төс ала. Һәркайда специальләштерү, концентрацияләү бара. Игенчелектә һәм терлекчелектә механикалаштыру, автоматлаштыру көчәйде. Бу үзгәрешләр колхоз эшчәннәрен профессиональ яктан туктаусыз үстерүне, аларның белем һәм культура дәрәҗәсен өзлексез күтәрүне таләп итә. Замана шундый хәзер: беләгең җегәрле булудан битәр, башның белемле булуы кирәк. Чөнки, халык әйтмешли, «беләге юан берне егар, белеме булган меңне егар». Кешеләрне шундыйлар итеп тәрбияләү өчен, партия оешмалары эшенең стилен, методларын һәм формаларын да камилләштереп торырга кирәк.

Тугызынчы бишьеллык Лаеш районы хуҗалыклары өчен иҗади эзләнүләргә бай чор булды. Төп хәзинәбез — җирне саклау, туфрак структурасын яхшырту, авыл хуҗалыгы культураларының сортларын яңарту, уңышын арттыру, терлекчелектә нәсел эшен фәнни нигезгә кору, һәр тармакта югары сыйфат өчен көрәш оештыру — менә шундый төп мәсьәләләр игътибар үзәгендә торды. Җыеп әйткәндә, без *барлык хуҗалыкларны да тоташ комплекслы нигезгә күчерү, тулысынча концентрацияләү һәм специальләштерүгә керешү өчен ышанычлы база булдырдык.*

Октябрьның беренче еллыгында ук Ильич, ул вакыт өчен мөһим булган мәсьәлә итеп, җирләрне эреләндерү, күмәкләшеп эшләү кирәклеген әйтә. Ә бүген, Октябрьның 60 еллыгын каршыларга җыенган көннәрдә, партия безне авыл хуҗалыгы проблемаларын заманга хас масштабларда—эре комплекслар төзү, хуҗалыкара берләшмәләр

оештыру, концентрацияләү һәм специальләштерү юнәлешендә хәл итәргә чакыра.

Бу безнең, Ленин сызган юлдан барып, яңа киңлекләргә чыгуыбыз, тагын да биегрәк үрләргә юл алуыбыз!

Безнең район колхоз-совхозларында да дистәләрчә комплекс барлыкка килде. Һәркайсын район масштабындагы КамАЗ дип зурларга мөмкин. Чөнки алар, авыл пейзажына индустриаль төс биреп, зурзур заводларга охшаган шәһәрчекләр булып калка, тирә-якның йөзен үзгәртә. Гомумән, Лаеш районын безнең көннәрдә авыл хуҗалыгы өлкәсендәге КамАЗ дип бәяләргә була. Монда үзгәртеп кору бармаган бер генә хуҗалык та юк. Әйтик, «Комсомольский» совхозында күркә асрау комплексы барлыкка килде — ел әйләнәсенә ул 600 тонна кош ите бирә. Ә Лаеш кошчылык фабрикасында 250 мең тавык бар. Бу предприятие һаман зурая әле. Сокурида чын мәгънәсендәге фәнни хуҗалык-экспериментал база үзәге булдырылды. Анда 600 баш сыер асрала. «Волжский» совхозындагы терлекчелек комплексында мөгезле эре терлекләр 1100 баш. Бу хуҗалыкларның барысында да продукция җитештерү процесслары индустриаль нигезгә корылган. Аларны салу өчен районыбызга 42 миллион сум акча бирелде. Лаеш якларында без хәзер бөтен тавышка трибун шагыйрь Һади Такташның шигъри юлларын кабатлый алабыз:

> Бишьеллыкның бөек гигантлары
> Һаман үсә,
> Һаман күккә таба үрелә...

Эшчәннәренең бу җиңүләре ил һәм хөкүмәт тарафыннан югары бәяләнде: тугызынчы бишьеллык нәтиҗәләре буенча районга КПСС Үзәк Комитеты, СССР Министрлар Советы, ВЦСПС һәм ВЛКСМ Үзәк Комитетының күчмә Кызыл байрагы тапшырылды. Лаеш районы Бөтенсоюз Халык хуҗалыгы казанышлары күргәзмәсендәге Мактау тактасына кертелде.

Күтәрелгән үрләребез шактый биек, ләкин тынычланып калырга урын юк. Авылда хәзер индустриаль нигезгә корылган производство булдыру гына аз, аны идарә итү дә заманча булырга, аның куәтләренә, үзенчәлекләренә җавап бирергә тиешле. Безнең бурыч — шуны тәэмин итү. Хуҗалык җитәкчеләренең һәм партия работникларының көндәлек, атналык эшенә бәя биргәндә, барыннан да элек, бу эшнең реаль нәтиҗәләре исәпкә алына. Төп юнәлешебез — җитәкче кадрларда ленинчыл стиль: эшлеклелек, максатчанлык, мәсьәләләрне тиз һәм дөрес хәл итә белү осталыгы тәрбияләү. Билгеле, болардан соң тагын бер сыйфат — тәвәккәллек тә кирәк, чөнки тәвәккәллек таш яра, диләр бит.

Тәвәккәллек турында сүз чыкканда, беренче чиратта, күз алдыма «Победа» колхозы партоешмасын, Кече елга коммунистларын китерәм. Анда партком секретаре Альберт Беляев производство һәм идеология эшендәге яңалыкларга бик сизгер. Ә колхоз председателе Җәүдәт Вәлиуллин хуҗалык оештыру эшләрендә ут уйната торган кеше. Баш агроном Хөсәен Яруллин — яңалык дигәндә атлыгып торган белгеч. Аның холкын бөтен район белә: берәр эшкә тотындымы — үз дигәненә ирешми тукталмас. Колхоздагы барлык орлыкны иң яхшы сортлыларга алмаштырып бетерү инициативасын ул башлады. Тәҗрибә итеп, егерме гектарга тритикале дигән арыш-бодай гибридын ул чәчтерде. Хәзер инде колхоз яхшы сортлы орлык хәзинәсен күршеләре белән дә уртаклаша.

Партоешмада сиксәнләп коммунист бар, шулардан 51 кеше производствода эшли. Күбесе хезмәт алдынгылары. Бередә поручениесе булмаган бер коммунист та юк. Бу формаль нәрсә генә түгел, ә бөтен партоешманың ритмлы эшләвен, коммунистларның производствода һәм җәмәгать эшләрендә активлыгын тәэмин итә торган мөһим фактор. Партком утырышларында, җыелышларда хуҗалыкны үстерү, камилләштерү, колхозчыларны тәрбияләү һәм авылның культура йөзен үзгәртүгә кагылышлы мөһим мәсьәләләр тикшерелә. Аларны җитди өйрәнеп, коммунистларның актив тикшерүе һәм кыю хәл итү — «Победа» колхозы партоешмасының төп стиле.

Кешеләрдәге инициативалылык турында уйлаганда, халык телендә йөргән бер «хикмәт» искә төшә.

Бер юлаучы чит авыл аша үтеп барганда күрә, имеш: урта яшьләрдәге ир чалбар каешы белән улының арт сабагын укытыпмы-укыта икән. Узгынчы аңардан сорый:

— Нишләп улыңны суктырасың, абзый? — ди.

— Кушканны эшләми,— ди малайның әтисе.

— Дөрес итәсең,— ди дә юлаучы китеп бара. Икенче авылда тагын шундый ук хәлгә юлыга.

— Улыңны ни өчен суктырасың, ни гаебе бар? — дип сорый.

— Кушканны гына эшли, — дип җавап бирә аңа малайның әтисе.

— Дөрес итәсең, — ди юлчы. — Егет кеше үзе белеп тә эшләргә тиеш...

Тормыш диалектикасын шактый үтемле итеп ача бу хикмәт. Бүгенге чынбарлыкта да шулай лабаса. Югары оешмалар кушканны үтәми калырга ярамый, чөнки аларның директиваларында, күрсәтмәләрендә алга баруыбызның төп юнәлешләре, төп юллары билгеләнә. Шул ук вакытта төп юлдан алга баруның конкрет шартлар өчен уңайлырак формаларын, ысулларын эзләргә, табарга, «үзең белеп тә эшләргә» кирәк. Бу җәһәттән безгә, партия работникларына, хуҗалык җитәкчеләренең инициативасына юл ачып, ул мөстәкыйльлекнең эшне кая алып барачагын алдан чамалый белү шарт. Икенче төрле әйткәндә, алмагач үсентесен утырткан чакта ук инде үскәч нинди җимеш бирәсен белергә кирәк.

«Победа» колхозында барган тәҗрибәгә, эзләнүләргә дә нәкъ шулай каралды. Анда коммунистлар партия карарларын үтәүнең заманга хас юлларын эзләделәр һәм инициатива белән эшләделәр. Бу хуҗалыкта идарә структурасын үзгәртү шундый тәвәккәл адымнарның берсе булды. Аны тормышка ашыруның нинди җитди эш икәнлеген чамалау өчен, бүгенге авыл хуҗалыгының барлык тармакларын, бөтен үзенчәлекләрен бер комплекста күз алдына китерергә кирәк.

Җитмешенче елларда колхоз гаҗәеп катлаулы, күп тармаклы, бик үзенчәлекле производство берәмлеге ул. Бер яктан индустрия куәтенә таяна, икенче тарафтан — фәнгә, өченчедән — кешеләрнең осталыгына. Промышленность предприятиесеннән аермалы буларак, колхоз производствосы табигый шартларга да бәйле. Аңа, Тукай әйтмешли, җил дә вакытында исеп, яңгыр да вакытында яусын, кары да җитәрлек төшсен. Монысы хуҗалык итүнең объектив ягы. Субъектив факторлар да бар. Болар — идарә итү, җитәкчелек системасы, белгечләрнең белем дәрәҗәсе һәм башкалар. Менә шуларның заман таләпләренә җавап бирерлек дәрәҗәдә оештырылуы объектив факторларга да йогынты ясый, аларның тискәре көчен киметеп, уңай якларын көчәйтүгә китерә. Шулай итеп, табигать белән кеше арасында союздашлык мөнәсәбәтләре урнаша һәм ныгый. Производствоны идарә итү структурасын камилләштерү — шундый зур эшнең әһәмиятле элементы.

Билгеле булганча, бу мәсьәлә башлап КПСС Үзәк Комитетының

1965 елгы март Пленумында куелган иде. Аннары партиябезнең XXIV һәм XXV съездларында, авыл хуҗалыгын үстерүнең башка мөһим проблемалары белән беррәттән, ул тагын да конкретрак итеп билгеләнде.

Безнең районда бу зур эшкә җиң сызганып берничә хуҗалык кереште. «Победа» колхозы — шуларның берсе. Монда партком секретаре белән идарә председателе кешеләрне яңалык көченә ышандыра алдылар.

Яңача идарә итү системасына күчү хакында сөйләшү-киңәшүләр 1974 елда ук башланган иде, ә күчеш исә былтыр гына гамәлгә ашырылды. Колхоз җитәкчеләре, кызу канлы булсалар да, акыл белән эш итәргә, «җиде үлчәп, бер кисәргә» омтылдылар. Производствоны цех структурасына корган совхозның тәҗрибәсен башта колхоз председателе энәсеннән-җебенәчә өйрәнде. Аннары, партком киңәше белән, баш белгечләр һәм экономист, һәркайсы үз күзлегеннән күршеләрдә «гыйбрәт-сабак» алды. Шуннан соң Кече елгада партком һәм идарә утырышларының берсендә производство тармакларын цехларга бүлделәр, икенчесендә цех начальникларын һәм аларның вазифаларын расладылар, өченче утырышта һәр цехның индустрия куәте билгеләнде.

Райком, әлбәттә, «Победа»ның эшен, эзләнүләрен читтән күзәтеп кенә тормады: кирәк чагында тиешле ярдәм күрсәтелде, киңәш бирелде. Тик без аларга әзер карар, әзер рецепт бирергә уйламадык һәм аларны ашыктырмадык та: уйласыннар, яңача эшли торган хуҗалыкларның тәҗрибәсен өйрәнсеннәр, үзләре тәвәккәлләсеннәр, дидек. Бу исә коммунистларның җаваплылык тойгысын арттырды, колхоз демократиясенең бөтен мөмкинлекләрен эшкә җигәргә мөмкинлек ачты.

Хуҗалык җитәкчеләренең бер ишеләре вак-төяк мәсьәләне дә, зур итеп, райком белән килештерү ягын каера. «Райком хупласа, мин әзер» — боларның принцибы. Алай иткәндә, әлбәттә, җан тыныч була. Төптәнрәк уйласаң, әлеге «җан тынычлыгы» дигәннәре җаваплылыкны өскә алудан читләшү икән. Без мондый «җаваплылыкка», дөресрәге, җавапсызлыкка, каршы. Юк, иптәшкәй, коммунист икәнсең, җаның тынгысыз булсын! Заман сулышын той, зиһенгә партия сүзен сал да үзеңә йөкләнгән вазифа киңлекләрендә кыю эш ит, эзлән, уйлан.

«Победа» коммунистлары тынгысыз җанлы булып чыкты. Алар заман куйган бурычны кыю үтәделәр. Идарә итүнең цех структурасы беренче елда ук көзен санарлык чебешләрне күп бирде. Шуларның кайберләрен генә булса да әйтеп үтик.

Элек артель хуҗалыгы берничә бригадага бүленгән иде. Һәркайсына тракторлар, кыр эшләрен башкару өчен кирәкле техника бирелгән. Бригада башлыкларының төп принцибы да бик билгеле: «Үз бригадамның эше барсын, бүтәннәрдә гамем юк». Әйтик, яз көне, ди. Беренче бригада кырларында инде туфрак өлгереп җиткән — чык та тырмала, культивация үткәр, чәчә башла. Ә икенче бригада басулары өчен әле кояшның тагын ике-өч көн елмаеп торуы кирәк. Мондый чакта, үзеннән-үзе аңлашыла ки, бөтен техниканы өлгергән участокка чыгару, эшне дәррәү башкару кирәклеге көн кебек ачык. Ләкин «бүтән» бригада башлыкларының исәбе башка — алар «үз» кырларында туфрак өлгергәнне көтәләр. Техниканы «күрше» басуына чыгарырга әйтә күрмә. Ә председатель яки партоешма секретаре бригадирларга нәкъ шуны — «колхозныкы — димәк, барыбызныкы да» дигән гади хакыйкатьне кабат аңлатырга мәҗбүр булалар. Шуннан соң гына механизаторларга «күрше» бригада кырларына чыгарга нәрәт бирелә.

Ә цех структурасы — бөтенләй башка. Игенчелек цехы начальни-

гы — ул, гадәттә, колхозның баш агрономы да — кыр эшләренә кагылышлы бөтен техникага үзе хуҗа. Кешеләрне дә ул оештыра. Колхоз председателенә: «Гайнан агай, иртәгә семена ташырга чыгарсың, синә Зәйни абзый булышыр», — дип, радио аша нәрәт бирү дә кирәк булмый. Ул инде колхоздагы барлык эшләрнең оператив барышын контрольдә тота, төп мәсьәләләрне хәл итә, икенче төрле әйткәндә, нәкъ менә үзенең җитәкче вазифаларын үти ала. Колхозның аргы басуы өлгерсә дә, биргесе кибеп җитсә дә — ул белә: цех начальнигы техниканы кирәк чакта, кирәк төшкә чыгарачак. Механизаторлар гвардиясе аның командасын гына көтә һәм үтәргә әзер тора. Шулай итеп, яңа структура колхозның индустриаль куәтен — техниканы маневрлы һәм җитештерүчән файдалану мөмкинлеге тудыра. Заданиеләр, конкрет күрсәтмәләр бирү дә гадиләшә — аларны цех начальнигы җиткерә. Болар барысы да эш темпларын тизләтә. «Победа»да җитмеш алтынчы елгы язгы кыр эшләре биш көндә тәгәлләнгәч, моңа хәтта күпне күргән белгечләр дә гаҗәпләнде. Игенчелек цехы начальнигы Хөсәен Яруллин болай диде:

— Ничә еллар эшләп, мондый темпны күргәнем юк иде...

Ә көзен, партоешманың отчет җыелышында, өлкән яшьтәге коммунист Нурулла абый Хәбибуллин цех структурасы өстенлекләрен үзенчә аңлатып бирде.

— Элгәре безгә эш кушучы, күрсәтмә бирүче нәчәльство күп була торган иде. Ә хәзер бер генә командир. Фронттагы шикелле. Цех начальнигы әйттеме — вәссәлам!.. Шуны үтисең.

Яңа система белгечләр күзендә дә, гади колхозчылар карашында да үз өстенлекләрен раслады. Элек бригадирлар председатель кушканны үтәүчеләр генә иде, ә цех начальниклары — гомуми үсеш, уртак уңыш өчен җаваплы кешеләргә әйләнде. Биредә без бик кызыклы проблема — производство үсешенең кешеләр аңына тәэсире һәм ул аңның шул ук производствоны тагын да үстерүгә йогынтысы белән очрашабыз. Соңгы елларда колхоз тормышында булган кайсы гына үзгәрешне алсаң да шул закончалыкны күрергә мөмкин. «Победа» колхозы мисалында моны партком секретаре Альберт Беляев былтыргы отчет җыелышында болай аңлатты:

— Идарә итүнең яңа системасы безгә, күп мәшәкатьләр белән бергә, җиңеллекләр дә алып килде. Күчешне әзерләү, беренче адымнар кыен булды. Аның каравы, цех структурасы шартларында эш темплары һәм сыйфат ягы сөенерлек. Яңача эшләвебезнең беренче елы зур уңыш китерде. Бу, әлбәттә, табигать бүләге генә түгел. Көзнең гадәттән тыш явымлы булуына карамастан, урып-җыюда югалтуларга юл куелмады. Урып-җыюны без районда беренче булып тәгәлләдек. Быел, колхозыбыз тарихында беренче тапкыр, дәүләткә ашлыкны өч план күләмендә тапшыруга ирештек!

Тугызынчы бишьеллык йомгаклары буенча «Победа» КПСС Үзәк Комитеты, СССР Министрлар Советы, ВЦСПС һәм ВЛКСМ Үзәк Комитетының күчмә Кызыл байрагы белән бүләкләнде. Унынчы бишьеллыкның беренче көзен дә Кече елга эшчәннәре зур җиңүләр белән каршылады. Тагын партком секретареның отчет докладына күз салыйк: «Иң яңа техника белән җиһазландырылган ындыр табагы булдырдык. Ашлык чистарту һәм киптерү заводы диярлек ул! Аның экономик нәтиҗәсе дә сизелерлек. Элек ындыр табагында 47 кеше эшли иде, хәзер сигезәү калды. Бөртек әрәм-шәрәм ителми. Экономистларыбызның исәпләвенә караганда, ындыр табагында урнаштырылган агрегат колхоз кассасына елга 15 мең сумны кертеп торачак. Мондый үзгәрешләр терлекчелектә дә бар. Аларны чагыштырмача тиз башкарып чыгуыбызның төп сәбәпләреннән берсе — идарә итүнең яңа структурасына күчү».

Партком секретаре хаклы. Производствоның структур формасы да, аны идарә итү дә хезмәт җитештерүчәнлеген, димәк, үсеш темпларын тизләтә. Моны без киләчәге зур булган идарә формасы, авыл хуҗалыгын промышленность нигезенә күчерүдә әһәмиятле адым, дип бәялибез.

Уңышчы бишьеллыкны сыйфат һәм нәтиҗәлелек бишьеллыгы дип атыйбыз икән — моңа зур һәм тирән мәгънә салына. Димәк, промышленностьта булсын, авыл хуҗалыгында булсын — һәркайда бөтен эшне сыйфатлы итеп башкарырга кирәк. Ә сыйфатлы эш бар яктан да уйланылган, барлык үзенчәлекләре комплекста хәл ителгән чакта гына мөмкин. Бу бер производствога гына кагылмый. Безгә, партия работникларына, экономик, социаль, әхлак, психологик проблемалар белән эш итәргә туры килә. Шуларның барысын да ленинчыл пөхтәлеккә ирешеп, төгәл һәм конкрет хәл итә алсак, производствода уңышларга ирешәчәгебез бәхәссез. Район колхозларында һәм совхозларында оештыру эшләренең төрле формаларын эзләү һәм нәтиҗәләләрен гамәлгә кертү процессы бара.

Безгә еш кына: «Кем ул хәзерге колхоз председателе?» дигән сорауны ишетергә туры килә. Аңа болай җавап бирергә мөмкин: бүгенге колхоз яки совхоз җитәкчесенең вазифалары производствоны оештыру белән генә чикләнми, аңа кырларда, терлекчелек комплексларында ил байлыгын тудыручылар арасында идеологик эш алып барырга да, педагог һәм тәрбияче булырга да, агитатор һәм пропагандист хезмәтен үтәргә дә туры килә. Ул — партиянең аграр политикасын конкрет шартларда тормышка ашыруны оештыручы кеше. Ул — политик эшлекле дә, агроном да, механик та, җир-туфрак хикмәтләрен практикада үзләштергән тәҗрибәле игенче дә, кырларда төрле тәҗрибәләр үткәрүче укымышлы да, культура эшләрен оештыручы да. Бүгенге авыл хуҗалыгын төпкә җигелеп тартучы җитәкчеләр шундый.

Моннан берничә ел элек, «Кызыл йолдыз» колхозына барып керүгә:

— Безнең якларда туфрак начар!.. Көлдә нинди иген үссен инде? — дигән зарны ишетергә туры килә иде. Пәрәү авылы кешеләре бу хакта иман нығытканнар иде шикелле. Хуҗалыкка председатель постына коммунист Тәвкил Вафин тәкъдим ителде. Ул исә үз эшен кешеләр күңелендәге шушы ялган «иманны» какшатудан башлады.

Яңа председатель колхозга җитмеш өченче елның башында килде. Кыен чак иде. Бөртеклеләрнең гектарыннан уртача 5,5 центнер уңыш алынган. Фермалардагы терлек азыгы кыш уртасына хәтле генә җитте.

Тәвкил Вафин Апас якларында туып-үскән кеше. Ә ул тирәләрнең туфрагы безнең колхозчыларның төшенә генә керә. Пәрәү җирләре аның янында — чүл комы. Яңа председательгә шул «комда» иген үстерү мөмкинлеген эштә расларга, кешеләрне шуңа ышандырырга кирәк иде.

Ул Пәрәү кешеләренә үз хыялларын, планнарын аңлатырга кереште.

— Шушы кырлардан җыеп алынган ашлык көшелләрен күреп, үзегезнең дә исләрегез китәр әле! — дип кабатларга ярата иде ул. Ләкин аңа тиз генә ышанмадылар. Шулай да ярдәмгә килүчеләр булды. Төрле тәҗрибәләр башланды. Туфракны ашлау вакытлары һәм ашлама дозаларын билгеләү буенча фәнни тикшеренүләр үткәрелде. Туңга тирән һәм сай сөреп карадылар. Эзләнә торгач, комлы туфракның да җиме табылды. Биредәге шартларда ул җим дигәнебез — туфракны язын һәм көзен ашлау, уҗымны тамырда тукландыру, туңга тирән сөрү һәм тагын бик күп төрле агротехник чаралар комплексы

булып чыкты. Ниһаять, 1974 ел көзендә пәрәүләләр моңарчы һич күрелмәгән уңыш — гектардан 18,4 центнер бөртек алдылар. Колхоз җитәкчесенең Пәрәү җирләренең серенә төшенүен таныргa теләмәүчеләр сагаеп калды: «Очраклы хәлдер бу! — диделәр. — Киләсе ел ни бирер тагын, карарбыз», янәсе.

Ә «киләсе ел» үтә коры булды. Күп кенә хуҗалыкларда чәчүлекләр көеп бетте. Ләкин «Кызыл йолдыз»да гектардан 14,7 центнер бөртек алынды. Бу инде алдан программалап куелган уңыш иде. Былтыр исә Пәрәү кырларының һәр гектарыннан 23,7 центнер ашлык җыеп алдылар. Җиргә караш үзгәрде:

— Үз кырларыбызның ни кадерен, ни хикмәтен белмәгәнбез икән моңарчы, — диләр хәзер.

Вафин үзе мондый сүзләргә әллә ни колак салмый. Ләкин шактый кырыс чырайлы бу җитәкченең карашында юк-юк та җиңү шатлыгы чагылып китә. Күңеле сөенә председательнең, ә уе тагын да нәтиҗәлерәк яңалыкларны эзли. Җирне ярата ул, аның кадерен белә, игенче хезмәтенә мәхәббәте олы.

Ихтыярсыздан, бу җирдә аңарчы эшләгән кешеләр турында уйлап аласың. Шушы колхозда ничәмә-ничә ел буена агроном булып Фәсих Шәһитов торган. Туфракның уңдырышсыз булуына ул шаһит. Туган ягы кырларының хикмәтен нигә аңлый алмады икән ул? Белем җитмәгәнме? Эзләнә, тикшерә белмәгәнме? Әллә җирне яратуы чамалы булганмы? Өзеп әйтүе дә кыен. Ә җитәкче кадрлар белән эшләгәндә, мондый сорауларга да төгәл җавап табарга кирәк була. Мин үзем болай уйлыйм: авылда җитәкче постта эшләүче кеше җирне ярата белсен! Ул үзенең җитәкче булуын онытып та тора ала, әмма җирне ярату хисеннән башка яши алмый. Шунсыз ул игенче түгел,— аны үстерә алмый, шунсыз ул әйбәт җитәкче түгел, — кешеләр күңеленә ачкыч таба алмый. Игенченең күңел ачкычы да — җирдә, туфрак куәтендә, игендә. Шуны аңлаган кешеләрнең эше уңучан була. Җирне сөйгән, игенчеләрне яраткан тынгысыз җаннарның тырышлыгы уңдырышсыз туфракны да юмарт итә. Авылда башкарырга мөмкин булган иң зур эшләрнең берсе бу.

Үз заманында татар шагыйре Габделҗаббар Кандалый: «Иген иккел, рәхмәт өмид итәр булсаң»,— дип язган. Ничәмә-ничә ел буена ашлык уңмаган басуларда мул уңыш үстерә алган Тәвкил Вафин, яшь агроном Фәннүр Ибәтов, сыйфат комиссиясе члены, Бөек Ватан сугышы инвалиды Әмирхан ага Корбанов һәм «Кызыл йолдыз» колхозының башка игенчеләренә нинди генә рәхмәт сүзләре әйтсәң дә аз булыр!

Биредә кыр киңлекләрендә үскән башакны саклый да беләләр. Бу сыйфатны да кешеләр күңелендә тынгысыз председатель керткән яңа алымнар тудырган.

Былтыр көз, шул колхоз кырлары аша узганда, сәер хәл күрергә туры килде. Комбайн арыш ура, ә артыннан механизатор бара. Комбайнчының ярдәмчесе булса кирәк. Нигә агрегатта түгел ул? Без туктап калдык, карап торабыз. Менә ул, иелеп, җирдән бер-ике башак алды да тагын китте. Тагын иелде... Башак җыя лабаса!.

Шундук борылып, «Кызыл йолдыз»га кайттык. Председательне «кыздырып» алырга исәп. Кылны кырыкка ярырдай көндә комбайнчы ярдәмчесен башак җыйдырып йөртмәс!

Тик Вафинны кыздырырга туры килмәде.

— Берәүгә дә башак җыярга кушканым юк, — диде ул.

— Ә җыялар бит..

— Алар сыйфат өчен көрәшә, — дип җавап бирде председатель.— Балл җыялар алар, Дания Салиховна.

Хикмәт колхозда сыйфатны бәяләү өчен кертелгән яңалыкта бу-

лып чыкты. Урып-җыюда югалтуларга юл куймас өчен, һәр агрегатка сыйфат кенәгәсе бирелгән. Анда, бер квадрат метрда фәлән башак калса, ничә балл киметелүе акка кара белән язылган. Шул ук кенәгәдә икенче язма да бар: иң югары баллны җыйган агрегат, башка түләүләрдән тыш, сыйфат өчен өстәмә премия ала.

Комбайнчыларның эшен кич белән сыйфат комиссиясе кабул итә. Участокка аның «очлы күзе» төшкәнче дип, комбайнчылар анда-санда калгалаган башакларны җыеп чыгалар икән. Комиссия члены сыйфат кенәгәсенә баллны язып куя, колхоз экономисты, шул сан нигезендә, механизаторларга тиешле премия күләмен билгели, председатель шуны раслап кул куя. Күрәбез, сыйфат өчен көрәшне оештыруның шактый җитди уйланылган системасы бу. Партком аны председатель тәкъдиме белән раслаган.

Хезмәт сыйфатын болай бәяләү алымы безнең район шартларында әйбәт нәтиҗәле булып чыкты. Ул күпләрне кызыксындырды. Былтыр октябрь аенда без «Кызыл йолдыз»да җирдән файдалануны яхшырту юллары һәм техниканы саклау мәсьәләсенә багышланган семинар уздырдык. Шунда колхоз председателе Тәвкил Вафин болай диде:

— Без исәпләп карадык: балл системасы колхоз буенча һәр гектардан 1,5 центнер ашлыкны артык җыеп алырга мөмкинлек бирде. Безнең җирләрдә аның һәр бөртеге кадерле бит. Кимендә 1850 центнер игенне саклап калдык. Дөрес, механизаторларыбыз сыйфат өчен премияне аз алмады. Ләкин саклап калынган ашлыкның экономик файдасы меңнәр белән исәпләнә. Аннары бит, иптәшләр, эш акчада гына да түгел. Хикмәт — икмәктә! Хикмәт — кешеләр аңында! Без шушы җирләрдә дә ярыйсы гына уңыш үстерергә мөмкин дигән карашны раслый алдык һәм үстерелгән ашлыкларның һәр башагын сакларга кирәк дигән хакыйкатьне сүз белән түгел, сыйфатны бәяләү системасы белән аңлата алдык...

Бик дөрес нәтиҗә ясады иптәш Вафин. Хәзер ул бөтен тармакларда да сыйфатны балл белән билгеләү мөмкинлекләре турында уйлана. Сыйфат кенәгәсе урынына «Хезмәт паспорты» кертергә нияте. Без, әлбәттә, сәләтле, уйлана торган председательнең тәҗрибәләрен күз уңында тотабыз. Яңа алымнарны эзләнүче, тормышка ашырырга омтылучы һәр җитәкчегә кирәк ярдәм һәр вакыт күрсәтеләчәк.

Сыйфат өчен көрәшнең максаты барлык хуҗалыклар өчен уртак булса да, аның формалары бик күп төрле. Әйтик, «Кызыл йолдыз»да балл системасы белән эш йөртсәләр, Столбище совхозында «Сыйфатны идарә итү советы» эшли. Икесенә дә хас булган уртак моментлар да, аерымлыклар да бар. Безгә шушы охшашлыклар һәм аерымлыкларны белеп эшләргә кирәк. Менә шуңа күрә райком һәр хуҗалыкның үзенчәлекләрен өйрәнә, алардагы җитәкче кадрлар һәм коммунистлар белән эшләүдә урындагы шартларны нигез итеп ала.

Столбище коммунистларының бер җыелышына «Сыйфатны идарә итү советы» махсус план тәкъдим итте. Анда совхоз производствосының барлык тармакларын үстерү, фән-техника казанышларыннан киңрәк һәм нәтиҗәлерәк файдалану юллары билгеләнгән иде. Шул планда «Бөтен чәчү мәйданнарындагы культураларның уңышын күтәрү программасын эшләргә» дигән пункт та язылган. Зур планның шушы өлешен үтәү өчен генә дә совхозда гаять күп төрле һәм җитди эшләр башкарылды. Баш агроном Рафас Мәҗитов җитәкчелегендә белгечләр һәр участокта агрохимик тикшеренүләр үткәрде, туфрак структурасын анализлады. Шул нигездә, кайсы басуга нинди культура чәчү нәтиҗәлерәк булыр, дигән сорауга җавап алынды, һәр участокка күпме һәм нинди ашлама чыгарырга кирәклеге билгеләнде. Бу эшләр — чын мәгънәсендә, булачак уңышның якынча күлә-

мен һәм хәтта үсәчәк бөртекләрнең сыйфатын да алдан программалау иде.

Бүгенге колхоз-совхозлар өчен гадәти хәл инде болар. «Аргы басуга бодай чәчик, биргесенә солы да ярар» дип эшләгән заманнар үтте. «Аргы» басуның да, «биргесенең» дә хикмәтләрен-үзенчәлекләрен бел башта, аннары ни чәчәсеңне, нинди орлык чәчәсеңне билгелисең. Колхоз җитәкчеләреннән, белгечләрдән фәнни нигезләрдә эшләү таләп итеlә.

Район партия оешмасы күтәргән кадрлар арасында үсеш перспективасын алдан күреп, заман таләпләренә җавап бирерлек эшләүче, билгеләнгән планнарны инициатива белән үтәүче кешеләр дә аз түгел. Партиянең аграр политикасын яхшы аңлый, аны конкрет эштә, үзенә тапшырылган хуҗалыкта, тармакта, участокта тормышка оста ашыручы кадрлар барында, халык әйтмешли, таулар күчерергә була. Тәҗрибә шуны раслый: теге яки бу хуҗалыкның «аксап» китүе күп кенә очракларда аның башында торган кешенең үз чанасында утырмавыннан килә. Нишлисең бит, андый очраклар да булгалый әле. Әйткәнебезчә, җитәкче кешегә заманның таләпләре бик зур һәм җитди. Кайберәүләр аларны җиренә җиткереп үтәрлек сәләтле, энергияле дә була алмый.

Моннан берничә ел элек районда бер совхоз «аксый» башлады. Партия оешмасы бу хуҗалыкка директор итеп А. Н. Белобородовны тәкъдим итте. Яңа «хуҗа» эшне кадрлардан башлады. Аларның булдыклылыгын, оештыру сәләтен һәм башка сыйфатларын исәпкә алып, кайберләрен бүтән участокларга күчерергә дә туры килде. Болар барысы да эш өчен кирәк иде.

Лаеш кошчылык фабрикасы — иң яңа фәнни-техник казанышлар, аларны практикада куллану җирлегендә барлыкка килгән предприятие. Бу хуҗалык мисалында бүгенге авыл производствосын промышленность нигезләренә күчерү, специальләштерү һәм концентрацияләү кебек иң мөһим проблемаларның бергә төенләнешен дә, хәл ителүен дә күрергә мөмкин.

Анда производство киң масштаблы, технология катлаулы. Эш ритмын атналар-айлар түгел, көннәр-сәгатьләр билгели. Бу ритм «мәрхәмәтсез»: һәр эшчедән, һәр җитәкчедән төгәллек һәм оперативлык таләп итә. Бүген йомыркадан чыгасы чеби нәкъ бүген һәм графикта билгеләнгән сәгатьтә «пип-пип» дип тавыш бирәчәк. Фабрикада бу авазны вакытында ишетәләр. Эш ритмының төгәллеге шуннан башлана. Моңа исә эшчеләрне укыту, профессиональ дәрәҗәләрен күтәрү, тәрбияләү, алар өчен яхшы хезмәт һәм көнкүреш шартлары тудыру нәтиҗәсендә ирешелде.

Бүгенге авыл тормышында бер күренеш кайбер җитәкчеләрне зарланырга мәҗбүр итә. «Безнең авылда нигәдер яшьләр тормый, шәһәргә китү ягын карый» дигән сүзләрне еш кына ишетергә туры килә. Әйе, билгеле чамада безнең районда да бар андый күренеш. Ләкин зарланып кына хәл ителә торган мәсьәлә түгел ул. Аны уңай хәл итүнең үрнәге дә үзебездә — шул ук кошчылык фабрикасы. Аның шәһәрчә салынган поселогыннан яшьләр китми. Киресенчә, элек киткәннәре дә кайта. Монда аларга бөтен мөмкинлекләр бар. Тораклар шәһәр тибында, яслесе, балалар бакчасы, ашханә, культура йорты... Фабрика яшьләре өчен бию мәйданчыклары, тынлы оркестр, төрле түгәрәкләр. Әйе, хуҗалык җитәкчесе яшьләрнең бию мәйданчыгы турында да кайгырта белергә тиеш. Ул производство өчен генә түгел, шул производствода эшләүче кешеләрнең социаль аңы, культура дәрәҗәсе өчен дә җаваплы. Бу җаваплылыкны аңа, җитәкчелек вазифалары белән бергә, партия йөкли. «Безнең авылда нигәдер яшьләр тормый...» дип зарланучы җитәкче агайларга җаваплылыкның

шул ягы турында да уйлана башларга бик вакыт. «Нигәдер» дип мәсьәләне кую үзе үк, без моның хикмәтен аңлап бетермибез, дигән шикелләрәк булып ишетелә. Ә төшенергә кирәк. Әлеге зарланырга яратучы агайларыбыз тормышның производстводан тыш якларын — тәрбия, культура, көнкүреш мәсьәләләрен «иртәгәгә» калдыруны артыграк күрәләр. Ә А. Н. Белобородов производствоны күтәрү эшен нәкъ менә шул яктан — кешеләр турында кайгыртудан башлады. Үзләре турында кайгыртучанлык тойган эшчеләр производство интересларына гамьсез калмый. Фән-техника казанышларын производствога кертә белгән шикелле үк, производствоны яшьлек романтикасына да бәйли белү осталыгы кирәк безгә. Без моны унынчы бишьеллыкта яшьләр белән эшләү программасы дип саныйбыз.

Сыйфат бишьеллыгына район күләмендә гомумән мондый бурычлар билгелибез: производствода нинди хезмәт башкарсаң да, эшең югары нәтиҗәле һәм сыйфатлы булсын! Сәүдә һәм халыкка хезмәт күрсәтүне оештырабыз икән — бу эшебез өчен кешеләр рәхмәт әйтерлек булсын! Авылларыбызны төзекләндерү, хезмәт ияләренең культурасын күтәрү, ялын оештыру турында кайгыртабыз икән — бу кайгыртучанлыкның нәтиҗәсе бөтен халыкны сөендерерлек булсын!

Эшен югары сыйфатлы итеп башкарган кеше, кайда гына эшләсә дә, җәмгыять тарафыннан тиешенчә бәяләнергә тиеш. Монысы инде һәм мораль, һәм материаль стимуллар өлкәсе.

... Мин күңел күземне якын киләчәккә төбим. Анда район колхозлары һәм совхозларының унынчы бишьеллыкта күтәрелгән үрләре балкый. Анда яңа комплекслар:

«Путь Ленина» совхозында 800 баш сыер асрый торган предприятие, «Казан» совхозында 10 мең баш мөгезле эре терлек бар. «50 лет Октября» совхозы бозау үстерү буенча махсус хуҗалык итеп үзгәртелгән. Анда алты мең баш бозау исәпләнә.

Столбище белән Песчаные Ковали авыллары арасында яңа кошчылык фабрикасы салынган. Тавыклар саны — 1 миллион!

«Кызыл ялкын» колхозы сарыклар үрчетүгә специальләшкән. Бередәге комплекста 10 мең баш сарык асрыйлар.


«Нармонский» совхозында яшелчәчелек комплексы эшли. Андыйлар республикада ике генә әле: берсе — Чаллы ягында, икенчесе — безнең Лаеш районында. Ул комплекс ел әйләнәсенә 40 мең тонна яшелчә бирә. Аның билгән мәйданы — 2500 гектар. «Яшел фабрика» янында ук яңа поселок — хәзерге заманның иң яхшы архитектура казанышлары нигезендә төзелгән агрошәһәрчек...

Болар барысы да унынчы бишьеллык ахырына булачак. Бу зур эшләрне башкарып чыкканнан соң, без инде әйтә алачакбыз: Лаеш районында авыл хуҗалыгы производствосын специальләштерү һәм концентрацияләү тәгәлләнде, аның барлык тармаклары индустриаль нигезгә күчерелде.

Без шул көнгә барабыз.

## Изаил Зарипов

# ТУГАН КЫР БАТЫРЫ



Кыш бик җылы килеп, айлар буе гел җепшек тә җепшек булды. Ниһаять, январь урталарында иртән туңдырып җибәрде. Кыш үзенекен итә шикелле: арматура мәйданчыгына менгәндә киез итек астында кар шыгырдый, бияләйләр эченә суык үтеп керә, тимерне ялан кул белән тотсаң, «пешереп» ала. Ә нефтьче, бернигә исе китмичә, гадәти эшен эшли бирә: сальникны тикшерә, электромоторны кармалый, салкын кояшка карап елмая. Аннары — чаңгыларына баса да икенче скважинага юл ала. Таяклары юк аның, канатларын кагынгандай, кулларын селкә-селкә шуа, адымнары пошиныкы шикелле куәтле, матур...

Ул көнне Әнвәр Сафиуллин унҗиде скважинаны йөреп чыкты.

Көн саен шулай.

Егерме өч ел рәттән...

Ә ул иртәдә аның, Герой исеме алганнан соң, беренче вахтасы иде.

Моннан егерме өч ел элек үзенең шау-шуы, ыгы-зыгысы белән промысел сугыш елларындагы хәрби комиссариатны хәтерләтә иде. Әмма бу эшлекле ыгы-зыгы иде.

Кадрлар бүлегеннән Әнвәрне өлкән инженерга җибәрделәр. Закиров — үзе дә гадәтләре белән хәрби комиссариат офицерына охшаш кеше — сүзне бик коры тотты.

— Бездә хәзер фронттагы кебек. Көнне төнгә ялгап эшлибез. Дисциплина да армиядәгечә.

— Ярый.

— Шагалиевкә барырсың, — диде Закиров, әйтерсең Әнвәр ул Шагалиев белән күптән таныш. Әй-йе, өлкән инженер Әнвәр белән ягымлы сөйләшмәде. Бәлки Шагалиев дигәннәре кешелеклерәк булыр...

— Шагалиевне кайдан табарга мөмкин?

— Әй, Рәис, сиңа өстәмә көч килде.

Рәис Шагалиев аңардан да яшьрәк булып чыкты, гәүдәгә дә тәбәнәгрәк. Әнвәргә баштанаяк күз йөртеп чыкты да:

— Монда йөреп тор! — дип бүлмәдән чыкты, ләкин озак тормады.

— Әйдә киттек, — диде, Әнвәрнең җиңеннән тотып.

Озак бардылар. Кәшер авылы янында туктадылар. Скважина янында трактор нефть суырта иде. Каяндыр моторист-оператор килеп

чыкты. Рәис аны насос янына алып килде, сальниктан нефть ага торган урынны күрсәтте.

— Эш урынын тикшереп торырга кирәк. Ничә тапкыр әйтергә сиңа, машина игътибарны ярата, дип.

Әнвәр уйлап куйды: «Кирәгеңне бирер бу, безнең старшинадан да кырысрак. Әлегә соң түгел...» Рәис аның уйларын бүлде:

— Гадәтлән! Кисәтеп торырлык булмасын!

«Әлегә соң түгел, чистарак урын эзләргә кирәк. Мазут мазут инде ул. Машинаны туктатып, төшеп калыргамы икән әллә?»

Урал-ЗИС, текә борылыш ясап, туктап калды. Каршыга моторист-оператор килә иде. Өстендә — яңа гына юылган гимнастерка: «үз кеше». Йөзе ачык, самими. Ул мазутлы кулларын яхшылап сөртте дә мастер белән күреште һәм хуҗалыгын күрсәтергә алып китте.

Шагалиев бер атна буе Әнвәрне үзе белән йөртте. Әнвәр скважинага беркетүләрен, моторны ходка җибәрүгә, кыргычны төшерүгә өйрәтүләрен көтте. Ә аны һаман төрле материаллар, запас частьлар, ягулык төяргә-бушатырга мәҗбүр итәләр, ул скважиналарга солярка ташый һәм тигез итеп бүлә.

Сафиуллин участок территориясе белән танышты. Күп кенә скважиналар Зәй үзәнлегендә иде. Ә Зәй Әнвәргә бала чактан таныш. Ул монда балык тотты, беренче буразнасын сөрде.

Сиксән җиденче скважинада Шагалиев оператор Дегтяревка:

— Сиңа ярдәмче китердем, — диде. Аннары Сафиуллинга мөрәҗәгать итте: — Кара аны, — һәм китеп барды.

Тиздән ул вахтага берүзе чыкты. Алты чакрымлап җәяү барырга туры килде. Караңгы төн иде. Бала чактан таныш урыннар булганга, ул кирәкле җиргә турыдан китте. Бу урында Әнвәр әтисе белән кайчандыр печән чапкан иде. Әнә вышка очы күренә, гөрелте ишетелә башлады. Бу скважина элеккегесеннән көчлерәк — нефть ташкын булып бәрә, ә гөрелтедән арматура һәм трап калтырап тора. Әзрәк курkыныч булып китте: бу гадәти хәлме? Тыңланды, барысын да карап чыкты, тикшерде. Тәртип. Бу — җир асты гөрелтесе.

Ике тармак нефть үткәргеч елга аша үткән урында һәр яз саен боз китәр алдыннан дежур тору тәртибе бар иде. Дежурлар зур игътибар белән боз торышын күзәтәләр. Боз китә башлаганны искәрмәү зур бәла-казага китерергә мөмкин: нефть үткәргеч торбалар шундук өзелә.

Илле дүртенче елда яз иртә килде. Язгы ташу тиз башланды. Кар эри башлау белән, Зәй елгасында боз күтәрелде. Гадәттәгедән ике атнага иртәрәк булды бу. Промыселда боз китүгә әзерләнеп өлгермичалдылар. Өлкән оператор Насыйбуллинга өметле, тырыш егетләрне җыеп, нефть үткәргеч торбаларны саклау бурычы куелды. Насыйбуллин Язкәр оператив группага Сафиуллинны, Зямревны, Тумановны һәм Калашниковны алды.

Үткәргеч янына группа кичен килде. Боз күе зәңгәр төстә булып һәм бик тыныч күренә, ул кешеләргә бәла-каза китерә алыр дип уйларлык та түгел иде.

— Тын булыгыз! — диде Насыйбуллин.

Боз тонык кына ухылдап куйды, аның өстендә яшен сызыклары сыман ярыклар барлыкка килде. Боз мена-мена кузгалырга тиеш иде. Ломнар ходка китте. Башта Зәй өстендә металл тавышлары гына ишетелде: торбаларны боздан аердылар. Аннары тавышлар тоныкланды — бозга күчтеләр.

Боз инде бөтен елга киңлегендә ватылды. Иң куркынычы артта калды. Операторларның күңеле күтәренке иде. Алар бер-берсенә мәзәк сүзләр әйтергә тотындылар. Иң күбе Язкәргә эләкте.

— Промыселда түгел, бозваткыч пароходта эшләргә кирәк аңа.
— Атом бозваткычы ясый башлаганнар икән.
— Әлегә урын булганда, заявка биреп кал.
— Ничәнче разрядлы икәнеңне әйт. Капитан сине берсүзсез алыр.
— Ни дисәң дә диңгезче шул. Аңа Зәй генә түгел, диңгез дә тубыктан.

Төн буе күз йоммадылар. Боз китә башлавын көттеләр, иртән суга көймәләр төшерелде. Алар торбалар буйлап йөреп торды. Операторлар, боз кисәкләрен багорлар белән әләктереп, яр буйларына китерәләр дә аннан елга буйлатып түбәнгә озаталар. Багор белән дә, ишкәкләр белән дә эш итәргә кирәк иде. Көймәләрнең берсе зур бер боз кисәгенә якын килергә өлгермәде, чак кына капланмыйча калды, ә багор да, ишкәкләр дә суга төшеп югалды. Көймәне баулар белән ярга тарттылар, ярга җитәргә аз гына ара калгач, бер зур боз кисәге бәрелеп, көймәне җимерде. Оператор торбага менде, берничә адым атлады һәм, ярга җитәр алдыннан гына тигезлеген югалтып, суга мәтәлеп төште. Әнвәр белән Туманов елгага кереп, аны ярга тартып чыгардылар, учак янына алып килделәр. Кирза итекләренә тулган суны түктеләр, киемнәрен киптерергә ярдәм иттеләр дә яңадан торбалар янына чаптылар.

Әнвәр өенә иртә белән генә кайтты. Хатыны Фая, ишек ачкач, ирен танымый торды, чак-чак кына «Сезгә кем кирәк?» дип әйтмәде.

— Балык тотуны тәмамладык, — диде Әнвәр.

Мәзәк әйтеп маташа. Ә тавышы гадәттәгечә түгел. Димәк, салкын тидергән. Көч-хәл белән басып тора. Ниткән эш бу?! Аның турында күпме кайгыртырга мөмкин? Иренең юеш киемнәрен ут алдына элә-элә, Фая шулай уйланды. Ә бит кияүгә чыгар алдыннан Әнвәр нефть чыгаручыларның эше турында бик мавыгып, мактанып сөйләгән иде.

Иртәнге аштан соң Әнвәр яңадан промыселга җыенды. Фая беренче һәм соңгы тапкыр: промыселда синнән башка да эш тукталмас әле, дип әйтеп ташлады.

— Фая, мин үзем генә түгел бит. Бармыйча булмый, — дип җавап бирде Әнвәр.

... Ә тиздән чынлап та берничә скважинага берүзе калырга туры килде аңа.

Операторлар түземсезлек белән бораулаучылардан яңа скважиналарны көттеләр, аларны бер-ике көнгә булса да алданрак көйләп җибәрергә тырыштылар. Сафиуллин да үзенә тиешле скважинаны бик көтеп алды. Кырык алтынчы скважинадан менә-менә фонтан бәрергә тиеш иде. Әмма бу фонтанны туктатырга туры килә. Скважинадан нефтьне кудырырга урын юк. Бораулыдылар, бораулыдылар, метрлар артыннан кудылар, югары тизлек өчен премия алдылар — әмма боларның барысы да юкка иде. Кырык алтынчы — Сафиуллинның бишенче скважинасы. Бер көнне ул күрше кырык җиденче скважинаның моңа кадәр файдаланылмыйча яткан линиясен тапты. Әгәр дә кырык алтынчы скважинаны вакытлыча шуңа тоташтырсаң? Алай иткәндә скважина срогыннан җиде көнгә элегрәк ходка китәчәк.

Промысел идарәсендә бу гади генә тәкъдимнең нәрсәләр бирәсенә тиз төшенделәр. Тоташтыруның эше бик аз, әмма файдасы гаять зур булачак.

Бу тәҗрибә уңай нәтиҗә биргәч, Сафиуллин идеясе буенча кырык җиденчегә вакытыннан элек өлгергән тагын ике скважинаны тоташтырдылар. Берничә еллар үткәч, кырык җиденче күп кенә скважиналардан нефть җыючы установка булып әверелде. Шул көннән баш-

лап Сафиуллин эзләнде, уйланды, тапты һәм гел камилләштерү тәкъдимнәрен кертеп торды. Соңрак ул инженерлар белән берлектә тагын да мөһимрәк яңалыклар уйлап тапты.

Фая тегү тегә. Әнвәр укый, вакыт-вакыт күзләрен китап битләреннән аерып, рәсем ясап утыручы улына карап ала. Быел Илдар беренче класска барачак. Ә хәзергә ул этисенә һәм әнисенә Беренче Май бүләге әзерли. Түгәрәк тәрәзәле ике будка ясаган. Алар ике багана өстенә куелган. Илдар тагын ике багана өсти. Араларын буяп куя. Өскәрәк кран-блокка охшашлы тагын бер будка ясый. Нәрсә соң бу? Әнвәр китабын бер кырыйга куя да:

— Бу нәрсә, улым, буровоймы? — дип сорый.

— Юк, бу син, эти.

— Шулаймыни, ә монысы сыерчык оясымы?

— Түгел. Анысы теге вакытта сине буровойга алып киткән абый.

Якшәмбе көнне булды бу. Барысы да әбиләренә кунакка киттеләр. Әбиләре өе янына җиткәндә генә аларны сыерчык оясына охшашлы шушы абзый куып тотты да Илдарның этисе Әнвәрне ияртеп алып китте. Шуның аркасында әбисе өстәлендә бик күп чәк-чәк калды. Илдар әнә кәгазьгә кара ноктлар төшерә. Чәк-чәк булырга тиеш.

— Тавык төшенә тары керә, — ди Фая һәм урын җәяргә керешә.

Шул вакыт ишек шакыйлар. Әнвәр ача. Дегтярев кереп тә тормый, бусагадан ук:

— Киттек, әйдә, — ди.

Фая эш киемнәрен бирә, бер сумкага азык-төлек сала. Кая барасыларын, озаккамы икәнен сорап тормый — мәгънәсе юк, кайчан кайтасыларын, эшләре кайчан бетәсен алар үзләре дә белмиләр...

Икенче бер бригада мастеры Тукаев оператор Сафиуллин эшен инде күптән күзәтә.

Партия оешмасы секретаре булганда, Тукаев Сафиуллинны бүтән профоргларга үрнәк итеп китерә иде. Профорг буларак, Сафиуллин, социалистик ярышта җиңүчене билгеләү өчен, иң элек барлык скважиналарны йөреп чыга, барысын да үз күзләре белән күрә, аннан соң гына кәгазьдә расылый. Уйланучан, инициативалы профорг иде ул. Һәркемнән тигез таләп итәргә мораль хокукы бар аның һәм шул ук вакытта барысы белән дә уртак тел таба белә. Сафиуллинны үз бригадасында эшләтәсе килә иде Тукаевның. Бервакыт ул уйлап куйды: «Әнвәр менә дигән парторг була алыр иде. Әмма...»

Тукаев, җае туры килгәндә кереп чык әле дип, Сафиуллинны үзенә чакырды. Вахтадан соң Әнвәр аның янына керде.

— Син, Әнвәр Шакирҗанович, кайчан партиягә керергә уйлыйсың?

Кайчан?.. Бу турыда ул инде күптән уйлап йөри. Әйтергәме моны? Бәлки дөрес аңламас, яки «ник озакка сузасың?» дип гиргн башлар. Ә соң ул нигә суза? Белеме азрак дип саный. Ел саен кичке мәктәпкә керергә уйлап йөри. Гел туры килми. Олыгайган саен партага утырырга уңайсызлана бара. Аннан соң бит әле Илдарны тикшереп тору хокукын да онытырга ярамый. Улы инде җиденчедә укый. Ул үзе сигез классны егерме ел элек бетерде. Бер көнне, аның дәфтәрләрен карап утырганда, Әнвәр иң гади математик мәсьәләнең чишелешен аңлый алмады. Ул Илдарның өлгерешен бары тик язу матурлыгы, төзәтүләрнең булмавы, өчлеләрнең күпме икәнлеге буенча гына тикшерә ала. Әнвәр аның яшендә улы белгән кадәр белми иде. Аңа улы алдында «кулын күтәрергә» яки үзенең белемен арттыру турында гына уйларга кала.

Шунысы да бар: скважиналарында эш гел ул теләгәнчә, ул уйлаганча бармый. Камилләштерү тәкъдимнәре, яңа техниканы үзләштерү исәп-хисапны тирәнтен белүне таләп итә. Ул бер тәкъдим турында сүз кузгаткан иде, нәкъ шул арифметик мәсьәләдә буталды. Ә аның бу тәкъдим өстендә эшләве бөтен промыселга билгеле иде бит.

Әнвәр парторгка әнә шулар турында сөйләде.

Ә парторг болай диде:

— Әлбәттә, уку — бик мөһим нәрсә һәм син укырсың да. Әмма синең кебекләр партиягә хәзер үк кирәк. Рекомендация бирерлек ике кеше тап. Өченчесен үзем язам.

Бер айдан Сафиуллин партия членлыгына кандидат итеп алуларын сорап гариза бирде. Ә бер елдан эшче яшьләр мәктәбенә керде.

Дәресләрне Илдар белән бергәләп әзерлиләр иде. Әнвәр Сафиуллинга моның кадәр авыр туры килгәне булмагандыр. Зәйдә боз ватканда да, көтелмәгән фонтанны «тезгенләгәндә» дә, төнге вахталарда да мәктәп партасы янындагы кебек киеренкелек юк иде кебек. Белемне башка кертүе кыен. Барысы да онытылган. Әйе, алар буынына күп укырга туры килмәде — сугыш комачау булды. Ә хәзер дөнья мәшәкатьләре Печориннар, Наташа Ростовалар, Базаровлар турында түгел, үзеңнең төп бурычың турында уйланырга мәҗбүр итә. Хәзер ул үзенең улы булырлык укучылар белән бер класста. Бәлки хәзер аталарга һәм балаларга төрле программалар кирәктер, дип уйланды Сафиуллин, Печорин образының психологик катлаулылыгын аңларга теләп.

Математика һәм физика дәресләрендә тагын да катлаулырак. Ул аксиома белән теоремаларны бутый, исбатларга кирәкмәгәнне дә исбатларга тырыша. Ә бер дәрестә, теорияне белмәгән килеш, үзенең рационализаторлык практикасыннан бер мисал китерде. Мисал дөрес иде. Ә мәсьәләнең чишелеше табылмады. Дневникка бәя куелды. Өйгә кайткач, аны Илдардан ерак яшерде.

Болай дәвам итәргә мөмкин түгел, нәрсәдер эшләргә кирәк иде. Бер көн дәрескә бармады ул, ике көн. Бер атна ял итте. Әмма кичләрен эче поша иде. Шундый кичләрнең берсендә аның янына оператор Дашков керде.

— Әйдә, җыен! — диде ул.

Әнвәр шатланып китте. Бер-бер хәл булдымы икән әллә? Ул һәртөрле аварияне бетерергә риза, тик дәресләргә генә барырга булмасын. Әмма Дашков эш киемендә түгел иде. Сумкасында — китаплар. Шул көннән башлап Әнвәр өстәмә дәресләр ала башлады. Ял итүне, йокыны кыскартты, кинога йөрүне, телевизор карауны сирәгәйтте.

Үзенең эш практикасын физика дәресләрендә алган белемнәре нигезендә тикшерергә өйрәнеп китте.

Сафиуллинны тагын бер нәрсә борчый иде. Озакламый квалификацияле эшче кадрлар җитмәячәк. Димәк, яшьләрдә бала чактан ук һөнәргә мәхәббәт тәрбияләргә кирәк. Нефть якларында туып-үскән яшь егет каникул вакытларын буровойларда, промыселларда үткәрергә тиеш.

Әнвәр, беренче чиратта, үз улын аеруча игътибар белән күзәтергә керешге. Тиздән ул паспорт алачак. Ә үзе, нефтьче улы була торып, кырлардагы эшне, бораулауны да күргәне юк. Төп мәсьәлә шунда: бу аның гаебе түгел. Әтисенең уйлап җиткермәве...

— Улым, — диде ул бер көнне вахтага китешли. — Бүген миңа төшке ашны китерерсең.

Илдар иптәшләре белән велосипедта кырык җиденчегә килде. Үлән өстенә утырып тамак ялгадылар. Кинәт кенә насос тавышы ишетелде. Ул автоматка көйләнгән. Малайларның күзләре шар булды. Кем эшләтә башлады аны, ул ничек эшли?

— Сез физикадан поршеньлы насосларны үттегезме?

— Җиденче класста ук.

— Димәк, аның эшләү принцибын беләсез? Әйдәгез, хәзер автоматны карыйбыз.

Оператор автомат ячейкасын ачты. Нефть билгеле күләмдә җыелгач, калкавыч насосны эшләтә башлый. Нефть кимегәч, насос туктый. Алар автомат эшен гаҗәпләнеп карадылар, скважинага килүләренә бик канәгать булдылар.

Илдар этисе янына бик еш килеп йөри башлады. Һәм мәктәбеннән соң укырга кереп, Мәскәү нефть институтының автоматика бүлеген тәмамлады.

1971 елның 14 мае.

Бу көнне Әнвәр Сафиуллин үзенең егерме скважинасыннан Татарстан миллиарды исәбенә соңгы тонналарны чыгарды. Беренче тонналарны да ул чыгарган иде.

Бу көнне аның дуслары һәм ярышташлары өч мең дә 100 нче скважинадан миллиард тоннаның соңгысын алдылар. Аның 25 проценттан артыгы «Әлмәтнефть» өлешенә туры килә иде.

Бу көнне Әлмәттә тантаналы бәйрәм булды. Тагын биш кешегә Социалистик Хезмәт Героеның Алтын медальләрен тапшырдылар. Геройлар инде хәзер егерме кешегә җитте. Бу көнне Әнвәр Сафиуллин егерме беренче Герой үзе булачагын белми иде әле. Әмма ул җиңүгә нинди кыенлыклар аша ирешкәнлекне яхшы аңлый. Ә киләчәктә кыенлыклар тагын да күбрәк булачак, планны арттырып үтәү авыррак киләчәк. Чөнки катламнар зәгыйфьләнә бара, нефть запаслары азая. Елга 100 миллион тонна — Татарстан территориясендә җир астыннан нефть чыгару мөмкинлегенең чиге шул. Ләкин чигенергә ярамый. Фронттагы кебек приказ бирелде — ирешелгән чикне озаграк сакларга! Бу, Түмән фронтында һөҗүм киң җәелгәнче, массированный оборонага охшый иде. Ә мондый оборона вакытында гадәттә аеруча батырлык күрсәтүчеләрне генә бүләклиләр.

«Әлмәтнефть» участокларында иң иске скважиналар. Коллектив үз алдында нефть өчен көрәшнең иң авыр еллары торганын яхшы аңлый иде.

Җитмеш өченче ел бик авыр башланды. Январьда кар күп яуды, буран барлык юлларны күмеп китте, электр баганаларын аударды. Тирәндәге насослар, качалкалар тынып калды. Җир астындагы искергән колонналар һәм үткәргечләр дә үзләрен сиздерә тордылар. Өстәвенә катламнар нык суланды.

Егермеләрендә графиктан чыктылар. РИТС начальнигы Александр Карпович Ильин Сафиуллинны вахтадан соң калырга сорады.

— Миңа егермесенә сводка, — диде Ильин.

Әнвәр бер тәүлеклек мәгълүматларны карады: промысел җиде йөз уналты тоннага артка калган иде. Барысын да исәпләдек, барысын да карадык кебек. Әш шунда: бары тик катлам үзгәртү озакка киткән саен югалтуларны бетерү кыенлаша бара. Ильин әйткәнчә, берничә яңа скважиналарны сафка кертү, куәтлерәк насослар кую һәм башка чаралар үткәрү промыселга графикка керергә һәм табигый югалтуларны чикләргә мөмкинлек бирәчәк. Әмма югалтулар табигый гына түгел иде.

— Әнвәр Шакирҗанович, коммунистларны җыярга кайчан булдыра аласың?

— Хәл кыен, Александр Карпович. Бер промысел көче белән генә эшне төзәтеп булмый. Артта калуның сәбәпләре бер бездән генә тормый бит.

— Син нәрсә тәкъдим итәсең?

— Партия җыелышына безгә хезмәт күрсәтә торган башка цехларның да коммунистларын чакырырга кирәк. Безнең сүзләрне ишетү аларга да файдалы булыр.

Партия җыелышының көн тәртибе бик гадәти иде: «Планны үтәү чаралары». Ильин доклад ясады. Ул үз хуҗалыгындагы җитешсезлекләрне күрсәтте дә ремонтчыларга күчте.

— Март аеннан башлап майга кадәр, — диде ул, — промысел өстендә кара төтен эленеп тора. Нигә без үзебезнең арттан кара эзләр калдырабыз? Ремонтчылар аркасында...

Ремонтчыларга эләкте. «Ну Карпыч, үзеңә дә әйтәсе сүзләр бар әле»,— дип уйлап утырды Сафиуллин.

Ул җир өсте җиһазларын прокатлау һәм ремонтлау цехын төнкыйтьләде. Электрикларга да өлеш чыгарды.

— Барысы да дөрес, — диделәр цех работниклары. — Нефтьнең югалган тонналары гаебен без үз өстебезгә алабыз. Тик сез дә аны бүлешегез. Январь аенда гына безгә планнан тыш күпме эш йөкләдегез?.. Дәшмисез?.. Ә скважиналарны ремонтлауга ничек әзерләдегез?

— Вакыт булмады.

— Умырзая[1] җыйдыгызмы?

Нефть чыгаручыларның кимчелекле якларын, әлбәттә, алар яхшы беләләр һәм юкка сүз болгатмыйлар. Яраның нәкъ үзегенә күрсәтәләр...

Бу җыелыштан соң барысының да күзләре киңрәк ачылды.

Сафиуллин участогында бораулаучылар яңа ике скважина бораулап бетереп киләләр. Әмма икесе дә нәтиҗә күрсәтер кебек түгел иде. Ул моннан ун еллар элек бораулаучыларның траншеяларда су үткәргеч коммуникацияләрен калдырып китүләрен исенә төшерде. Аның очы да хәтердә. Бу нәкъ ул унбиш яшьлек малай вакытта беренче буразнага аяк баскан урында иде.

Әнвәр бу урынга таң алдыннан килде. Кыш буе ял иткән җир апрель кояшы астында тирән сулый. Дөя тавы итәгенә килеп тоташкан кыр читендә пычрак соры төстәге кар катламнары ята. Ә кыр өстендә, игенченең күңелен дулкынландырып, куе пар күтәрелә.

Әнә кыр уртасына газик машинасы килеп туктады. Машинадан ике кеше чыкты. Чүмәштеләр. Учларына туфрак алып, иснәп карадылар, бармаклары белән изгәләделәр. Аннары аны сак кына кабат җир өстенә сиптеләр. Председатель белән агроном булырга тиеш, дип уйлап куйды Әнвәр, язгы чәчүгә керешергә җыеналар. Аның йөрәген нәрсәдер чеметеп алды. Менә игенче шатлыгының дулкынландыргыч мизгеле. Аны яучы көтүче кыз күңеле белән генә чагыштырырга мөмкин. Кызык, нинди игенче чыгар иде икән Әнвәрдән. Хәзер эшче хезмәтен яраткан тикле крестьян хезмәтен ярата алыр идеме икән ул. Йоклаган баласын уятырга вакытмы-түгелме дип уйланып торган анадай, җир хакында бу ике кеше кебек борчылып кайгырта белер идеме икән... Хәер, ул үзе дә шушы ук кырдан «уңыш» җыя бит. Туган җирнең тирән катламнарыннан. Менә инде егерме елдан артык. Үзенең көченә ышанып, белеменә, табигый талантына таянып эшли. Ә бәлки шуңа күрә аның эше уңышлы бара-

[1] Яз көне калкып чыккан кар катыш нефтьне шаяртып умырзая дип йөртәләр.

дыр: бу бит аның беренче мәртәбә буразнага аяк баскан кыры, аның туган кыры...

Әлеге ике кеше кабат машинага утырды. Кирегә борылсалар, бер-ике сәгатьтән тракторлар килеп җитә, аның ниятеннән берни чыкмый кала. Ары китсәләр — бүтән участокны тикшерәчәкләр. Машина ары юнәлде. Димәк, туфрак өлгермәгән әле биредә. Әнвәр бу участокта язгы кыр эшләре башланганчы, яңа скважиналарны иске нефть үткәргеч торбага тоташтыру өчен, кичекмәстән траншеяләр казырга карар кылды.

Техниканы бик тиз җибәрделәр. 11290 һәм 10034 нче скважиналар шул ук көнне гомуми системага тоташтырылды. Үз төркемнәрендәге установка сафка басканчы алар 25 мең тонна нефть бирделәр.

Сигезенче установкада эш моның белән генә чикләнмәде. Төзүчеләр аны вакытында өлгертә алмадылар, җирне сөрергә керешер алдыннан биредән китәргә мәҗбүр булдылар. Установканы көзге кыр эшләре алдыннан сафка кертергә ниятләделәр. Скважиналарны тоташтыра торган торба очларын әлегә җир астына яшерделәр. Янәсе, көз көне табылыр...

Җәй көне бу тирәдә тагын биш скважина борауланды. Әмма идарә нефть чыгару буенча планны үтәмәде. Бер тонна нефть чыгару өчен тугыз тонна су кудыртырга кирәк иде. «Әлмәтнефть» парткомы скважина фондларын, хезмәт һәм производство дисциплинасын тикшерү, ярыш оештыру һәм резервларны ачу буенча махсус комиссия төзеде. Бу комиссия идарәгә ярдәм итәргә тиеш иде. Комиссия алдынгылардан саналган беренче служба участокларында да кимчелекләр тапты. Күптән нефть бирүдән туктаган, ремонт көтеп яткан скважина әле эшли торган скважина булып исәпләнә икән. Администрация дә, партия оешмасы да бу күзбуяуны вакытында искәрмәгән. Ильин белән Сафиуллин уңайсыз хәлгә калды: ремонтка тукталган өч скважина тикшерү вакытында ремонтланмыйча җибәрелгән. Сафиуллин өчен бу гомерендә беренче җитди кичереш иде.

РИТС начальнигына һәм партия оешмасы секретарена кисәтү белдерделәр. Сафиуллинга моның бик зур тәэсир итүен күргән партком членнарының берсе коридорда аны тынычландырырга кереште:

— Ул кадәр кичермә. Төзәтерсең. Личное делоңа язмыйча гына бит.

Әһәмияте бармы соң аның: делога яз ни дә, язма ни. Эш шунда: ул күзбуяучы, куркак булып калды. Нишлисең инде, бер кыйналганга өч кыйналмаганны бирәләр, диләр...

Бөтен коллектив белән бердәм булып эшкә керештеләр. Яңа скважиналар кабул ителде, искеләренең режимын яхшырттылар. Скважиналарны машинага көйләү һәм герметизация системасына күчерү планы тиз арада үтәлде. Шулай да эш һаман да киеренке дәвам итте әле.

Ильин Сафиуллин белән Гриникны үзенә чакырды.

— Төзүчеләр сигезенчегә кайта алмыйлар. Шушы көннәрдә колхоз анда туңга сөрү башлаячак. Шуңа кадәр барлык скважиналарны установкага тоташтырырга тырышыгыз, — диде.

Игеннәр инде урып-җыелган. Сигезенче төркемдәге ун скважина үз чиратларын көтә. Ә камыл белән капланган кыр астыннан тоташтырылырга тиешле торба очларын һич кенә дә табып булмый. Аларны табу өчен операторлар һәр торбага су җибәрергә булдылар. Насос эшләргә керешге. Басымны арттырганнан арттыра бардылар. Манометр әнә егермене күрсәтә, егерме бишне...

— Тагын азрак арттырыйк әле!

Стрелка утызны күрсәтә. Кинәт кыр өстенә зәгыйфь кенә фонтан бәреп чыкты — бер торбаның очы табылды. Акрынлап башкаларының да очыннан су бәрде. Соңгы торбаны тоташтырганда, туңга сөрергә чыккан колхоз тракторлары установка янында тора иде инде.

Көн ахырына таба Ильинга бораулау службасы начальнигы шалтыратты.

— Ничек инде алай була, Александр Карпович? Без бораулыйбыз, сез нефтьне суыртасыз. Бертуганнар кебек. Ат аунаган җирдә төк кала, диләр. Бер-беребезгә бәйләнмик инде.

— Эш нәрсәдә? Юньләп сөйлә!

— Безнең егетләр скважинаны үзләштергән арада азрак нефть түккәннәр. Җир өстендә кечкенә генә тап калган. Синең операторың килде дә акт төзеде.

— Башта ук шулай диләр аны. Ул — Сафиуллин. Актны укыдым мин.

— Аңа ход бирмә инде син. Без аны үзебез чистартабыз. Бәлки күндерерсең үзен?

— Бу эшкә мин алына алмыйм!

— Карпыч?

— Ул акт инде миндә юк. Сафиуллин аны, шәһәр Советы депутаты буларак, санэпидстанция аша райсоветка җибәрде.

— Акылдан шашканмы әллә ул?

— Аңла син аны. Ул бу җирләрне яшьтән үк эшкәртеп үскән. Сөргән, чәчкән, урып-җыйган... Ә сез ул җирләрне пычраткансыз. Аны үгетләргә минем тел бармый.

Трубка беравык тынып торды. Аннан икеләнеп кенә тагын телгә килде.

— Бәлки минем үземә аның белән сөйләшеп карарга дыр?

— Сөйләшеп кара.

Ә эш болай булган иде. Скважиналарны карап йөргәндә, Сафиуллин кипкән чишмә ерганагында нәрсәдер ялтыраганын күреп алды. Бу — нефть ага иде. Ул ерганак буйлап югарыга таба атлады. Алда — нефть тулы зур гына чокыр. Өстендә кыр үрдәге тыпырчына. Мөгаен, нефтьне су дип белгәндер дә төшеп ябышкандыр. Әнвәр таяк табып алды да үрдәкне кырыйга тартып чыгарды. Каурыйлар, нефть сеңеп, бер-беренә ябышкан, канатлары авырайган. Әнвәр аны кулына алды. Үрдәк авыр итеп бер сулады да тынып калды. Ә Әнвәр, үрдәкне кулына тоткан килеш, ерганак буйлап ары китте. Ерганак аны буровойга алып килде. Скважинаны бораулап кына бетергәннәр. Үзләштерү бара. Территориядә өч бульдозер нефть җәелгән мәйданны туфрак белән каплый иде.

Сафиуллин тимер белән торбага сугып, чаң кагарга керешге. Бульдозерлар тукталды. Буровойда да эш тынып калды. Күпердән ашыкмыйча гына аның янына бораулаучы төште.

— Оһо! — диде ул. — Менә бу трофей! Ау сезонын озайттылармәллә?.. Петро, кил әле. Син юкка гына берданкаңны апкайтып куйдың. Кешеләр тик тормый. Әнә, төшке ашка нинди каклаган үрдәк китергән!

— Мин сине, имансызны, үзеңне каклармын, — диде аңа оператор һәм борын төбенә үрдәкне китереп төртте.

— Син нәрсә үләксәң белән селтәнәсең? Нефть исенә түзәрлек түгел. Ташла.

— Ә нигә нефтьне агыздыгыз. Мастер кайда?

Бораулаучы эшнең нәрсәдә икәнен аңлады, тынып калды. Аннары:

— Әнә, будкада, — дип ымлады.

Будкада сүз зур булды.

Икенче көнне Ильин янына бораулаучы үзе килде.

— Рәхмәт, — диде.

— Килештегезме?

— Килештек. «Колхоз басуларын пычраткан өчен» дип, үз кесәмнән илле сумга чек язып бирделәр. Елмай, елмай. Бүген сез безне, ә иртәгә без сезне түләргә мәҗбүр итәрбез.

— Менә монысы инде туганнарча түгел, — дип җавап бирде Александр Карпович.

Аның В. И. Ленинның тууына 100 ел тулу уңае белән бирелгән «Хезмәттәге батырлык өчен» медале бар иде. Ул инде сигезенче бишьеллыкта ирешелгән уңышлары өчен Хезмәт Кызыл Байрагы ордены белән бүләкләнгән иде. Аңа республикада нефть промышленностен үстерүдә күрсәткән зур хезмәтләре өчен «Татарстанның атказанган нефтьчесе» исеме бирелде. Актив депутатлык эшчәнлеге өчен ул Әлмәт шәһәренең Почетлы гражданины исеменә лаек булды. Ләкин ул еллар үсеш еллары, һөҗүм еллары иде, үзеңне күрсәтергә җиңелрәк иде.

Әмма Әлмәт нефтьчеләренә бөтен фронт буенча киеренке оборона тотар вакытлар җитте. Елның иң ахыргы көненә кадәр Ленин орденлы «Әлмәтнефть» идарәсендә планның үтәлүе-үтәлмәве билгеле булмады. Шуңа күрә коллективта күзгә ташланып торган хезмәт батырлыклары да юк кебек иде.

Шулай да нәкъ Яңа ел алдыннан Мәскәү газеталарында Указ басылып чыкты. Указда болай дип язылган иде: «Хезмәттә күрсәткән батырлыгы һәм социалистик йөкләмәләрне үтәүдә ирешкән зур казанышлары өчен иптәш Сафиуллин Әнвәр Шакирҗан улына Социалистик Хезмәт Герое исеме бирелә».

Яңа елның беренче вахтасына ул Герой исеме белән чыкты. Көне буе, скважинадан скважинага йөргәндә, бер үк вакытта шатлык та, горурлык та, борчылу да кичерде. Герой исеме егерме өч ел дәвамында кичергән кыенлыклар, авырлыклар өчен түгел, ә алдагы, киләчәктәге авырлыклар белән көрәшкә рухландыру өчен бирелгән кебек тоелды аңа.

Иртәгесен дуслары митингка җыелды. Аның портреты астына зур хәрефләр белән котлау сүзләре язылган. Ораторлар аның турында сөйли, залдагыларның күзләре — аңарда. Димәк, бүгеннән башлап ул һәркемнең күз алдында. Шушындый ук салкын январь көнне — Фая бала табу йортыннан Илдарны алып кайтасы көнне — аенә кайта алмавы никтер исенә төште. Скважинада насоска нидер булган иде. Икенче вахтага калырга туры килде. Герой исеме аны хәзер дә шундый кыенлыкларга, хәтта артыгракка да мәҗбүр итәчәк...

**Мансур Хәсәнов,**
филология фәннәре докторы, профессор

# ТУКАЙ ХАКЫНДА СҮЗ

*Г. Тукайның 90 еллыгына багышланган тантаналы кичәдә сөйләнелгән доклад буенча*

Күп милләтле Ватаныбыз мәдәнияте тарихында шундый исемнәр бар, В. Г. Белинский сүзләре белән әйткәндә, алар «мәңге яши һәм хәрәкәт итә торган күренешләрдән саналалар, алар гомерләрен үлем өзгән ноктада туктальп калмыйлар, ә бәлки җәмгыятьнең агышында алга таба үсүләрен дәвам иттерәләр». Татар халкының бөек шагыйре, күренекле фикер иясе һәм җәмәгать эшлеклесе Габдулла Тукай шундый әдипләр рәтенә керә.

Халыкның бөек шагыйрьләре «буш урында» тумый. Аларны зур социаль һәм милли күтәрелеш дәверләре тудыра. Тукайның иҗат юлын XX йөз башындагы, В. И. Ленин сүзләре белән әйтсәк, «йокымсырау хәлендәге Россия революцион пролетариат һәм революцион халык Россиясенә әверелгән чордагы»[1] азатлык хәрәкәте ялкыны яктырта. Шагыйрьнең беренче иҗат адымнары 1905—1907 еллардагы революция тәэсирендә татар дөньясында көчле демократик хәрәкәт башланган чорга туры килә. Шул хәрәкәт тәэсирендә Тукай яңа татар әдәбиятын башлап җибәрә, милли әдәбиятта критик реализмга нигез сала.

Шагыйрь үз иҗаты белән гасыр башындагы татар мәдәниятенең иң матур сәхифәләрен яза. Татар халкының күңелендә йөргән социаль теләкләрне, аның патриотик һәм милли омтылышларын, эстетик хисләрен Тукай искиткеч тулылык һәм тирәнлек белән чагылдыра. Шуңа да аның мирасының әһәмияте бер татар поэзиясе белән генә чикләнми. Аның иҗат мирасы милли әдәби телнең формалашуында һәм иҗтимагый фикер үсешендә тулы бер эпоханы тәшкил итә. Тукай, беренче булып, рус, дөнья әдәбияты классиклары һәм халык авыз иҗаты җәүһәрләренең татар әдәбиятына үтеп керүенә киң юл ача. Бу җәүһәрләрне аның поэзиясе аша татар укучылары гына да үзләштереп калмый. Әлеге мәсьәлә уңае белән күренекле әдәбият галиме И. С. Брагинский болай дип язган иде: «Габдулла Тукайның әдәби осталык ягыннан гомум Европа биеклегенә күтәрелгән һәм революцион эчтәлек белән сугарылган поэзиясе Россиянең Шәрык әдәбиятларына көчле йогынты ясаган әдәби факторга әйләнә»[2].

Тукай кыска, әмма иҗади яну белән тулы гомер юлы үтә. Матбугатта беренче шигырьләре басыла башлаган 1905 елдан алып рәхимсез чахотка кабергә алып киткән 1913 елга кадәр вакыт эчендә шагыйрь тарафыннан йөзләгән шигырь, тугыз поэма, дистәләрчә публицистик мәкалә язылган. Аның иҗатын һич икеләнүсез гасыр башындагы милли тормышның энциклопедиясе дип атарга мөмкин. Ләкин шагыйрьне бер татар дөньясы алдында торган мәсьәләләр генә борчымый, ул бөтен Россиядә,

[1] В. И. Ленин. Әсәрләр. 4 басмадан тәрҗемә. 23 том. Казан, 256 бит.
[2] «Вестник истории мировой литературы» альманахы, 1960 ел, 5 сан, 4 бит.

нәтта бөтен дөнья күләмендә барган вакыйгаларны иңләргә омтыла. Ул кешә күңелендәге иң яшерен хисләрне уятучы нечкә лирик, эксплуатациягә нигезләнгән тормыштагы гаделсезлекне кискен фаш итүче үткен сатирик, үз чорының иң мөһим сәяси һәм социаль мәсьәләләрен яктыртып баручы ялкынлы публицист була. Тукай шагыйрьлек талантын органик төстә җәмәгать эшлеклесе, гражданлык батырлыгы белән бергә куша, үз гомеренең бөтен мәгънәсен халкын бәхетле итүдә күрә — аның бөеклеге әнә шунда. С. Рәмиевкә язган хатларының берсендә ул зур горурлану белән: «Мин бит синең шикелле саф, коеп куйган поэт кына түгел, мин дипломат, политик, общественный деятель дә бит. Минем күз күпне күрә, колак күпне ишетә»,— ди. Аның бөтен иҗат эшчәнлеге шул сүзләрнең дөреслеген раслый.

Тукайның баһадир шәхесен бер күз ташлауда иңләп бетерү бик кыен, кыска бер мәкаләдә тормышының һәм иҗатының бөтен якларына үтеп керү мөмкин түгел. Шуңа күрә биредә шагыйрь иҗатына бәйле кайбер мәсьәләләргә генә тукталып үтәргә туры килә.

Тукайның иҗат эшчәнлеге башланган чор татар халкы тарихында, аның рухи тормышында һәм культурасында гаҗәеп бер дәвергә туры килә. Яңарыш чоры Европа халыклары өчен нинди роль уйнаган булса, татар халкы өчен Беренче рус революциясе еллары шундый ук роль уйный. XIX йөз ахырында һәм XX йөз башында татар милләте иске, дини кысалардан, феодаль йомыклыктан гомум Россия һәм дөнья прогрессы киңлекләренә таба зур борылыш ясый. Халыкның социаль һәм милли үзаңы уяна. Иҗтимагый фикернең үсешенә көчле этәргеч ясаган көндәлек матбугат туа. Татар театры барлыкка килә. Тарих аренасына революционерларның, талантлы әдипләрнең һәм культура әһелләренең бөтен бер плеядасы күтәрелә: Хөсәен Ямашев, Галиәсгар Камал, Фатих Әмирхан, Мәҗит Гафури, Шәриф Камал, Галимҗан Ибраһимов, Гафур Коләхметов... Нибары ун ел вакыт эчендә алар яңа татар поэзиясен, проза һәм драматургияне, публицистика һәм әдәби тәнкыйтьне, тарих фәнен һәм тел белемен тудыралар. Егерме яшьлек Тукай хаклы рәвештә милли культура әһелләренең иң алгы сафына баса. Аның купкырлы талантында халыкның яңа уянып килгән көчләре аеруча тулы чагыла.

1905—1907 ел революциясе чәчкән орлыклар шагыйрьнең өлгергән, җитлеккән иҗатында мул шытым бирәләр. Изүгә нәфрәт, хөрлеккә сусау һәм туган җиргә тирән мәхәббәт аның иҗатының нигезен тәшкил итә. Революцион демократлык карашлары аның поэзиясенең пафосын һәм төп юнәлешен билгели.

Тукай патша Россиясенең реакцион асылын, тарих тарафыннан аның үлемгә һәм һәлакәткә дучар ителгәнлеген ачып бирә, әрнү һәм нәфрәт белән халыкның авыр хәлен сурәтли. Әмма ул бер вакытта да халыкның көченә һәм мөмкинлекләренә аз гына да шикләнми. Шагыйрьнең үлемсез әсәрләре безгә үткәндәге авырлыклар һәм кыенлыклар турында гына түгел, ә туган җирнең гүзәллеге, аның кешеләренең рухи матурлыгы хакында да сөйли:

> **Кысса да синдә фәкыйрьлекләр, ятимлекләр мине,**
> **Изсә дә үз ишләремнән хур вә кимлекләр мине...**
>
> **Бәрсә дә дулкыннарың, һич алмады, гаркъ итмәде;**
> **Алды дүрт ягымнан ялкын, якмады, харкъ итмәде.**
>
> **Бу сәбәптән аңладым мин, и туган җирем, синең**
> **Җанга ягымлы икәндер ялкының да дулкының!**
>
> **(«Туган җиремә».)**

Тукай поэзиясенең сәнгатьчә байлыгын туган җиргә, туган халкына мәхәббәт сугарып тора. Аның гүзәл лирикасы һәм «Шүрәле» поэмалары шул хакта сөйли. Ул әсәрләрдә һәркемгә таныш җирләрнең, бала чактан таныш табигатьнең, үзенә генә хас йолалары, гореф-гадәтләре булган халык тормышының матурлыгы яңадан ачылгандай була. Халыкка, хезмәт кешеләренә булган шушы мәхәббәт Тукай эстетик концепциясенең буеннан-буена сузыла. Шагыйрьнең: «Халык зур ул, көчле ул, дәртле ул, моңлы ул, әдип ул, шагыйрь ул»,— дигән мәгълүм сүзләрендә бу бик ачык чагыла. Бүген, Коммунистлар партиясе җитәкчелегендә совет кешеләре коммунизмның мәһабәт бинасын салган көннәрдә, халык массаларының иҗади куәтенә һәм зур мөмкинлекләренә шул рәвешчә тирән ышану безне аеруча нык дулкынландыра.

Тукайның бөтен шигъри эшчәнлеге новаторлык характерында. Армый-талмый, өзлексез эзләнүләр нәтиҗәсендә ул татар поэзиясен революцион идеяләр, гражданлык лирикасы белән баета, татар әдәбиятында реалистик поэма, үткен политик сатира жанрын гамәлгә ашыра. Тукай интонацияләр байлыгы һәм эмоцияләр төрлелеге белән аерылып торган, әле моңсу, әле шаян яки ироник рухта яңгырый торган, кеше хисләре турында нечкә итеп, ихлас күңелдән сөйләгән бик күп шигырьләр яза. Аның социаль стройның бозыклыгын, тормышның консерватив формаларын фаш иткән кискен һәм үткен эпиграммалары, сатирик шигырьләре киң яңгыраш ала. «Печән базары, яхуд яңа Кисекбаш» поэмасы — аның иң әһәмиятле әсәрләренең берсе. Ярсулы сарказм һәм табигый көлү, политик памфлет һәм тормышчан юмор, фантастик шартлылык һәм реаль картиналар бу поэмада табигый һәм органик рәвештә бергә кушылалар, җитди реалистик сатираның ныклы эретмәсен хасил итәләр. Тукай монда Октябрьга кадәрге татар җәмгыятенең реакцион күренешләрен хурлык баганасына тери, прототиплары реаль тормыштан алынган образларның бөтен бер галереясын тудыра. Дини поэманың сюжет һәм стиленнән файдаланып, ул дини-патриархаль катлауларның рухи хәерчелеген ачып сала, татар тормышындагы феодаль калдыкларны дөмбәсли.

Шагыйрь, кеше һәм гражданин буларак, Тукай бүген безне — коммунизм җәмгыятен төзүчеләрне дә сокландырырлык күп кенә сыйфатларга ия. Аның нык һәм эзлекле патриотизмы, туган җиргә бирелгәнлеге — шундый сыйфатларның берсе. Шунысы аеруча кыйммәт: бу — чын интернационалистның патриотизмы. Шагыйрьнең милли горурлык хисе аның интернационалистлыгыннан аерылгысыз. Тукай, иң беренчеләрдән булып, үз милләтенең хәзергесе һәм киләчәге бөтен илнең тарихи юлыннан, барлык халыкларның азатлык өчен көрәшеннән аерылгысыз булуын аңлый:

**Монда тудык, монда үстек, мондадыр безнең әҗәл;**
**Бәйләмеш бу җиргә безне тәңребез (гыйззе вә җәл).**

**Иң бөек максат безем: хөр мәмләкәт — хөр Русия!**
**Тиз генә кузгалмыйбыз без, и гөрүһе ру сияһ!**

**(«Китмибез!»)**

Шагыйрь руслар һәм башка халыклар белән дуслыкка дан җырлаучыга әйләнә. Җәмгыятьне революцион үзгәртеп кору өчен барган көрәштә төрле милләт хезмәт ияләренең үзара берләшү темасы Тукай иҗатында бөтен көчкә яңгырый. Аның буржуаз милләтчеләргә, пантюркистларга һәм панисламистларга каршы килешмәүчән көрәше идея ягыннан тирән ышанганлыгыннан килә.

Ихлас күңелле лирик һәм ялкынлы трибун Тукай бер үк вакытта тирән фикерләр һәм фәлсәфи гомумиләштерүләргә ия шагыйрь дә була. Аның иҗатында халыкның күп гасырлык тәҗрибәсе, акылы чагыла. Шуның белән бергә, Шәрык поэзиясенә хас хикмәтле сүз традициясе Тукай иҗатында алдынгы рус һәм Европа әдәбиятларының фикер казанышлары белән баый. Татар шагыйре иҗатының буеннан-буена кешенең тормышта тоткан урыны, замандашларының язмышы турында борчылып уйланулар сузыла. Һәм бу пассив борчылу түгел. Тукай иҗатында кешегә мәхәббәт һәм аңа теләктәшлек тарихи оптимизмнан, хөрлек хисеннән аерылгысыз. Ул кеше акылының бөеклеген җырлый. Яктылыкка, аң-белемгә, акылга мөрәҗәгать итү — аның поэзиясенең даими мотивлары. Гади кешене капитал дөньясыннан югары күтәрә торган хезмәтне ул шундый ук кайнарлык белән зурлый. Яшьләргә адресланган шигырьләрендә Тукай гуманистик моральне, дөньяви һәм фәнни карашларны, чынбарлыкка сәламәт мөнәсәбәтне алга сөрә.

Шагыйрь үзен халкының якты киләчәге өчен, иҗтимагый тормышны тамырдан үзгәртеп кору өчен барган көрәштән читтә итеп күз алдына китерә алмый. 1906 елда «Мөселман иттифакы» партиясенә һәм аның җитәкчеләреннән И. Гаспринскийга багышланган «Шартлар» исемле памфлетында ул: «Капиталистический строй бетеп, дөньяга социалистический тормыш чыкмыйча, капиталның һәр хакыйкатькә пәрдә булып торуы бетмичә, мин үзебезне мөселман дип йөрүдә бер мәгънә дә тапмыйм», — дип яза.

Тукай инанган революцион демократ була, эшче сыйныфы партиясе сафларына баскан кешеләрне котлап язган шигырьләре белән ул марксизм-ленинизм идеяләренең бөеклеген аңлауга якын килеп җитә. Шуның белән бергә, Тукайның сәяси карашлары хакында сүз йөрткәндә без, билгеле, шагыйрьнең каршылыклы якларына, аның дөньяга карашындагы кимчелекләргә дә күз йоммаска тиеш. Шул ук вакытта ул кимчелекләрнең объектив, социаль факторларга, шагыйрь яшәгән һәм иҗат иткән шартларга бәйле булуын да онытырга ярамый. Бигрәк тә реакция еллары шагыйрь күңелендә газаплы уйланулар, тирән рухи яралар калдырмый калмаган. Кайчак Тукайның шигъри уйлануларында гаделлеккә, бәхетле тормышка шикләнү авазлары яңгырап китә. Ул чор кешеләрендәге иң яхшы сыйфатларны буып-үтереп торган буржуаз Россия шартларында башкача була да алмаган. 1915 елда А. М. Горький татар шагыйре Тукай турында болай дип язган: «Бу дөнья художниклар өчен түгел, анда һәр вакыт аларга кысынкы һәм уңайсыз булды — шуңа күрә аларның роле мактаулырак та, батыррак та.

Ачлыктан һәм чахоткадан үлгәндә, Казан татарларыннан бер шагыйрь: «Очты дөнья читлегеннән тарсынып күңелем кошы!» дип бик шәп әйткән». Әлеге сүзләрне язганда А. М. Горький нәкъ шул хәлне күздә тоткан. Буржуаз дөньяның тимер читлегендә Тукайның хөрлек сөюче шигъри табигатенә тар һәм тынчу була. Хәтта шундый мизгелләрдә дә татар шагыйренең йөрәгендә изү-кыерсытулар эчендә яшәгән хезмәт кешеләренә мәхәббәт уты сүнми. Без Тукай гуманизмы дип йөрткән якты башлангыч җиңеп чыга. Ул халыкның иҗади көченә ышана. Азат көннәр турында хыялланып, ул:

Җиргә рәхмәт күк төшәр яшьләрнең изге касдлары,
Шаулап аккан су булыр тау башлары, тау астлары.

Күк булып күкрәр һавада хөр яшәү даулашлары,
Ялтырар изге көрәшнең хәнҗәре, алмаслары, —

дип яза. Без үзебезне менә шул какшамас тарихи оптимизмның, шагыйрь һәм гражданин буларак, менә шул ышануның рухи варислары дип саныйбыз.

Новатор шагыйрь буларак, Тукайның роле бәяләп бетергесез зур. Ул татар поэзиясендә үзенә кадәр хакимлек иткән иске кануннарны, дини-мистик һәм сентиментальь романтиканы җимереп ташлый. Ул милли шигъри культураны һәм татар шигырь төзелешен гаять киң юлга чыгара, аның артыннан килүче шагыйрьләр бүген дә шул юлдан баралар.

Әмма татар әдәбияты тарихына новатор шагыйрьнең иҗат практикасы гына түгел, ә бәлки теоретик фикерләре дә гаять тирән йогынты ясый. Ф. Әмирхан, Г. Ибраһимовлар белән бергә, Тукай әдәби тәнкыйтькә, революцион-демократик эстетикага нигез сала. Аның әдәби тәнкыйть мәкаләләрендә сәнгатьнең чынбарлыкка мөнәсәбәте, аның халыкчанлыгы һәм партиялелеге, реализм принциплары кебек гаять мөһим мәсьәләләр күтәрелә һәм хәл ителә. Тукай үз чорындагы әдәбиятның күп кенә күренекле вәкилләре иҗатына тәпле бәя бирә.

Тукай демократик татар культурасын үзенең поэзия, публицистика һәм әдәби тәнкыйть өлкәсендәге әсәрләре белән генә баетып калмый. Чын интернационалист булуы аның рус һәм Европа әдәбиятына иҗади якын килүендә, күп санлы тәрҗемәләрендә һәм тәкъдимнәрендә дә чагыла. Ул, беренче булып, рус теленнән тәрҗемә итүне чын иҗат эшенә әйләндерә һәм бу өлкәдә гүзәл үрнәкләрга ирешә. Тукай аркасында татар укучылары рус язучыларының В. А. Жуковскийдан алып А. М. Горькийга хәтле булган киң даирәсе белән танышалар. Әмма аның милли культураны алдынгы рус һәм Европа әдәбиятларының казанышлары һәм традицияләре белән баету өлкәсендәге роле тәрҗемәләре белән генә чикләнми. Тәрҗемә итү белән бергә, ул алдынгы рус язучыларының ачышларын һәм тәҗрибәсен үзләштерә. Әле иҗат таңында ук «Пушкинә» исемле шигырендә Тукай болай дип яза:

Тыңдасаң шагыйрьсең [афәрин], Пушкин Александр!
Минем дәрт-омтылышым синең дәртең белән бер үктер...

**Бөтен әсәрләреңне укыдым һәм күңелдән ятладым;**
**Гөлбакчаңа кереп, мин дә җимешләреңнән авыз иттем...**

Тукай Пушкин поэзиясенең гуманизмын, хөрлек сөючәнлеген һәм тормышны раслаучан рухын үзләштерә; ул Лермонтов шигырьләренең бунтарьлык пафосын тирән аңлый; аңа Некрасов иҗатындагы нәфрәт һәм сагыш якын була; ул Лев Толстой һәм Максим Горькийга соклана. Менә шуңа да ул үз халкын алар иҗаты белән таныштырып кына калмый, ә бәлки алдынгы рус язучыларының иҗатына хас идеяләрне һәм образларны татар әдәбиятының асылына, татар халкының рухи тормышына алып керә.

Тукай үз күңеленә якын фикер һәм хисләрне Көнбатыш Европа әдәбиятының иң яхшы үрнәкләреннән, аерым алганда, Байрон, Гете, Шиллер һәм Гейне әсәрләреннән эзли. Аның поэзиясенең ялкынында Шәрык, рус һәм Европа шигъриятенең иң яхшы традицияләре бергә кушыла һәм бу яшь татар әдәбиятының идея-эстетик мөмкинлекләрен бик нык көчәйтеп җибәрә.

Тукай иҗаты милли эстетик процессның яңа юлга чыгуы хакында сөйли. XX йөз башыннан, Беренче рус революциясе көннәреннән алып, татар халкы акрынлап дөньякүләм тарихи процесска килеп кушыла. Колониаль артталыктан һәм милли йомыклыктан арына барып, ул дөньякүләм тарихи вакыйгаларга катнаша башлый, гомум Россия күләмендәге азатлык хәрәкәтенең бер өлеше булып әверелә. Халыкның чын тормышын чагылдырган әдәбият та принципиаль яңа биеклеккә күтәрелә. Ул милли чикләнгәнлек һәм Шәрык «оригинальлеге» кысаларын җимерә. Аның тема һәм образлар диапазоны, сәнгатьчә тасвирлау мөмкинлекләре, бер яктан, халыкның яңа тарихи тәҗрибәсе, икенче яктан, дөньядагы алдынгы әдәбиятларның сәнгать тәҗрибәсе исәбенә байый. Башкача әйткәндә, милли әдәбият үсеше дөнья күләмендә барган эстетик процессның магистраль юлына килеп кушыла. Кушылу ноктасы исә — нәкъ менә Габдулла Тукай мирасы.

Билгеле, боларның берсе дә татар әдәбияты үзенең милли йөзен, сәнгатьчә фикерләүнең гасырлар буена туплана килгән милли формаларын югалткан икән дигән сүз түгел. Заманга йөз белән борылу татар халкының рухи тормышына гасырлар буенча якын булган нәрсәләрне читкә алып ташлау түгел. Тукай бу мәсьәләдә дә иң дөрес юлны таба. Ул сәнгатьтәге милли традицияләрнең прогрессив якларын кабул итә, ләкин аларны чынбарлыкны сурәтләүнең яңа реалистик тәҗрибәсе хисабына яңарта, үзгәртә, икенче төрле рәвешкә кертә. Ул XX йөз башында формалашкан дөньякүләм әдәби-эстетик критерийлар биеклегендә торып иҗат итә һәм бу биеклек милли әдәбият һәм сәнгатьнең алга таба үсеш юлында төп нокта булып кала. Тукайның татар әдәбияты, татар халкының рухи культурасын үстерүдәге тарихи роле шунда, һәм аның поэзиясенең интернациональ әһәмияте дә шунда.

Кешелек җәмгыятенең дөнья күләмендәге культура хәзинәсе нәкъ менә күп төрле булуы белән кыйммәтле дә һәм һәр милли культура аңа үз буяуларын, үз төсмерләрен өсти. Тукай мирасы — вакыт ягыннан да һәм әһәмияте ягыннан да татар культурасының XX йөздәге гомум кешелек культурасына керткән беренче казанышы. Шул хакта сөйләүче бик күп дәлилләр китерергә мөмкин.

Ф. Яруллин иҗат иткән «Шүрәле» балетын бөтен Европада беләләр. Ул Европа континенты буйлап Лондон сәхнәсенә кадәр барып җитте. Ә бит «Шүрәле»нең сәнгатьчә образлар дөньясы Тукайның даһи талант көче белән тудырылган. Ләкин хикмәт аерым фактларда гына түгел. Иң мөһиме шунда, Тукайның иҗади батырлыгы күп милләтле социалистик культураның бер өлеше булган хәзерге татар сәнгатенең нигезен тәшкил итә. Шагыйрь эшкәрткән уңдырышлы туфракта соңыннан Һади Такташ, Салих Сәйдәшев, Муса Җәлил, Нәҗип Җиһанов кебек бөтен союзга билгеле сәнгать әһелләре үсеп чыкты.

Тукай поэзиясенең интернациональ әһәмияте төрки телле әдәбиятлар үсешенә әле Октябрьга кадәр үк йогынты ясый башлый. Аның шигъри мәктәбе бик күп татар әдипләрен генә түгел, ә бәлки башка милләтләрнең сүз осталарын да үзенә тарта. Башкорт шагыйрьләре Шәехзадә Бабич һәм Сәйфи Кудаш, үзбәк язучылары Абдулла Кадыйри һәм Гафур Голем, казакъ совет әдәбиятына нигез салучылар Сәкен Сәйфуллин һәм Баимбәт Майлин, таҗик әдәбияты классигы Садретдин Айни, төркмән

язучысы Бирде Кербабаев — үзләрен Тукай мәктәбе шәкертләре дип санаган әдипләрнең тулы булмаган исемлеге менә шундый. Тукай әле исән чакта ук төрки халыклар арасында киң танылa. Казакъ совет язучысы, академик С. Мұканов аны «Шәрык поэзиясенең титаны» дип атады.

Россиядәге төрки телле халыкларның иҗат интеллигенциясен бөек рус культурасына якынайтуда Г. Тукайның роле бигрәк тә зур. Садретдин Айнидан Октябрь революциясенә хәтле Пушкин поэзиясен белә идегезме дип сорагач, ул: «Әйе, белә дә идем, укыганым да бар иде, Тукайдан укыдым», — дип җавап биргән.

Тукай бөек рус әдәбиятын ихлас күңелдән пропагандалаучы була. Шуның белән бергә, рус әдәбияты үзе дә татар шагыйре алдында бурычлы булып калмады. Тукайның русчадан тәрҗемәләре Пушкин, Некрасов, Горький әсәрләрендәге образ һәм идеяләрне төрки халыкларга илтеп җиткерә. Үз чиратында, Тукай иҗаты шундый зур интернациональ яңгыраш алган икән, моның өчен ул шактый дәрәҗәдә русча тәрҗемәләренә бурычлы. Бу тел — шагыйрь иҗатын безнең илдәге һәм чит илләрдәге миллионнарча укучыларга җиткерүче гади арадашчы гына түгел. Рус теле бик күп милли әдәбият әсәрләренә икенче һәм бик еш кына тагын да көчлерәк, киңрәк сулыш бирә. Менә ни өчен бүгенге тантаналы бәйрәм көнендә Тукайны тәрҗемә иткән рус шагыйрьләренең илебез халыклары арасындагы интернациональ дуслыкны ныгытуга керткән өлешен аерым билгеләп үтәсе килә. Аларның иҗади хезмәте татар шагыйренең әсәрләрен яңа яклары белән яктыртырга булышты. Тукайны тәрҗемә итүчеләр арасында Анна Ахматова һәм Павел Радимов кебек олы шагыйрьләр, С. Липкин һәм С. Маршак кебек тәрҗемә осталары булуын әйтү дә җитә.

*
* *

Бөек художникларны һәр эпоха үзенчә ача. Бөек Октябрь революциясе Габдулла Тукай язмышында ифрат зур роль уйнады. Революция булмаса, шагыйрь мирасы тарих байлыгы, үткәннең бер әдәби истәлеге булып калыр иде. В. И. Ленин 1910 елда Л. Толстой үлеме уңае белән болай дигән иде: «Художник Толстой хәтта Россиянең үзендә дә бик аз кешегә билгеле. Аның бөек әсәрләрен һәр кешегә илтеп җиткерү өчен көрәш, миллионнарны һәм дистә миллионнарны караңгылыкка, басынкылыкка, каторга хезмәтенә һәм хәерчелеккә дучар иткән иҗтимагый стройга каршы көрәш кирәк, социалистик алмашыну кирәк». Юлбашчының бу сүзләрен Тукайга карата да кулланырга мөмкин.

Бөек Октябрь революциясе нәтиҗәсендә Тукай мирасы күпкырлы үсеш алган Татарстан сәнгатенең нигез ташына әйләнде. Гыйбрәтле бер факт искә төшә. Г. Тукайны белгән һәм аның талантын югары бәяләгән революция юлбашчысы В. И. Ленин, 1921 елның мартында РКП(б)ның X съездына килгән Казан делегатлары белән очрашкач, татар әдәбиятының хәле белән кызыксына, Г. Тукайның эшен лаеклы дәвам иттерүчеләр бармы, дип сорый. В. И. Ленинга берничә яшь татар язучысын атагач, ул әйтеп: «Димәк, базда дары бетмәгән икән!» — дип куя.

Нәкъ менә социализм җәмгыяте Тукай чәчкән орлыкларга тишелеп чыгарга уңай шартлар тудырды. Әлеге шытымнар хакында сөйләгәндә, без татар совет әдәбиятының һәркемгә билгеле уңышларын гына түгел, ә бәлки татар музыкасының, сынлы сәнгатьнең, театр сәнгатенең дә уңышларын күздә тотабыз. Тукай ачкан образлар дөньясы сәнгатьнең барлык төрләрендә дәвам иттерелә. Аның иҗатының халыкчанлыгы һәм гражданлык хисе, эзлекле интернационализмы республика сәнгать осталарының бүгенге иҗатына үтеп керде.

Безгә бүген Тукай мирасындагы һәм аның гражданлык йөзендәге күп нәрсә — гуманизм һәм хөрлек хисе, фәлсәфи оптимизм һәм халыкка тирән мәхәббәт, Ватанны сөю һәм интернационализм хисе — якын һәм кадерле. Тукай мирасына совет Татарстанының әдәби һәм культура тормышында катнашу хокукы бирә торган бәйләнешне — халык тормышы һәм бүгенге көн белән һәрьяклы бәйләнешне — без югары бәялибез.

Житмешенче еллардагы татар совет әдәбияты һәм сәнгатенең йөзен коммунистик төзелешнең гомум пафосы билгели, ә XXV съезд карарлары аларга алга таба үсү өчен дөрес юнәлеш бирә. Съезд культура әһелләрен «тарихыбызга, бүгенгебезгә һәм иртәгәбезгә, партиябезгә һәм халыкка, бөек Ватаныбызга лаек сәнгать әсәрләре иҗат итәргә» чакырды. Шунысы куандыра, Тукай мирасы бу бурычларны үтәүдә таяныч була ала. Аңардан үрнәк алып, иҗат интеллигенциясе вәкилләре халык арасыннан, замандашларыбызның уй һәм теләкләреннән, бүгенге совет кешеләре тормышыннан үз әсәрләренә яңа темалар эзләп табалар.

Ел саен әдәбият һәм сәнгать өлкәсендәге иң яхшы әсәрләр Г. Тукай исемендәге республика премияләре белән билгеләп үтелә. Әлеге югары бүләкне бирү теге яки бу художникның партиялелеген һәм халыкчанлыгын, югары иҗат осталыгын, аның бүгенге көн белән тыгыз элемтәдә яшәвен тану дигән сүз. Әдәбиятчының һәм сәнгать кешесенең үз хезмәтенә карата таләпчәнлеге дә бу югары бәянең аерылмас бер өлеше булып тора. Сүз татар халык шагыйренә бик тә хас булган таләпчәнлек хакында бара. Шунысы куанычлы, лауреатлар арасында без күп милләтле совет культурасы казанышы булып саналырлык әсәрләр иҗат иткән кешеләрне очратабыз. Менә шуңа күрә Тукайның әһәмияте, аның безнең әдәбияттагы, рухи тормыштагы роле үткән елларга караганда да масштаблырак, тирәнрәк, колачлырак булып килеп баса.

А. С. Пушкин бервакыт «Чын шагыйрьнең әсәрләре мәңге яңа һәм мәңге яшь булып кала» дигән. «Ваксынмыйм» дигән шигырендә Тукай да:

> **Анда мин мәңге көләч һәм мәңге яшь булмак телим;**
> **Бу кояш сүнсен, җиренә мин кояш булмак телим, —**

дип яза.

Без, аның теләге үтәлде, Тукай халык күңеленә шундый кеше булып керде, дип расый алабыз. Эчтәлекләре ягыннан күп мәгънәле һәм тирән булганга күрә, аның әсәрләре мәңге яшь, мәңге яңа булып калалар. Новаторлыгы бер яки берничә әсәрдә түгел, ә бәлки автор шәхесенең, характерының, фикерләү рәвешенең асылында булган бөек художникның язмышы әнә шундый.

Татарстан хезмәт ияләре белән бергә, бүген Тукайны бөтен совет халкы белә һәм ярата. Аның поэзиясе күптән милли чикләрне үтеп чыкты, безнең илдә, ихтимал, татар халык шагыйренең әсәрләре тәрҗемә ителмәгән тел юктыр да. Аның шигырьләре рус, украин, башкорт, казакъ, үзбәк, әзербәйҗан, латыш, уйгыр, чуваш, удмурт һәм башка бик күп телләрдә яңгырый. Немец һәм төрекләр, инглиз һәм венгрлар Тукайны үз телләрендә укыйлар.

Тукай әсәрләренең интернациональ яңгырашы турында сөйли торган күп мисаллар китерергә мөмкин. Аның иҗатына күп милләтле совет әдәбиятының классиклары, прогрессив чит ил әдәбиятларының күренекле вәкилләре югары бәя бирә.

Без инде Габдулла Тукайның тууына 90 ел тулуны билгелибез. Һәр ел саен бу бәйрәм киңрәк интернациональ төс ала бара. Бәйрәм тантаналары бер Татарстанда һәм аның башкаласы Казанда гына түгел, ә бәлки Уфада һәм Уральскида, Ташкентта һәм Алма-Атада, Бакуда һәм Пермьдә, илнең башка шәһәрләрендә һәм республикаларында булып үтте. Күп республикалардан һәм өлкәләрдән килгән кунаклар катнашында үтә торган бүгенге кичә — бәйрәмнең интернациональ характеры турында сөйләүче матур бер мисал. Габдулла Тукайның 90 еллыгына багышланган тантаналы кичә быелның көзендә илебезнең башкаласы Мәскәүдә уздырыла. Кыскасы, татар шагыйренең юбилее күп милләтле бөек илебездәге әдәбият һәм культураларның чын дуслык бәйрәменә әйләнде.

Тукай үз халкының бәхетле һәм якты киләчәге турында хыялланды, шул эшкә үзенең бөтен талантын багышлады һәм гомерен бирде. Шуңа күрә аның мирасы — аның әсәрләрендә генә түгел. Тукай мирасы, аерылмас бер өлеш буларак, үз халкының бүгенге данлы язмышына, аның героик эшләренә һәм батыр хезмәтенә, бөек шагыйрьнең варислары ирешкән бөтен казанышларга килеп тоташа. Бөек Октябрь революциясе һәм КПССның милли политикасы нәтиҗәсендә татар халкы илебез халыкларының туганнарча гаиләсендә үзенә лаеклы урынны алды. Республиканың коммунизм төзелешендәге уңышлары Тукайга иң яхшы һәйкәл булып тора.

Шагыйрьнең туган җире — аның әсәрләрендә гүзәллеге мактанган, авыр тормышы ачынып сурәтләнгән як — бүген иҗади хезмәт республикасына, зур нефть һәм химия, куәтле машина төзелеше, грандиоз төзелешләр республикасына әйләнде. Шуларны тормышка ашыру барышында моңарчы күрелмәгән күп милләтле хезмәт коллективлары барлыкка килде. Шундый коллектив көче белән гигант КамАЗ комплексы төзелеп яткан район хәзер Тукай исемен йөртә. Монда символик мәгънә бар. Бөек халык шагыйренең иң нәтиҗәле иҗат еллары узган, аның шигырьләрендә җырланган мәңге яшь һәм борынгы Казан бүгенге промышленность һәм алга киткән культура үзәгенә әйләнде.

Тукай чын күңелдән үз халкына бәхетле көннәр киләсенә ышанды. Без шул көннәрдә яшибез. Һәм халык аны мәңге үз йөрәгендә саклаячак. Тукай мирасы коммунизмга кирәчәк һәм гасырлар буе онытылмый яшәячәк.

# ИЛЕБЕЗ ӘДИПЛӘРЕ ТУКАЙ ТУРЫНДА

*Журналыбызның бу санында 1976 елның октябрендә илебезнең башкаласы Мәскәүдә Г. Тукайның 90 еллык юбилеена багышлап уздырылган тантаналы кичәдә сөйләнгән чыгышларның берничәсен урнаштырабыз.*

*РЕДАКЦИЯ.*

**Чыңгыз Айтматов,**

Ленин премиясе лауреаты

## МИРАСЫ — ҺӘРКЕМ ӨЛЕШЕ

Г. Тукай калдырган мираста мин үземне дә өлешле итеп тоям, чөнки Тукай ул татар халкының гына шагыйре түгел. Бу мирасның таралу чикләре күп мәртәбәләр киңрәк. Төрки телле әдәбиятларда безнең элгәребез булган бу бөек кеше турында кыскача гына түбәндәгеләрне әйтергә телим.

Мин Мостай Кәримнең, Г. Тукай татар тарихында иң бөек шәхес, дигән сүзләренә тулысынча кушылам. Мондый шәхеснең мәйданга чыгуы очраклы хәл түгел. Минем фикеремчә, андый шәхес тарихның иң киеренке, иң кискен, иң авыр бер мизгелендә, ышаныч һәм өметләр уята торган бер чорында калкып чыга. Россия тарихының революция алды чоры нәкъ әнә шундый иде, Тукайның шигъри аһәңе шул җирлектә бөтен көченә яңгырый башлады. Тик шулай да Тукай — үзе бер могҗиза. Шагыйрь бөеклеге — серле нәрсә, талантны аңлатып бетерүе кыен. Андый талантлар ничек дөньяга килә? Әйтик, М. Ю. Лермонтов һәм дөньяда аның белән бер яшь яшәгән Г. Тукай ни өчен дөньяга килә алганнар? Тукай таланты үзенең өлгереп җиткәнлеге белән таңга калдыра, кайчак хәтта дөньяда ул егерме җиде ел түгел, ә ике йөз җитмеш ел яшәгәндер, дип уйлыйсың. Тукайның фикерләү көче һәм зирәклеге әнә

шундый. Бу бөек шагыйрь һәм бөек художник үзенең политик сизгерлеге һәм социаль аңы дәрәҗәсе белән дә сокландыра. Тукай милләтне уяту, күтәрү өчен көчен кызганмый көрәшә, һәм шул ук вакытта милләтчелекне инкарь итә. Тукай үз урынын милләтне җитәкләп алып баручылар арасында күрә һәм аны артка таба өстерәүчеләргә нәфрәт белән карый.

Тукай эшчәнлегенең әһәмияте — үз халкының тарихын һәм культурасын яңача бәяләүдә. Художник өчен, шәхес өчен бу — бөек казаныш һәм моңа ул рус культурасы, Россия чынбарлыгы белән бердәм булуы нәтиҗәсендә ирешә.

Элеккеге Төркестан, бөтен Урта Азия халыклары өчен дә Тукай иҗатының гаять әһәмиятле булуын әйтәсем килә. Төрки телдә сөйләшүче барлык халыклар Габдулла Тукай шигъриятенең чын-чыннан тирән һәм җуелмаслык тәэсирен кичерделәр, ул бүгенгә көнгә кадәр изге саклана. Безнең якта, Урта Азиянең төрки телле халыклары арасында, Г. Тукай иҗаты белән таныш булмаган, аны белмәгән кеше юк дип әйтергә мөмкин. Чөнки безнең халыкларыбыз рус культурасын һәм рус тәҗрибәсен үзләштерә генә башлаган чорда Г. Тукай Европа һәм рус революцион художестволы фикерен үткәрүчеләрдән булды.

**Рәсүл Гамзатов,**

*Ленин премиясе лауреаты*

# ГАҖӘЕП ЯЗМЫШЛЫ ШАГЫЙРЬ

Габдулла Тукай — татар халкының, төрки телле халыкларның мактанычы, иң күренекле рухи углы. Мин моны куаныч белән әйтәм. Хәзер генә шагыйрьнең юбилей кичәсе узды, бик матур узды. Бу шатлыклы хәл. Минемчә, Г. Тукайның бөтен иҗат юлының безнең барлык халыкларга турыдан-туры бәйләнеше бар. Шуңа күрә без Г. Тукайны үз акыныбыз, шагыйребез, үзебезнең зур һәм олы туганыбыз дип саныйбыз.

Г. Тукай әйтерсең лә үзен тудырган бөек халыкның олы талантына таныклык биреп тора. Аңа минем мәхәббәтем нәселдән килә дип әйтергә мөмкин: мин шагыйрь гаиләсендә туып үстем. Тукай исемен бала чагымда үзебезнең тау битендәге саклябызда ишеттем, шул чактан ук ул минем күңелемә сеңеп калган. Искиткеч язмышлы шагыйрь ул Тукай! Әтием татарча белми иде бит. Төрле телләрдә шигырь язучы безнең Дагстан шагыйрьләре дә әле бер-берсен белеп бетермиләр иде. Ә менә Тукай исеме ерак Татарстаннан елгалар, диңгезләр кичеп килеп җиткән, һәр өйдә үзенә урын тапкан... Аның хакында әтиемнең: «Нинди искиткеч шагыйрь!» дип әйткәне хәтердә. Атаклы рус шагыйре С. Есенин да аны укып: «Нинди шагыйрь бит!» дигән. Тукай шигырьләре белән танышкан һәр кеше дә, мөгаен: «Нинди шагыйрь бит!» дияр. Әнә шундый бөек шагыйрь ул.

Минем туган ягымда, тауларда, шәм дә, электр да юк чагында, утны сүндермичә саклап торучы кешеләр булган. Утны уч төбендәге кебек кадерләп йөрткәннәр. Г. Тукайны да үз халкының ут тотучысы дип атарга мөмкин. Ул талант һәм мәхәббәт уты, ялган һәм вак җанлылык белән килешмәүчәнлек, үз җиренең — һәм инде хәзер безнең бөтен илебезнең — дошманнарына карата нәфрәт уты. Бу утны ул безгә васыять итеп калдырган, һәм без аны еллар, гасырлар аша күтәреп барырга тиеш. Аның яшендәй гомере, исеме һәм язмышы безгә бик кадерле, чөнки ул гомер халык язмышы белән үрелгән. Тукай — зур мирас калдырган шагыйрь, татар халкы өчен генә түгел, барлык халыклар өчен дә уртак мирас ул. Һәм шуңа күрә татар

теленн белмәвем өчен күп тапкыр үкенәм, үземне ярлы итеп сизәм. Әмма шул ук вакытта, аны аңлавым, аның мәхәббәтен, аның дуслык хисен, талантын тоюым белән мин үземне бай кеше дип исәплим. Безгә әнә шундый бөек шәхесне бүләк иткән халыкка рәхмәт әйтәм.

*Шагыйрьнең Мәскәүдә Татарстан телевидениесенә биргән интервьюсыннан.*


**Людмила Татьяничева,**
РСФСР дәүләт премиясе лауреаты


# МӘҢГЕЛЕК ГОМЕРЕ БАКЫЙ

Бөек шагыйрьләрнең туу датасы гына була. Ә гомерләре исә, вакытның үзе кебек үк, туктаусыз дәвам итә, чикләрне танымый. Аларның иҗат мирасы җир йөзендә яшәгән һәм яшәячәк һәр буынның казанышы, бөтен кешелек хәзинәсе булып әверелә. Гомер белән Шекспирны, Пушкин белән Байронны бөтен кешелек дөньясы үзенеке итеп саный.

Ватаныбыз горурлыгы булган олы исемнәр арасында Габдулла Тукайның үлемсез исеме дә биектән якты нур чәчеп балкып тора. Тукайның очкын чәчкән кыска гомере, гражданлылык һәм иҗат батырлыгы, аның элгәресе һәм яшьтәше Лермонтов сызган юл кебек үк, акыл җитмәс дәрәҗәдә гүзәл булып күренә.

Шагыйрьнең яшьлек рухы белән яктырган йөзенә текәлеп караган, аның әле ярсулы һәм нәфрәтле, әле ялкынлы-гайрәтле, әле искиткеч дәрәҗәдә назлы-нәфис шигырьләрен йөрәккә куеп тыңлаган саен, аның шәхесенә, югары намуслылыгына, тирән фикерләр белән тулы әсәрләренә сокланганнан-соклана барасың.

Г. Тукай өлешенә бәяләп бетергесез дәрәҗәдә җаваплы миссия туры килде: ул татар әдәби теленә нигез салучы булды. Русның нәфис сүз өлкәсендә Пушкин нинди эш башкарган булса, үз халкы өчен ул да шул бурычны үтәде, бөек шагыйрь белән рухи туганлыгын ул бик ачык аңлап эш итте.

**Нәзыйрсыз шагыйрь улдың (афәрин), Пушкин Александр!**
**Бәнем дә дәрде шәүкым һәм синең дәрдеңлә якъсандыр.**

Тукай үз халкын Пушкин һәм Лермонтов, Кольцов һәм Никитин шигъриятенә якынайтырга омтылды, аларның әсәрләрен туган теленә гаять оста тәрҗемә итте. «Милләт,— дип язды ул,— образаунный кешеләргә һәм халык файдасын һәртөрле үзенең шәхси мәнафигыннан вә корсак файдаларыннан өстә тота торган, милләт файдасын күз өстендәге кашы дәрәҗәсендә гәҗиз тота торган милләт арысланнарына мохтаҗ». Ул үзе дә әнә шундый баһадир йөрәкле зат иде һәм татар яшьләрендә дә баһадир характерларны күрә алды:

**Йөрмәсен бәгъре өзек милләт киеп кашсыз йөзек,—**
**Без аның бик зур фәхерле, чын бриллиант кашлары!**

Тукай — бөркеттәй үткен күзле кеше — еллар пәрдәсе аша ерактан күрә белде. Һәм ул үзенең горур тормышын соңгы тамчысына кадәр якты килачәк өчен көрәшкә бирде. Беләм, ышанам, аның кабатланмас дәртле, ихлас тавышы яшел планетабыз өстендә һәр вакыт яңгырап торыр. Җир шарының һәр яңа әйләнеше саен ул яңгыраш көррәк, гайрәтлерәк була барыр, чөнки чын шигърият телләр арасындагы киртәләрне үтеп, кешеләрнең йөрәкләрен магниттай үзенә тарта, күңелләрне нурландыра һәм канатландыра ала. Мәңгелекнең гомере мәңге.

**Николай Шундик,**
РСФСР Язучылар союзы идарәсе секретаре

# ХАЛЫКЛАР КҮҢЕЛЕНДӘ

Габдулла Тукай үз гомерен «ярты төш» дип атаган. Ләкин шагыйрь күңеле әнә никадәр рухи энергияне үзенә туплаган булган! Ул энергия аның кыска гомеренең бары тик сигез елы буена очкын чәчеп яктырып тора. Үз халкының язмышына ул якты бер комета булып килеп керә. Әнә шундый шәхесне тудырган татар халкы аны бөек илебезнең — һәм безнең илнең генә дә түгел — барлык халыкларына бүләк итте.

Габдулла Тукай кебек зур иҗатлы, тумыштан килгән бөек талант иясен татар халкы арасыннан 1905 ел революциясенең вулканик көче тартып чыгарды. Социаль темалар Тукайны тирән дулкынландыра, аның рухын азатлык, мәгърифәт идеяләре хәрәкәткә китерә. Шагыйрьнең, асылда беренче булып, татар әдәбиятында большевик образын тудыруы очраклы хәл түгел. Сүз атаклы татар революционеры Хөсәен Ямашевка багышланган «Хөрмәтле Хөсәен ядкаре» дигән шигырь хакында бара.

Габдулла Тукай — чын халык шагыйре һәм чын милли шагыйрь, шуңа күрә дә, диалектика кануннары буенча, чын интернациональ шагыйрь. Әгәр художник үз халкын да ялчы ролендә генә күрергә яраткан милләт аксөякләренең милләтчелек омтылышларын түгел, ә халыкның милли үзаңын чагылдыра икән, аның иҗаты һәрчак интернациональ мәгънәгә ия була, бөтен кешелек өчен кыйммәтле хәзинәгә әверелә. Габдулла Тукай да нәкъ менә шундый шагыйрь.

Бала чагыннан ук хәерчелек һәм хокуксызлык ачысын үз җилкәсендә татып, патша ялчылары һәм үз байгуралары изүеннән җәфа чигүче халыкның аяныч язмышын күреп үскән Тукай беркайчан да хезмәт кешеләренә аркасы белән борылмый, шул халыкның җырларыннан, хыял һәм өметләреннән ул үзенең рухына көч туплый. Милли горурлыкның нәрсә икәнлеген ул яхшы белә, ләкин милли кәпрәю, борын чөю кебек түбәнлеккә беркайчан да төшми.

Монда шунысы бигрәк тә әһәмиятле: Габдулла Тукай кебек югары кешелеклелек башлангычын гәүдәләндерүләре белән бүгенге көндә дә тере һәм эшкә сәләтле булган шәхесләр халыкларның үзара якынаюына ярдәм итәләр. Милләтләр арасындагы киртәләрне җимерүдә алар тыелгысыз көчкә ия, үз халкы туплаган рухи хәзинәләрне башка барлык милләт кешеләренә өләшү бурычын аларга язмыш үзе йөкләгән.

Чыннан да, иҗатларының төп һәм асыл мәгънәсе белән алар, ишек-тәрәзәләрне киң ачып, теләге бар һәр кешене үз халыкларының туган йортына, якты өй түренә чакыралар, ә өйнең хуҗаларына исә алар, киң күңеллелеккә өндәп: күпме бирә алсаң — шул кадәр баерак булырсың! — диләр. Икенче яктан исә Г. Тукай башка халыклар рухи хәзинәләренең дә кадерен белә. Әйтик, ул рус халкының йортына керә, Пушкин, Лермонтов, Кольцов шигъриятенә гашыйк була, аларны татар теленә тәрҗемә итә.

Әмма бу хакта сүз алып барганда, мөһим бер шартны истә тоту тиеш: Габдулла Тукай кебек кешеләрнең халыкларны туганлаштыру миссиясе үзенең бөтен тулылыгында бары тик безнең чорда һәм безнең илдә тормышка аша ала. Г. Тукай үз халкының тулы вәкаләтле рухи вәкиле, дуслык һәм туганлык хәбәрчесе булып әверелде, чөнки илебезнең һавасы, ленинчыл тормыш рухы аңа күкрәк тутырып сулыш алырга, кыска гомер юлын 1913 елда ук тәмам иткән шагыйрьгә Бөек Октябрьдан соң яңадан туарга, мәһабәт сыны белән басып, илебезнең барлык халыклары аңында үз урынын алырга мөмкинлек бирде.

Революцион-демократ, чын гуманист Габдулла Тукай рухы хөкем сөргән шушы залда безнең интернационализмның табигате хакында сүз әйтеп китү бик тә урынлы

булыр, чөнки бу шагыйрьнең иҗаты чын-чыннан бөтен кешелек өчен әһәмияте булган һәм иң якты, иң тирән фикерләрне хәрәкәткә китерүче ышанычлы шартлаткыч-детонатор хезмәтен үти.

Прогрессив акыл ияләре халыклар арасында дошманлык һәм үзара читләшүне бетерү юлларын бик күптәннән эзләгәннәр. Габдулла Тукай да шундый кешеләрнең берсе.

Кайсы гына динне алма, аларның бер-береңне ярату, туганлык турындагы өндәүләре буш сүз булып калды. Алар берсе дә чын туганлыкка ирешә алмады. Руханиларның, хәтта ихлас күңелдән тырышкан хәлдә дә, туганлык урнаштыруда аз гына булса да уңышка ирешкәнен кешелек тарихы белми. Киресенчә, тәре походлары китергән афәтләр, инквизиция һәм дини суешлар фаҗигасе генә тарихка билгеле. Бары тик без, интернационалистлар гына, хезмәт халыклары туганлыгын күзгә күренеп торган, какшамаслык һәм конкрет чынбарлыкка әверелдердек. Менә ни өчен милли мәсьәләне хәл итүдәге безнең тәҗрибә дөньякүләм әһәмияткә ия.

Безнең интернационализм зур сынаулар үтте. Нигезе нык аның. Шуңа күрә дә ул җиңелмәслек, табигый көчкә ия булды. Һәм үзләрен советологлар дип йөртүче әфәнделәр, милли мәсьәләне хәл итүдә без туплаган бу бөек тәҗрибәнең әһәмиятен, пролетар интернационализмның яшәү көчен шик астына алырга теләп, күпме генә көчәнсәләр дә, файдасыз булачак.

Безнең интернационализм агачының куәтле тамырлары гасырлар тирәнлегенә дә, киләчәк чорларга да сузылган. Шундый идея ияләрен бер кем дә һәм бер нәрсә дә бетерә, йолкып ташлый алмый. Җир шарының миллионнарча һәм миллионнарча кешеләре расачылык һәм колонизаторлык политикасы белән килешеп яшәргә теләмиләр. Безнең интернационализм гасырның үз авазы, кешелек дөньясының якты киләчәгенә ышаныч билгесе булып әверелгән бер идея ул. Кешелекнең иң алдынгы акыл ияләре, милли мәсьәләне хәл итүдә без үткән юлны күз алдына китереп һәм киләчәккә карап, алдагы язмышларының якты һәм бәхетле булуына ышаналар, киләчәк көннәре дошманлык һәм явызлыктан, акылны томалаучы дин пәрдәләреннән, шовинистик һәм милләтчелек шаукымнарыннан азат булыр дип өметләнәләр. Һәм тарихта үрнәге булмаган безнең тәҗрибә моңа ныклы нигез бирә. Киләчәкнең бу нурлы йөзе безнең илебез тормышында инде ачык һәм калку булып күренеп тора. Ул гүзәл йөздә без халыклар дуслыгы һәм туганлыгы җырчысы Габдулла Тукай кебек кешеләрнең дә чалымнарын күрәбез. Бүгенге кадерле кичәдә ул үзе дә янәбызда утыра кебек; зирәк шагыйрь Габдулла Тукай белән әңгәмә корганда, күңелгә үзеннән-үзе әнә шундый уйлар килә.

**Михаил Львов,**
СССР Язучылар союзының Мәскәү оешмасы секретаре

## ДӨНЬЯ КЛАССИКАСЫ ДӘРӘҖӘСЕНДӘ

Безнең өчен Тукай — бишек җыры да, баланың телгә килеп, беренче сүзләр әйтү могҗизасы да, шигъри даһилык сере дә, дөньяга караш тәрбияләү дә ул. Тормышы һәм фаҗигасе, гомер ялкыны, безгә аңардан мирас булып калган һәр нәрсә — барыннан да элек, дисталәрчә меңшигырь юллары, кырык басма табактан артык публицистика һәм тәнкыйть — болар һәммәсе безне таңга калдыра, тетрәтә. Ул 1905 елгы Беренче рус революциясе шагыйре иде, революциянең җиңелүеннән соң да ул аңа тугрылыклы булып калды, чөнки революция аның күңелендә, канында, фикер һәм хис-тойгыларында иде. Халык намусы һәм революция идеаллары Г. Тукайның шәхси гадәт-холкын, характерын да билгеләде.

Тукай әсәрләрен укыган саен, аның шигъри даһилыгына гына түгел, фикер һәм карашларының заманыбызга аһәңдәш булуына сокланмый кала алмыйсың. Халыклар дуслыгы бүгенге тормышыбызда һава шикелле үк ихтыяҗга әверелде. Ә ул заманда исә халыклар дуслыгы идеясен тарату, бу идеянең тантана итәсен алдан күрү өчен гаять үткен һәм зирәк акыл, халыкка, туган җиренә аеруча тугрылыклы, намуслы кеше булырга кирәк булган бит. Милли рәнҗү хисенә бирелеп, читкә тибәрелергә дә мөмкин иде бит. Әмма ул халкына хас намуслылык белән һәм бернинди чигенүләр ясамыйча, бернинди эчке һәм тышкы коткы-провокацияләргә бирелмичә, Россия халыклары язмышының бер-берсеннән аерылгысызлыгын алга сөрде. Ул татарларның рус халкы белән элек-электән бергә яшәүләрен күрсәтеп, «без шушы олуг мәмләкәтемезнең сакчысы вә чын гражданы вә бөтен мәгънәсе белән «ватан хадиме» (хезмәтчесе — тәрҗ.) булырга тиешлемез», дип язды. һәм Тукайның укучылары аның бу васыятенә тугрылыклы булуларын мең нәрсә тапкырлар исбат иттеләр. Шагыйрь туган җиргә, халыкка, Россиягә, революция, демократия һәм гуманизмга тугрылыгы белән иң авыр һәм караңгы чорларда да халыкны тәрбияләүдән туктамады. Тормышның шушы бөек юнәлешен яклап һәм раслап нинди генә бәрелешләр аша үтәргә туры килмәде аңа?! Дошманнарыннан чаткылар очты, аларның каурыйлары өтелде. Тукай сатирасын аның шигырьләрен белгән кадәр үк белмиләр. Егерме еллар элек Татиздат тарафыннан Г. Тукай әсәрләренең рус телендәге ике томлыгы (чәчмә әсәрләрдән торган икенче томын редакцияләүдә мин дә катнаштым) әзерләнгән вакытта татар шагыйрьләренең әсәрләрен тәрҗемә итү эше белән Казанга М. Луконин килеп төште. һәм мин аңа, әле кульязмада килеш, шагыйрьнең публицистика һәм сатирасыннан аерым өзекләрне укый башлагач, ул сокланып бетә алмады һәм болар дөнья классикасының иң яхшы сәхифәләре, Гейне язган иң яхшы үрнәкләр дәрәҗәсендә тора, моны шиксез басарга кирәк, чөнки болар Тукайның иҗат йөзенә бик күп яңалык өстәячәк, безнең барлык республикаларыбыздагы укучылар аңында аны баетачак, диде.

Г. Тукай — гаять үткен публицист, ярсулы һәм аяусыз полемист, тирән фикерле тәнкыйтьче, сабыр һәм зирәк тәрбияче. Аның шигърияте дә, публицистик мирасы да дөнья әдәбиятының иң югары сәхифәләре белән янәшә тора.

Г. Тукай Пушкин һәм Лермонтовны изге итеп күрде, аларны кояшка тиңләде, үзен исә аларны чагылдыручы ай дип атады. Әмма үз халкы өчен ул шушы бөек шәхесләр башкарган эшне башкарды.

**Семен Липкин,**
тәрҗемәче

## МАЯК КАБЫЗУЧЫ

Г. Тукай — мөселман мөхитендә яшәп, үзен Пушкинның шәкерте дип атаган шагыйрьләрнең беренчесе. Ватаныбызның төрки телле әдәбиятлары аның әсәрләре аша рус әдәбиятының куәтле йогынтысын татыдылар. Без Тукайның Пушкинга нинди зур хөрмәт белән каравын беләбез. Үзенең атаклы «Шүрәле» әсәрен дөньяга чыгарганда, сүз ахырында ул «...мин бу «Шүрәле» хикәясен Пушкин вә Лермонтовларның шундый авыл җирендә сөйләнгән хыялый хикәяләрне язуына истинадән яздым», ди. «Шүрәле» бүген Ватаныбызның бик күп телләренә тәрҗемә ителгән. Мин дә «Шүрәле»не рус теленә тәрҗемә иттем. Тәрҗемә өстендә эшләгәндә, мин татар шигыренең мәгънәсен генә түгел, ә музыкасын да бирергә тырыштым.

**Иосиф Брагинский,**
филология фәннәре докторы

# ГАБДУЛЛА ТУКАЙ ҺӘМ УРТА АЗИЯ ӘДӘБИЯТЛАРЫ

Бу тема гаять күпкырлы һәм әле ныклап өйрәнүне сорый, табигый, бер генә чыгышта[1] аны иңләп бетерү мөмкин түгел. Шуңа күрә мәсьәләне көн тәртибенә куюю белән чикләнәбез. Сүз Габдулла Тукай иҗатының бер татар мәдәниятендә генә түгел, ә бәлки Урта Азиядәге тугандаш халыкларның мәдәниятләре үсешендә тоткан роле һәм бу мәсьәләне алга таба өйрәнү юллары хакында бара.

Әлеге мәсьәләне дөрес хәл итү өчен, аны киң тарихи аспектта алырга һәм мәгърифәтчелек әдәбиятлары үсешенең уртак характердагы тарихи-типологик закончалыклары белән бәйләнештә карарга кирәк. Совет әдәбияты фәне тарафыннан һәм Көнбатыш, һәм Көнчыгыш әдәбиятлары материалында ныклап өйрәнелгән ул закончалыкның асылын кыскача болай аңлатырга мөмкин. Мәгърифәтчелек идеяләрендә, бер яктан, демократик, халыкчан, икенче яктан, саф буржуаз тенденцияләрнең бергә үрелүен, ә кайчакта үзара бәрелешүен истә тоткан хәлдә, мәгърифәтчелек хәрәкәтенең беренче этабында бу әдәбият вәкилләренең карашларында зур охшашлык һәм шуннан соңгы этапларда алар сафында бүлгәләнү, идея ягыннан аерымлану барлыкка килүне бу хәрәкәткә хас уртак күренешләрнең берсе дип санарга кирәк. Россиядәге Шәрык халыкларының—Идел буе, Урта Азия, Казагыстан һәм Кавказ халыкларының—әдәбиятларындагы мәгърифәтчелек идеяләренең үсешендә дә шул закончалык күзгә ташлана. Шуның белән бергә, XX йөз башыннан алып, Урта Азия һәм Казагыстан белән чагыштырганда, сыйнфый көрәшнең нәкъ менә Идел буенда һәм Кавказда аеруча кискен төс алуы аркасында һәм алдынгы рус мәдәниятенең рухландыргыч тәэсире зуррак булганга күрә, татар һәм әзербәйҗан әдәбиятларындагы мәгърифәтчеләр арасында аерымлану, дифференциацияләнү аеруча кискен төс ала. Мин бары татар әдәбиятына гына тукталам.

Чыннан да, XIX гасыр ахырында татар халкы арасында барлыкка килгән һәм җәдитчеләрнең кадимчеләргә каршы бердәм көрәше төсен алган мәгърифәтчелек хәрәкәте прогрессив характерда була. Идел буенда масса күләмендә революцион хәрәкәт барлыкка килгәнче, җәдитчеләрнең феодаль-клерикаль тәртипләрнең аерым күренешләренә каршы көрәше чагыштырмача прогрессив роль уйный. Шуңа күрә ул заманның алдынгы карашлы язучылары җәдит шәкертләрне уңай геройлар итеп сурәтлиләр, ә аларның дошманнарын — кадимчеләрне кискен тәнкыйть итәләр (мәсәлән, Муса Акъегетнең 1886 елда язылган «Хисаметдин менла» исемле сатирик повестенда).

XX йөз башыннан, бигрәк тә 1905—1907 еллардагы Беренче рус революциясеннән соң хәл тамырдан үзгәрә. Ике юнәлешкә, асылда ике лагерьга — алдынгы, революцион-демократик һәм артка калган, буржуаз-милләтчелек лагерена — тамырдан аерымлану шуннан башлана да инде.

Г. Тукай поэзиясе беренче юнәлеш — революцион-демократик юнәлешнең байрагына әйләнә, өстәвенә, татар мәдәнияте масштабында гына да түгел, ә бәлки күп кенә дәрәҗәдә Урта Азия халыкларының мәдәнияте өчен дә. Г. Тукайның «Мил-

---

[1] Таҗикстан Фәннәр академиясенең член-корреспонденты, «Народы Азии и Африки» журналының баш редакторы И. С. Брагинскийның бу мәкаләсе Г. Тукайның 90 еллыгына багышланган гыйльми сессиядә сөйләү өчен язылган булган. Авыру сәбәпле ул Казанга килә алмады. Редакция.

пәтчеләр» (1908 ел) исемле мәгълүм шигыре программ характерындагы әсәр булып яңгырый. Шуннан берничә юл мисал китерик (бирегә инде җәдитче шәкерт бөтенләй башка, халыкка каршы планда алынган):

**Милләтчеләр сине фәкать алдый гына,**
**Дигән булып: «Җанланасың син тиз минә».**
**Алданма син, калган акчаң өчен алар**
**Укыйлар ич баш очыңда ясин генә!..**
**Алданмыйча, ялгыз башың кабергә керт,**
**Милләтчеләр барчасы да эшсез шәкерт;**
**Алар өчен барыбер: син теләсәң бет!**
**Алданма син: шәкерт алар, шәкерт! Шәкерт!**

Таҗик әдәбиятына нигез салучы С. Айни «Истәлекләр»ендә алдынгы татар культурасының үзенә бик нык тәэсир итүе турында яза. Заманында ул миңа Г. Тукай шигырьләрен ничек яратып укуы, аларга ничек соклануы турында да сөйләгән иде.

Остаз үлеп, берничә ел вакыт үткәч, миңа аның Ташкенттагы рус большевиклары йогынтысында җәдитчелек карашларыннан арынган чорда язылган (1918 елның маенда), моңарчы беркайда да басылмаган «Әй, Ватан» дигән эпиграммасын табарга һәм матбугатта чыгарырга туры килде. Әлеге эпиграммада С. Айни Урта Азиядәге милләтче-җәдитчеләрне камчылый. Халыкка мөрәҗәгать итеп, шагыйрь болай яза:

**Золымнан башка ул сиңа һич нәрсә кылмаса да,**
**Күрсәтә үзен: җан эшем, халкым, ди, фәкать сиңа!**
**Дисен ул: «Хәтта гомерем дә ил өчен, Ватан өчен!»**
**Барчасы үзен кайгырту, алданма, дисә: «Сиңа!»**

Тукай үлеп байтак вакыт узгач язылган бу эпиграмма эчтәлеге ягыннан да, аерым мотивлары һәм тәгъбирләре ягыннан да нәкъ аның иҗаты белән аваздаш.

Бу — очраклы хәл түгел. Бу — гыйбрәтле хәл.

Эш шунда, политик аренага бераз соңрак, шактый дәрәҗәдә 1905 ел революциясенә реакция төсендә чыккан Урта Азия җәдитчелеге үзенең беренче адымнарыннан ук XIX йөз ахырындагы таҗик мәгърифәтчелегеннән (Әхмәт Дониш һәм аның даирәсе) бер адым артка китү булып торган. Анда, әйтик, татар һәм әзербәйҗан әдәбиятларындагыча, төгәл һәм анык аерымлану булмый. Күпмедер мәгънәдә аерымлану бер юнәлеш эченнән намуслы кешеләр эзләүгә кайтып кала. Нәкъ менә С. Айни яки үзбәк әдәбиятындагы Хәмзә һәм Зәукый кебек, намуслы төстә хаклыкны эзләүчеләр үзләренә аһәңдәш мотивларны Габдулла Тукай поэзиясендә очраталар, үзләренең революцион-демократик идеологиягә таба үсешләрендә аңарда әхлакый таяныч табалар.

Габдулла Тукай поэзиясенең революционлаштыру роле турындагы мәсьәлә киңрәк күләмдә куелырга тиеш. Тукай ялгыз булмый бит. Рус революциясе белән рухланып, татар мәдәниятенең башка талантлы вәкилләре дә хәрәкәт итәләр. Шәрыктагы беренче большевистик газета Хөсәен Ямашев җитәкчелегендә нәкъ менә татар телендә чыга бит. Боларның һәммәсе «Айкап» журналы тирәсенә тупланган беренче казакъ язучыларына да революцион йогынты ясамый калмаган, билгеле. Русның демократик, революцион культурасының рухландыргыч йогынтысын таратуда да алдынгы татар культурасының роле сизелә. Шул җирлектә Идел буе, Казагыстан һәм Урта Азиядәге алдынгы кешеләрнең үзара якынаюы һәм туганнарча аралашуы бара. Бу исә безнең бөек совет Ватанының көнчыгыш чикләрендә әлеге халыкларның ленинчыл партия җитәкчелегендә Октябрь һәм социализмның җиңүе өчен бергәләп көрәшүләренә нигез сала.

Боларның һәммәсе җентекләп һәм һәрьяклап өйрәнүне, өстәвенә, коллектив төстә — тугандаш республикалар галимнәренең бергәләп өйрәнүен көтә. Әгәр бу чыгыш шуңа этәргеч бирсә, автор үзалдына куелган бурычны үтәдем дип саный ала.

**Нил Юзиев,**
филология фәннәре докторы

# ФИДАКАРЬЛЕК

Горький урамы белән барып, Татар дәүләт академия театрын һәм Татарстан радио тапшырулар комитеты урнашкан бинаны узгач, Горький һәм Гоголь урамнары чатында сугышка кадәр үк салынган дүрт катлы сары бер йорт бар. 17 нче йорт. Татар халкы өчен кадерле һәм истәлекле йорт. Бу хакта стенага эленгән мәрмәр такта да сөйләп тора: биредә 1940—1941 нче елларда Советлар Союзы Герое, Ленин премиясе лауреаты Муса Җәлил яшәгән. Беренче катта, беренче квартирада. Шушы ук йорт, шушы ук квартира безгә икенче яктан да кадерле: монда озак еллар дәвамында татар халкының социалистик культурасын үстерүгә гаять зур өлеш керткән күренекле җәмәгать эшлеклесе, галим, язучы, тәнкыйтьче, журналист, Җәлилнең иң якын һәм ышанычлы дусты Гази Кашшаф яшәде, соңгы көннәренәчә шушында иҗат итте. Бу квартираның хуҗасын — киң күңелле, гаять ягымлы һәм самими Гази аганы — язучылар гына түгел, күп төрле профессия кешеләре яхшы белә, тирән хөрмәт белән сагынып искә ала. Бөек Ватан сугышының авыр елларында фронтка киткән язучыларның семьялары биредә сыенып урын — җылы почмак тапкан. Сугыштан соңгы елларда да квартираның ишеге һәр кемгә, һәр вакыт ачык булды. Көндезен өйдә туры китерә алмыйсыз икән, кичен рәхим итегез! Әгәр театрга кереп китмәгән булса, ул сезне якты йөзе белән мөлаем елмаеп каршы алыр, эшен куеп торып, эштән бүленгәнгә борчылуын чыраена чыгармыйча, иркенләп сөйләшер. Эшләгән вакыты булса, өстендә аның, мөгаен, җәлилчеләр бүләк иткән җылы халат булыр. Җылы халат дип басым ясап әйтүнең дә сере бар. Беренче катта булуы, зур һәм биек булуы белән Гази аганың квартирасы болай уңайлы гына иде. Әмма җылылык мәсьәләсендә ул хуҗасын бер дә кинәндермәде. Гази ага райсовет, горсоветларга да мөрәҗәгать итте. Берничә тапкыр килеп, ремонт үткәреп, хәтта батареяларны алыштырып та карадылар — хәл әллә ни үзгәрмәде. Гази агага җылырак квартира алу мөмкинлекләре булды, шундый җылы квартираларны тәкъдим итеп тә карадылар. Әмма ул күчмәде. Олы яшьтәгеләргә бер ияләшелгән җирдән китүе, гадәттә, авыр була. Әмма Гази агага килгәндә хикмәт ияләшенгән җирдән китә алмауда гына түгел, моның сәбәпләре тирәнрәк һәм җитдирәк. Монда аның характерына хас сыйфатлар чагыла дияр идем. Сүз тугрылык һәм даимилек турында бара. Иҗатында да, тормышта да ул шулай даими һәм тугры булды. Әдәбиятка, татар культурасына ул гомере буена (егерменче елларның ахырыннан алып үзенең соңгы көннәренәчә) фидакарьлек белән бирелеп хезмәт итте. Авыр еллар һәм салкын айлар да, күңелен рәнҗеткән көннәр дә аз булмагандыр. Әмма ул үпкәләп читкә тайпылмады, ачуланып аркасын бормады — даими һәм тугры булып калды. Әдәбият һәм сәнгать исә тугрылыкны, даимилекне, фидакарьлекне ярата. Шушы уңайдан Башкортстанның халык шагыйре Сәйфи Кудашның Гази Кашшаф турында әйткән сүзләрен китереп үтәсе килә:

«Минемчә, Гази Кашшаф татар совет әдәбиятының сабан туйларында яки ипподромнарда елына бер тапкыр чаба һәм юырта торган аргамакларыннан түгел,— диген иде ул.— Ул татар совет әдәбиятының ел әйләнәсенә муенынннан камыт төшерми торган йөк аты булды. Аны нинди зурлыктагы арбага җиксәләр һәм аңа күпме йөк салсалар, ул шуны тарта һәм алга таба сөйри бирде».

Хаклы әйтелгән сүзләр... Бөек Ватан сугышы һәм сугыштан соңгы елларда (20 елга якын) Татарстан Язучылар союзының партоешма секретаре булып эшләгәндә, озак еллар дәвамында Язучылар союзы идарәсенең председатель урынбасары вазифасын башкарганда, шулай ук «Совет әдәбияты» журналының җаваплы редакторы булганда аның нәкъ әнә шул сыйфатлары аерата ачык күренде. Казан университетының яңа ачылган журналистика бүлегендә укытканда да аңа «авыр йөк аты» кебек эшләргә туры килде: ничә ел буена 900—1000 сәгатьле нагрузка алып барды, өр-яңа курслар хәзерләп укытты. Күпме йөк салсалар, шуны тартты...

Иптәшләре һәм дуслары белән мөнәсәбәттә дә ул шундый — принципиаль һәм тугры иде. Шушы уңайсыз квартирасыннан күчеп китмәве дә, мөгаен, аның Җәлил һәм башка каләмдәш дуслары белән бәйләгән соңгы җепләрне, тарих белән бәйле истәлекләрне, театр белән якынлыкны өзәргә теләмәвеннән килгәндер.

Гази Кашшафның театр тәнкыйтьчесе буларак формалашуында квартирасының театрга якынлыгы нинди роль уйнагандыр, әйтүе кыен. Әмма шунысы ачык: театр Гази агага үз йорты кебек якын булды. Соңгы елларда үзенең фәнни һәм әдәби тәнкыйть эшчәнлеген йомгаклаган китаплар чыгару уе тугач, ул бу эшен театр һәм драматургия турындагы мәкаләләрен туплаган җыентык төзүдән башлады. Шундый җыентык төзеп, нәшриятка тапшырырга да өлгерде. Тик «Күңел көзгесе» исемле ул җыентыкның дөньяга чыкканын гына күрергә өлгерми калды...

Бу квартира белән күп истәлекләр бәйле. Гази аганың шәхси тормышына караган истәлекләр генә түгел, татар әдәбияты тарихына, аның барышына караган, күп язучыларның, театр әһелләренең исемнәре белән бәйле истәлекләр. Бөек Ватан сугышы елларында шушы йорттан язылган хатлар хәрәкәттәге армия сафындагы татар язучыларына әдәбият яңалыкларын ирештергән, аларның күңелләрен җылыткан, аларны иҗатка рухландырган. Шушы йортның хуҗасына — ул чакта Татарстан Язучылар союзының җитәкчесе һәм партоешма секретаре, «Совет әдәбияты» журналының җаваплы редакторы булып эшләгән Гази агага фронтовик әдипләр журнал һәм яңа чыккан китапларны сорап кына түгел, семьяларына ярдәм итүне үтенеп тә, рәхмәтләр әйтеп тә хатлар язганнар. Әгәр М. Җәлил, Ф. Кәрим, Г. Кутуй, И. Гази, Ш. Маннур, А. Шамов, Н. Баян, Г. Әпсәләмов, Ш. Мөдәррис, Г. Хуҗиев һ. б. язучыларның Г. Кашшаф белән язышкан хатларын бергә җыеп бастырырга мөмкин булса, сугыш елларындагы әдәби хәрәкәт шактый тулы булып күз алдына басар, әдәби хәрәкәтне оештыруда, җитәкләүдә Гази аганың нинди роль уйнавы шактый ачык күренер иде.

Бу йорт үз стенасындагы мәрмәр такта белән генә түгел, эчке яктан да Муса Җәлил рухын һәм аның истәлеген даими һәм тугры рәвештә саклап килде. Беренче квартираның Җәлил тормышын һәм иҗатын өйрәнүче үзәк булып әверелүе дә очраклы хәл түгел. Биредә хәзер дә Җәлилнең тормышына һәм иҗатына караган гаять кыйммәтле документлар, материаллар саклана. Әминә ханым Җәлилова Казанга килгән чакларында һәр вакыт шушы йортка туктый. Кызы Чулпанны, бабасына бик нык охшаган оныгы Таняны алып килеп, әти-бабаларының эзләре калган истәлекле урыннар белән таныштыра. Элегрәк, Гази ага исән чакта, аңа Казанга килү күңеллерәк тә, җиңелрәк тә иде. Һәр вакыт Гази ага үзе каршылый, үткәннәрне искә алып төн ката сөйләшеп чыгалар, иртәгесен бергәләп Җәлил һәйкәленә чәчәкләр куялар иде. Хәзер — авыррак... Мәскәүдән алып килгән кып-кызыл роза чәчәкләрен ул икегә бүлә — бер өлешен Җәлил һәйкәленә, икенче өлешен татар зиратына Гази ага каберенә илтә...

Муса Җәлил һәм Гази Кашшаф... Тормышта озак вакытлар бергә очрашып, якын дус булып киткән бу ике шәхеснең исемен үзләре үлгәннән соң да тормыш гел бергә йөртә... Китапларда, газеталарда, документаль фильмнарда, күпләгән кешеләрнең күңелендә... Максим Горький урамындагы йортта бергә очрашканнар

һәм үлгәннән соң да шулай янәшә яшәүләрен дәвам итәләр икән, монда тирән символик мәгънә бар сыман.

Әдәбиятның Горький урамы... Бу — дөнья әдәбиятында Горький нигез салган, хезмәт халкының яңа дәвердәге революцион энергиясен, талант көчен, гуманистик омтылышларын чагылдырган яңа типтагы әдәбият... Шушы яңа әдәбиятны тудыру процессында Горький юнәлеше — Горький урамы ике талантлы татар егетен очраштыра, дуслаштыра һәм тормышның төрле давылларында аларның дуслыгын төрлечә сыный. Утызынчы елларда сыный, Бөек Ватан сугышы елларында сыный... Җәлил хәбәрсез югалганнан соң да тәнкыйтьченең шагыйрь дустына булган тугрылыгын сынау дәвам итә.

Җәлилнең иптәшләре һәм дуслары бик күп булган. Авыр вакытлар килгән чакларда ул шул дуслары арасыннан иң ышанычлы дигәннәрен сайлап алган, шуларга таянган, шуларга ышанган. Гази Кашшаф Җәлилнең әнә шундый иң ышанычлы, иң кайгыртучан якын дусты булган. Бу турыда шагыйрь үзе исән чакта ук хатларында кат-кат искәрткән, язып үткән. Тик Гази аганың тыйнаклыгы аркасында гына ул хатлар, ул хатлардагы күп кенә юллар соңгы елларга хәтле укучыларга тулы хәлендә билгесез булып килде, журнал битләрендә һәм Җәлилнең өч томлык сайланма әсәрләрендә кыскартылып басылды. Гази ага шагыйрьнең яңа дүрт томлыгын хәзерләгәндә дә Җәлилнең үзе турында язганнарын кыскартып бирү фикерендә иде. Редколлегия членнары бердәм үгетләгәч кенә ул элек кыскарткан урыннарны тулыландырырга ризалык бирде. Менә элек кыскартылган шундый өзекләрнең берсе:

> «Кадерлем минем, Кашшаф!
>
> Син минем иң якын һәм кайгыртучан җан дустым идең һәм шулай булып калдың. Минем шундый авыр көннәремдә син үзеңнең дусларча саф күңелдән язылган хатларың белән миңа ярдәм иттең, минем иҗатым, китабым һәм гаиләм турында кайгырттың. Мин чын күңелдән сиңа рәхмәт әйтәм. Ышанам, син хәзер дә мине онытмассың. Минем поэзиямне һәм минем гаиләмне җылы кайгыртучанлык белән чолгарсың. Әгәр мин һәлак була калсам, мин барлык иҗатымны тулысынча сиңа ышанып тапшырам. Васыятем шул, исән чакта язганнарымның барысы да тулысынча синең күзәтүгә бирелә, синең яклавыңа һәм кайгыртуыңа күчә. Мин шат, минем поэзиям ышанычлы кайгыртучан кулларга бирелә...
>
> 20 март, 1942 ел.
> Хәрәкәттәге армия».

Муса Җәлил аңа шулай ышанып һич тә ялгышмаган. Бу хат язылганнан соң ун ел, егерме ел, утыз ел үткәннән соң да — әгәр тылсым көче белән Җәлилне терелтергә мөмкин булса — ул шул ук сүзләрне кабатлар иде: «Син минем иң якын һәм кайгыртучан җан дустым идең һәм шулай булып калдың»...

1944 ел... Җәлил үлемгә хөкем ителгән һәм үтерелгән ел. Шагыйрь турында шикле хәбәрләр таралган ел. Нәкъ шушы елда Казанда «Письмо из окопа» исемендә шагыйрьнең яңа җыентыгы басылып чыга. Җыентык турында иң беренче кайгыртучы кеше — Гази Кашшаф. Үзе төзеп бирә, үзе үк күзәтеп бастыра.

Сугыштан соңгы беренче еллар. Шагыйрьнең Моабит дәфтәрләре туган илгә кайтып җиткән һәм төрле шикләр тагын да куерган еллар. Шагыйрьнең язмышын иң беренче кайгыртып йөргән кеше — шул ук Гази Кашшаф. Ул шушы мәсьәлә белән КПССның Татарстан өлкә комитеты секретаренда була, аның киңәше белән Мәскәүгә — СССР Язучылар союзы генеральный секретаре А. Фадеевка бара, аны мәсьәләнең торышы белән таныштыра, шагыйрьгә булган ышаныч турында сөйли...

Илленче еллар... Шагыйрьнең язмышы ачыкланган, исеме акланган еллар... «Моабит дәфтәрләре»нең авторы бөтен союзга һәм дөньяга танылган чак. Шагыйрьнең әсәрләрен халыкка җиткерү, иҗатын популярлаштыру буенча Гази Кашшаф гаять зур эш алып бара. «Моабит дәфтәрләре»нә иң беренче фәнни комментарийларны язучы да, шагыйрьнең татарча өч томлыгын, русча бер томлыгын хәзерләп чыгаручы да, Муса турында истәлекләр җыючы да — ул. Күп милләтле совет укучылары Муса Җәлил һәм аның көрәштәшләре белән Г. Кашшаф аша, яки аның

хезмәтләреннән файдаланып язылган мәкаләләр аша танышалар. Кашшафның герой-шагыйрь турындагы мәкаләләре дистәләгән телләргә (шул исәптән чит телләргә дә) тәрҗемә ителеп басыла.

Муса Җәлилнең тууына 60 ел тулган көннәр... Әгәр Татарстан Язучылар союзында эшләгән кемнән дә булса: «Муса Җәлилнең тууына 60 ел тулу уңае белән үткәрелгән юбилей көннәрендә укучылар белән иң күп очрашкан, герой-шагыйрь турында иң күп әңгәмә-лекцияләр сөйләгән, иң аз йоклаган, иң күп эшләгән кеше кем?» дип сорасалар, икеләнмичә «Гази Кашшаф!» диячәкләр. Университетның журналистика бүлегендә дәресләр алып бару өстенә, ул илебезнең һәм чит илләрнең газета-журналларына, матбугат агентстволарына Җәлилнең фашизмга каршы алып барган патриотик көрәше турында мәкаләләр язарга да, радио һәм телевидение аша кызыклы әңгәмәләр алып барырга да, көненә берничә урында Җәлил һәм аның көрәштәшләре турында чыгышлар ясарга да өлгерә. Аны без шул ук юбилей көннәрендә Казан һәм Мәскәү дәүләт университетларында Җәлилгә багышланган фәнни конференцияләрдә докладчы итеп тә, Берлинда «Совет-Германия дуслыгы» җәмгыяте тарафыннан оештырылган кичәдә чыгыш ясаучы һәм Җәлил турында тикшеренүләр алып барган немец журналисты Леон Небенцальнең кунагы итеп тә күрдек. Г. Кашшафның шундый күп төрле эшчәнлегенә һәм фидакарьлегенә гаҗәпләнергә һәм сокланырга гына кала.

1976 елда шагыйрьнең 70 еллык юбилее бөтен ил күләмендә киң рәвештә билгеләп үтелде. Авыруы нык көчәюгә дә карамастан, Гази ага бу бәйрәмне үткәрүгә иң зур өлеш керткән кеше булды. Юбилейга хәзерлек берничә ел алдан башланды. Әйтик, М. Җәлил әсәрләренең дүрт томлыгы, фотоальбом, русча бер томлыкларны хәзерләү эше 1974 елның башларында ук кызу темп белән бара иде. Бу айларда унҗиденче йорттагы беренче квартира чын мәгънәсендә Җәлил юбилеен хәзерләү штабына әйләнде. Авырып больницага кергәч тә Гази ага эшен туктатмады: больница палатасында дүрт томлыкның искәрмәләрен язды, булышчыларына корректураларын укып җибәрә торды. Врачлар аның шулай күп эшләвенә кырынрак карый башлагач, ул өенә чыгаруларын үтенде. Квартирасында каты авыру хәлендә эшен дәвам итте. Соңгы фәнни хезмәте — Җәлилнең өченче томына шагыйрьнең яңарак табылган хатларын хәзерләү, искәрмәләр язу булды. Соңгы язмасы — шагыйрьнең семьясы турында кайгыртып язган хаты. Гази ага үлгәндә дә, шагыйрь дустының васыятен үтәп, тугрылык һәм фидакарьлек үрнәге күрсәтеп, батырларча үлде...

Гази Кашшафның әдәби-фәнни мирасы гаять бай. Басылган кадәресе дә күп, басылмаганы, мөгаен, аннан да күбрәктер. Әйтик, соңгы елларда ул университетта татар журналистикасы тарихы буенча лекцияләр укыды, фельетон, очерк кебек махсус предметлар алып барды. Боларның берсе дә хәзергә дөнья күргәне юк — аларны доцент Гази Кашшаф аерым китап рәвешенә китерергә өлгерә алмады. Киләчәктә аның шәкертләре бу кыйммәтле материаллар белән ныграк кызыксынырлар һәм журналистикага караган хезмәтләрен университет нәшриятында аерым китап итеп чыгарырлар дип ышанырга кирәк.

Барлый башласаң, Гази Кашшафның әдәби тәнкыйть һәм әдәбият тарихы буенча басылган һәм басылмаган хезмәтләре дә шактый күп икәнлеге күренер. Аның беренче тәнкыйть мәкаләләре 1928 елда, Казанда Көнчыгыш педагогия институтында укыган вакытларында ук басыла башлый. Утызынчы елларда инде ул әдәби процесста актив катнашкан тәнкыйтьче буларак таныла. 1940 ел аның өчен аеруча истәлекле. Бу елны берьюлы ике китабы дөнья күрә: Шәриф Камал турындагы монографиясе һәм тәнкыйть мәкаләләрен туплаган «Каләм мастерлары» исемле җыентыгы. Тәнкыйтьченең язу мәйданы, иҗади кызыксынуы елдан-ел киңәя. Ул Г. Тукай һәм М. Гафури, Г. Камал һәм Һ. Такташ, М. Гали һәм Г. Кутуй, А. Шамов һәм Ш. Маннур, Ә. Фәйзи һәм М. Әмир, Ф. Хөсни һәм Г. Әпсәләмов турында да яза, барысы турында да төпле сүз әйтергә өлгерә. Татар театрының һәм әдәбиятының ярты гасыр чамасы үсү юлы тәнкыйтьче Гази Кашшафның исеме белән аерылгысыз.

Һәр язучының «төп китабы» булган кебек, тәнкыйтьче һәм әдәбият галиме Гази Кашшафның да «төп китабы», «алтын китабы» бар. Бу — аның Җәлил турындагы хезмәтләре, «Муса Җәлил» исемле монографиясе (1957 һәм 1961 еллардагы басмалары). Җәлил тормышына һәм иҗатына Гази Кашшаф татар әдәбияты тарихының

героик бер сәхифәсен ачучы буларак якын килә, үзенең бай тәҗрибәсен, сәләтен чорыбызның легендар каһарманы һәм бөек җырчысы булып әверелгән шәхесне тикшерүгә багышлый. «Муса Җәлил» монографиясе шагыйрь иҗатын һәм тормыш юлын озак еллар буе фидакарьлек белән өйрәнүнең матур нәтиҗәсе буларак дөньяга килде.

Гази Кашшаф — тәнкыйтьче дә, әдәбият тарихчысы да, публицист та. «Муса Җәлил» монографиясендә авторның бу сыйфатлары үзенчәлекле булып берләшәләр, бер-берсен тулыландыралар. Тәнкыйтьчелек осталыгы Җәлилне шагыйрь һәм язучы буларак ачарга ярдәм иткән. Әдәбият тарихчысы булу аңа Җәлил иҗатын киң әдәби фонда, әдәби процесс белән бәйләп күрсәтергә, тормыш һәм иҗат юлының тулы картинасын тудырырга булышкан. Публицист-журналист булуы аны шагыйрь турында хикәяләүне киң укучы массасына аңлаешлы итеп, җиңел әдәби телдә алып барырга этәргән. Гази Кашшафның шагыйрь белән озак еллар таныш һәм дус булуы китапка төрле истәлекләрне, әдәби процессның җанлы күренеш хатирәләрен алып кергән, эмоциональ җылылыкны тудырган.

«Муса Җәлил» монографиясе хәзергәчә герой-шагыйрьнең тормышы һәм иҗаты турында иң тулы фәнни чыганак булып килә. Шуңа да Җәлил образын әдәбиятта һәм сәнгатьтә гәүдәләндерергә алынган прозаиклар да, драматурглар да, кино эшлеклеләре дә аңа таяналар, андагы бай фактик материалдан файдаланалар.

Гази Кашшаф Муса Җәлилнең тормыш юлына бәйле күп нәрсәләрне ачыклады, тормышына һәм иҗатына караган бик күп яңа фактларны, шагыйрьнең бик күп билгесез әсәрләрен эзләп тапты. Ә бит һәр табылган шигырь, һәр ачылган тормыш факты артында күпме йокысыз төннәр, күпме газаплы һәм татлы эзләнүләр ятканын Гази Кашшаф үзе генә белгәндер. М. Җәлил турындагы безнең белемебез илленче-алтмышынчы елларда никадәр тулыланды, тирәнәйде! Моңа, әлбәттә, барыннан да элек, Гази Кашшафның эзләнүләре, аның ачышлары сәбәпче булды. Ул Муса Җәлилнең героик характерын, фашистларга каршы алып барган яшерен көрәшен яңадан-яңа, берсеннән-берсе кызыклырак мәгълүматлар белән баета торды. 1957 елны басылган китабында ул безгә Җәлилнең фашистларга каршы көрәше турында «Моабит шигырьләре»нә таянып, гомуми рәвештәрәк сөйләгән иде. Ул чакта хәтта шагыйрьнең блокнотында фашистлар тарафыннан гаепләнеп төрмәгә ябылган 12 кешенең, Җәлил һәм Алиштан калганнарының, кем икәнлекләрен дә, көрәшнең ничек һәм нинди конкрет шартларда баруын да белми идек. Җәлил үзе дә:

**Әкияттәге серле йомгак булып**
**Җырым калды сүтелеп юлымда,—**

дип, очраклы рәвештә генә язмаган. Гази Кашшафка бу катлаулы эштә чын мәгънәсендә эзтабар, тикшеренүче булырга, С. Смирнов кебек, йөзләгән кешеләр белән бәйләнешкә керергә, Н. Андроников кебек, хакыйкать эзләп илне аркылыдан-буйга гизәргә, «серле йомгак»ны күп көч куеп, зур түземлелек белән сүтәргә туры килә. Ул М. Җәлилнең инде үлгән дип исәпләнгән көрәштәш дусларын эзләп таба, шагыйрь дәфтәрендә язылган исемнәрдән башка көрәшчеләрне һәм яшерен төркемнәрне ача, аларны тарих өчен терелтә. Бу — әдәбият галименең фидакарьлеге һәм батырлыгы аркасында гына мөмкин булды. Гази Кашшаф тикшеренүләрендә Җәлил оештырган яшерен оешманың 12 кешедән генә тормыйча, Берлин һәм Радом төркемнәре белән генә чикләнмичә, гаять киң колач җәюе, Германиядә, Польшада, Франциядә барган Каршылык хәрәкәтенә барып тоташуы, интернациональ колач алуы ачыла. Гази Кашшаф бу очракта тарихчы буларак та зур эш башкара. Икенче бөтендөнья сугышында фашистларга каршы көрәштә татар халкының батырлык сәхифәләрен язганда Гази Кашшафның бу ачышлары тарихка кыйммәтле материал булып керәчәк.

Гази Кашшафның герой-шагыйрь һәм аның көрәштәш дуслары турындагы тикшеренүләре Җәлилгә һәм җәлилчеләргә лаеклы һәйкәл булды. Аның бу өлкәдәге хезмәтләре — Гази Кашшаф иҗатының гына түгел, ә бөтен татар әдәбият белеменең олы казанышы, якты сәхифәсе.

## Гази Кашшаф

# ЖУРНАЛИСТЛЫК КАЙДА БЕТӘ?

Күптән журналистика хакындагы уйларым белән уртаклашасым килеп йөри иде. Һәм кайдадыр читтә дә түгел, ә нәкъ менә журналистлар арасында[1]. Алдан ук бәхәскә исәп тотам. Бәхәс чыкмаса — кызыксыз булачак, шуңа күрә фикерләрегезне бер тузгытып аласы килә.

Һәр журналистның һәм язучының иҗаты үзенчә башлана. Аны каләмгә тотынырга мәҗбүр иткән сәбәпләр була. Зур һәм кечкенә сәбәпләр, шәхси һәм иҗтимагый сәбәпләр. Берәүләр, журналистиканың нәрсә, журналистның кем икәнлеген белмәгән килеш, аңарга бала чактан ук омтылалар. Журналистның фамилиясе газета битләрендә басыла, аны укыйлар, аның исемен кабатлыйлар — ул бары шуны гына белә...

Икенче журналистларны тормыш үзе чакырып китерә, өченчеләре көтмәгәндә ачылып китәләр. Бу төр журналистлар — зур идеяләр белән яну, үз халкының тормышын яхшырту, аны коллыктан һәм изелүдән коткару, үз халкын тагын да бәхетлерәк итү, берәр тармакта нәрсәгә дә булса омтылу, кешеләр арасындагы мөнәсәбәтләрне, табигать, фән, социология, сәнгать серләрен ачу уе белән янып яшәү аркасында журналист булучылар — күпчелек дип уйлыйм.

Царизм һәм капитализм белән көрәшнең кырыслыгы, кискенлеге, халыкка каршы һәр төрле партияләр белән шундый ук кискен көрәш ялкынлы кайнар сүзләр, тормыш хакыйкате булган сүзләр, тимер логика белән нык итеп һәм чын күңелдән әйтелгән булуны таләп иткән. Профессиональ революционерларның большевик журналистлар да булып китүләре очраклы хәл түгел. Бу өлкәдә дә алар үзләрен күренекле журналистлар итеп, журналистикадагы бу тармакта яңа сукмак салучылар итеп таныталар. Луначарский, Ольминский, Воровский, Карпинский, Кржижановский, Калинин, Крупская, Свердлов, Киров, Х. Ямашев, М. Вахитов, Г. Ибраһимов һәм башкаларны искә төшерик.

Журналистика — чыннан да чиксез киң өлкә. Хәзер ул тормышның, гаять күп төрле, катлаулы һәм каршылыклы тормышның, барлык якларына үтеп керә... Бөтенләй керергә ярамый торган төшләргә күз ташлый. Күз ташлау белән генә дә калмый, ныклап ябылган ишекләр артында ниләр эшләнгәнен күрә. Шулай да аның бу юнәлештәге уңышлары һич кенә дә җитәрлек түгел әле... Аның әле космоста булганы юк, ул әле фәннең барлык тармакларын да квалификацияле итеп яктырта алмый...

Барыбыз да беләбез, хәзер фән бик тиз үсә. Соңгы ун елда фәннең бөтенләй яңа тармаклары — космик биология, атом төше физикасы һ. б. барлыкка килде. Университетның физика кафедрасында эшләүче бер доцентның аларда гына дә егермегә якын махсус юнәлеш булуы, хәтта физикларга да бер-берләрен аңлавы бик кыен икәнлеге хакында сөйләгәне бар. Ә журналистика? Хәзергә әле ул фән хакында иң яхшы дигәндә информация бирергә генә мөмкин.

Бездә хәзер журналистлар вакыйга һәм күренешләргә тирән үтеп керсен өчен бөтен шартлар тудырылган... Журналистиканың теориясенә тартылу да шуннан килә.

Тарих журналистиканың социаль үзгәртеп корулар, революцион күтәрелеш чорларында үсүен күрсәтә. Нәкъ шулай ук ул халык, ил сынаулар узганда яки яңадан аякка басканда үсә һәм киңәя. 1812 елгы Ватан сугышыннан соң да, Бөек Октябрь революциясеннән соң да, Бөек Ватан сугышыннан соң да нәкъ шулай булган. Һәм

---

[1] Г. Кашшафның бу мәкаләсе рус телендә язылган булган. Оригиналы авторның шәхси архивында саклана. Матбугатта беренче тапкыр басыла. Редакция.

хәзер, без тарихи адым ясау — социалистик революцияләр гасырының икенче яртысына аяк басу алдында торганда шул ук хәл кабатлана.

Журналистика үсә һәм халык белән бергә үсә. Ә халык хәзер грамоталы гына түгел, ә бәлки белемле дә. Укучыны хәзер алдый, адаштыра алмыйсың, начар нәрсәне ул кабул итми генә. Хәзер ул журналистикага акчасы белән тавыш бирә — газета-журналларның тиражы үзгәреп тору шул хакта сөйли.

Егерменче еллар башында материалларны редакцияләү бөтенләй диярлек булмаган. Бер журналистның ничек итеп редакторны «алдавы» хакында сөйләгәне бар. Шулай бервакыт мәкалә яза бу, ә мәкаләсе артык озынга, 20—25 битләргә сузыла. Редактор кульязманы тотып карый да кире кайтара. Яртысыннан артыгын кыскартырга куша. Журналист аны берни эшләтми, бары вак хәрефләр белән тагын бер күчереп чыга, нәтиҗәдә мәкаләнең күләме 10 биткә кала. «Менә бу бара» дип, редактор аны берсүзсез алып кала...



Соңрак, редактор булып эшли башлагач, миңа 20 нче еллар мирасыннан аерым китап итеп чыгарырга тәкъдим ителгән шундый күп кенә әсәрләр белән очрашырга туры килде. Зур гына кешеләрнең әсәрләрендә матбугатта җибәрергә ярамаган хаталар очравы мине гаҗәпкә калдыра иде. Әйтик, очеркка герой Петр булып килеп керә, ә Андрей булып чыгып китә һ. б. ш. Исемле журналист ни генә язмасын, аны үзгәрешсез басарга дигән язылмаган закон була. (Андый закон хәзер дә бар, тик Шолохов, Федин кебек аерым кешеләр өчен генә.)

Мин егерменче еллар ахырында журналистикага килгәндә мондый хәл инде беткән иде. Бүлек мөдирләре, редакциянең җаваплы секретаре, редактор бар иде. Әдәби хезмәткәр буларак, мин аларның һәммәсенә буйсынырга тиеш. Һәркайсы төзәтә, кыскарта, яңа эш куша ала. Гадәттә мондыйрак эшләр кушыла иде.

— Фәлән-фәлән темага 200 юл әйбер язарга.

— Ударник турында 120 юл материал кирәк...

Мин промышленностьны, хезмәт кешеләрен ярата идем һәм промышленность бүлегендә эшләдем. Предприятиеләрнең ударниклары, партия, комсомол һәм профсоюз активы белән ныклап дуслаштым. Профсоюзлар ул чагында зур роль уйный иде...

Тиздән мин төзәтүсез типографиягә китәрлек материаллар яза башладым. Бүлек мөдире укый, җаваплы секретарь юллар санын исәпли, шуннан кульязма типографиягә китә. Минем почерк тигез, матур булганга, материалны машинкада басып торасы да булмый. Һәм шуның аркасында секретарьны да, тәнге редакторны да еш кына уңайсыз хәлләргә куя идем. Кайчан карама, минем материал 200 юл урынына 250 юл, 120 юл урынына 160 юл килеп чыга. Һәм төнге редактор, сыймаган гранкаларны кая куярга белмичә иза чигеп беткәч, мәкаләне тота да теләгән җирдән өзеп калдыра һәм иң кызык җирендә өзеп калдыра. Похтәлеккә шулай өйрәтәләр.

Шушы урында мин материалларны редакцияләү турындагы мәсьәләгә күчәр идем. Журналистика тарихына караган бер генә хезмәттә дә бу мәсьәләгә тиешле игътибар бирелми. Минем уемча, бу журналистиканың үзенә аерым бер тармагы. Әгәр журналистиканы иң элек практик журналистика һәм теоретик журналистика кебек ике кисәккә бүлеп булса, практик журналистиканы үз чиратында тагын берничә өлешкә бүлгәләргә мөмкин:

а) иҗади журналистикага — бусына газетадагы барлык жанрларга да яза ала торган журналистларны кертергә була;

б) һәм ярдәмчел журналистикага — бусына, редакциянең техник хезмәткәрләрен-

нән тыш, язганнары белән иҗади журналистларга ярдәм итүче, ә үзләре әле гомумиләштерү көченә, фантазиягә, кыю эзләнүләр югарылыгына ирешеп җитмәгән журналистлар кирә. Ышанып әйтергә була: мондый журналистлар аз түгел. Алар информацион характердагы фактлар табалар, килгән хатларны тикшерәләр, кайчак аларга теге яки бу фактны тикшерергә кушалар, алар укучы хатларына җавап язалар һ. б. Сирәк-мирәк алар хатларга күзәтү ясыйлар һәм шуннан да югарырак баскычка күтәрелмиләр. Мин редакциядә кырык ел һәм аннан да күбрәк вакыт эшләп матбугатта үз эзен калдырмаган андый журналистларны белә идем.

Ә менә редактура эше ничектер үзенә аерым тора. Ул иҗади журналистиканың, сәяси яки әдәби юнәлешенең, оештыру эшләренең эретмәсе. Редактура ул — информацион характердагы материалларны сайлап ала белү, жанрларны чиратлаштыру, иллюстрацияләрне оста урнаштыру, һәр санга авторларны сайлап ала белү дигән сүз. Редактура ул — координация үзәге, ә сүзләр яки җөмләләр төзәтү түгел (бу эш бүлектә эшләнә)...

Инде теоретик журналистикага килсәк, ул иҗади журналистикадан (теоретик журналистика шулай ук иҗади характерда була, шуңа күрә, бәлки, практик журналистикадан дип алу яхшырактыр) нык артта кала. Билгеле, кайбер эшләр бу өлкәдә дә эшләнә. Тарихчылар зур ярдәм күрсәтә. Матбугатның үсешен тарихи яктан күзәтеп бару, тематик күзәтү, журналистиканың тормыш белән бәйләнеше, партия һәм партия съездлары карарларын, хөкүмәт карарларын пропагандалауда матбугатның роле — боларның һәркайсы өйрәнелә дияргә була. Бу — шулай ук бик кирәкле һәм бик мөһим эш. Әмма журналистика өлкәсендәге тикшеренү эшләре шулар белән генә чикләнәмени?!. Юк, билгеле.

Журналистика фәне — бөтенләй яңа фән. Аның барлык төп мәсьәләләрне иңләп бетерә алганы юк әле. Хәзергә ул ничектер партия тарихы, СССР тарихы, әдәбият тарихы арасындагы чиктә тора (хәер, әдәбият галимнәре журналистиканы әле һаман яхшы әдәбият, классик әсәр үсеп китәргә мөмкин булган ярдәмчел җирлек итеп карыйлар. Җәяләр эчендә генә шул кадәресен дә әйтеп үтәргә мөмкин: рус һәм татар әдәбиятларының классикларына багышланган күп кенә монографияләрдә өйрәнелә торган язучыларның... журналистлык эшчәнлекләре читләтеп үтелә.)

Жанр мәсьәләләре, әйтик, искиткеч зур әһәмияткә ия. Яки катнаш жанрлар (дөрес, теориядә мондый термин юк) мәсьәләсен алыйк. Кайда зарисовка тәмамланып, очерк башлана? Кайда корреспонденция тәмамланып, мәкалә башлана? Нәрсә ул уңай фельетон? һәркем фельетонның шундый төре бар дипраслый бит.

Мәрхүм Иван Рябов, әгәр фельетон көлдерми икән, бу әле аның зур кимчелеге түгел, ди иде. «Уңай фельетон,— дип яза ул,— очерк кебек формада һәрчак күтәреп булмый торган мәсьәләләргә кагыла. Очерктан ул үзенең формасы, теле, интонациясе белән аерылып тора». Л. Леоновның «Дусны яклап» исемле әсәрен ул уңай фельетонның үрнәге дип саный.

Ә Семен Нариньяни менә беркем дә, берни дә тәнкыйть ителмәгән фельетонны уңай фельетон, үткен тәнкыйть булганын кире фельетон дип саный. Бу дөрес түгел. Оста язылган һәм социалистик төзелешкә файда китерә торган фельетонны мин уңай фельетон дип, ә бер генә кимчелек, бер генә начар кеше дә фаш ителмәгәнен кире фельетон дип исәплим...

Рябов һәм Нариньяни бу өлкәдәге кытлыкны бетерделәр дип буламы? Юк, билгеле. Бу әле теория түгел, ә бәлки әлеге фельетонистларның үз фикерләре генә. Монда яшь галимнәр өчен эш бик күп. Теоретик гомумиләштерүләр ясар өчен монографияләр кирәк. Практик журналистиканы, аерым журналистлар иҗатын өйрәнәсе дә, өйрәнәсе әле...

Тагын бер мәсьәлә. Миңа калса, СССР кебек күп милләтле ил өчен ифрат мөһим мәсьәлә. Алай гына да түгел, мин аны хәтта халыкара мәсьәлә дияр идем. Саф милли журналистика бармы? Милли республикаларда журналистика ничек үсә? Бу рус журналистикасына да кагыла торган мәсьәлә. Мин безнең шартларда аерым рус журналистикасы шулай ук юк, ә бер-берсен баета, бер-берсенә йогынты ясый торган совет журналистикасы гына бар дип саныйм. Моның белән мин һич тә рус журналистикасының җитәкчелек ролен, аның бай тәҗрибәсен, традицияләрен һәм

квалификациясен инкарь итәргә җыенмыйм, болар һәммәсе милли республикалардагы журналистика өчен һәр вакыт бер мәктәп, өлге булып торды һәм торачак.

Революциягә кадәр, азчылык милләтләрне царизм изеп яшәгәндә, милли журналистиканың аерымлыгы була, әлбәттә. Азатлык хәрәкәте, халыкның узаңы, милли горурлыгы белән бәйле бик күп мәсьәләләр публицистиканың тематикасын да, проблематикасын да, пафосын да үзенчәлекле итеп билгели. Октябрь революциясеннән соң да андый мәсьәләләр яши әле. Төрки хатын-кызларны азат итү, ислам диненең гадәт-йолаларыннан котылу өчен озак һәм кискен көрәш бара. Элекке арттa калган халыкка интеллектуаль тәрбия бирү кебек специфик бурычлар да кала. Социализм төзелешенең уңышлары аларны акрынлап көн тәртибеннән ала. Без хәзер гасырның икенче яртысына аяк басу алдында торабыз. Хезмәттә булсын, дошманнарга каршы көрәштә булсын һәм көндәлек тормышта булсын, Советлар Союзы халыклары шул хәтле якынайдылар, хәзер инде милли журналистикага гына хас специфик мәсьәләләр булмаска да тиеш кебек. Шулай да барлык чикләр җуелып беткәнме әле? Бу гади мәсьәлә түгел...

Халыклар аерымлашуга таба түгел, ә кушылуга таба баралар. Ләкин шул хәтле озак һәм катлаулы процесс, әлбәттә, декретлар белән җайга салынмас. Бездә хәзер катнаш семьялар күп. Рус татарга өйләнә яки, киресенчә, әтисе — яһүд, әнисе — татар, кызлары үзен рус дип йөри. Әтисе — хохол, әнисе — башкорт, уллары үзен татар дип йөри... Андыйлар күп... Гаилә кору һәм өйләнешү кебек нәрсәләр әле бик озакка хәтле журналистикада проблема булып калачак — бу социологик эзләнүләр алып баруны таләп итүче бик кызыклы мәсьәлә.

Шулай да, миңа калса, милли журналистика тел (материалны теге яки бу милли телдә бәян итү) ягыннан гына аерылмый, жанрлар мәсьәләсендә булсын, көндәлек специфик мәсьәләләрдә булсын, беренче карашка күзгә ташланмый торган төсмерләр бар, миллилек мәсьәләсе шулай ук журналистларның турыдан-туры яки читләтеп кенә теге яки бу халыкның милли горурлыгын кузгаткан публицистик чыгышларында да сизелеп кала. Һәрхәлдә, бер нәрсә ачык, милли журналистиканы үстерергә һәм өйрәнергә кирәк.

Ләкин бөтен совет журналистикасының уртак үсеш юлына караган икенче мәсьәлә дә бик мөһим. Шул уңайдан тагын бер мәсьәләгә кагылып үтәсем килә. Журналистика проблемалары журналистларның үзләре тарафыннан теоретик яктан үзләштерелми торып, практик-иҗади журналистика үсә аламы? Бу сорауга кыска гына итеп: «юк» дип җавап бирергә мөмкин. Журналист бары мәкаләләр, репортажлар гына язып, ә кемдер коры теория белән генә шөгыльләнеп утыра алмый. Чыннан да, кем (һич югы, үзе өчен) жанр мәсьәләләрен һәм үзенә якын журналистның иҗат тәҗрибәсен өйрәнә, кем каләмдәш дуслары туплаган тәҗрибәне үзләштерә, шул кеше генә осталык үрләренә күтәрелә ала...

Көндәлек матбугатта инде көн тәртибенә куелган тагын бер кызыклы мәсьәлә: язучы белән журналист арасында нинди аерма? Алар арасында берәр төрле дистанция бармы? Бу сорауларга төрлечә җавап бирергә мөмкин. Аңа, шаяртып, болай җавап бирүчеләр дә булды: үз китабын чыгара алган журналист бәхетле кеше һәм ул язучы дип йөртелә, ә инде китап чыгара алмаганы бары тик журналист кына булып кала. Бу, чыннан да, шаяру. Билгеле, алар арасында аерма бар һәм аз түгел.

Беренчедән, язучы үзен бары бер генә мәсьәләгә багышлау кебек юмартлыкка юл куя ала: мәсәлән, 1905 елны, коллективлашу чорын яки Бөек Ватан сугышы елларын өйрәнү һәм яктырту. М. Шолохов, Мих. Соколов («Искры»), Вяч. Шишковлар («Пугачев») кебек. Кайчак бер тема, бер проблема язучының тормыш максатына әйләнә.

Журналист шулай эшли аламы? Юк. Ул заман белән бергә атлый, талантлы икән — заманнан да алдарак атлый. Аның детальләр өстендә утырырга вакыты юк. Аңа күренешнең иң мөһим сыйфатларын, асылын ачу, аны башкалар күрмәгән ягыннан күрсәтү мөһим...

Икенчедән, язучы хезмәтендә иң мөһиме фантазия, хыял. Журналист эшендә болар иң мөһиме түгел. Фантазия һәм хыял аңа ярдәмче алым буларак кына хезмәт итәләр. Факт һәм күренешләрне, тарихи материалны өйрәнеп, язучы тормышта

булуы мөмкин хәлләрнең җанлы рәсемен сурәтли. Журналист нигездә фактларга таяна. Алар хезмәте арасында башка аерымлыклар да күзгә ташлана — темага, проблемага якын килүдә, фикерләү алымнарында (масштаблылык һ. б.) алар арасында нечкә нюанслар бар.

Ләкин журналист белән язучы арасындагы аерманы башлап кузгаткан кеше боларны гына күздә тотмаган, билгеле. Ул кем биегрәк дигән нәрсәне дә күзаллаган. Бу сорауга җавап бирү кыен. Монда талант дип йөртелгән икенче бер атрибут килеп катнаша! Талантлы язучылар, шулай ук талантлы журналистлар да бар.

Ләкин бурыч шунда, әгәр язучы белән журналист арасында ниндидер дистанция бар икән, аны соңгы чиккә хәтле кыскартырга кирәк. Бүгенге журналистлар бу юнәлештә файдалы һәм кызыклы бик күп эш башкаралар. Аграновский, Татьяна Тэсс, Валентин Зорин, Виктор Маевский, Крутинскийларның эш тәҗрибәсен алыгыз...

Әлеге журналистлар мисалында мин кайда журналист бетеп, кайда язучы башланганын әйтергә кыенсыныр идем. Пушкиннан алып Паушкинга кадәр барлык күренекле язучыларның иҗат эшчәнлеге һәрчак журналистлык практикасы белән бәйләнгән булган. Ихтимал, киләчәктә дә шулай булыр (дөрес, сугыштан соңгы чорда яшь шагыйрь һәм язучыларның бөтен бер төркеме әдәбиятка башка юл белән, газета практикасын читләтеп килделәр... Аларның язмышы ничек? Күбесе соңыннан газетага әйләнеп кайтты. Бездә Роберт Әхмәтҗанов...).

Язучы журналистлык мәктәбе аша узарга, газетада эшләргә тиеш, чөнки бу дисциплинага өйрәтә, күнекмәләр бирә, тормыш темпына иярергә, ничектер, җыйнак булырга өйрәтә.

А. М. Горький гомере буе газета-журналлар белән элемтәдә була. Һәм үзе үк К. Федиңга газета эшен ташларга куша. «Сезнең өчен газета — агу,— ди ул. — Мин үзем газетада эшләдем. Сезгә үз өстегездә әдәбиятчы буларак эшләргә, әдәбиятка керергә, әдәбиятта эшләргә кирәк... Газетада үз-үзеңне саклап буламыни?» Әйе, яшь чакта газетада эшләргә кирәк. Соңыннан, журналистлык эшендә тәҗрибә, кешеләр белән эшләү тәҗрибәсе туплагач, чемоданнар көндәлек дәфтәрләре белән тулгач, гомумиләштерү көченә ия булгач эшкә утырырга мөмкин. Ләкин яхшы журналист беркайчан да журналны, газетаны ташлап бетерми... Сүз җаеннан көндәлек дәфтәрләре турында берничә сүз. Вакытында журналист бөтен язганын бастырып бармый, янга калдыра... Үзем берничә очракны хәтерлим, файдаланмаган материалларны каләмдәш иптәшләремә биргәнем бар (С. Хәкимгә, Г. Минскийга, Ә. Еникигә...).

Тиз арада журналистларның осталыгы шундый югарылыкка күтәрелер, язучы белән журналист арасында барган яшерен конкуренция ике як өчен дә файда гына китерер, дип уйлыйм. Кем шул ярышка кушыла алмый, ул (журналист булса да, язучы булса да) читкә алып ташланачак һәм управдом булып эшләргә китәчәк!

Шулай итеп, журналистлык кайда бетә? Һәркем үзенчә журналист була. Бәләкәйдән, кечкенәдән башлыйлар, шул гөрләвек зур тормышка килеп кушыла, масштаб белән фикер йөртүче кешеләргә, халык тормышында үзенчәлекле компаска әйләнәләр, һәм алар үлем белән генә бетми, юк... Әгәр теориядән аерылса, тормыштан аерылса, үз сүзен — яңа сүз әйтергә, шулай ук үз китабын чыгарырга омтылмаса, ул журналист журналист булудан туктый. Күп тәҗрибә туплаган, күп нәрсә күргән журналист язган китаптан да кызыклырак берни дә юк.

**27 октябрь, 1967 ел.**
**Казан.**

## Галия Кайбицкая

# ДУСТЫМ САРА ТУРЫНДА

Талантлы артистка һәм композитор Сара Садыйкованың музыкасын ишеттем исә, аның туганы-апасы күз алдыма килеп баса. (Туганы-апасы — Сараның анасы белән бертуган. Аның күзләре тумыштан сукыр булып, картайганчы Саралар гаиләсендә яши.) Бишектәге Сараны ул җырлап тирбәтә, кулына алып сөя, тәпи йөри башлагач күкрәгенә кысып, йомшак сүзләр әйтә, киңәшләр биреп юата, җаны-тәне белән үз баласы кебек тәрбия кылып үстерә.

Тумыштан сукыр булып, бала чагыннан дөнья мәшәкатендә чыныгып үскән бу апаның кулы һәрбер эшкә ябыша торган була. Ул апасының башка балаларын да карап үстерә. Аларны үзе ашатаэчертә, аш-суларны да оста пешереп, йорт эшләрен дә үзе башкара, пөхтә аналар күк балаларга күз-колак була.

Шушы апаның миңа сөйләгән сүзләре әле дә исемдә: «Безнең Сара бәхет күлмәгенә уралып туган ул. Нәни чагыннан ук җырга-биюгә бик тә оста булды. Зур үсә барган саен кулына анасының гармунын алып, шунда үзе төрле көйләр уйнап җырлап китә иде. Мин хәйран булып тыңлый идем дә: «Җырла, балам, җырла, бу һөнәреңнән өзелмә, уйна. Гармун белән уйнап җырлавыңны мин бик тә яратам», дип әйтсәм, ул янә минем яныма килеп утыра да дәртләнеп уйнап җырлаудан туймас була иде. Шул чакларда баланы кочарга дип кулымны сузсам, ул балалык шаянлыгы белән, янымнан йөгереп китә иде дә, үзе берәр җиргә качып, «мине эзләп тап» дип, миннән үзен эзләтә иде.

Сара бер көн шулай зур бүлмәнең өстәле астына кереп утырган да бик матур итеп гармун уйный. Мин бераз сокланып тордым да, көндәлек гадәтем буенча, гармун тавышына карап аны эзләргә керештем. Эзли торгач, моң тавышына тукталып, үзем дә шул өстәл кырыена килеп утырдым. Сара баламның көе күңелне тибрәтә, озак тыңлап утырганнан йөрәкләрем өзгәләнеп, чайкалып киттем. Сараның йөзен күргәндәй булдым. «Сара, мин сине күрәм! Ямьле йөзле балабыз кебек күренәсең миңа» дидем, артык хисләнүдән шул вакыт үзем аңымны югалтканмын. Сара кулымнан җитәкләп бүлмәгә кертеп салган».

Шундый моңлы, музыкаль сәләтле булган Сара дустым белән беренче очрашу көннәрем хәтердә.

1926 ел. Без — Казан драма театры артистлары — Мәскәү, Оренбург, Әстерхан шәһәрләренә гастрольгә чыгып киттек. Репертуарыбызда Кәрим Тинчуринның «Сүнгән йолдызлар» һәм «Казан сөлгесе» дигән пьесалары.

Сәяхәтебез Мәскәүдән башланды. Башкаладагы спектакльләребез зур уңыш белән барды, театр халык белән шыгрым тулы булды. Мәскәү тамашачылары белән саубуллашу кичәбездә «Сүнгән йол-

дызлар» спектакле куелган иде. Соңыннан безне «Шереметьев» дачасына, сәнгать сөюче Мәскәү тамашачылары тарафыннан оештырылган зур банкетка кунак итеп чакырдылар. Килгән кунаклар арасында Мәскәүдә эшләүче татар артистлары да бар иде. Алар безне спектакль уңышлары белән котлап сөйләделәр. Сөйләүчеләр арасында кара кашлы, сөрмә күзле, зифа буйлы, яшь кенә булса да үзенең матур тембрлы тавышы белән Мәскәү халкы каршында зур шөһрәт казанып өлгергән, шат күңелле җырчы Сара Садыйкова үз чыгышында болай диде: «Шашкан кызны уйнаган яшь артистканың уены миңа бүген бик тә ошады. Нәкъ үзен китерде. Чын шашкан кыз булып, образны оста күрсәтә белде». Театр сәнгатен якыннан белгән, бигрәк тә үзе җырчы булган кешенең, бу спектакльдәге уеныма шулай уңай бәя бирүе мине канатландырып җибәрде. Бу җырчы белән якыннанрак танышасым, иҗат серләрем белән уртаклашасым килде. Шул кичне мин аның белән якыннанрак танышу бәхетенә ирештем. Тора-бара без аның белән аерылмас дуслар булып киттек.

1927 елда Сара Садыйкова Казанга килде. Шушы елны композитор Василий Виноградов, Солтан Габәши һәм җырчы Газиз Әлмөхәммәтов тарафыннан бергәләшеп эшләнгән «Сания» операсы сәхнәгә куелды. Сания партиясен колоратура тавышлы Сара искиткеч нәфис башкарып, матур образ тудырды. Сараның музыкага сәләте табигый талант кына түгел, музыкаль җанлы әти-әнисе һәм туганнарының тәрбиясеннән дә килгәндер. Сараның сеңлесе Разия да шул ук операда беренчеләрдән булып Сания образын башкарган кеше иде.

1930 елда Сара Казан театрына бөтенләйгә кайтты. Өч-дүрт ел элек башланган дуслыгыбыз ул кайтуга тагын да якынаеп китте. Моңа безнең яшьтәш булуыбыз, бер үк хезмәт белән янып яшәвебез, бер-беребезне эчкерсез яратуыбыз да сәбәп булгандыр, күрәсең.

1928—29 нчы еллардан башлап драма театры репертуарында музыкаль әсәрләр куелуы елдан-ел арта барды. Җырчы артистларга драма спектакльләреннән бигрәк музыкаль әсәрләрдә генә уйнарга да туры килә иде. Баштарак без бер үк рольне Сара белән чиратлашып уйнасак, тора-бара һәркайсыбызга аерым рольләр дә бирә башладылар. Бу безгә иҗади үсеш өчен зур мәйдан иде һәм без — ике дус — киңәшә-киңәшә яңа образлар тудыру өстендә дәртләнеп эшли идек. Мәсәлән, Таҗи Гыйззәтнең «Наемщик» әсәрендә мин Гөлйөзем булсам, Сара — Зөбәрҗәт, К. Тинчуринның «Кандыр буе» әсәрендә Сара Фәридә ролен, мин Гөләндәмне шулай бергәләп иҗат иттек.

Иртә сәгатьтән репетицияләрдә күрешеп, кичләрен спектакльләр уйнап, без аның белән көннәр буе бергә булдык. Грим сала торган өстәлләребез дә, кием-салымыбыз да — барысы да бер бүлмәдә иде. Мәскәүгә консерватория каршында оештырылган опера студиясенә дә без бергә киттек. Казанда опера театры ачылу, опера җырчылары буларак, шул театрда эшләр көннәребез турында хыялланып яшәдек. Уку җиңел булмады. Драма артистлары булып формалашкан кешеләр өчен сәнгатьнең бөтенләй башка төренә күчү иде бу. Уен алымнары да, тавышның куелуы да, барысы да башкача. Шулай да без студияне уңышлы тәмамладык һәм 1939 елның гыйнварында Казан опера театрының беренче пәрдәсен ачу бәхетенә ирештек. Студиядә укыганда композитор Нәҗип Җиһановның «Качкын» операсында Рәйхана партиясен әзерләгән идек. Казанга кайткач та бу партияне, алмашлап, икәү җырладык.

Мин, сәхнә кешесе буларак та, күп еллар буе Сараның иҗади дусты буларак та, аның үз хезмәтенә никадәр зур җаваплылык белән каравын әйтә алам. Бу җаваплылык хисе аңа артистка буларак та, концерт эшчәнлегендә дә һәм, ниһаять, композитор буларак та зур уңышка ирешеп, халкыбызның мәхәббәтен яуларга мөмкинлек бирде.

Флүн Мусин

# БЕРДӘМЛЕК ҺӘМ КҮПТӨРЛЕЛЕК

Әдәби стиль мәсьәләләре тирәсендә илленче елларда башланган сөйләшүләр алтмышынчы елларга таба тагын да җанлана төшә[1]. Әдәбият галимнәре төп игътибарларын социалистик реализм методының төрле стильдәге язучыларның иҗат эшчәнлеге өчен чикләнмәгән мөмкинлекләр бирүен өйрәнүгә юнәлтәләр. Берәүләр бу төрлелекне татар прозасының яңа әсәрләре мисалында дәлиллиләр. Икенче бер тәнкыйтьчеләр прозадагы стиль агымнарын ачыклауга игътибар юнәлтәләр. Р. Мостафин, мәсәлән, «Тормыш дөреслеге һәм сәнгать дөреслеге» исемле мәкаләсендә (1961) безнең прозада ике стиль агымы яшәп килүен күрсәтә. Аларның беренчесенә тәнкыйтьче М. Әмир белән Г. Әпсәләмовны кертә һәм аларга «вакыйгаларны, ничектер, читтән торып, үзләре катнашмыйча гына сурәтләү» хас булуын әйтә. Ә икенче агымның характерлы вәкиле итеп ул Ф. Хөснине саный, автор «хикәяләүгә әледән-әле үзе катнашып китә, лирик чигенүләр ясый, геройларга, аларның эш-хәрәкәтләренә аңлатмалар бирә, үзенең фикерләрен белдерә бара», ди[2]. Бераздан прозадагы стиль агымнары мәсьәләсен өйрәнүгә Н. Юзиев килеп кушыла. Ул да ике стиль агымы турында сүз алып бара һәм аларны бәяләүдә Р. Мостафинга шактый якын тора. Шул ук вакытта галим һәр ике агымны яңа әдипләр исәбенә беркадәр киңәйтә һәм тулыландыра төшә. Аларның беренчесенә, Н. Юзиев фикеренчә, «вакыйга һәм геройларны объектив агышында, авторның турыдан-туры катнашыннан тыш тасвирларга омтылу хас». Бу агымга тәнкыйтьче М. Әмир, И. Гази һәм Г. Әпсәләмов кебек әдипләрне кертә. Икенче агым вәкилләреннән Г. Бәширов, Ф. Хөсни, Р. Төхфәтуллин әсәрләрендә исә «лирик башлангыч, романтик рух көчле, вакыйгаларны һәм геройларны тасвирлаганда авторның «мин»е нык сизелә»[3] дип яза.

Алтмышынчы еллар башында әдәбиятта заманга хас стиль хакында бәхәсләр әүручә көчәеп китә. М. Әмирнең 1962 елда «Социалистик Татарстан» битләрендә проза турында барган сөйләшүгә катнашып язган мәкаләсенең исеме үк «Заманга хас стиль» дип атала. Анда әдип заман рухына лаеклы яңа стиль табу турында сүз алып бара һәм болай дип яза: «Әдәби стиль — ул теге яки бу язучының шәхси үзенчәлеге мәсьәләсе генә түгел. Ул билгеле дәрәҗәдә тарихи шартларга бәйләнгән[4]». Күренә ки, М. Әмир биредә теге яки бу чорның тарихи шартлары белән бәйләнгән гомум стильне күздә тота.

---

[1] Авторның татар тәнкыйтендә стиль мәсьәләләренә багышланган беренче мәкаләсе журналыбызның 1975 елгы 12 нче санында басылган иде. Анда сүз бу мәсьәләләрнең 20—50 нче еллар тәнкыйтендә ничек яктыртылуы турында бара.

[2] «Совет әдәбияты» журналы, 1961 ел, 6 сан, 119 бит.

[3] Шунда ук, 1962 ел, 11 сан, 122 бит.

[4] «Социалистик Татарстан» газетасы, 1962 ел, 16 июнь.

Татарстан язучыларының бишенче съездында тәнкыйть буенча ясаган докладында Г. Халит та заманга хас яңа стиль булдыру мәсьәләсенә туктала. «Заман герое һәм шул геройны гәүдәләндерүгә тиң стильне табу ихтыяҗының көннән-көн үткенрәк тәс алуы, — ди ул, — әдәбиятыбызга тормыш таләпләренең басымы тагын да көчәя баруы хакында сөйли» [1].

Заманча стиль нинди булырга тиеш соң? Бу хакта сүз алып барганда, барыннан да элек, яңа стильнең үткәндәге әдәбияттан күчеп килгән кайбер искергән сыйфатлардан азат булырга тиешлегенә басым ясала. Шундый иске сыйфатлардан киңрәк таралганын Р. Мостафин «аңлатмалылык стихиясе» дип, ә М. Әмир «мәгърифәтчелек күренешләре» дип атый. Мондый күренешләрнең үткәндәге әдәбиятта киң таралу сәбәпләрен М. Әмир шул дәвердәге укучылар массасының аң-белем дәрәҗәсе түбән булу белән бәйләп аңлата. Әдәби әсәр укучыларга аңлашылсын өчен, дип дәвам итә сүзен М. Әмир, язучы ул заманда «һәр кечкенә эпизодны да мотивлаштырырга, аның тарихи һәм социаль сәбәпләрен ачыклап, аңлатып бирергә» тырышкан [2]. Әдипнең бу сүзләрендә күпмедер дәрәҗәдә дөреслек бар, әлбәттә. Әмма аңлатмалылык стихиясен яки мәгърифәтчелек белән мавыгуны үткәндәге бөтен әдәбиятка хас сыйфат итеп күрсәтү һич тә чынлыкка туры килми. Биредә аерым фактлар нигезендә артык киң нәтиҗә чыгару күренеп тора. Р. Мостафин, мәсәлән, болай ди: «Кагыйдә буларак, моңа кадәр алар (татар романистлары — Ф. М.) күбесенчә кешенең хәлен һәм аның хәрәкәтсез тойгыларын сурәтләү, аларны аерым кисәкләргә аеру, психик процессның үзен онытып, аның бары тик нәтиҗәләрен генә тасвирлау белән чикләнделәр» [3]. Бу фикер белән дә килешеп бетүе кыен. Р. Мостафин белән бәхәскә кереп, Н. Юзиев ул санаган сыйфатларның татар прозасы өчен һич тә кагыйдә булмавын, киресенчә, үткәндәге иң яхшы роман-повестьларыбызның «кешенең хәрәкәттәге тойгыларын, шәхеснең «рухи диалектикасын» чагылдырулары белән көчле» [4] икәнен әйтеп чыкты.

Шул еллар татар прозасына хас аңлатмалылык һәм мәгърифәтчелек күренешләренә, күп сүзлелеккә яңа стиль нәрсә белән җавап бирергә тиеш иде соң? Стиль мәсьәләсенә кагылган күпчелек чыгышларда бу сорауга: «Кыскалык белән»,— дип җавап бирелде. Кыскалык заман стиленең хәлиткеч сыйфаты итеп карала башлады. «Мәхәббәт сагышы» исемле повестенда Ш. Хөсәенов кыскалыкка табынуны заманча стильнең иң төп сыйфаты дип белдерде. «Секундларның йөзенче һәм меңенче өлешләре белән хисаплашучы» атом гасырында, «вакыйгаларның калейдоскопик тизлек белән алышынып тору» заманында, диде ул, укучының «Киек каз юлы шикелле озын һәм чуар романнар суында эрегән гомеопатик дозадагы файдалы фикерне эзләп вакыт үткәрәсе килми». Һәм Ш. Хөсәенов: «Әдәбият шаһы — кирпеч калынлыгы роман картаеп бара»,— дигән нәтиҗә ясый.

Безнең тәнкыйтьтә әлеге мәсьәләгә иң аек килүчеләрнең берсе И. Нуруллин булды. «Кыскалык турында» исемле мәкаләсендә ул иң элек бу сыйфатка омтылуны үзмаксатка әйләндерүгә, аны «заман стиленең бердәнбер күрсәткече итеп» карауга каршы чыкты. Аныңча, әсәрнең «озынлыгын яки кыскалыгын аның «файдалы эш коэффициенты», характерларның өлгереп, «пешеп» җитү дәрәҗәсе, әйтергә теләгән фикернең, куелган проблеманың зурлыгы билгели» [5].

Җыеп әйткәндә, шул нәрсә ачыклана: гәрчә 60 нчы еллар башындагы татар тәнкыйтендә заман стиле турында әледән-әле бәхәсләр кузгатылса да, бу мәсьәлә бездә үзәк матбугаттагы кебек популярлык казана алмаган. Нининдидер яңа стиль булдыру турында кайгыртудан бигрәк, безнең тәнкыйтьчеләр татар әдәбиятының конкрет ихтыяҗлары, аның идея-эстетик сыйфатын күтәрү хакында уйланганнар. Кыскалык турында сөйләшү дә, телеграф стилен тудырырга чакырудан бигрәк, сыйфат өчен көрәшнең бер чагылышы булган.

Алтмышынчы еллар башында барган сөйләшүләрдән соң стиль мәсьәләсе татар тәнкыйтенең гомум игътибарыннан төшебрәк тора. Һәм менә соңгы вакытларда гына аның белән кызыксыну тагын көчәя башлады.

---

[1] «Совет әдәбияты». 1963 ел, 4 сан, 144 бит.
[2] «Социалистик Татарстан», 1962 ел, 16 июнь.
[3] «Совет әдәбияты». 1960 ел, 7 сан, 133 бит.
[4] Шунда ук, 1962 ел, 11 сан, 127 бит.
[5] Шунда ук, 1963 ел, 4 сан, 147 бит.

Хәзерге әдәбиятыбызның стиль табигате бөтенләй диярлек өйрәнелмәгән. Шуңа күрә хәзергә аерым күзәтүләр һәм уйланулар белән генә чикләнергә туры килә. Әдәби практика стильнең катып калган бер нәрсә булмавын күрсәтә. Кайчак ул байтак еллардан соң һәм язучы зур иҗат тәҗрибәсе туплагач кына ачыклана. Мәсәлән, А. Расих әдәбият дөньясына 30 нчы еллар уртасында ук аяк баса. Әмма аның стиле 60 нчы еллар уртасында, «Язгы авазлар» һәм «Ике буйдак» романнарында гына ныклап ачыкланып җитә. Биредә әдипнең гыйльми эшчәнлеге дә зур роль уйнаган, күрәсең. Чөнки аның хәзерге әсәрләрендә гыйльми эшчәнлекнең һәм фикерләүнең йогынтысы шактый нык сизелә. Бер яктан, А. Расих заман проблемаларын һәм конфликтларын еш кына фән дөньясыннан эзли. Икенче яктан, аның хикәяләвендә гыйльми фикерләүдән килә торган рациональлек һәм төгәллек шактый ачык сизелә. Әсәрнең идеясен һәм геройның характерын ачуда ул конфликттан аеруча актив файдалана һәм аны эзлекле рәвештә үстерүгә зур игътибар бирә. Аның романнары динамик конфликтка корылган булулары белән аерылып торалар.

Кайчак язучының стиле күп кыяфәтле була һәм төрле вакытта төрле тестә гәүдәләнә. Мисалга М. Әмир иҗатын алырга мөмкин. Аның 30 нчы еллар иҗаты өчен аеруча характерлы әсәре — «Агыйдел» повесте. Бу әсәрдә язучы башлыча романтик һәм лирик рухлы әдип булып алга баса. Заман чынбарлыгы һәм геройлар күбрәк шушы планда сурәтләнә. 40 нчы елларда М. Әмир «Миңлекамал» пьесасын яза. Сугыш чоры авылын бөтен тулылыгы белән гәүдәләндергән бу әсәрдә инде кырыс буяулар һәм драматизм өстенлек итә. 50 һәм 60 нчы елларда ул «Саф күңел» романын яза. Бу роман иң элек төсләргә бай булуы белән дикъкатьне җәлеп итә. Анда романтика, лиризм һәм драматизм үзара үрелеп бара. Ә иң мөһиме шунда, бу әсәрдә М. Әмир стиле эпик төс ала. Ә менә 70 нче еллар башында язган «Балыкчы ялганнары» повестенда әдипнең стиле бөтенләй башка яктан ачылып китә. Дөрес, юмор аның иҗаты өчен ер-яңа нәрсә түгел. Мәгълүм ки, ул — күп кенә юмористик хикәяләр һәм комедияләр авторы. «Балыкчы ялганнары»ның стиль яңалыгы шунда, язучының нигездә җылы юморга корылган хикәяләве лирик геройның заман турында уйланулары, хәзерге тормыштагы кайбер күңелсез күренешләр өчен борчылулары белән чиратлашып бара. Бу хәл повестька күпмедер дәрәҗәдә фәлсәфи яңгыраш бирә. Шул ук вакытта М. Әмир стиленең үзгәрүчән һәм яңаручан категория булуын күрсәтә.

Билгеле булганча, 60 нчы елларда әдипләребезнең сәнгатьчә эзләнүләре тагын да активлаша төшә һәм шул нигездә аларның стильләрендә дә кызыклы үзгәрешләр барлыкка килә. Әйтик, Г. Бәширов, И. Гази, К. Нәҗми, М. Әмир, Г. Әпсәләмов кебек әдипләрнең 40 — 50 нче еллар иҗатын бер уртак сыйфат үзара якынайта иде. Аны югары пафослы хикәяләү алымы дип атарга була. Дөрес, бу төр хикәяләүнең һәр әдип иҗатында үз төсмерләре, үз нюанслары була. К. Нәҗми әсәрләрендә публицистика шактый көчле булса, Г. Әпсәләмовта исә романтиканың роле аеруча зур була. Әмма бу алар стилендәге уртак моментларны һич тә кире какмый. Уртаклык әдипләрнең тормыштагы яңалыкны киң план белән һәм калку итеп гәүдәләндерергә алынуларында һәм шуны актив һәм ихтыярлы геройларның искелек калдыкларына каршы көрәшен якты буяулар һәм рухи күтәренкелек белән сурәтләү аша чагылдыруларында күренә.

Ә менә 60 нчы елларга килеп кергәч, әлеге әдипләр стиль ягыннан бер-берсеннән «ераклаша» төшәләр. Әгәр Г. Әпсәләмов 50 нче еллардагы стиленә шактый дәрәҗәдә турылыклы булып калса, И. Гази, М. Әмир иҗатлары яңа идея-эстетик сыйфатларга баый. Г. Бәшировка килсәк, бу чорда әдипнең иҗатына, сәнгатьчә фикерләвенә аның табигать, халыкның рухи мирасы һәм традицияләре турында тирәнтен уйланулары җитди эз сала. Әлеге уйлануларның нигезендә халык рухын һәм характерын тарихи яссылыкта карарга, аларның чыганакларын, чишмә башын ачыкларга теләү ята иде. Моны хәзерге әдәбиятта көчәйгән тарихилык рухының үзенчәлекле бер чагылышы итеп карарга мөмкин.

Патша заманында тарихның иң авыр сынауларын намус белән үткән, яшәү өчен көрәштә үзенең мөстәкыйльлеген саклап кала алган һәм заманның олы юлыннан барган татар халкының рухи көчен Г. Бәширов аның күңел байлыгыннан һәм характерыннан эзли. Ә инде милли характерны һәм рухны ачу өчен, әдип халыкның гореф-гадәтләренә һәм традицияләренә мөрәҗәгать итә. Бу яктан «Туган ягым—яшел бишек» рус

язучысы В. Смирновның «Дөньяны ачу», литвалы Ю. Балтушисның «Сатылган еллар», үзбәк язучысы Н. Сәфәровның «Каргышлы һәм өметле көн» романнарына шактый якын тора. Г. Бәширов повесте белән Н. Сәфәров романнары арасында якынлык аеруча көчле. Үз халыкларының күркәм гореф-гадәтләрен һәм традицияләрен сурәтләү аша әдипләр татар һәм үзбәк халыкларының гүзәл әхлакый сыйфатларын, шигъриятле күңелен һәм рухи оптимизмын ачалар. Һәм шундый сыйфатларга ия булган хезмәт иясе массаларының, тарих сынауларын уңышлы үтеп, пролетариатның революцион көрәшенә килеп кушылуын күрсәтәләр. Кыскасы, милли характерны һәм рухны ачу өчен гореф-гадәтләргә һәм традицияләргә мөрәҗәгать итү, халыкның рухи хәзинәсен яхшы белү Г. Бәшировның бу повестьтагы сәнгатьчә фикерләвенә мәгълүм эз салган, аның стиленең характерлы бер сыйфатын тудырган. Аны халык тормышы турында халыкча фикерләү дип атап булыр иде. Хикәяләүнең нәкъ менә революциягә кадәрге татар авылына хас рухта алып барылуында һәм бик табигый чыгуында сүзнең 6 — 7 яшьлек авыл малае Гомәр исеменнән алып барылуы мөһим роль уйный.

Хикәяләүнең халыкчанлыгы ягыннан Г. Бәшировны Ф. Хөсни белән чагыштырып карау кызыклы. Алар икесе дә авыл турында язалар һәм чын мәгънәсендә «авылча» итеп язалар. Әмма шул ук вакытта алар бер-берсеннән шактый аерылалар. Сүз монда, әлбәттә, әдипләрнең теле турында гына бармый — монысы аның иң өстә ята һәм гади күзгә дә күренеп тора. Сүз биредә әсәрнең эчендәрәк, тирәндәрәк ята торган сыйфат — әдипнең сәнгатьчә фикерләү үзенчәлекләре турында бара. Г. Бәширов стиленә үзенә бер тыйнаклык, әдәплелек һәм нәзакәтлек хас. Аннан соң биредә халыкның фәлсәфи фикерләү үзенчәлеге дә сизелә. Ф. Хөснигә килсәк, аның әсәрләрендә инде халыкның икенчерәк сыйфатлары — сүзгә җорлыгы, шаянлыгы ныграк чагыла. Гомумән алганда, Г. Бәширов стилендә халык иҗатының, ә Ф. Хөснинекендә халыкның җанлы сөйләменең йогынтысы ачыграк күзаллана. Ә менә Ә. Еникине алсак, аның стиле үткәндәге язма әдәбиятка барып тоташа. Бу яктан аңарда бигрәк тә Ф. Әмирханга якынлык сизелә. Билгеле булганча, Ф. Әмирхан үткәндәге татар әдәбиятының сәнгатьчә фикерләү тәҗрибәсен, язу культурасын тирән үзләштергән һәм үз иҗатында аеруча көчле чагылдырган зыялы әдип була. Ә. Еники әсәрләрендә дә шул ук нәрсә көчле. Моны язучы геройларының характерында һәм рухында да, хикәяләү пафосында да сиземләргә мөмкин. Әдип үзенең уңай геройларын гадәттә әхлакый тәрбияле һәм әдәпле кешеләр итеп күрсәтә. Бу яктан, мәсәлән, Ф. Әмирханның «Хәят» романындагы Хәят һәм Максим образлары белән Ә. Еникинең «Гөләндәм туташ хатирәсе»ндәге Гөләндәм һәм Сәйдәшев образларын гәүдәләндерүдә билгеле бер аваздашлык булуын сиземләве кыен түгел. Ф. Әмирхан кебек үк, Ә. Еники үз геройларын гаять саф күңелле, әхлакый гүзәл затлар итеп күрсәтә, аларның үзара мөнәсәбәтләрен бөтен нечкәлекләре белән һәм шул ук вакытта зур әдәп белән тасвирлый. Һәр ике әсәрдә дә героиняларның гаять мөлаем, самими һәм нәзакәтле күңел дөньясы бөтен табигыйлеге белән ачыла. Аннан соң героиняларның шәхси язмышларын сурәтләүдә дә уртаклык бар. Хәят тә, Гөләндәм дә ата-ана сүзенә буйсынып, мәхәббәтләреннән ваз кичәргә мәҗбүр булалар. Дөрес, семьяда алган тәрбияләре һәм характерлары буенча бер-берсенә нык охшаган бу кызларның уй-хисләренә һәм үз-үзләрен тотуларына заман мәгълүм эз сала. Әгәр революциягә кадәр яшәгән Хәят үз юлын билгеләүдә ата-ана сүзенә һәм язмышка буйсынуны табигый хәл, тормыш законы дип кабул итсә, 20 нче елларда яшәгән Гөләндәм исә мондый караш белән инде килешеп бетә алмый. Тик аның тормыш юлын үзе теләгәнчә сайларга ихтыяр көче генә җитми. «Хәят» белән «Гөләндәм туташ хатирәсе»н үзара якынайта торган тагын бер сыйфат аларда хикәяләүнең пехтәлегенә, үткәндәге әдәбият традицияләре белән бәйләнгән эчке культурага ия булуларына карый. Эчке культура дигәндә мин хикәяләүне оештырудагы рационализмны, төгәллекне күздә тотам.

60 нчы елларда И. Гази стилендә дә кызыклы үзгәрешләр барлыкка килә. 40 — 50 нче елларда ул күбрәк кече жанрларда эшли. Инде романга мөрәҗәгать итсә дә, җыйнаграк, артык киң колачлы булмаган романнар яза.

60 нчы елларда исә ул нәкъ менә киң колачлы һәм зур масштаблы романнар язарга алына. Шул юнәлештә зур гына уңышларга ирешә. «Онытылмас еллар» трилогиясенең икенче китабы шул хакта сөйли. Әйтергә кирәк, эпик хикәяләү өлкәсендә безнең әдипләр 50 нче елларда да кызыклы эзләнүләр алып баралар. Ул вакытта

эпиклыкка башлыча вакыйгалылык ярдәмендә, заманның киң панорамасын тудыру аша ирешелә. Хәзер И. Гази үзенең «Онытылмас еллар»ында 20 нче елларның күрәшле һәм катлаулы чынбарлыгын чагылдыруда панорамлык белән психологик анализның тыгыз бәйләнешенә омтыла. Нәтиҗәдә без әсәрдә, шул заманның шактый киң панорамасын күзаллау белән бергә, аерым шәхесләрнең катлаулы язмышлары, бай рухи дөньялары белән дә танышабыз. Менә ни өчен бу әсәр татар прозасының гражданнар сугышы чорын бөтен зурлыгында һәм катлаулылыгында сурәтләү юлында җитди бер адым булып санала. Моның белән «Онытылмас еллар» хәзерге татар прозасының гражданнар сугышы дәверен тасвирлауда 60—70 нче еллар совет прозасының магистраль юлыннан атлавын күрсәтә. Мәгълүм ки, хәзерге күп милләтле совет прозасында әлеге тарихи дәверне бөтен зурлыгы һәм катлаулылыгы белән сурәтләү тенденциясе көчәйде. Бик еракка китмичә, күрше әдәбиятларга гына мөрәҗәгать итсәк тә, без казакъ Ә. Нурпеисовның «Кан һәм тир», таҗик Җ. Икраминың «Бохараның унике капкасы», башкорт Ф. Исәнгуловның «Ир-егеткәй белән ат башы» романнарының И. Гази әсәренә шактый якын торуларын күрербез. Сүз әлеге дә баягы панорамлык белән психологик анализның тыгыз бәйләнешенә ирешү, шул нигездә хикәяләүнең эпик төс алуы турында бара.

60 нчы еллар прозасының тагын бер үзенчәлеге ул елларда язылган роман-повестьларда аналитик рухның көчәюе белән бәйләнгән. Моның уңай нәтиҗәсе итеп элеккерәк еллар әдәбиятының игътибары җитмәгән күренешләргә һәм язмышларга дикъкать артуын санарга кирәк. Бу 50 нче еллар ахырында һәм 60 нчы еллар башында әдәбиятка килгән прозаиклар иҗатында аеруча ачык чагыла. Р. Төхфәтуллин, Г. Ахунов, Н. Фәттах, А. Гыйләҗев, Ә. Баянов, Э. Касыймов, Б. Камалов һәм башкалар әдәбиятка шәхси күргән һәм кичергәннәрен тасвирлап килеп керәләр, прозаны һәм тематик, һәм проблематик яктан шактый баеталар. Дөрес, Г. Ахунов, Н. Фәттах, Э. Касыймов кебек авторлар бу юлдан озак бармыйлар, беренче күләмле әсәрләреннән соң ук үзләренә таныш булмаган яңа материалны, чынбарлыкның безнең әдәбият өчен яңарак якларын үзләштерергә керешәләр. Ә менә Р. Төхфәтуллин, А. Гыйләҗев һәм Ә. Баянов беренче әсәрләрендә күтәрелгән темага теге яки бу дәрәҗәдә бүгенге көнгә кадәр турылыклы булып калалар. Р. Төхфәтуллин, мәсәлән, нефтьчеләр тормышына мөрәҗәгать иткәндә дә («Агымсу» повестенда), сугыштан соңгы авыл малае язмышын чагылдыруны максат итеп куя һәм үзе өчен яңа теманы шушы яссылыкта яктыртырга алына. Балалык һәм яшьлек чоры истәлекләренә таянып иҗат итү бу язучыларның әсәрләрендә стильгә караган кайбер уртак сыйфатлар да барлыкка китерә. Шулардан берсе һәм, минемчә, иң әһәмиятлесе — лиризм. Шул ук вакытта лиризмның һәр язучы иҗатында үз төсмерләре, үз нюанслары булуын әйтергә кирәк. Әгәр Р. Төхфәтуллин әсәрләрендә ул беркадәр публицистика белән азыкландырылса, А. Гыйләҗев һәм Ә. Баянов аңа фәлсәфилек рухы өрергә омтылалар. Дөрес, алар бу теләкләренә һәр очракта да ирешә алмыйлар. Хикмәт авторның фәлсәфи уйларының әсәр тукымасыннан аерылып торуында, фәлсәфи фикерләрне чагылдыру өчен геройларның уңышсызрак сайлануларында. Гомумән алганда, Р. Төхфәтуллин, А. Гыйләҗев һәм Ә. Баянов әсәрләре 60 нчы еллар прозасында лирик агымның көчәюенә китерәләр. Бу агымга соңрак В. Нуруллин, М. Мәһдиев, Ф. Мансуров һәм башкалар килеп кушыла.

Инде әйтелгәнчә, «Яшьлек яме» һәм «Ә сезнеңчә ничек?» кебек беренче күләмле әсәрләреннән соң Г. Ахунов белән Н. Фәттах үзләре өчен яңарак тормыш материалын үзләштерүгә күчәләр. Бу алар иҗатының бераз башкарак юнәлештә үсеп китүенә сәбәпче була. Чөнки Г. Ахуновның «Хәзинә» һәм «Хуҗалар», Н. Фәттахның «Бала күңеле далада» һәм «Әтил суы ака торур» романнарында сурәтләнгән чынбарлык авторлардан башкарак пафос, сурәтләү чаралары һәм алымнары сорый. Барыннан да элек заманның зур иҗтимагый-политик һәм рухи процессларын, тарихи вакыйгаларны чагылдыруга алыну авторлардан «Хәзинә», «Әтил суы ака торур» романнарында масштаблырак тасвирны, күп төрле төсләр белән эш итүне таләп итә. Һәр ике очракта да хикәяләүнең эпос рухындарак башланып китүе дә шушы хәл белән бәйләнгән, күрәсең. Дөрес, эпос стиле әлеге әсәрләрнең ахырына кадәр сакланмый. Бераздан авторлар игътибарларын берничә геройның башлыча шәхси язмышына туплыйлар һәм сүзне күбрәк шулар тирәсендә алып баралар. Бу хәл «Әтил суы ака торур» романын-

да аеруча нык сизелә. Болгар йортның туу, оешу процессын сурәтләүгә багышланган бу әсәр, киң колачлы хикәяләү белән башланса да, Ф. Хөсни әйткәнчә, «ахырга тарая-тарая барып, ниһаять, бәк балаларының «башсыз» тәвәккәллекләрен, сөешүмәхәббәт романтикаларын бик тәфсилле сурәтләү белән очлана»[1]. Аннан соң әлеге әсәрләрдәге төп геройларның фаҗигале язмышларын сурәтләүдә дә күпмедер аваздашлык бар. «Хәзинә» романының герое Кәрим шәхси дан артыннан куып һәлак булса, Тотыш исә мәхәббәт корбанына әверелә. Дөрес, бу фаҗигаләр төрле-төрле сәбәпләр белән аңлатылалар. Кәримнең фаҗигале үлеме элеккерәк елларда нефть промыселларында шактый таралган кайбер тискәре тәртипләрнең, аерым алганда, рекордчылык белән мавыгуның шәхескә кире йогынтысы нәтиҗәсе итеп күрсәтелә. Тотышның үлеменә аның мәҗнүнлеге сәбәпче була.

Сюжетның ахырга таба шулай тараюын авторларга әдәби осталык җитмәү белән генә аңлату тулы булмас иде. Биредә анализ рухының тәэсире дә бардыр, күрәсең. Чөнки авторларның масштаблы хикәяләүгә әллә ни омтылмаулары, аерым шәхесләрнең язмышлары белән күбрәк кызыксынулары, шуларны җентеклебрәк сурәтләүне өстенрәк күрүләре сизелеп тора. Мондый омтылыш Н. Фәттахның «Бала күңеле далада» романында аеруча көчле. Һәм ул И. Салаховның шулай ук чирәм җирләрне үзләштерүчеләргә багышланган «Күкчәтау далаларында» романы белән чагыштырганда тагын да ачыграк күренә. И. Салахов үз әсәрен эпик рух белән сугарырга, аңа фәлсәфи яңгыраш бирергә омтыла һәм романның баштагы өлешләрендә моңа беркадәр ирешә дә. Н. Фәттах романында исә мондый рухның һәм пафосның эзе дә юк. Язучы бары иксез-чиксез дала киңлегендә эшләп яткан кечкенә генә трактор бригадасы белән кызыксына һәм шушы бригаданың көндәлек тормыш-көнкүрешен җентекләп һәм эзлекле рәвештә тасвирлап бара.

Кабатлап әйтсәк, болар барысы 60 нчы еллар прозасында аналитик башлангыч көчәю белән бәйләнгән. Бу тенденция 70 нче еллар башында да дәвам итә. Дөрес, ул үткәнне кабатлау төсен алмый, бәлки әдипләр иҗатында яңарак сыйфатлар да тудыра. Мәсәлән, 70 нче еллар башы прозасында хәзерге авылга игътибар көчәеп, бу темага багышланган әсәрләрдә колхоз җитәкчесен эшлекле герой итеп тасвирлауга дикъкать артуы күренә. Биредә мин Г. Ахуновның «Чикләвек төше», Х. Хәйруллинның «Канатлар талмасын» повестьларын һәм М. Хәбибуллинның «Чоңгыллар» романын күздә тотам. Әлеге мәсьәләне яктыртканда әсәрләрдә кызыклы гына стиль сыйфатлары чагылып китә. Г. Ахунов хикәяләвенә динамизм, штрихлы язу алымына мөрәҗәгать итү хас. Х. Хәйруллин җитәкче герой образында шәхси белән иҗтимагый якны тыгыз бәйләргә омтыла. М. Хәбибуллин романында исә хикәяләүдә салмаклык көчәя.

Хәзерге прозабызның эстетик байлыгы, индивидуаль стильләрнең күп булуыннан тыш, анда тагын стиль агымнарының яшәвендә дә чагыла. Күргәнебезчә, 60 нчы еллар башы тәнкыйте бу мәсьәләгә беркадәр игътибар иткән иде. Ул вакыттан соң үткән елларда бу агымнар тагын да ачыклана һәм яңа әдипләр иҗаты исәбенә тулылана төшә. Дөрес, стиль агымнары арасында нинди дер кытай стенасы үткәрү кыен эш. Кайчак бер үк әдип стилендә төрле агымнарга хас булган моментлар очрый. Шулай да иҗатларының иң мөһим сыйфатлары белән алар билгеле бер агымга карыйлар.

Безнең хәзерге прозада нинди рәк стиль агымнары турында сүз алып барырга мөмкин соң? Барыннан да элек ике агымның аеруча күзгә ташлануын әйтергә кирәк. Аларның беренчесенә өлкән әдипләрдән Г. Әпсәләмов белән М. Әмирне, ә урта буын прозаикларыннан Г. Ахунов, Б. Камалов һәм Э. Касыймовларны кертергә була. Бу әдипләрне бер-берсенә чынбарлыкның үзәк иҗтимагый-политик проблемаларына һәм заманның алдынгы героена йөз тотү, хикәяләүдә шактый көчле публицистик башлангыч, пафослылык, контраст төсләрне ярату, автор позициясенең аермачык булуы, яңа белән искенең көрәшен калку итеп, ә кайчак хәтта беркадәр ялангачландырып күрсәтү һәм башкалар якынлаштыра. Башында Ә. Еники торган икенче агымга Н. Фәттах белән А. Гыйләҗевне кертергә мөмкин. Бу әдипләр күбрәк тормыштагы катлаулы күренешләр яки шәхесләр белән кызыксыналар, аларны бөтен

[1] «Казан утлары» журналы. 1973 ел, 2 сан, 177 бит.

табигыйлеге белән күрсәтергә омтылалар, сурәтләнгән вакыйга-хәлләргә шәхси карашларын һәм мөнәсәбәтләрен яшерә төшәләр. Нәтиҗәдә әсәрдә тасвирланган күренешләргә бәя бирү эше еш кына укучының үзенә калдырыла.

Болардан тыш тагын берничә локальрәк агымны күзалларга була. Г. Бәширов белән Р. Төхфәтуллинны, мәсәлән, авыл халкының бөтен холык-фигылен, үзенчәлекле эчке рухын, шигъриятен һәм фәлсәфәсен бик нечкә һәм тирән сизеп иҗат итү үзара якынайта. Алар авыл турында чын мәгънәсендә авылча язалар. Мондый сыйфатларны тагын яшьрәк прозаиклардан В. Нуруллин белән Ф. Мансуровның шушы темага багышланган әсәрләрендә беркадәр сиземләргә була.

Ф. Хөсни байтак вакытлар стиле буенча безнең прозада башка беркемгә охшамаган әдип булып һәм ничектер бер ялгызы торып килде. Һәм менә 60 нчы еллар ахырында аның бу «ялгызлыгына» беркадәр чик куйган бер язучы әдәбиятка килде. Ул — М. Мәһдиев. Алар арасындагы якынлык барыннан да элек көндәлек тормышның гадәти күренешләрендә һәм фактларында зур мәгънә эзләүдә, беренче карашка бик гади һәм хәтта мескенрәк тә булып күренгән кешенең олы күңелен һәм рухи оптимизмын ачуда чагыла. Икенче яктан, бу әдипләрнең икесе дә халыктан килә торган җор һәм тапкыр тел белән язалар. Бу хәл хикәяләүне үзгә бер эмоциональлек белән сугара.

Теге яки бу стиль агымын тәшкил итүче язучылар белән беррәттән, безнең хәзерге прозада стиль ягыннан ялгызрак торган әдипләр дә очрый. Мәсәлән, А. Расихны катгый рәвештә биредә саналган агымнарның берсенә дә кертеп булмый. Аның әсәрләрендә төрле агым сыйфатларын табарга була. Ачык һәм динамик конфликтларны яратуы, уңай геройларны калку итеп сурәтләве белән ул Г. Әпсәләмов, М. Әмир, Г. Ахуновлар төркеменә якын тора кебек. Ә менә традицион тискәре персонажларны катлаулы һәм каршылыклы шәхесләр итеп сурәтләве, аларның гыйбрәтле рухи эволюциясен нигезләп ачуы белән ул инде Ә. Еники һәм А. Гыйләҗевне хәтерләтә төшә. Шул ук вакытта үзенең фикерләүдәге рационализмы белән А. Расих беркемгә дә охшамаган. Ә. Баянов иҗаты турында да нигездә шул ук сүзләрне кабатларга мөмкин. Әйтик, киң эрудицияле геройны сурәтләргә, хикәяләүнең фәлсәфилегенә омтылуы белән ул беркадәр А. Гыйләҗевне хәтерләтә. Әммә мондый сыйфатлар Ә. Еники белән Н. Фәттах иҗатларына әллә ни характерлы түгел. Әлеге фәлсәфилеккә әдәби шартлылык алымнары аша ирешергә омтылу исә бары Ә. Баяновның үзенә генә хас. Хәзергә башлыча А. Расих белән Ә. Баянов стильләренә генә караган сыйфатларның — гыйльми фикерләүдән килә торган рациональлекнең һәм сәнгатьчә шартлылык алымнарына мөрәҗәгать итүнең перспективалы булуын әйтергә кирәк. Алар киләчәктә яңадан-яңа авторларның дикъкатен җәлеп итәрләр дип уйларга мөмкин.

Социалистик реализм әдәбиятындагы стильләр мәсьәләсенең бер мөһим аспекты итеп, 60 нчы еллар башыннан милли стиль мәсьәләсе карала башлады. Бу терминны гамәлгә кертүнең кирәклеген әдәбиятчылар 50—60 нчы елларда совет әдәбиятының эстетик базасы тагын да баю һәм тирәнәю белән, аларда стильләр структурасының бермә-бер катлауланы белән бәйләп аңлаталар. Әдәбиятларның стиль табигатендәге мондый үзгәрешләрне инде индивидуаль стиль һәм стиль агымнары ярдәмендә генә аңлатып булмавы ачыклана. Яңарак күтәрелә башлаган мәсьәлә булганга күрә милли стильнең асылы турында әдәбият фәнендә әле ачык фикер юк. Бу киләчәк эше булып кала. Моның өчен милли стиль мәсьәләсен ныклап көн тәртибенә куясы һәм бу өлкәдә киң тикшеренүләр үткәрәсе бар. Ә хәзергә әле мәсьәлә гомум төсләрәк күтәрелә, яки аның аерым моментлары турында гына сүз алып барыла. Мисал өчен украин милли стиленә романтиканың, эстон милли стиленә социаль панорамлыкның аеруча хас булуы хакында сөйлиләр.

Гәрчә мәсьәләнең асылы ныклап ачыкланмаган булса да, бер хакыйкатьне ачык итеп әйтергә мөмкин: милли стильне «эпоха» стиле кебек әдәбиятта стильләр төрлелеген һәм язучыларның индивидуальлеген кире кага торган күренеш итеп, аз санлы алымнар һәм чараларның арифметик суммасы рәвешендә күзалларга ярамый. Киресенчә, ул стильләр төрлелегенә нигезләнгән катлаулы, динамик һәм үзгәрүчән эстетик структура булырга тиеш. Шул ук вакытта милли стильне ниндидер саф милли

алымнар һәм чаралар суммасы итеп кенә карау да чынлыкка туры килми. Чөнки башка әдәбиятлар тәҗрибәсе белән, бигрәк тә реалистик традицияләр белән баетылганда милли стиль үзен тагын да көчлерәк сиздерә. Мәсәлән, М. Әуэзов казакъ милли стиле формалашуда рус әдәбиятының реалистик традицияләре зур роль уйнавын әйтә. Әдәбиятның милли үзенчәлеге аның реализм бирә торган мөмкинлекләрдән никадәр тулы һәм тирән файдалана алуында, аның реалистик сәнгатьне үстерүгә керткән өлешендә чагыла. Әгәр теге яки бу әдәбиятның шундый сыйфатлары еш кына аның иң күренекле вәкилләре иҗатында тулырак гәүдәләнүен искә алсак, милли стиль нәкъ менә олы художниклар стилендә ачыграк чагылыш таба дип фараз кылырга мөмкин. Әдәбият тарихы үзе шул хакта сөйли. Мисал өчен Г. Тукай, Г. Ибраһимов һәм һ. Такташ яңа заман татар әдәбиятының гигантлары булып тарихка керделәр. Үткәндәге милли традицияләрне рус һәм дөнья әдәбиятының реалистик тәҗрибәсе белән баетып, алар милли әдәбиятыбызны сыйфат ягыннан яңа баскычка күтәрделәр. Менә ни өчен бу әдипләр стилендә шул заман татар милли стиле сыйфатлары аеруча көчле чагылды.

Хәзерге әдәбиятта милли стиль белән эш ничегрәк тора соң? Бер нәрсәне ачык әйтергә була: безнең көннәрдә милли стильне, Тукай һәм Ибраһимов заманнарындагы кебек, аерым әдипләр стиле белән генә бәйләп карарга ярамый. Мондый принципны иң элек хәзерге әдәбиятта стильләрнең гаҗәп күп төрле булуы кире кага. Шуның өстенә бу стильләр үзләренең әһәмияте ягыннан еш кына бер дәрәҗәдәрәк торалар, аларның берсен икенчесеннән өскәрәк куеп карап булмый. Алдарак куелган сорауга җавап бирү өчен, шушы стиль байлыгын җентекләп тикшерергә кирәк.

Хәзерге вакытта милли стильнең интенсив рәвештә үзгәрә, яңара баруы эшне тагын да кыенлаштыра төшә. Проза өлкәсендә бу үсеш-яңарыш, бер яктан, өлкән әдипләрнең стильләре байый һәм үзгәрә бару белән бәйләнгән булса, икенче яктан, 60—70 нче елларда урта һәм яшь буын әдипләренең стильләре формалашу һәм җитлегүе мөһим роль уйный. Дөрестән дә, хәзерге прозабызның стиль байлыгын Р. Төхфәтуллин, Г. Ахунов, Н. Фәттах, А. Гыйләҗев, Ә. Баянов, Б. Камалов, М. Мәһдиев һәм башкаларның иҗатларыннан башка берничек тә күз алдына китереп булмый. Алар милли стильне яңа бизәкләр белән баеттылар.

Хәзерге әдәбиятыбызның милли стилен тулы итеп күзаллау шактый кыен булса, аның аерым тотрыклы сыйфатлары турында конкретрак та сөйләргә мөмкин. Биредә мин буыннан-буынга күчә-күчә әдипләр аңында кристаллашкан әдәби традицияләрне күз алдында тотам. Тарих сынауларын уңышлы үткән мондый традицияләр милли стильнең какшамас нигезен тәшкил итәләр. Шуларның берсе рәвешендә, минемчә, татар прозасында «кечкенә кеше»не сурәтләүне алырга була. «Кечкенә кеше»гә ничек канатлар чыкты» исемле мәкаләсендә Ф. Хөсни аны безнең әдәбиятның К. Насыйридан башлап килә торган традициясе дип саный. Аның фикеренчә, бу традиция революциягә кадәр Ф. Әмирхан, Г. Газиз, Ш. Камал һәм Г. Ибраһимов хикәяләрендә ачык чагыла. Әмма Ф. Хөснинең революциягә кадәрге әдәбиятта «кечкенә кеше»не тасвирлауның үрнәге итеп Ф. Әмирханның «Сәмигулла абзый» исемле хикәясендәге сәүдәгәр образын алуы бәхәсле иде. Һәм бу моментка тәнкыйть тә игътибар итте. Татарстан язучыларының V съездында ясаган докладында Г. Халит, мәсәлән, болай диде: «Бу әсәрдән байтак элек Ш. Камал һәм Г. Ибраһимов хикәяләрендәге чын мәгънәсендә халыкның үзеннән чыккан хезмәт иясе, гадел кеше образлары була торып, Сәмигулла кебек обывательләрне татар әдәбиятындагы «кечкенә», гади кеше тәхетенә менгерү, әлбәттә, бик сәер».[1] Моннан тыш, Ф. Хөснинең революциягә кадәрге әдәбиятта сурәтләнгән «кечкенә кеше»не кырт кисеп «перспективасыз, канатсыз, тик үзенең бер тиенлек идеалы белән генә яшәүче көлке «татар кәрләсе»[2] дип бәяләве белән дә килешүе кыен. Чөнки мондый бәя башлыча Ф. Әмирханның Сәмигулласы кебек типларга карый. Ә инде Ш. Камал һәм Г. Ибраһимов хикәяләрендәге «кечкенә кеше» башкачарак бәяләүне сорый. Бу очракта әдипнең капиталистик җәмгыять шартларында яшәгән гади хезмәт кешесен зур симпатия белән сурәтләве,

[1] Г. Халит. Кешегә һәм чынлыкка мәхәббәт белән. Казан, 1975 ел, 316 бит.
[2] «Совет әдәбияты». 1958 ел, 9 сан.

аның үзенең күңел сафлыгы белән бозык чынбарлыктан өстен торуын күрсәтүе турында сүз алып бару дөресрәк булыр. Ф. Хөснинең икенче фикере, «кечкенә кеше»не сурәтләүнең традиция рәвешендә совет чоры әдәбиятында да яшәвен әйтүе инде чынлыкка туры килә. Шул ук вакытта ул бу традициянең социалистик чынбарлык тарафыннан тагын да үстерелүенә, яңартылуына игътибар итә. Хәзерге әдәбиятта, ди автор, әлеге тип «революция тудырган яңа шартларда яңача тереклек итә башлаган гадел күңелле, тыйнак характерлы, шау-шусыз гына яши һәм эшли белүче тыйнак совет кешесе сыйфатында» алга баса. Болардан тыш хәзерге әдәбиятта тагын «кечкенә кеше»нең, ягъни беренче карашка бик гади, хәтта урта кул шәхес булып күренгән геройның олы күңелен һәм рухи матурлыгын ачуга дикъкать ителә. Бу сыйфат аеруча Ф. Хөсни иҗатына хас. Бу рәвешле сурәтләнгән герой тагын Р. Төхфәтуллин, Э. Касыймов һәм башка язучылар әсәрләрендә әледән-әле очрый. Әмма бу әдипләрнең уртак бер традицияне дәвам итүләре һич тә аларны бер-берсен кабатлауга китерми. Киресенчә, аларның һәркайсы бу традицияне үзенчә үстерә, аны яңа бизәкләр белән баета. Моның шулай икәненә ышану өчен Ф. Хөснинең Бәдретдинен («Бәдретдин»), Р. Төхфәтуллинның Нәбиен («Авылдашым Нәби») яки Э. Касыймовның Мирычын («Томан аша») искә алу да җитә. Уртак идеяне чагылдырган бу образлар сәнгатьчә гәүдәләндерү ягыннан бер-берсеннән шактый аерылалар.

Әдәбиятның стиль табигатенә һәр тарихи дәвер үз эзен сала. Хәзерге күп милләтле совет әдәбияты илебездә бара торган фән-техника революциясенең көчле йогынтысы астында үсә. Фән-техника революциясе замандаш әдипләрнең сәнгатьчә фикерләвендә ике сыйфатның аеруча көчәюенә китерде. Сүз хәзерге әдәбиятта документальлек белән шартлылыкка игътибар арту турында бара. Беренче карашка бу төшенчәләр бер-берсеннән бик ерак торалар һәм хәтта бер-берсен инкарь итәләр кебек. Чынлыкта исә алар бер-берсенең «ярдәменә» мохтаҗлар, бер-берсен тулыландыралар, баеталар. Әгәр документальлек үзе генә булса, әдип документка, фактка ябышып ятса, бу хәл әдәби иҗатның сәнгатьчә камиллегенә зыян итәргә, аның сулышын һәм колачын тарайтырга мөмкин. Инде шартлылыкка килсәк, әгәр ул реаль тормышка нигезләнмәсә, формализм чирен тудырырга мөмкин. Гомумән алганда, документальлек белән шартлылык миңа чын сәнгатьнең ике канаты кебегрәк тоела. Шул ук вакытта документальлек белән шартлылык әдәби иҗатның ике нигез сыйфатын чагылдыралар. Документальлек ул, һичшиксез, әдәбиятта аналитик тенденция көчәюен күрсәтә. Шартлылык исә сәнгатьчә гомумиләштерү, синтез чарасы булып тора. Автор фикерен гомумиләштереп һәм зур эмоциональ-фәлсәфи көч белән чагылдырырга ярдәм итә торган шартлылык чараларын эзләп, соңгы вакытта илебез әдәбиятларында халык иҗаты традицияләренә актив мөрәҗәгать ителә һәм бу өлкәдә кызыклы нәтиҗәләргә ирешелә. Бу уңайдан минем бер чагыштыру китерәсем килә. Ч. Айтматовның «Ак пароход» һәм А. Гыйләҗевнең «Мәхәббәт һәм нәфрәт турында хикәят» повестьларында бер-берсенә шактый якын торган ике вакыйга тасвирлана. Ч. Айтматов повестенда ул боланны (маралны) атып үтерү вакыйгасы, ә А. Гыйләҗев әсәрендә кемнеңдер төнлә зиратта кабер ташларын кубарып йөрүе. һәр ике очракта да бу хәлләр авторлар тарафыннан халыкның үткәненә, үткән буыннар истәлегенә һәм рухына җинаятьчел төстә кул сузу, аларны аяк астына салып таптау дип бәяләнә. Әмма шушы уртак фикерне сәнгатьчә гәүдәләндерү ягыннан әсәрләр бер-берсеннән шактый аерылалар. Ч. Айтматов маралны үтерү кебек көндәлек тормышта гадәти браконьерлык булып кына саналырлык фактка киң иҗтимагый-фәлсәфи һәм идея-әхлакый яңгыраш бирүгә ирешә. А. Гыйләҗевкә килсәк, әсәрендә сурәтләнгән фактка үзенең шәхси мөнәсәбәтен генә белдереп үтүе сәбәпле, өнә шундый киң әхлакый-фәлсәфи яңгыраш бирә алмый. Шушы ук темага Ч. Айтматовның «Иртә килгән торналар» исемле яңа повесте багышланган. Анда 15—16 яшьлек малайларның сугыш чоры авырлыкларын үз җилкәләрендә күтәрүләре, аларның беренче мәхәббәтләре һәм нәфрәтләре турында сөйләнелә. Әмма безгә таныш шушы хәлләрне һәм күренешләрне тасвирлауга Ч. Айтматов үзенчә килә. Эш шунда ки, сугыш чоры авылы өчен гадәти күренешләргә ул фәлсәфи яңгыраш бирә. Бу эштә әдипкә тагын халык иҗаты образлары ярдәмгә килә. Сугыш чоры колхозы йөген үз җилкәләрендә күтәрүче кешеләрне Ч. Айтматов кыргыз халкы эпосы «Манас» геройлары белән чагыш-

тыра. Сугыштан яраланып кайтып председательлек вазифасын үз өстенә алган Тыналиевны ул Манасның үзе белән чагыштыра. Ә инде авылның төп эшче көчләре — язгы чәчүгә чыгучы 15—16 яшьлек малайлар автор алдына борынгы Алыплар булып басалар. Кыскасы, шартлылык Ч. Айтматовка үз геройларын, аларның эшләрен фәлсәфи зурайтып, масштаблы итеп бирергә булыша. Мондый эзләнүләре белән Ч. Айтматов әдәбият алдына заман куя торган таләпләрне тирәнтен тоеп иҗат итүен һәм хәзерге әдәби-эстетик хәрәкәтнең алгы сафында баруын күрсәтә. Эш шунда ки, фән-техника революциясе заманы хәзер художниктан фәлсәфилекне, заман һәм шәхес турында масштаблы фикер йөртүне сорый. Укучы әдәбияттан дөньякүләм әһәмиятле эшләр башкарган һәм башкаручы совет кешесенең эре характерын, монументаль образын эзли. Хәзерге совет әдәбияты үзенең иң яхшы әсәрләрендә менә шушы ихтыяҗны канәгатьләндерергә омтыла.

Хәзерге әдәбиятның стиль табигатен өйрәнү хакында сүз алып барганда тагын бер мәсьәләгә игътибар итәсе килә. Мәгълүм булганча, хәзерге әдәбиятның төрле өлкәләре арасында эстетик бәйләнеш ныгый бара. Әдәби практика чәчмә хикәяләү алымнарының яки элементларының поэзиягә һәм драматургиягә, поэзиянең прозага һәм драматургиягә үтеп керүләрен күрсәтә. Шул ук вакытта әдәбиятның шушы өлкәләрендә эшләүче әдипләрнең стиль эзләнүләрендә кайбер уртак моментлар күзгә ташлана. Конкретрак әйтсәк, хәзерге урта буын прозаиклар, шагыйрьләр һәм драматурглар иҗатында, аларның сәнгатьчә эзләнүләрендә игътибарга лаеклы уртак моментлар күзаллана. Мондый уртаклыкларны бер әдәбият эчендә генә түгел, бәлки хәзерге сәнгатебезнең төрле-төрле өлкәләрендә дә сиземләргә мөмкин. Мәсәлән, шул ук урта буын әдипләр, композиторлар һәм театр эшлеклеләре иҗатында сәнгатьчә фикерләү ягыннан кайбер уртак моментлар күзгә чалына. Аларны җентекләп тикшерү хәзерге сәнгатебезнең гомум үсеш тенденцияләре, аның милли үзенчәлеге турында сөйләү өчен кызыклы материал бирер иде. Моның өчен хәзерге сәнгатьнең төрле-төрле жанрларын һәм тармакларын үзара чагыштырып һәм комплекслы өйрәнү сорала. Һәм бу эш безнең хәзерге әдәбият һәм сәнгать фәненең мөһим бурычы булып тора.

------------

# ҮЗӘК ПРОБЛЕМАЛАР

КПСС Үзәк Комитетының «Әдәбият-сәнгать тәнкыйте турында»гы мәгълүм карарыннан соң бездә әдәбият белемендә һәм әдәби тәнкыйть мәсьәләләренә караган китаплар саны бик нык артты. Әдәбият тарихына караган хезмәтләр һәм төрле монографияләр белән бергә, тәнкыйтьчеләрнең коллектив җыентыкларын чыгару гамәлгә кереп бара.

Г. Ибраһимов исемендәге тел, әдәбият һәм тарих институтының әдәбият секторы һәм Татарстан Язучылар союзы каршындагы тәнкыйть секциясе тарафыннан хәзерләнгән шундый беренче җыентык 1972 елда дөнья күргән иде. «Герой, стиль, осталык» исемле ул китапны әдәби җәмәгатьчелек җылы каршылады.

Узган ел шул ук сериядән «Метод, стиль, жанр» исемле икенче җыентык басылып чыкты. Исеменнән үк күренгәнчә, бусында да әдәбият фәне һәм әдәби тәнкыйть алдында торган мөһим мәсьәләләр күтәрелә. Метод, стиль һәм жанр кебек проблемалар бер өлеше мәкаләләрдә гомум теоретик планда, ә икенчеләрендә аерым әдипләр иҗатына һәм аерым әсәрләргә нигезләнеп яктыртыла.

Җыентык күренекле әдәбият галиме Гали Халитның «Иҗат методы һәм стиль мәсьәләләре» исемле зур күләмле мәкаләсе белән ачыла. Аның бу хезмәте совет әдәбияты фәне ирешкән казанышлар югарылыгында, шул казанышлар белән тыгыз бәйләнештә язылган. Галимнең фәнни фикерләре — тирән һәм дәлилле. Автор иҗат методын язучының дөньяга карашы, идея позициясе белән генә чикләүгә, янсә аны сәнгатьчә чаралар һәм алымнар системасы итеп кенә карауга каршы чыга. Аныңча, иҗат методы ул дөньяны сәнгатьчә сурәтләү принциплары бердәмлегеннән гыйбарәт. Мәкаләнең метод һәм стиль арасындагы мөнәсәбәтләрне ачыклауга багышланган урыннары аерым әһәмияткә лаек. Билгеле булганча, әдәбият галиме Л. И. Тимофеев «стиль — методның индивидуаль чагылышы» дип саный. Г. Халит моны стиль һәм метод арасындагы катлаулы мөнәсәбәтләрне гадиләштерү һәм схемалаштыру дип бәяли. Стильне «художникның сәнгатьле фикерләү үзенчәлеге, эчтәлекле форма» итеп карап, ул аның эстетик идеал белән аерылгысыз бәйләнештә булуын искәртә.

Автор, бер стильлелек һәм күп стильлелек, синтетик стиль, стиль аныклыгы, норматив стильләр кебек татар әдәбияты белеме өчен яңа төшенчәләр, атамалар кулланып, татар әдәбиятының үткәндәге сәхифәләренә, Тукай, Ибраһимов, Дәрдмәнд, Рәмиев, Гафури, Такташ, Җәлилләрнең сәнгатьчә фикерләвенә караш юнәлтә.

XX нче гасыр башы татар әдәбиятындагы тизләтелгән үсеш процессы турында Г. Халит моннан берничә ел элек язып чыккан иде. Бу мәкаләсендә ул әдәбиятыбызда тизләтелгән үсеш һәм стильләр яшәеше арасындагы закончалыклы мөнәсәбәтләрнең асылын ачарга омтыла. Галимнең проза һәм поэзия стильләре, лиризм, эпиклык, лирик драма, романтик реализм турындагы фикерләре шулай ук әдәбиятыбызның үткәне һәм бүгенгесе турында тирәнтен уйлану нәтиҗәсендә туганнар. Алар безгә бу хакта кабат-кабат фикер йөртергә, эзләнергә юл күрсәтәләр.

Рафаэль Мостафинның «Үсештәге, хәрәкәттәге тәгълимат» исемле мәкаләсе исә социалистик реализм методы хакындагы бәхәсләр уңае белән язылган. Автор социалистик реализмның революцион чынбарлыкны чагылдыруда чикләнмәгән мөмкинлекләре булуга басым ясый, аны тарайтып янсә, киресенчә, киңәйтеп, «ярларсыз» итеп карауга каршы чыга. Әйе, со-

циалистик реализм үсештә, хәрәкәттә һәм ул чыннан да чор сулышын, чор кешесен күп төрле юллар белән, ләкин сәнгатьчә дөрес гәүдәләндерүгә хезмәт итеп килә. Р. Мостафин буржуаз язучылар иҗаты белән социалистик реализм әдәбияты арасындагы капма-каршылыкларның асылын да шактый төгәл күрсәткән.

Соңгы елларда әдәбиятларның милли үзенчәлеген өйрәнү юлында совет әдәбият фәне уңышлы гына адымнар ясады. Безнең республикада бу юнәлештә Йолдыз Нигъмәтуллина аеруча уңышлы эшләп килә. Мин аның «Эстетик идеалның милли үзенчәлеге» («Национальное своеобразие эстетического идеала») исемле китабын күздә тотам. Рецензияләнә торган җыентыкта ул «Милли стиль диалектикасы» дигән мәкалә белән катнаша. Татар әдәбияты белемендә беренчеләрдән булып, автор сәнгатьле фикерләү процессына психик төзелешнең милли үзенчәлекләре тәэсир итү юлларын ачыкларга омтыла. Сәнгатьле фикерләүдә психик төзелешнең милли үзенчәлекләре гәүдәләнүне калкурак күз алдына бастыру нияте белән ул әрмән һәм татар әдәбиятлары тарихына мөрәҗәгать итә. XX гасыр башы әрмән әдәбиятында трагиклык, монументальлек, ә шул чор татар әдәбиятында төсмерлелек, нюанслылык, аныңча, милли стильнең бер гәүдәләнеше итеп карала ала. Әлеге әдәбиятлар тарихына бу ноктадан карап якын килү аларның эстетик табигатьләрен, үзенчәлекле үсеш юлын тагын да ачыграк күзаллауга юл ача. Бүгенге поэзиябезнең күренекле вәкилләреннән Х. Туфан һәм С. Хәкимнең сәнгатьчә фикерләү үзенчәлекләрен күзәтү исә мәкаләне тагын да тулыландыра төшә.

Татар әдәбият фәне һәм тәнкыйте әдәби стильне өйрәнү белән әле егерменче елларда ук кызыксына башлый. Флүн Мусин үзенең мәкаләсен татар әдәбият фәнендә һәм тәнкыйтендә әдәби стильне өйрәнү тарихына багышлаган. Автор Г. Ибраһимов, Г. Сәгъди, Г. Нигъмәти кебек галимнәрнең хезмәтләрен күздән кичерә, алардагы җитешсез якларны ачып салу белән бергә, ул алар эшчәнлегендәге уңай моментларга да нык игътибар итә.

«Метод, стиль, жанр» китабындагы күпчелек мәкаләләр әдәбиятыбыздагы төрле жанрларның үткәненә һәм бүгенге торышына багышланган. Мәсәлән, А. Әхмәдуллин хәзерге драматургиягә хас жанр һәм стиль үзенчәлекләрен тикшерә. Д. Вәлиев, Х. Вахит, Т. Миңнуллин, А. Гыйләҗев һәм башка драматургларыбызның әсәрләренә нигезләнеп, автор бүгенге сәхнә әсәрләренә хас тенденцияләрне ачыклый, бу өлкәдә яшәп килгән кимчелекләрне тәнкыйть итә. Язучыларыбызны шартлы алымнарга, театральлекнең төрле формаларына кыюрак мөрәҗәгать итәргә өнди. Н. Ханзафаров мәкаләсендә беренче карашка сүз Н. Исәнбәтнең сәхнә әсәрләре хакында гына бара кебек. Ләкин чынлыкта мәкалә пьесаларыбызның һәм спектакльләребезнең киң сулышлы һәм эстетик югарылыкта булуының мөһим алшарты — жанр аныклыгы мәсьәләсен үзәккә куеп, аны язучы стиленең үзенчәлекләре белән бәйләнештә карап язылган.

Х. Хәйри тарихи роман жанры турында уйлана. Әдәбиятта халыкның үткәнен, тарихын гәүдәләндерү тәҗрибәләрен күздән кичерә килеп, ул беренче тарихи романның татар әдәбиятында Октябрь революциясенә кадәр ук тууын әйтә.

Ф. Хатиповның татар совет прозасын психологизм проблемасына мөнәсәбәттә тикшерүен дә хупларга кирәк. Психологик прозаның вакыйгалы прозадан аермалы яклары турында фикер йөртеп кенә калмыйча, ул геройның эчке дөньясын бирүдә «мин» исеменнән һәм автор исеменнән сөйләүнең урынын, тышкы хәл, вакыйгалар белән үрелеп бару юлларын да күрсәтә алган. Татар прозасы турында сүзне алга таба И. Бәширова дәвам иттерә. Ул сүз белән тасвирлау үзенчәлекләрен әдипнең индивидуаль осталыгын ачу юлындагы мөһим чара итеп карый. Авторның Г. Ахунов, А. Гыйләҗев, Н. Фәттах, Р. Төхфәтуллин кебек язучыларыбызның кабатланмас индивидуаль стильләре турындагы уйлануларын кызыксынып укыйсың һәм мондый төр эзләнүләрне киләчәктә дә дәвам иттерү кирәклегенә ышанасың.

Татар әдәбияты тарихында шигъри жанрларның туу-формалашу һәм яшәешләре хакында җентекле тикшеренүләр әлегә сирәк күренә. Шунлыктан Х. Курбатовның «Татар әдәбиятында иркле шигырь» дигән мәкаләсе белән очрашу да безне нык шатландырды. Автор, дөнья әдәбият белеме казанышларына нигезләнеп, иркле шигырьне өч төргә бүлә, аның татар әдәбияты җирлегендә дә классик формалар белән янәшә яшәргә хаклы булуын яклый.

М. Гайнетдинов күренекле шагыйребез Хәсән Туфанның илле еллык иҗатын тари-

ки планда карый, үсеп-үзгәреп, яңарып килгән хасиятләрен заман, чор сулышына бәйләп күзәтә. Яшь әдәбият белгече Н. Морадымов исә Әхмәт Фәйзинең сатира-юмор жанрына караган әсәрләре хакында сүз йөртә. Автор Ә. Фәйзинең егерменче-утызынчы еллар, сугыш, сугыштан соңгы чорлар дәвамында иҗат ителгән әсәрләрен шагыйрьнең идея-эстетик эволюциясенә бәйләп тикшерә.

Бу хәтле мактагач, китап бар яктан камил икән дип уйлый күрмәгез. Билгеле, анда кимчелекләр дә шактый гына. Әйтик, анда метод, стиль һәм жанр төшенчәсенә карамый торган мәкаләләр дә урын алган. Язучы һәм шагыйрьләрнең иҗатына хас үзенчәлекләрне эзләп, чагыштыруларга тагын да кыюрак мөрәҗәгать иткәндә, әсәрләрнең эстетик табигатьләре ныграк ачыла төшәр иде. Баштагы мәкаләләрдә күтәрелгән мәсьәләләргә җыентыкта катнашкан башка авторларның да мөнәсәбәтен күрәсе килгән иде. Бу нәрсә күренми. Гомумән, киләчәктә мондый төр китапларда проблемаларның тыгыз үрелеп куелышына ирешү кирәктер.

Биредә борынгы һәм 18—19 гасырлар татар әдәби әсәрләре фәнни-теоретик фикерләү мәйданында бик аз урын алганлыгын да әйтеп үтәсе килә.

Шулай да китап бүген басылып чыгып иртәгә искерә торган басмалардан түгел. Татар әдәбият фәне үсеше, галимнәребезнең мөһим проблемаларны бөтен тирәнлегендә куя, чишә алулары «Метод, стиль, жанр» китабында бик ачык күренә.

**ЗӨФӘР РӘМИЕВ,**
**филология фәннәре кандидаты.**

# ЙӨЗ ДӘ БЕРЕНЧЕ МОГҖИЗА

СССР язучыларының алтынчы съездында, әдәби иҗат эшенең ифрат та үзенчәлекле бер өлкә булуына басым ясап, Г. М. Марков болай дигән иде: «Язу өстәле янында утырганда язучы күп нәрсә турында уйланырга, күп нәрсәне күңеленнән уздырырга тиеш. Бу минут һәм сәгатьләрдә аның бөтен тормыш тәҗрибәсе, әдәби сәләтенең барлык яклары, иҗтимагый вөҗданы, дөньяга карашы һәм фикер сөреше гаҗәеп бер хәрәкәткә килә... Бөтен игътибарын туплап, әлегә үзенә дә бик үк анык булмаган нәрсәне эзләп азапланган бу кешегә читтән караганда: менә бер вак һөнәрче каләм-өтергесе белән сихерчелек кылып утыра, дип уйларга мөмкин... Нәрсә тудырырга тиеш соң ул? Могҗиза, бөек могҗиза тудырырга тиеш ул!»

Камил Мостафинның «Современник» нәшриятында чыккан яңа җыентыгы янә бер тапкыр Г. М. Марковның шул сүзләрен искә төшерде. Җыентык үзе дә «Йөз дә беренче могҗиза»[1] дип аталганга күрә генә түгел. Хикмәт шунда, андагы шигырьләр белән танышканда, мин чын поэзия әсәрләрендә генә очрый торган могҗизага орыну ләззәте кичергәндәй булдым.

Камил Мостафин — поэзия белән генә көн күрүче профессиональ шагыйрь түгел. Казан дәүләт университетының физика-математика факультетын тәмамлагач, менә егерме ел инде ул Чиләбе шәһәрендәге заводларның берсендә инженер булып эшли. Гәрчә татар поэзиясендә күптән үз урынын алган шагыйрь булса да, ул әле һаман да рәсми рәвештә Язучылар союзында член булып тормый. Әмма поэтик эшләнешләре, шигъри культуралары ягыннан аның шигырьләре — тәмам җитлеккән профессиональ әсәрләр. Алар тирән фикерле, табигый яңгырашлы, формаларының пөхтә эшләнгән булулары белән игътибарны җәлеп итәләр.

Камил Мостафинның иҗатын мин беренче адымнарыннан ук күзәтеп барам. Шагыйрьнең матбугатта чыккан тәүге шигырьләрендә үк мине фикер тирәнлеге, форма төгәллеге сокландыра иде. Нүрсәң, матбугатта басыла башлаганчы ук инде ул шактый гына әзерлек чорын үткән булган. Һәрхәлдә, укучылар каршына Камил Мостафин шигъри тәҗрибәләр һәм өйрәнчек әсәрләр белән түгел, ә бәлки үзенең каләм көченә ышандыра торган тулы кан-

[1] К. Мостафин. Йөз дә беренче могҗиза. Шигырьләр, рус телендә, Мәскәү, «Современник» нәшрияты, 1976 ел.

лы шигырьләр белән чыга. Тик аның акрынрак язуы гына күңелне борчый иде. Чыннан да, өч-дүрт, хәтта биш елга ике, иң күп дигәндә өч басма табак күләмендәге юка гына җыентыкны һич тә күп дип әйтеп булмый. Хәер, ныклабрак уйлап караганда, бу әллә ни зур гөнаһ та түгелдер әле?!

Камил Мостафин иҗаты ни өчендер тәнкыйтьчеләр игътибарыннан читтә кала килә. Унбиш-егерме ел эчендә басылган ике-өч дежур рецензия һәм ел йомгакларында әйтеп үтелгән берничә авыз сүз... Бар булганы әнә шул диярлек. Шагыйрьнең иң әйбәт шигырьләре тупланган «Йөз дә беренче могҗиза» җыентыгының дөньяга чыгуы миңа аның иҗат юлына күз төшереп үтәргә, аның шигырьләренә хас үзенчәлекле якларны ачыклау юлында бер омтылыш ясап карарга мөмкинлек бирә.

Камил Мостафинның үз укучылары бар, әдәбиятта үз урыны бар. Аның артык күп булмаган, әмма үзләренә җәлеп итә торган шигырьләреннән башка безнең поэзиянең күге шактый дәрәҗәдә тоныклanып калыр иде.

Аның шигырьләренең җыйнак һәм төгәл эшләнгәнлекләрен алда әйтеп үткән идем. Бу исә авторның шигърияткә бик җитди һәм профессиональ күзлектән чыгып каравы турында сөйли. Дөрес, бүгенге көндә моның белән генә укучыны шаккаттырып булмый. Чөнки хәзер югары профессиональ дәрәҗәгә ия булу бөтен татар поэзиясе, хәтта башлап язучылар өчен дә хас нәрсә. Камил Мостафин иҗаты безне иң элек башка шагыйрьләрдә булмаган, башка шагыйрьләрдә очрамаган сыйфатлары белән үзенә тарта. Берише шагыйрьләр, әйтик, шигырьләрендә табигать күренешләре, күргән-белгәннәре, кичерешләре турында сөйләп бирәләр. Икенчеләре үзләренең хисләрен, тормыштагы теге яки бу вакыйгага уңае белән туган тойгыларын образлар ярдәмендә гәүдәләндерәләр. Ә Камил Мостафин үз шигырьләрендә уйлана:

Без серләрне югалтабыз,
Югалтабыз,
Кыен җавапларны тапкан чакта...
Серне саклап йөртә күңел.
Серле күңел нинди бай ул өмет кебек,
Ә ачылса сере, күңел — укылган хат,
Иске китап... Нигә серләр мәңге түгел?

(«Без серләрне югалтабыз...»)

Камил Мостафин шигырьләрен мин интеллектуаль шигырьләр дияр идем... Әгәр соңгы вакытта үзләрен интеллектуаль кешеләр дип расларга азапланучылар бу төшенчәнең кадерен бетереп ташламаган булсалар. Шагыйрь безне бүгенге кешенең әхлакый эзләнүләре мохитенә алып керә, хәзерге көн мещанының потребительлек омтылышларына каршы чыга. Аны дөньяның, табигатьнең, безне чорнап алган тирә-юньнең киләчәге борчый. Аның иҗатында тормыштагы теге яки бу конкрет вакыйга уңае белән язылган шигырьләр очрамый диярлек. Ул шулай ук рифмалаштырылган публицистиканы да өнәми. Ләкин, моңа карап, К. Мостафин заман ихтыяҗларына битараф шагыйрь икән, дип уйларга ярамый. Аның заманчалыгы, заманга авазадашлыгы — фикерләвендә, әйбер һәм күренешләргә мөнәсәбәтендә. Шагыйрьнең лирик герое — «теоремалар, исәпләүләр, саннар дөньясы белән» чолганып алынган кеше. Һәм ул, нинди дә булса әйбернең яки күренешнең асылын ачыклаганда, эмоция, хисләргә бирелүдән бигрәк, аны үлчәп-тикшереп карарга, башкача әйткәндә, төпченергә ярата. Менә шуңа күрә Камил Мостафин шигырьләренең кайберәүләргә салкын булып тоелуы мөмкин. Чынлыкта исә бу салкынлык бүгенге көн кешесенең, техник интеллигенция вәкиленең рациональ акыллы булуын чагылдыра.

Шуның белән бергә, аның лирик героена эмоцияләр һәм ургып торган кайнар хисләр дә ят түгел. Әмма ул эмоцияләр, ул хисләр, шагыйрь иҗатына хас булганча, ирләрчә сабырлык белән ачылалар.

Кар нинди саф — безнең намус кебек.
Карлы юллар — зәңгәр, аксыллар.
Аумасыннар утка төз наратлар,
Часовойлар булып калсыннар.

(«Төз наратлар утка аумасыннар».)

Камил Мостафин поэзиясе уңдырышлы туфракта, Габдулла Тукай, Һади Такташ, Муса Җәлил кебек киң ябалдашлы имәннәр күләгәсендә шытып чыга. Шул ук вакытта аның шигырьләре традицион характерда да түгел. Гасырлар буена көнчыгыш шигърияте эзеннән барган татар поэзиясе өчен әдәби сурәтләрнең шактый дәрәҗәдә бизәкле булуы хас. (Бер уңайдан шул кадәресен дә әйтеп үтәргә кирәк, безнең шигъриятнең бу үзенчәлегенә укучылар да күнегеп беткән инде.) Ә Камил Мостафин поэтик тәгъбирләрнең ифрат дәрәҗәдә гади булуына, сулышның һәм сөйләм интонациясенең табигыйлегенә омтыла, көнчыгыш поэзиясенә хас булган бизәкләрдән качарга тырыша.

Ул шулай:
Без очрашабыз йөзгә-йөз,
Тик кирәкми монда хәнҗәр һәм наган,
Йөзгә-йөз, йөрәккә-йөрәк, күзгә-күз...
Ә вакыт, ах, чабуыннан туктаган.

(«Мәхәббәт».)

Бу юллар мәхәббәт турында. Әмма мәхәббәт турында сөйләгәндә, шагыйрь безнең башка шагыйрьләр белән бәхәскә керә сыман. Шунысы характерлы, шагыйрь бирелә оригиналь булып күренергә тырышып һич тә көчәнми. Шул ук вакытта үзе булып калуы белән үк ул инде оригиналь. Ул — урта буын вәкиле, башыннан аягына кадәр шәһәр кешесе. Ләкин ул үзенең балалык еллары узган авылны да онытмый. Аңа бүгенге фәнни-техник фикернең иң югары казанышы булган космик ракета да, «борынгы, Бах органы» да бер үк дәрәҗәдә якын һәм кадерле. Фәлсәфи фикер йөрткәндә ашыкмаучан, тыныч, сабыр холыклы бу кеше үзенең тойгыларын белдергәндә дә бик тотнаклы:

Кыш килмәгән әле, чирәмнәргә
Кар яумаган...
Кара читән... Ул кыйшайган гына,—
Ул аумаган,
Ә читәндә — әни элеп куйган
Иске казан...
Һәм мин уйлап куйдым (һаман исән кебек):
«Ник алмаган?..»

Шагыйрь монда әнисен яратуы, аны югалтуның никадәр авыр икәнлеге турында бер сүз дә әйтми. Ләкин бу хисләр шигырь юлларына салынган һәм шуның белән, укучы буларак, миңа көчлерәк тәэсир дә итә. Троплар, чагыштыру, метафора кебек сурәтләү чаралары кулланганда да шагыйрь бик саран. Вакыты-вакыты белән аның шигыре нибары ике генә төрле — кара һәм ак буяулар ярдәмендә ясалган гап-гади рәсемне хәтерләтә.

Күрәм бүген карлы җирдә ике төсне:
ак һәм кара. Ап-ак түбә, кара койма.
Кара морҗа һәм ак сукмак. Ә сукмакка
кемдер әнә кара каргаларны койган.
Ак каеннар кара белән бизәкләнгән
Кара көчек карны ялый мыштым гына...

(«Күрәм бүген кара җирдә ике төсне».]

Белмим, шушы рәвешчәрәк язылган әсәрләр өчен шагыйрьне гаепләргә кирәкме икән? Монда аның поэтик йөзенә хас үзенчәлекләренең берсе чагыла түгелме соң? Өстәвенә, безнең алдыбызда тәрҗемә шигырьләр тупланган җыентык ятканлыгын да истән чыгарырга ярамый. Шагыйрь Лев Смирнов тәрҗемәсендә чыккан бу җыентыкта кайбер төгәлсезлекләрне, аерым очракларда уңышсызрак тәрҗемә ителгән юлларны да эзләп табарга мөмкин. Ләкин, тулаем алганда, оригиналда мин белгән шагыйрьнең иҗат рухы рус телендә дә әйбәт сакланган. Каләмдәш дустының шигырьләрен тәрҗемә итү өлкәсендә күптәннән һәм намус белән эшләүче шагыйрьнең төп уңышын мин әнә шунда күрәм.

**РАФАЭЛЬ МОСТАФИН.**

# «КАПКЫН» ЖУРНАЛЫ БЕЗДӘ КУНАКТА

Чувашчадан тәрҗемәләр

## Александр Галкин

### Салмыш Якку маҗарасы

Айнымас Яккуга бер көн
Бәйрәм килгән тагын да:
Чөмергән аракысын да,
Чөжлап торган балын да.

Үз-үзен белә алмаслык
Хәлгә җиткән көенә, —
Ава-түнә, бата-чума
Атлый икән өенә...

Тик капкадан кайтып керсә,
Күрә, эшләр начар ла:
Ишек тышкы яктан бикле,
Аны ничек ачарга?

Яккуга соң моның гына
Җаен табу озакмы...
Бер тимер табып ала да
Каера ул йозакны.

Чормадан сикергән мәче
Аудара буш чиләкне.
Кинәт куркып сискәнергә
Яккуга күп кирәкме:

— Кем анда тавыш чыгара,
Азына үз башына?
Көчен сынашасы килсә,
Чыксын минем каршыма.

Йодрыкларын төйнәп Якку
Әрле-бирле йөренә.
Шунда ике йодрык аңа
Дүртәү булып күренә.

— Әһә, миңа яныйсыңмы...
Инде менә түз генә!
...Китереп бәрә үз шәүләсен
Чагылдырган көзгегә.

Башы белән сөзеп шуны
Кызык итим дигәндә, —
Һушын югалтып ул үзе
Авып төшә идәнгә.

## Василий Tоймак

### Инфаркттан качып

Бер күршем бар — яше узган
Җитмештән ашып.
Сер итеп әйтим: яши ул
Инфаркттан качып.

Кояштан да алда чыга
Ишеген ачып:
Чуп-чар түгәргә йөгерә
Инфаркттан качып.

Ишегалдында домино
Сугалар шашып.
Ул бер читтә утын яра
Инфаркттан качып.

— Кибеттән әйләнеп кайттым,
Ишетәмсең, карчык?!
Сөт шешәләрен тапшырдым
Инфаркттан качып.

Керен юа... Футбол тибә
Ярсыпмы-ярсып.
Каршы капкага туп кертә
Инфаркттан качып...

Йөгерешләрдә таң калдыра
Һәммәбезне дә...
Инфаркттан качып әле ул
Узар йөзне дә.

Рәшит Гәрәй тәрҗемәләре.

## Надежда Черепанова

### Сихерле апрель

Нигезе бар, дивары бар...
Юк түшәме, түбәсе.
Плакаты бар, сүзләре бар:
«Апрельдә өлгерәсе!»

Узды язлар. Нигезендә
Кычыткан атты чәчәк.
Ә плакаты шаулады гел:
«Апрельдә өлгерәчәк!»

Кошлар кебек бер-бер артлы
Тезелеп узды көннәр.
Ә плакат сөйләде гел:
«Апрельдә өлгертәләр!»

Апрельдә булгач, апрельдә,
Ышаныгыз инде сез.
Кайсы елның апрелендә? —
Шунысы гына белгесез.

### Үтенеч

Ничегрәк әйтим икән?..
Кыскасы, әни мине
Кайчандыр шушы яслегә
Бирмәкче булган иде.
Мин үзем зур инде... Ләкин
Чират җитте бит менә!..
Шул чират белән кызымны
Алмассызмы яслегә?!.

## Вениамин Тимаков

### Трибун шагыйрь

Тыныш билгеләренә ул
Мәктәптә үк гашыйк иде.
Онытмады буй җиткәч тә,
Гомер буе шашып сөйде.

Сигез юллы шигырендә
Тыныш билгеләре — сиксән.
Чуплап бетерәлмас кошлар,
Җим урынына җиргә сипсәң.

Шигырь язгач өндәү тезеп,
«Трибун шагыйрь!» ди ул үзен.
Газетларның, журналларның
Бәйрәм саны гына түзсен!..

## Александр Калган

### Моральсез мәсәл

Төнлә куянны өенә
Озата икән керпе.
Әйбәт кенә барган чакта
Куян кычкырган өркеп:
— Елан, елан! Кара елан!..
Керпе әйткән: «Шаулама!
Бер читкә кит, ә мин хәзер
Сабак укытам аңа».
Куян дер-дер килеп һаман
Кычкыра икән анда:
«Ай, ул мине йоклата ич,
Гипнозлап тартып ала!»
Инәләрен тидергән дә
Куян тәпиенә керпе:
«Йоклама, бар, йөгер, — диган, —
Йөгер, тими бит беркем!..»
Агулы дәртен сүндергәч
Керпе зәһәр еланның,
Дәшә икән: «Әй, куян дус,
Кил монда, кайда калдың?..»
Ә куян исә бу вакыт
Судка гариза язган:
«Явыз керпе пычагыннан
Чак исән калды абзаң...»

* * *

Моральләрсез-нисез генә
Булсын, әйдә, бу мәсәл...
Елан куянга ымсынган,
Тик чагалмаган... Ә жәл!..

Фаил Шәфигуллин тәрҗемәләре

## Виталий Енеш

# АЛТЫН КЕШЕ

Туган авылыма чакырып телеграмма килде. Үч иткәндәй, автовокзалда халык — кара болыт. Касса янында эткәләшә-төрткәләшә торгач, ике төймәмне өздереп, сыңар бияләемне төшереп югалттым.

Аптырагач-йөдәгәч, кесә ягын чамалап карадым да такси ялларга булдым.

— Кара әле, агай-эне,— дидем мин, шакмак билбаулы машинаның тәрәзәсен кагып. — Авылга кайтасы иде. Бик ашыгыч... Әнием авырып киткән.

— «Ноль өч»кә шалтырат. «Ашыгыч ярдәм» машинасы хәзер илтеп куяр, — дип авыз ерды шофер.

— Ха-ха... Шаян егет икәнсең, — дидем мин, тегенең күңелен кү-

рергә тырышып һәм кесәмнән шыгырдап торган бишлекне чыгарып, уч төбенә салдым.

— Ә сиңа чыра кирәкмиме? Нарат чырасы, — диде шофер, минем кулдагы бишлеккә күз агы белән карап.

— Чыра? Нигә ул?

— Миннән җүләррәк таксист эзләргә. Көндез чыра яндырып.

Егетнең тел төбен аңлап, кесәдән унлык чыгардым.

— Теге йорттан справкаң бармы? — дип мыскыллы елмайды шофер. — Юкса, синең бер шөребең бушагандай тоела. Таксины чытыр арбадан аера белмисең.

Әмма ни генә булмасын, миңа көнендә авылга кайтып җитәргә кирәк иде. Шунлыктан, эчтән әрнеп булса да, теге унлык янына тагын бер бишлек өстәдем.

— Мин бюрократ түгел түгелен... — дип авыр сулап куйды таксист. — Шөрепләрең үз урынында икәнлегенә справкасыз да ышанам. Әмма җиде чакрым — җиде адым түгел. Бу ләшпердектә, ул тикле җиргә барып, солы кесәле чөмерергә...

— Што син! Нинди кесәл?! Менә мо-оннан сыйлап җибәрермен!— дидем мин, җилнең уңай якка авыша башлаганын сизеп.— Әҗерен дисәң, тагын биш сум өсти алам.

— Ярый, хуп, сыйладың да ди. Тик ул авыл юлларында... — дип муенын кашып куйды егет, — сикәлтәдә машинаны чегән арбасы кебек чөя. Андый чакта шоферның игътибары беләсеңме нишли?.. Асфальтка сипкән борчак кебек тарала да китә. Берәр яры бәрелеп, харап булуыңны көт тә тор... Юк, туганкай, булмый.

Шоферның бу сүзләре чеп-чи уйдырма икәнне бик яхшы аңласам да, каршы әйтмәдем.

— Ышанам, дус кеше,— дидем, аны һаман юмаларга тырышып.— Тик мин нитәрмен... Юл буе сиңа кызыклы анекдотлар сөйләп барырмын. Игътибарың һич таралмас.

— Кара әле, син ярыйсы кеше күренәсең бит, — дип, мыек астыннан көлеп куйды теге. — Анекдотларны яратам мин. Тик менә... Ул юллардан бер генә узып кара. Машинаны тәүлек буе юып та адәм рәтенә кертеп булмый.

Дөресен әйткәндә, минем нервылар какшый башлады. Әмма сер бирмәскә тырыштым.

— Исең киткән иске чикмәнгә! Үзем юып бирермен. Җылы су белән. Теләсәң, селтелесе белән.

— Хуп! Яхшы кеше икәнсең, — дип, машина ишеген ачып җибәрде таксист. — Әйдә, утыр булмаса. Справка сораганым өчен ачуланма. Әйтеп кара менә үзең, кем ул пассажир? Комсыз җанвар, ач күз! Машинага кереп утыру белән счетчикка текәлә дә ката. Янәсе, алдый күрмәсеннәр аны, бер тиенен эзләп кесәсенә кермәсеннәр хәрам корсакның! Ә син... Син һәйбәт кеше икәнсең. Справкасыз да күренеп тора.

Мин бик канәгать булып, машинага кереп утырдым. Әмма машина урыныннан кузгалмады.

— Тукта әле, братан, баруын барырмын да, кайтуы ничегрәк булыр икән соң? — дип, кинәт кенә каерылып карады егетем. — Кем белсен, юлда батып-нитеп калуың бар. Сиңа нәрсә, үз өеңдә — җылыда, йомшакта. Ә миңа төн буе йолдыз санаргамы?

Мин тизрәк аны юатырга тырыштым:

— Курыкма, бу турыда уйлармын инде, — дидем. — Минем абый колхоз председателе. Газик белән озаттырыр.

— Шулай да, сәер кеше син. Ярый, хуп, газик озата килде ди. Ә биредә, кабинада мин ялгызым булам түгелме соң? Шунда кинәт фикер таркалып китсә... Янда анекдот сөйләүче дә булмагач...

— Бусы өчен дә кайгырасы юк, — дип, көйсез шоферның сүзен бүлдем мин. — Күрше кызы инде әллә кайчаннан шәһәрдәге туганнарына кунакка килергә җыена иде. Сөйләшермен дә утыртып җибәрермен. Янында андый чибәр кыз утырганда...

— Алайса, булды гына, — дип кычкырып әйтте шофер. — Шәп кеше икәнсең, валлаһи! — Әмма шунда ук егетнең борыны салынып төште. — Тик... Тик куркам шул, братан. Ул чибәр кыз өчен егетләрегез тотып ярмагае үземне...

— Ихтимал. Бик ихтимал, — дип баш кактым мин. — Тик син курыкма. Беләсеңме, мин... мин көрәшче, гимнаст, мин боксер, мин, мин... ышанмыйсыңмы?..

Мин авызын кыйшайтып утырган таксистны якасыннан каптырып алдым да машинасыннан сөйрәп чыгардым.

— Ышанасыңмы? Әйт, ышанасыңмы? Мин штангист, мин самбист, мин...

— Ышанам, ышанам...— дип, көч-хәл белән хырылдап җавап бирде шофер.— Ышанам, братан... Шәп кеше икәнсең. Утыр, киттек... Алтын кеше икәнсең...

Һәм без ярты сәгатьтән, елдыртып, авылга кайтып җиттек.

## Аркадий Эсхил

# БАРЫП ҖИТТЕ

*Хикәя*

Көннәрдән бер көнне электросварщик Мигулай Якушин эшкә өр-яңа мотоциклга утырып килде. Сөенечтән Мигулайның авызы колагына җиткән иде. Тик ул үзенең бу куанычын башкаларга сиздерергә бераз кыенсына да иде кебек. Әмма төзелештә бергә эшли торган иптәшләре аны шунда ук сырып алдылар. Лаклы өслегендә кояш нурлары балкып торган җыйнак һәм җитез машинаны алар төрлесе төрлечә мактый башлады.

Бары тик монтажчы Алексей Айгашев кына авыз ачып ләм-мим сүз әйтмәде. Ул мотоциклны кат-кат әйләнеп чыкты, кырына беркетелгән бәллү арбасын селкеткәләп карады. Тик шуннан соң гына, үз-үзенә сөйләнгән кебек, борын эченнән генә мыгырданып куйды:

— «Урал-67»— ярыйсы машина инде ул. Көчле машина. Ләкин...

Аның нәрсә әйтергә теләгәнен беркем дә төшенеп җитмәде. Алексей үзе дә аңлатып торуны кирәк санамады, ахры, кырт кына борылды да эш урынына китеп барды. Башкалар да таралыштылар.

Мигулай мотоциклын эш кораллары саклана торган склад янына, күләгәгә илтеп куйды.

Җан дусты Алексейның әйтеп бетерелмәгән фикере көн буе аның башыннан чыкмады.

— Нәрсә әйтергә теләде икән соң бу Айгаш? — дип уйлады ул.— Башта мактады, аннары, нәрсәдәндер канәгать булмагандай, йөз чөереп китеп барды. Мин бит аны кирәкмәстән алмаган. Урлаган да. Хәләл кул көчем. Ничә еллар экренләп җыя килдем. Ни әйтсәң дә эз акча түгел бит — мең ярымнан артык. Ә ул... Дус дисәң дус!...

Әйе, иске дуслар иде Алексей белән Мигулай. Яшьлек дуслары

иде. Профессиональ-техник училищены икесе бергә тәмамладылар. Эштә дә, ял вакытында да гел бергә булдылар, бер үк тулай торакта яшәделәр. Бер үк язда гашыйк булдылар. Сөйгән кызлары да аерылмас дуслар иде. Төс-битләре дә, хәтта исемнәре дә бер-берсенә охшаш: Юлька белән Улька. Игезәкләр диярсең...

Тиздән туйлары да булды. Башта фатир мәсьәләсе шактый кыен иде. Тик балалар туып, якты дөньяда үз урыннарын даулый башлагач, һәр ике гаиләгә дә берәр бүлмәле әйбәт кенә фатир да биреп куйдылар.

Шулай итеп, әкрен-әкрен дөньялары түгәрәкләнә барды егетләрнең. Хезмәттә дә гел югарыга үрләделәр. Һәм, иптәшләре шаяртып әйткәнчә, иң югарыга, ак болытлар янына менеп җиттеләр. Берсе монтажчы, икенчесе электросварщик — икесе дә верхолазлар.

Хезмәтенә күрә хөрмәте, диләр. Һәм акчасы да хезмәтенә күрә түләнә. Әз-әзләп арттыра бара торгач, менә Мигулай мотоцикл да алып җибәрде. Тик нәрсәсен өнәмәде икән соң аның Айгаш? Әллә, юкса, көнләшүе микән соң?..

Шулай борчылып уйлана торгач, дусты белән электән ике арада булган бер сәер әңгәмә Мигулайның хәтеренә төште.

Икәүләшеп көндезге сменадан кайтып киләләр иде.

— Яшерен-батырын түгел, Мигулай... — дип, дустының колагына пышылдады Алексей. — Яшерен-батырын түгел, дөньяга акча хуҗа. Шуңа күрә дөньяның рәхәтен белеп яшәргә кирәк. Акчаң булса — син кеше, булмаса — чүп. Киңәшем шул — нинди дер коры хыяллар белән яшәмә. Булдыра алган кадәр умырып калырга тырыш. Мин ни өчен, көн таң атса, таракан кебек, тимер баганага үрмәлим? Яшермим, шул акча өчен. Егылып, муенымны сындырудан да курыкмыйм. Ник дисәң, акча кыштырдавы кыюлык бирә. Синең белән без югары разрядлы мастерлар. Дөньяның рәхәтен дә башкалардан күбрәк татып калырга тиешбез.

Дустының мондый сәер фәлсәфәсе кинәттән Мигулайның өнен алды. Шунлыктан ул, авыз ачып, каршы бер сүз дә әйтә алмады.

Ә бераздан алдынгы эшче Алексей Айгашевның мондый карашлары сүздә генә түгел, эштә дә күренә башлады.

Әйтик, бер генә мисал... Практика узарга төзелешкә һәр ел саен йөзәрләгән яшьләр килә. Аларны кулларыннан тотып өйрәтергә, аякка бастырырга, кеше итәргә кирәк. Мигулайга быел да ике өйрәнчек беркеттеләр. Ә Алексей исә аяк терәп баш тартты.

— Балалар бакчасы түгел бу. Минем үземнең эшлисем бар! — дип кырт кисте ул.

Дөрес, моңа гына карап, аны артык битәрләүче булмады. Ләкин Алексейның йоткошлыгы көннән-көн арта барды. Ул бер җирдә фатир ремонтлый, икенче берәүгә су кертә, өченчесенең идәнен буйый, унитазын төзәтә.

Дөрес, мондый эшләрне ул башта ял көннәрендә генә эшли иде, тора-бара, шәбрәк «чумара» күренсә, эштән дә сыпырткалый башлады.

Еллар узу белән, семьялар да зурайды. Иске дусларның икесенә дә бер үк йорттан өчәр бүлмәле фатир бирделәр. Шул ук атна ахырында Мигулай фатир «юарга» дус-ишләрен кунакка чакырды. Кунаклар арасында Алексей да бар иде. Ләкин Алексей үзе кунак чакырырга ашыкмады...

Мигулайның өй туеннан соң ике-өч атна да узмады, Алексей төзелешкә чия төсендәге ялтыравыклы «Жигули» машинасына утырып килде. Иптәшләренең котлавын ул, машинасыннан да чыкмыйча, бик горур кыяфәттә тыңлап утырды. «Без алай, кайберәүләр кебек, ты-

рылдавык мотоцикл белән вакланмыйбыз, — дигәндәй, кырын гына Мигулайга карап алды.

— Бүген барыгыз да миңа кунакка килегез, — диде ул, машинасыннан чыккач. — Бүген сәгать сигезгә. Берочтан «Жигулины» да юып алырбыз!

Алексейга кунакка барырга Мигулайның аягы тартмады. Хатыны Юлькка гына көч-хәл белән ризалаштырды.

Мигулайлар барганда кунаклар җыелып бетә язган иде инде. Иң түрдә иң хөрмәтле кунаклар — төзелеш җитәкчеләре утыра. Дөньяның җаен белеп яши торган Алексей җае чыккан саен аларга аерым игътибар күрсәтергә тырыша.

Бүлмәдә өр-яңа шифоньерлар, сервантлар, китап шкафлары, күзләрнең явын алырлык келәмнәр... Залда каз оясы хәтле чуклы-чуклы люстра. Чын хрустальдан! Сый-хөрмәттән өстәлләр сыгылып тора. Шәрабы дисәң — хет башыңнан коен.

Мәҗлес тиз арада кызып китте. Тостлар әйтелде, котлаулар булды. Яшьтән үк җыр-музыка ярата торган Юлькка яңгыравыклы матур тавышы белән җыр башлап җибәрде:

Цевиль ага, Цевиль ага,
Цевиль ага Иделгә...

Кунаклар аны дәррәү күтәреп алдылар. Җыр артыннан җыр ялганып китте. Аннары биюләр башланды. Яңа фатирның идәннәре генә түгел, түшәме дә дер селкенде кебек.

Әмма шул чак кинәт... Табынның тап уртасына кимендә ике пот авырлыгындагы әлеге хрусталь люстра килеп төште. Бүлмәдә ут сүнде. Хатын-кызлар чырылдап кычкырып җибәрделәр. Бәхеткә каршы, беркем дә зарарланмаган, имгәнмәгән иде. Түрдә утырган түрәләрнең берсе каушап калган хуҗаларны һәм кунакларны тынычландырырга ашыкты:

— Җәмәгать, борчылмагыз, — диде ул. — Мәҗлес вакытында савыт-сабамы, ниме... ватыла икән, бу инде бәхеткә диган сүз. Әнә, күрше бүлмәдә ут балкып тора. Ишекләрне ачып җибәрегез дә әйдә, күтәрегез. Зур бәхеткә! Хуҗалар бәхетенә! Яңа «Жигули»ның гомере озын булсын! Ура!

Мондый тосттан соң Алексейның кырылган кәефе яңадан рәтләнеп китте.

Әйе, «Жигули» аның күптәнге хыялы иде. Машинаның үзеннән дә бигрәк, киләчәктә ул китерәчәк табыш ярсыта иде аның күңелен.

Һәм күп тә үтми, Алексей Айгаш, машинасына утырып, ял көннәрендә кәсепкә чыга башлады.

— Канашкамы? Утыр әйдә! Свияжскигамы? Рәхим ит!

Бертуктаусыз ары да бире чаптыра. Ульяновск шәһәренә барып килә, хәтта Горький тирәсен әйләнә. Юлда автоинспекция туктатса, Алексейның җавабы әзер: «Туганнарымны илтәм» — вәссәлам!

Әмма хрусталь люстраның җимерелүе Алексейга бәхетне ни өчендер һаман китермәде. Безнең чуваш картлары әйтмешли, иң озын арканның да очы була!.. Көннәрдән беркөнне, «туганнарын» Канашка алып барганда, аны җәмәгать автоинспекторлары туктатты. Болары инде Айгашның «туганнарын» танырга теләмәделәр. Кырт кисеп әйтелде табышлы «Жигули» хуҗасына:

— Әйдә, төш, авылдаш! Килеп җиттең!

Әйе, шулай итеп барып җитте Алексей Айгашев. Иптәшләр суды алдына ук барып басты.

Судта аның иске дусты Мигулай да чыгыш ясады.

— Әйе, барып җиттең син, дустым Айгаш! — диде ул әрнеп.— Тәмам барып җиттең!

## Геннадий Мальцев

# СЫРТ СӨЯГЕ

Павел Васильевич, авыл хуҗалыгы институтын тәмамлап, туган авылына кайтты. Аның бәхетенә, колхозга югары белемле агроном кирәк иде. Ул, бик шатланып, шунда эшкә урнашып калды.

Булдыклы яшь агрономны авылдашлары да яраттылар. Киң күкрәкле, зәңгәр күзле, әзмәвердәй таза бу егет барыннан да бигрәк кызлар күңеленә хуш килде. Аның турында уйлап, күпме чибәркәйнең күпме төн йокылары калмагандыр!.. Тик Павел бу турыда үзе һичнәрсә сизенмәде. Чөнки аның кызларга күтәрелеп карарга да вакыты юк иде. Ник дисәң, яшь агроном җилкәсендә кырыкмаса-кырык мәшәкать: язгы чәчү, урып-җыю, туңга сөрү, ашлама кайтару, картоту... Аның өстенә агроуку, төрле җыелышлар, төрледән-төрле утырышлар... Әмма ул барысына да өлгерде, төн йокысын калдырып булса да, һәр эшен вакытында эш итеп барды.

— Вәт, ичмаса, безнең Павлуша! Җилкәсе киң, сырт сөяге нык. Күпме салсаң да тарта, — дип сокландылар колхоз җитәкчеләре.

Һәм озак та үтмәстән, аны комсомол оешмасы секретарьлыгына тәкъдим иттеләр. Авылдагы алтмыш биш комсомол, кул чабып, ура кычкырып, Павелны бертавыштан сайлап та куйды.

Ул арада зоотехник укырга китеп барды.

— Ярты ел өчен яңа кеше алып торуның ни мәгънәсе булыр икән, — диде председатель идарә утырышында. — Менә безнең арабызда Павел Васильевич утыра. Яшь иптәш, энергичный. Аңа гына йөкләп торсак дим. Җилкәсе киң, сырт сөяге нык. Тартыр бит?

— Ник тартмасын, тартыр! — дип, бертавыштан кычкырды идарә әһелләре һәм дәррәү кул чаптылар.

Озакламый колхозчыларның гомуми җыелышы булды. Анда иптәшләр судына судья сайлау мәсьәләсе карала иде.

— Мин Павел Васильевичны тәкъдим итәм, — диде авыл Советы председателе. — Булдыклы, яшь, тырыш...

— Дөрес, дөрес. Җилкәсе киң, сырт сөяге нык, — дип кычкырды тракторчы Игнат Сумков.

Колхозчылар дәррәү кул чаптылар. Бертавыштан сайлап, судья итеп куйдылар Павелны.

Тагын бер айдан колхоз стена газетасына редактор сайладылар. Бу эшне дә Павел Васильевичка тапшырырга тиеш булдылар.

— Туктагыз әле, иптәшләр, сез нәрсә уйлыйсыз? — дип, урыныннан купты Павел. — Минем өстә әнә бит никадәрле эш!..

Ул, бармакларын бөгә-бөгә, үзенә йөкләтелгән җәмәгать эшләрен саный башлаган гына иде, алгы рәттә утырган көтүче Осип Аверкиев кычкырып куйды:

— Әйдә, нитмә, Павел!.. Мәтәштермә, яме. Семьяң, бала-чагаң юк. Яшь, таза, сырт сөягең нык. Син тартмый, аны кем тартсын.

Башкалар да Аверкиев сүзен хуплады, бертавыштан Павелны редактор итеп сайладылар.

Шулай итеп, куласадагы тиен кебек бөтерелә башлады егетең. Иртә таңнан фермага чыгып чаба, аннан басуга, аннан симәнә амбарына, амбардан тагын фермага, бүген кич комсомол җыелышына, иртәгә идарә утырышына, политукуга, агроукуга... Төн урталарында гына өенә кайтып егыла да, кулына алган газетасын да укый алмыйча, йоклап китә, иртә таңнан тагын сикереп тора.

Шулай көннәрдән бер көнне, биш кенә минутка дип идарәгә сугылган иде, аның артыннан ук, пыр тузып, Осип Аверкиев чабып керде:

— Менә кара, иптәш секретарь, — дип умырылган күлмәк җиңен Павелның борынына төртте Осип. — Күр, менә нишләтте башкисәр Игнат. Күлмәгем күлмәктәй генә түгел иде, инде хәзер нәрсә?.. Идән чүпрәге... Тиешле чарасын күр. Син бит иптәшләр судында судья. Син газета редакторы...

Ул да булмады, бусагада тәмам ярсыган Игнат Сумков күренде.

— Әз эләкте бугай әле сиңа! Шулаймы? — дип гайрәт чәчте ул, бала башыдай йодрыгын Осипның борын төбендә селкеп. — Кирәкме тагын?! Шушындый беткән башка колхоз көтүен ышанып тапшыргач соң... Эссе, имеш, аңа! Арыган, имеш! Күләгәгә кергән дә хырылдап йоклап ята. Ә көтүе бодайга кереп тулган. Бодае нинди иде бит! Үзем сөреп, үзем чәчкән җир. Менә шул, секретарь, иртәгә үк комсомол җыелышын җый!

Икенче көнне Осип, иртә таңнан, көтү куганчы ук, Павел Васильевичка өч гариза китереп тоттырды. Аларның берсе комсомол оешмасы секретаре исеменә, икенчесе иптәшләр суды председателенә, өченчесе стена газетасы редакторына иде. Осипның таләпләре катгый: хулиган Сумковны комсомолдан куарга, иптәшләр судына тартырга, стена газетасына язып чыгарга.

Төш вакытында Игнат та нәкъ шундый ук өч гариза язып китерде.

Күп тә үтми, әлеге гауга турындагы хәбәр бөтен авылга таралып өлгерде. Колхозчыларның очраганы берсе Павел Васильевичны туктатып сораштыра, үз фикерен әйтә, киңәш бирә. Киңәшләре исә төрледән-төрле:

— Кул озайткан өчен Игнатны унбиш тәулеккә утыртырга.
— Осиптан тапталган иген бәясен түләтергә.
— Икесен тиң стена газетасына язарга.
— Шелтә бирергә...
— Эштән куарга...

Тик Павел Васильевичның гына аларны юньләп тыңларга вакыты юк иде. Көндәгечә — ут капкандай һаман йөгерә, һаман чаба. Идарәдән кырга, кырдан амбарга, амбардан фермага, фермадан җыелышка, җыелыштан утырышка...

Түзсәң, түз, түзмәсәң — ярыл!..

Тик җәйге эшләр бераз саегып, көзге яңгырлар башлангач кына комсомол җыелышы җыярга берара вакыт таба алды.

Җыелыш ачылганда Осип белән Игнат иң алгы рәттә, икесе янәшә күңелле генә гөрләшеп утыралар иде. Үзләренең гаризалары каралачагын ишеткәч, икесенең дә чәчләре үрә торды.

— Син нәрсә, иптәш секретарь, әллә кайчан онытылган юк-барны казып чыгарасың?! — дип торып басты Осип.

— Әйтәсе дә юк. Безне түгел, сине тикшерергә кирәк монда, — дип гайрәтләнде Игнат. — Кергән гаризалар өч ай буе саргаеп ята. Стена газетасына кайчаннан кулың тими.

— Дөрес, дөрес. Бәйрәмнәрдә генә чыга.

— Иптәшләр суды ник эшләми? — дип бер-бер артлы сүзгә кушылдылар башка комсомоллар.

Шау-шулы фикер алышулардан соң, җыелыш бертавыштан карар кабул итте: колхоз идарәсенең чираттагы утырышында стена газетасы редакторының һәм иптәшләр суды председателенең отчетын тыңлауларын сорарга.

— Дөрес эшләгәннәр комсомоллар, — диде председатель карарны

укыгач. — Ышанычны акламады ул егет. Сырт сөяге сыек булып чыкты. Шелтә чәпеми булмас.

Һәм чыннан да идарә утырышы, тапшырылган эшләргә салкын караганы өчен, бертавыштан карар кабул итеп, Павел Васильевичка каты шелтә белдерде.

## Григорий Луч

# КАДЕРЛЕ КӨЧЕК

*Хикәя*

Каникуллар җиткү белән мин шәһәргә, абзыкайларга кунакка барам. Абзыкайлар тугыз катлы әкәмәт зур йортта яшиләр. Икесе бер йортта, тик фатирлары гына башка.

Авыл малаен шәһәргә нәрсә тартканын аңлыйсыздыр инде. Әнә бит анда күпме кызык, күпме тамаша! Татлы тортлар дисеңме, шырпыга утыртылган әтәч-кәнфитләрме, көймәле даганнар, зоопарклар, өйрәтелгән арысланнар дисеңме... Дөрес, мин үзем дә хайваннар өйрәтергә хирес малай. Минем кәкре койрык Алабай өчкә кадәр саный белә, яңагын сыйпасаң — күрешергә тәпиен суза. Тик андый этләр авылда урам саен шул. Аның белән беркемне дә шаккаттырып булмый.

Ә менә быел кышкы каникуллар алдыннан минем кече абзыкай, сәер бер хат язып, бөтен авылны шаккаттырды.

«Хак булса, этегез бик матур көчекләр китергән, имеш,— дип язган иде ул.— Кыенсынмасаң, зинһар, бер көчегеңне миңа алып килә күр...»

Бу хатны алып укуга, бөтен агай-эне, туган-тумача, күрше-күлән баш ватарга тотынды. Соң инде!.. Шәһәр циркында өйрәтелгән арысланнарга тикле була торып, ни пычагыма икән аңа гап-гади авыл көчеге. Аннары килеп, шәһәр өендә эт оясын кайда кормак кирәк тә, ул көчекне ничек асрамак кирәк.

Тик мин артык баш катырып тормадым. Икенче көнне үк Алабай көчекләре арасыннан иң тересен, иң шаянын сайлап, арыш капчыгына тыктым да, автобуска утырып сәфәр чыктым.

Юлда андый-мондый хәвеф-хәтәргә юлыкмадым. Тик капчыктагы тиктормас көчегем генә берөзлексез теңкәгә тиеп йөдәтте. Иң элек ул, ничектер җаен табып, капчык киндере аша минем уң кулны тешләп алды, аннары янәшәмдә утырган бер агайның сул кулын тырнады, аннары, дуңгыз баласыдай чинап, автобустагы бар халыкның җенен чыгарды. Ярый әле, артык озак барасы түгел, нибары өч кенә сәгатьлек юл иде. Инде шул чыелдык аркасында автобустан сөреп төшерәләр икән дип шүрләп утырганда, шәһәргә килеп тә җиттек.

Артын-алдын абайлап, яңадан трамвай-фәләнгә утырып азапланмадым, капчыгымны җилкәгә асып, җәяү генә киттем.

Ишекне абзыкай үзе ачты. Минем кулдагы тере капчыкны күргәч, аның авызы колагына җитте. Шунда ук капчыктагы көчекне тартып чыгарды да чат-чот үбәргә кереште, бүлмә буйлап сыңар аягында биеп китте. Биеп арыгач, көчекне идән уртасына бастырды да, аның тирәсендә кушаяклап, тышаулы ат кебек сикеренеп йөри башлады. Ул сикерә, ә мин, тиле кеше кебек, ни эшләргә белмичә, ишек

төбендә басып тик торам. Белмим, әллә чишенеп түргә узасы, әллә борылып кире чыгып китәсе...

Ул арада абзыкай, нәрсәдер исенә төшкәндәй, түр бүлмәгә ташланды. Бүлмә ишегеннән шунда ук чибәр җиңгәчәйнең, ягъни мәсәлән, абзыкай хатынының, шатлыклы тавышы ишетелде. Озакламый алар этешә-төртешә алгы бүлмәгә йөгереп чыктылар да яңадан көчеккә ябырылдылар. Гәүдәгә шактый саллы булгангадырмы, чибәр җиңгәчәй сыңар аягында да биемәде, тышаулы ат кебек кушаяклап та сикермәде. Аның каравы, дүрт аяклап, бүлмә буенча мүкәләп йөри башлады. Көчекнең бер алдына, бер артына төште, эт булып өрде, бүре булып улады, мәче булып мыраулады. Ярты сәгать чамасы шулай мәш килгәннән соң, абзыкай белән җиңгәчәй ашыга-кабалана кухняга кереп киттеләр, аннан пар бөркеп торган берничә тәлинкә тотып чыктылар. Бүлмәгә авыздан су китерерлек хуш ис — суганлап, борычлап пешерелгән итле бәрәңге шулпасы исе таралды. Тәлинкәләрне өстәлгә түгел, идәнгә, көчек алдына тезгәннәрен күргәч, мин инде ычкындыра башлаган төймәләремне каптырдым. Ник дисәң... Ник дисәң, юлда мин үзем дә ул көчектән ким ачыкмаган идем. Шунлыктан өлкән абзыкайларга кереп чыгарга кирәктер дигән фикергә килдем.

Бәхеткә каршы, өлкән абзыкай да өйдә икән. Ул миңа ишегалдында ук очрады.

— О, Миша! — дип кычкырып җибәрде ул мине күргә. — Килдеңме? Сәлам, егет, сәлам. Син, күрәм, безгә кадәр кече абзыкайларыңа кереп чыгарга өлгергәнсең. Әйдә әле безгә, әйдә әле..

Без килеп керүгә, май кояшыдай балкып, түр яктан өлкән җиңгәчәй атылып чыкты. Аның кулында тар гына сары каеш, ә каешның бер башы... мәчедән чак кына калкурак көчекнең муенындагы муенчагына бәйләнгән.

Көчек өрмәде дә, ырламады да. Әмма, җәлт кенә үрелеп, минем чалбар балагының бер кисәген умырып алды.

— Курыкма, курыкма, тешләми ул, — диде абзыкай. — Беләсеңме, Миша, теге ни бит... Шәһәрдә яшәп без табигатьтән, җан иясләреннән тәмам бизеп бетә язганбыз. Шуңа күрә алдык әле менә тыгынчыкны. Ни әйтсәң дә, яшь чакларны, туган якларны искә төшереп тора. Аннары эт, мәче ише җан ияләре кешене нечкә күңелле, игътибарлы булырга өйрәтә... Жучка, Жучка, нәрсә бөтереләсең? Карының ачтымы әллә? Әнисе дим, ни карап торасың, бир ашарына... Хәзер, кечкентәй, хәзер, сорыкай... Ә син, Миша, чишен, түрдән уз, утыр.

Ул арада җиңгәчәй, кухнядан куш йодрык кадәрле симез ит алып чыгып, көчеккә бирде дә диванга, минем янәшәмә килеп утырды. Сагынып көткән икән бит, әкәмәт. Теге көчек симез калҗаны ботарлаган арада ничек укуым, ничек яшәвем турында, әти-әни, туган-тумача, күрше-күлән хакында энәсеннән-җебенә кадәр сораштырды.

Аннары алар, икәүләшеп, көчекләрен юындырырга керештеләр. Исле сабын белән сабынлап, җылы суда кат-кат коендырдылар, ап-ак сөлге белән сөртеп корыттылар, башына тасма күбәләкле калфак, өстенә казакига охшаган җиңсез җилән кигездfestival һәм, мине кузгатып, диванга, җылы урынга салдылар. Әмма урынымнан кузгатуларына минем һич хәтерем калмады. Чөнки, ниһаять, миңа өстәл янына күчеп утырырга куштылар. Җиңгәчәй теге яктан майда кайнап, кызарып пешкән пәрәмәчләр, морожный-пирожныйлар алып чыгып алдыма тезде. Тик... Тик бу юлы да миңа ашау насыйп булмады. Пәрәмәчкә үрелгән генә идем, ишек ачылып китте дә анда кече абзыкайның нурлы йөзе пәйда булды. Ул, бармак изәп, мине тышка чакырып чыгарды һәм колагыма иелеп пышылдады:

— Энекәш! Анда сине минем күрше көтеп тора. Мин аңа синең

кечекләрең турында әйткән идем. Түшәмгә сикерде. Перәме-тәки якадан алды. Әйдә, тынычландыр үзен. Берәр көчегеңне китереп бирергә вәгъдә ит. Шуның өчен күрше белән без сине зоопаркка алып барырбыз. Анда хәзер кешечә сөйли белә торган крокодил китергәннәр. Андый тамаша авылда төшеңә дә кермәгәндер әле... Ә көчек мәсьәләсендә вәгъдә-иман булсын. Белсәң килсә, эт, мәче ише җан иясе кешене игътибарлы булырга өйрәтә.

Габделхәй Сабитов тәрҗемәләре.

## Михаил Юхма

# ПУДЭШ ПАТЯН МӘЗӘКЛӘРЕ

### АЕРМАСЫ КЕЧКЕНӘ

Шулай бервакыт Патян Нюргечи дигән авылга кирпеч сатып алырга киткән. Күп кенә осталарда булып, алар суккан кирпечләрне капшап караган. Ләкин берсенекен дә ошатмаган. Шунда аның янына күршедәге Янкасы авылыннан бер агай килгән дә болай ди икән:

— Бу кирпеч кирпечмени? Син менә безгә кил, чын кирпечнең нинди икәнлеген шунда күрерсең.

— Әй,— дип кулын селтәгән Патян,— беләм мин сезнең кирпечләрегезнең нинди икәнлеген. Боларныкыннан бары тик бер генә ягы белән аерыла.

— Нинди ягы белән?

— Кулыңнан ялгыш төшереп җибәрсәң, боларның кирпече урталайга, ә сезнеке өчкә ватыла.

### КАЙСЫСЫ ФАЙДАЛЫРАК!

Бераз кәефләнеп алган поп чиркәүгә килүчеләргә үзенең белдеклелеген күрсәтмәкче булган:

— Кояшка караганда Ай файдалырак. Чөнки Кояш көндез генә, ә Ай төнлә дә яктырта.

Моны ишеткән Патян:

— Алай булгач, синең борының да күзләреңә караганда файдалырак бит, — ди икән.

— Ни өчен?

— Чөнки синең күзләрең якты вакытта гына күрә, ә борының караңгыда да ис сизә.

### ЧЕГӘН ХАТЫНЫ ФАЛ АЧА

Көннәрдән бер көнне урамда Патянны чегән хатыны туктата да әйтә моңа:

— Яле, фал ачыйм үзеңә.

— Барысын да дөрескә китерерсеңме соң?

— Тамчысына кадәр! Алла исеме белән ант итә алам.

Чегән хатыны Патянга нәрсәләрдер такылдарга тотына. Сүзенең ахыры күренмәгәч, Патян аны бүлдерергә мәҗбүр була:

— Ә менә син иң кирәклесен дөрес әйтмәдең, — ди ул. — Бу минутта минем кесәмдә бер генә тиен дә акчам юк!..

## СЫРА КҮБЕГЕНЕҢ БӘЯСЕ

Патян урам чатындагы кечкенә кибет янына туктап сыра эчкән дә сатучыдан сорый икән:

— Бер кружка сыраның күбеге ни хак тора?

— Син нәрсә, акылдан яздыңмы әллә? Бер тиен дә тормый.

— Алайса, миннән... ярты кружка сыра өчен алыгыз!

## ПАТЯН ТУЙГА БАРА

Кияү йортына төшкәндә яшь кәләш, туй йоласы кушканча, юл буенча елап бара. Йортка килеп җитәрәк ул бөтенләй акырып үксп башлый. Дуслары да, туганнары да аны һичничек юата алмыйлар. Шунда кызны озата баручылар белән бергә атлаган Патян арага керә.

— Нигә сез аны кияүгә чыгарга ирексезләп мәҗбүр итәсез? Әтиәнисе йортына кире кайтарып куегыз.

— Юк, юк, мин инде еламыйм, — дип җавап кайтара шунда кыз, куркуга төшеп.

## ПАТЯН ҺӘМ ИСЕРЕК

Бер авылда бер исерек Патянның юлына аркылы төшә.

— Син дә миңа каршымы?! — дип кычкыра ул, аңа бәйләнергә теләп.

— Юк, мин түгел, сиңа әнә теге бакчадагы кеше каршы,— дип җавап кайтара Патян һәм җилдә селкенеп торган карачкыга күрсәтә.

Ярсыган исерек читән аша бакчага сикереп керә дә карачкы белән «сугыша» башлый...

## МАЙ ЗАВОДЫНДА БУЛГАН ХӘЛ

Май заводында берникадәр вакыт ниндидер бер хәйләкәр бәндә җитәкче булып эшли. Кайбер астыртын эшләре өчен аны судка бирергә тиеш булалар.

— Син ничек уйлыйсың, Патян? — дип сорый моның белән кызыксынучы берәү. — Яначакмы ул, юкмы?

Патян көлемсерәп җавап кайтара:

— Юк, хәтта аз гына да көя дә башламаячак.

— Ни өчен?

— Майны күп салган...

## ПАТЯН СУДТА

Судта аерылышу турында гариза карала. Ике якны да тыңлаганнан соң: «Гаризаны канәгатьләндерергә, балаларны һәм йорт-җирне хатында калдырырга», дигән карар чыгарыла. Ахырдан судья залдагыларга мөрәҗәгать итә:

— Гражданнар, зирәк Пудәш Патян да судта утыра. Суд карары турында аның да фикерен ишетәсе иде.

— Минем фикерем мондый,— дип, урыныннан күтәрелә Патян.— Балаларны да, йорт-җирне дә иргә бирергә кирәк. Ләкин әле болар гына аз булыр.

— Ә соң тагын нәрсә? — дип гаҗәпләнә судья.

— Ә тагын аңа менә бу акыллы һәм гүзәл ханымны — үзенең хатынын да бирергә кирәк.

Залдагылар аның бу сүзләрен кул чабып алкышлыйлар.

Моны күреп, күңелләре йомшаган ир белән хатын кабат килешәләр.

*Рәшит Гәрәй тәрҗемәләре.*

## ИҖАТ ОЕШМАЛАРЫНЫҢ БЕРЛӘШТЕРЕЛГӘН ПЛЕНУМЫ

Республикабызда балалар өчен иҗат итүче язучылар, шагыйрьләр, композиторлар, рәссамнар, сәхнә осталары яшь буынны идея-эстетик тәрбияләү өлкәсендә шактый зур эш алып баралар. Январь аенда Казанның Актерлар йортында үткәрелгән иҗат оешмаларының берләштерелгән пленумы нәкъ менә шушы эшчәнлекне — балалар әдәбияты һәм сәнгатенең бүгенге торышын тикшерүгә багышланды, бу юнәлештә үсеш перспективаларын билгеләде.

Иҗат оешмаларының берләштерелгән пленумында Татарстан Язучылар союзы идарәсе председателе Г. Ахунов, Композиторлар һәм Рәссамнар союзларының житәкчеләре Н. Җиһанов, Ә. Тумашев, Бөтенроссия театр җәмгыятенең Татарстан бүлеге председателе Р. Җиһаншиналарның докладлары тыңланды. Фикер алышуларда ВЛКСМның Татарстан өлкә комитеты секретаре Р. Баһаветдинова, ТАССР мәгариф министры урынбасары З. Михайлова, республика хор җәмгыяте председателе В. Лукьянов, М. Җәлил исемендәге татар дәүләт опера һәм балет театрының баш режиссеры Н. Даутов, әдипләрдән Ф. Хөсни, Л. Ихсанова, Ш. Рәкыйпов, Казан курчак театрының баш режиссеры Р. Батуллин h. б. иптәшләр чыгыш ясады.

Пленумның эшендә ТАССР Министрлар Советы Председателе урынбасары М. Хәсәнов, КПССның Татарстан өлкә комитетыннан бүлек мөдирләре Н. Демидов, М. Мусин, Ә. Миңдубаев иптәшләр катнашты. Тикшерелгән мәсьәлә буенча йомгаклау сүзен партиянең өлкә комитеты секретаре М. Вәлиев сөйләде.

## ЯЗУЧЫЛАРНЫҢ ПАРТИЯ ҖЫЕЛЫШЫ

Татарстан Язучылар союзы партия оешмасының ачык җыелышында И. Юзеев белән Г. Зәйнашеваның иҗат отчеты тикшерелде. Шагыйрьләрнең иҗаты турында С. Хәким һәм Н. Арсланов докладлары тыңланды. Фикер алышуларда М. Әмир, Б. Камалов, М. Мазунов, композитор С. Садыйкова h. б. катнашты.

## «ХӘЗИНӘ» РОМАНЫ — ЭКРАНДА

Февраль аенда Әлмәттә «Хәзинә» исемле киң экранлы нәфис һәм төсле фильмның премьерасы булды. Картина Г. Тукай исемендәге республика премиясе лауреаты Г. Ахуновның шул исемдәге романы буенча Свердловск киностудиясендә эшләнгән. Сценарий авторы — В. Потоцкий, фильмны куючы режиссер — О. Воронцов, композиторы — С. Гобәйдуллина. Фильмда композитор Н. Җиһанов музыкасы да киң урын алган. Җыр текстларын М. Горький исемендәге Дәүләт премиясе һәм Г. Тукай исемендәге республика премиясе лауреаты С. Хәким язган.

Нефтьчеләр башкаласында фильмны күрсәтә башлау тантанасына картинада катнашучы рус һәм татар артистлары килде. Кунаклар арасында А. Филиппенко, Р. Громацкий, М. Вертинская, А. Кочетков, Ш. Биктимеров, Г. Шамуков, В. Минкина, Д. Ильясов, Р. Шәрәфиев һәм башка артистлар бар. Алар «Хәзинә» әсәренең тормыштагы геройлары — нефтьчеләр белән очрашуларда булдылар.

«Хәзинә» фильмы республикабызның барлык кинотеатрларында рус һәм татар телләрендә күрсәтелә башлады. «Хәзинә» Казандагы документаль фильмнар студиясендә татарчалаштырылды.

## ФОЛЬКЛОР ХӘЗИНӘСЕ

СССР Фәннәр академиясе Казан филиалының Г. Ибраһимов исемендәге тел, әдәбият һәм тарих институты татар халык поэтик иҗатының иң матур үрнәкләрен туплаган 12 томлык фәнни җыелма әзерләде. Бу фольклор хәзинәсенең беренче томы «Кыска җырлар» дигән исем белән басылып та чыкты инде. Якындагы елларда «Табышмаклар», «Әкиятләр» (өч китап), «Дастаннар», «Мәзәкләр», «Йола һәм уен җырлары», «Риваятьләр һәм легендалар», «Тарихи һәм лирик җырлар», «Мәкальләр», «Бәетләр» дигән томнарны бастырып чыгару күздә тотыла.

## ТУГАНЛЫК ҖЕПЛӘРЕ

* * *

Патриот-шагыйрь Муса Җәлилнең иҗатын һәм көрәштәшләренең сугышчан юлын өйрәнүче Ташкент галиме Исхак Зәбиров, Карши шәһәрендә булып, «Муса Җәлил һәм аның үзбәкстанлы көрәштәшләре» дигән темага лекцияләр укыды. Тыңлаучыларны ул соңгы араларда табылган яңа документлар һәм фоторәсемнәр белән таныштырды. Бу материалларны аңа 1920—30 нчы елларда шагыйрь белән бергә комсомол һәм партия эшендә эшләгән Яков Пантелеевич Сивожелезов (Украина ССРның Тернополь шәһәреннән), Гайшә Хөсәеновна Байчурова (Мәскәү), Фатих Султанович Султанов (Оренбург), Рәхим С. Абдурәхимов (Әндиҗан) һәм башкалар җибәргән булган.

* * *

Татар халкының бөек шагыйре Г. Тукайның 90 еллык юбилеен күп милләтле совет әдәбияты үзенең уртак бәйрәме итеп

билгеләде. Илебез башкаласы Мәскәүдә, барлык республикаларда, шулай ук чит телләрдә чыга торган бик күп төрле журналларда һәм газеталарда Г. Тукай турында фәнни хезмәтләр, хикәяләр, шагыйрь әсәрләренең яңа тәрҗемәләре дөнья күрде. Мәсәлән, «Советская культура» газетасында КПССның Татарстан өлкә комитеты секретаре М. Вәлиев, «Литературная газета»да — М. Горький исемендәге Дәүләт һәм Г. Тукай исемендәге республика премиясе лауреаты шагыйрь С. Хәким, «Литературная Россия»да — Татарстан Язучылар союзы идарәсе председателе Г. Ахунов, әдәбият белгече Н. Юзиевның күләмле мәкаләләре басылды.

Мәскәүдә «Советская литература» журналының венгр телендәге басмасында Г. Тукай шигырьләренең яңа тәрҗемәләре, Карелия АССРда фин телендә чыга торган әдәби журналда Э. Мәхмүтов мәкаләсе урнаштырылган, «Волга» һәм «Агыйдел» журналларында — И. Нуруллин, «Огонек»та — В. Ганиев, «Литературный Азербайджан» журналында — А. Абдулла, Казагыстанның әдәби журналы «Җулдуз»да — Ә. Дербисалинның бөек шагыйрь иҗатына багышланган мәкаләләре чыкты. Шулай ук, юбилей уңае белән, үзбәк, украин, латыш, төркмән, литва, таҗик, уйгур, балкар, авар, якут, каракалпак һәм башка телләрдә Г. Тукайның 90 еллыгына, иҗатына багышланган фәнни язмалар дөнья күрде, шагыйрьнең әсәрләре тәрҗемә итеп басылды.

* * *

Украина ССРның әдәбият музеенда 300 томнан күбрәк материал тупланган. Алар арасында «Татарстан — Украина» дигән томнар, «Татарстан әдәбияты — социалистик милләтләр телендә» дигән материаллар татар һәм украин әдәбиятлары арасындагы бәйләнешләрне чагылдыралар. Музейдагы бу материаллар Татарстан һәм Украина халыкларының туганнарча хезмәттәшлеге, татар әдипләренең украин теленә тәрҗемә ителгән әсәрләре, театр, музыка, кино сәнгате өлкәсендәге элемтәләр турында сөйли. Алар — ике халык арасындагы олы дуслыкның тарихи шаһитләры.

* * *

РСФСР Язучылар союзының Пермь шәһәрендәге җирле бүлекчәсе каршында оештырылган иҗат клубында «Азат хатын» журналының 50 еллыгына багышланган зур әдәби кичә уздырылган. Тантананы Язучылар союзының Пермь бүлеге секретаре Олег Селянкин ача. «Азат хатын» журналының ярты гасырлык эшчәнлеге турында докладны журналист Җәгъфәр Камалов сөйли. Соңыннан ул, журнал редколлегиясе исеменнән, «Азат хатын» журналын халык арасында таратуда актив эшләгән Пермь язучыларына һәм журналистларга Мактау грамоталары тапшыра.

## ТЕАТР УЧИЛИЩЕСЫНА 50 ЕЛ

Ярты гасыр элек татар театр техникумы сәнгать күгенә беренче карлыгачларны очырган иде. Быел республика башкаласының киң җәмәгатьчелеге шул техникумның беренче чыгарылышына 50 ел тулуны татар театрының күркәм бәйрәме итеп билгеләп үтте. Бөтенроссия театр җәмгыятенең Татарстан бүлеге, сәхнә ветераннары советы, бу датага багышлап, Актерлар йортында «Сәнгатькә багышланган гомер» дигән кичә үткәрделәр. Анда театр училищесының ярты гасырлык юлы турында сөйләнде, ветераннар хөрмәтләнде. Тантана кичәсендә татар театр техникумын беренче тәмамлаучы артистлар һәм сәнгать эшлеклеләре белән бергә Казан театр училищесында хәзер укучы яшьләр дә катнашты. Өлкән буын сәхнә осталарының иҗат отчеты да, яшьләргә хәерле юл теләп эстафета тапшыруы да булды бу кичә. Татар театры сәхнәсендә күп еллар иҗат итеп зур хөрмәт казанган ветераннар — РСФСРның һәм ТАССРның халык артисткасы Галия Булатова, ТАССРның халык артистлары Галия Кайбицкая, Галия Нигъмәтуллина, Хәким Сәлимҗанов, ТАССРның атказанган артисты Каюм Бариев һәм башка актерлар тантана кичәсенең түрендә булдылар.

## ТӘРҖЕМӘЧЕ ИҖАТЫН ТИКШЕРҮ

Моннан ике ел элек РСФСР Язучылар союзы каршында әдәби тәрҗемә советы оештырылган иде. Аның утырышларында төрле телләрдән русчага тәрҗемә проблемалары тикшерелә. Быел январь ахырында үткәрелгән бер утырышта тәрҗемәче шагыйрь Николай Беляевның татар поэзиясен русчага тәрҗемәләре турында сүз барды. Шагыйрьнең бу өлкәдәге эшчәнлеге хакында докладны С. Липкин сөйләде.

Рус укучылары татар поэзиясенең күренекле шагыйрьләре Һ. Такташ, С. Хәким, Х. Туфан һ. б. күп кенә әсәрләре белән Н. Беляев тәрҗемәсендә таныштылар. Алар русча ничек яңгырый? Тәрҗемәче татар шигыренең үзенчәлекләрен саклыймы? Утырышта чыгыш ясаган Л. Озеров, В. Нейман, Л. Копылова, Р. Моран, Ә. Кәримуллин, В. Ганиев, Р. Бухараевлар шул хакта сүз алып бардылар. Николай Беляевның татар поэзиясен рус укучысына җиткерүдәге хезмәтләре уңай бәяләнде, бу өлкәдә тагын да уңышлырак эшләү өчен аңа киңәшләр әйтелде.

## ЛАУРЕАТЛАР АРТА

Узган елның декабрь азагында Ульяновск шәһәрендә үзешчән сәнгать коллективлары һәм аерым башкаручыларның Бөтенсоюз фестиваленең зона конкурсы үткәрелде. Октябрьның 60 еллыгына багышланган бу сәнгать ярышында Татарстан, Чувашстан, Мордва автономияле республикалары, Ульяновск һәм Пенза өлкәләреннән үзешчәннәре катнашты. Татарстанның төрле районнарыннан фестивальгә 500 дән күбрәк үзешчән артист барды. Якташларыбызның җыр-бию осталыгына югары бәя бирелде. Республикабызның үзешчән сәнгать мастерлары 4 Зур алтын медаль, 110 Кече алтын медаль яулап алды. 9 коллектив, аерым башкаручылар һәм сәнгать түгәрәкләре житәкчеләре Бөтенсоюз фести-

вале лауреаты дигән мактаулы исемгә лаек булды. Татарстанда Бөтенроссия фестивале лауреатларының саны да 34 кә артты.

* * *

Сочида совет эстрада җырларын башкаручыларның Бөтенроссия конкурсы үткәрелде. Анда Федерациянең 53 шәһәреннән йөзләгән җырчы, вокаль һәм вокаль-инструменталь ансамбль коллективлары катнашты. Конкурста татар композиторларының эстрада җырлары да яңгырады. Аларны Г. Тукай исемендәге татар дәүләт филармониясенең Вадим Усманов җитәкчелегендәге «Орфей» вокаль-инструменталь ансамбле башкарды.

Бу яшь коллективның чыгышларын тыңлаучылар бик җылы каршылый. Жюри комиссиясе председателе композитор А. Флярковский ансамбльнең осталыгын «бу — иң музыкаль һәм иң сәнгатьле башкаручы коллектив» дип бәяли.

«Орфей», сәнгать ярышында икенче урын яулап, Сочидан Бөтенроссия конкурсы лауреаты дигән мактаулы исем алып кайтты.

## БАШКОРТ ДУСЛАРЫБЫЗ КАЗАНДА

Республикабыз башкаласында башкорт җырлары еш яңгырый. Яңа елның башында Казандагы Спорт сараенда тугандаш халыкның сәнгать осталары зур концерт куйды. Агыйдел моңнарын, башкорт халкының дәртле биюләрен Казан тамашачылары яратып карады.

## ЮБИЛЕЙ КҮРГӘЗМӘСЕ

Рәссам Харис Хәйдәровка 50 яшь тулды. Шул уңай белән Казандагы рәссамнар йортында аның юбилей күргәзмәсе ачылды. Анда халкыбыз тормышының бүгенге матурлыгын, хезмәт героикасын чагылдырган әсәрләр күрсәтелә.

## КОТЛЫЙБЫЗ

Совет әдәбиятын үстерүдәге зур хезмәтләре өчен һәм 70 яшь тулу уңае белән язучы **Мирсәй Әмир** (Мирсаяф Мәсәлим улы Әмиров) СССР Верховный Советының 1977 ел, 12 январь Указы нигезендә **Ленин ордены** белән бүләкләнде.

* * *

Совет музыка сәнгате өлкәсендәге хезмәтләре өчен композитор **Фасил Әхмәтгали улы Әхмәтовка Татарстан АССРның атказанган сәнгать эшлеклесе** дигән мактаулы исем бирелде.

* * *

Совет музыка сәнгате өлкәсендәге хезмәтләре өчен Г. Тукай исемендәге татар дәүләт филармониясенең эстрада җырчысы **Таһир Абдулла улы Якуповка Татарстан АССРның атказанган артисты** дигән мактаулы исем бирелде.

* * *

Совет музыка сәнгате өлкәсендәге хезмәтләре өчен **Сара Гариф кызы Садыйковага Татарстан АССРның халык артисты** дигән мактаулы исем бирелде.

* * *

Совет музыка сәнгате өлкәсендәге хезмәтләре өчен композитор **Бату Атаулла улы Мулюковка Татарстан АССРның атказанган сәнгать эшлеклесе** дигән мактаулы исем бирелде.

* * *

Совет матбугаты өлкәсендәге хезмәтләре өчен «Правда» газетасының Татарстан АССРдагы үз корреспонденты **Рәис Мәрдән улы Сабировка Татарстан АССРның атказанган культура работнигы** дигән мактаулы исем бирелде.

* * *

Совет театр сәнгате өлкәсендәге күп еллык нәтиҗәле эшләре өчен һәм Г. Камал исемендәге Ленин орденлы татар дәүләт академия театрына 70 ел тулу уңае белән артист **Ирек Вәли улы Баһманов**, художник-яктыртучы **Тамара Михайловна Галиәкбәрова**, костюмнар тегүче **Разия Хөсәен кызы Нурмөхәммәтова**, баш режиссер, РСФСР һәм ТАССРның атказанган сәнгать эшлеклесе **Марсель Хәким улы Сәлимҗанов**, элекке баш режиссер, РСФСР һәм ТАССРның атказанган сәнгать эшлеклесе **Ширьяздан Мөхәммәтҗан улы Сарымсаков**, театрның директоры **Әзһәр Миңшәех улы Хөсәенов**, ТАССРның халык артисты **Касыйм Шамил улы Шамил** КПСС өлкә комитеты һәм Татарстан АССР Министрлар Советының **Почет грамоталары** белән бүләкләнделәр.

## ЯЗУЧЫЛАР СОЮЗЫНЫҢ ӘЛМӘТ БҮЛЕГЕНДӘ

Язучы Азат Ганиевнең «Бәхәс» һәм «Иман» исемле яңа хикәяләре тикшерелде. Фәлсәфи темаларга язылган бу әсәрләр җыелышта катнашучылар арасында кызыклы бәхәс кузгатты. Р. Төхфәтуллин, М. Хәсәнов, Г. Афзал, С. Сөләйманова, Ш. Бикчурин, Ю. Әминов, Ә. Маликов, яшь язучылар Г. Кашапов, Ә. Галиев, А. Хәсәнов, Х. Сафина хикәяләрнең уңай һәм кимчелекле якларын анализлап сөйләделәр, авторга файдалы киңәшләр әйттеләр.

* * *

Нефть якларында яшәүче авторлар Әлмәт татар дәүләт театрының баш режиссеры, Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе Гали Хөсәенов белән очраштылар. Ул сәхнә серләре турында сөйләде, үзенең иҗади тәҗрибәсе белән уртаклашты. Театр репертуарындагы әсәрләр турында фикер алышуда Ә. Маликов, Р. Төхфәтуллин, Г. Афзал, С. Сөләйманова, Ш. Бикчурин, Ю. Әминов, М. Хәсәнов катнашты.

* * *

Азнакай нефтьчеләр поселогы китапханәсендә язучы Мәхмүт Хәсәновның «Саумы, кояш» исемле романы буенча укучылар конференциясе үткәрелде. Автор үзенең яңа әсәреннән өзекләр укыды.

* * *

Әлмәт, Лениногорск, Азнакай, Баулы әдәби берләшмәләренең чираттагы утырышлары әдәби осталык турында сөйләшү һәм яшь авторларның яңа әсәрләрен тикшерүгә багышланды. Язучылардан С. Сөләйманова, Г. Афзал, Ш. Бикчурин, М. Хәсәнов үзләренең иҗат тәҗрибәләре белән уртаклаштылар.

## ЯШЬ ТӘНКЫЙТЬЧЕЛӘР КОНКУРСЫ ЙОМГАГЫ

Февраль аенда махсус жюри яшь тәнкыйтьчеләрнең әдәби әсәрләргә иң яхшы рецензияләренә үткәрелгән конкурска йомгак ясады.

Утырышта В. Рәхмәтуллинаның «Чишмә суын уртлагач» («Казан утлары», 1 сан, 1976 ел), Рафис Гыйззәтуллинның «Фронтовиклар» романында хатын-кыз образлары» (1 сан, 1976 ел) һәм «Офыклар артында ачышлар» (1 сан, 1977 ел), Фәннур Сафинның «Саумы, бәйрәм!» (1 сан, 1976 ел), Рашат Низамиевның «Хикәяләр бакчасында» (5 сан, 1976 ел), Р. Бадыйговның «Инкыйлаб байракчысы» (9 сан, 1976 ел), Равил Лотфуллинның «Алгы сызыктан репортаж» (1 сан, 1977 ел), Мансур Вәлиевнең «Җаваплылык хисе, намус эше» (1 сан, 1977 ел), Ф. Сафаның «Яшь күңелләргә шифа булсын» (5 сан, 1976 ел) исемле рецензияләре тикшерелде.

Беренче премиягә лаек рецензия булмау сәбәпле, беренче премия бирәүгә дә бирелмәде.

100 сум күләмендәге икенче премиягә «Җаваплылык хисе, намус эше» рецензиясенең авторы Мансур Вәлиев лаек булды.

50 шәр сум күләмендәге ике өченче премия «Алгы сызыктан репортаж» исемле рецензиясе өчен Равил Лотфуллинга һәм «Хикәяләр бакчасында» рецензиясе өчен Рашат Низамиевка бирелде.

Жюри Ф. Сафинның «Саумы, бәйрәм!» (1 сан, 1976 ел). Р. Гыйззәтуллинның «Фронтовиклар романында хатын-кыз образлары» (1 сан, 1976 ел), «Офыклар артында ачышлар» (1 сан, 1977 ел) исемле рецензияләрен уңай яктан билгеләп үтте.

## Киләсе санда:

Журналыбызның киләсе — 5 нче саны нефтьле якларда яшәүче әдип М. Хәсәновның «Инженерлар» дигән яңа әсәре белән ачыла. Анда замандашларыбызның героик хезмәте сурәтләнә.

Поэзия бүлеге аеруча бай. И. Юзеев һәм Ф. Яруллинның яңа шигырьләре бирелә. «Дуслар җыры» дигән баш астында тугандаш халыкларның шагыйрьләреннән В. Кочетков, О. Шестинский, В. Броневский, И. Варавваның поэтик әсәрләре урнаштырыла.

Публицистика һәм очерк бүлеге сәхифәләрендә З. Нуриның «Җиңүче солдат, сүз синең хакта», В. Катановның «Шагыйрь мактар иде аны», М. Гәрәевнең «Җиңелмәс капитан» дигән язмалары тәкъдим ителә.

Октябрьның 60 еллыгына карата ТАССР Мәгариф министры В. Ивановның «Мәгърифәтле Казан», Р. Хәйретдиновның «Көрәшкә бирелгән тормыш» дигән чыгышлары басыла.

Сәнгать бүлегендә М. Фәйзуллаева «Татар драма театры һәм опера сәнгатебез» турында фикерләрен уртаклаша. Әдәби тәнкыйтькә багышланган битләрдә Ә. Баяновның яшь шагыйрьләр иҗатын анализлаган мәкаләсе бар.

Болардан тыш, 5 нче санда әдәбият тарихына материаллар, китап күзәтү, Муса Җәлилнең әнисе Рәхимә апаның балаларына язган шигъри васыять-хаты һәм башка материаллар урын алачак.

«Безнең календарь» сәхифәләре әдәбият белгече Р. Башкуров, балалар язучысы Б. Рәхмәт, М. Юныс, К. Латыйповларның юбилей даталарына багышлана. «Нәниләр дөньясы»нда Э. Мөэминова, З. Гомәрованың шигырьләре урнаштырыла. «Елмаеп та, көлеп тә...» бүлегендә яуда дошманны җиңешкән фольклор әсәрләре, Ә. Еникинең «Чикерткә» исемле әкияте, көлкеле шигырьләр, пародияләр бирелә.

Журналга хөкүмәт бүләге — Почет билгесе ордены тапшырылу уңае белән редакциягә бик күп котлаулар алынды. Шуларның кайберләре 5 нче санда урнаштырыла.

### ПОДПИСЧИКЛАР ИГЪТИБАРЫНА!

Укучыларыбызның күп санлы үтенечләрен искә алып, «Казан утлары» журналына язылу һәркайда дәвам иттерелә. Аңа елның теләсә кайсы аеннан башлап язылырга мөмкин. Бу хакта «Союзпечать»нең республика, өлкә, район агентлыкларына хәбәр ителгән. Журналга язылырга теләүчеләр подписканы үзләре яши торган урыннарда рәсмиләштерергә тиешләр.

«Казан утлары» журналының Бөтенсоюз каталогындагы индексы — 73210.

Бәясе 50 тиен
Цена 50 коп.

# КАЗАН УТЛАРЫ (ОГНИ КАЗАНИ)

Ежемесячный литературно-художественный и общественно-политический журнал

ОРГАН СОЮЗА ПИСАТЕЛЕЙ ТАТАРИИ